ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.2010



*Универсиада—2013*

# Казандагы яңа спорт корылмалары














# Казан утлары
# Qazan utları

2010

# 7
(1053)

*ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:*

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***Редакциянең хезмәт коллективы***

*НАШИРЕ:*

***«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте***
***Казан, Академия ур.; 2***

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир,**
**Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина,**
**Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Альберт ХӘСӘНОВ. Данәгөл. *Роман.* ........ 5
СӨЛӘЙМАН. Кыйбла. *Биләр дастаны (Г. Рәхимнең кереш сүзе белән).* ........ 50
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Тау артында кояш бар. *Роман.* ........ 70
Рашат НИЗАМИ. Вакыт эргәсендә. *Шигырьләр.* ........ 117
Әнәс ХӘСӘНОВ. Әҗәт. *Хикәя.* ........ 121

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 65 ЕЛ

Бөек Ватан сугышында катнашкан татар әдипләре. ........ 46

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Рамил ХАННАНОВ. Шартлы дөньяда. ........ 132

ХӘТЕР

Халисә МӨДӘРРИСОВА. Рәхмәт сиңа, дустым! ........ 137
Равил РАХМАНИ. Борылыш чорында *(Г. Толымбайның тууына 110 ел).* ........ 141
Афзал Шамов—Гомәр Бәширов: фронт һәм тыл хатлары. ........ 148

ПУБЛИЦИСТИКА

Рөстәм ЗАРИПОВ. Кояшка каршы һөҗүм. ........ 154

ФӘН

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ........ 164
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ........ 167

ЮБИЛЕЙЛАР

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Алтыдагы алтмышта... *(Камил Кәримовка 60 яшь)* ... 170
Заһид Мәхмүдигә 50 яшь ........ 173

АК ҖИЛКӘН

Алнур КАМАЛОВА. *Шигырьләр.* ........ 175
Рафаэль СӘХӘБИЕВ. Бәләкәй Сәхәби. ........ 177

Безнең календарь. ........ 174
Укучы сүзе. ........ 183
«Казан утлары» архивыннан. ........ 130, 184
Берлекнең яңа әгъзалары. ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: романы А. ХАСАНОВА «Данагюль»; Р. ГАБДУЛХАКОВОЙ «За горою солнце»; рассказ А. ХАСАНОВА «Долг»; поэма Дж. СУЛЕЙМАНА «Кыбла» с предисловием Г. РАХИМА; стихи Р. НИЗАМИ.
«К 65-летию Великой Победы»: «Татарские писатели—участники войны».
«Литературная критика»: Р. ХАННАНОВ. «В условном мире».
«Память»: Х. МУДАРРИСОВА «Спасибо тебе, друг»; статья Р. РАХМАНИ посвящена 110-летию Г. ТУЛУМБАЯ; А. Шамов и Г. Баширов: «Письма между фронтом и тылом».
«Публицистика»: Р. ЗАРИПОВ. «Наступление на солнце».
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.)
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Белый парус»: Р. САХАБИЕВ. «Маленький Сахаби»; стихи А. КАМАЛОВОЙ.
Новые члены Союза писателей.
«Наши юбиляры».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Лето»; поэтесса ИДЕЛБИКЭ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and Poetry»: novels by A. KHASANOV «Danagyul»; R. GABDULHAKOVA «Over mountain there is sun»; story by A. KHASANOV «Duty»; poem by J. SULEYMAN with foreword by G. RAHIM, poems by R. NIZAMI.
«To 65th anniversary of Great Victory»: «Tatar writers—participants in war».
«Literary Criticism»: R. HANNANOV. «In conventional world».
«Memory»: H. MUDARRISOVA «Thank you, friend»; article by R. RAKHMANI dedicated to 110th anniversary of G. TULUNBAY, A. SHAMOV and G. BASHIROV: «Letters between front line and rear».
«Journalism»: R. ZARIPOV. «Attack on sun».
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Pages from «Tatar Encyclopedia».
«White Sail»: R. SAHABIEV. «Little Sahabi»; poems by A. KAMALOVA.
New members of Writers' Union.
«Our jubilees.»
From photo archives of magazine.
Diary of social- cultural life.
On our covers: «Summer»; poetess IDELBIKE.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 1.07.2010, график буенча 1.07.2010.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О–880. Тираж 4471.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2010 ел.



Альберт
Хәсәнов

# ДАНӘГӨЛ

РОМАН

*Кемнәр сиңа Данәгөлем дия икән?*
*Кемнәр сине өзелеп сөя икән?*
*Нигә ул бәхетле мин түгел?*
*Башларны башларга куеп,*
*Башларны башларга куеп*
*аңлашырга*
*Соң түгел бит әле, соң түгел.*
*Соң түгел бит әле, соң түгел.*

Бакчадагы чия, груша, өрек агачларын, йөзем куакларын иркәләп, шыбыр-шыбыр яңгыр сибәләгән бу тын кичтә Данәгөл Таһир янында калды. Хәерлегә генә булдымы икән инде? Әйтерсең, Хак Тәгаләнең Үз рөхсәте, хәтта өстән күрсәтүе белән, берсе икенчесе өчен дөньяга килгән, шушы сәгатьне көтеп җиһанда яшәгән гөнаһсыз ике яшь йөрәк бу төндә, хәерлегә булсын инде, башларын бер мендәргә салдылар. Иртән исә Данәгөлнең әти-әнисенә, аларның шушы сәгатьтән ир белән хатын булуларын әйттеләр, хәер-фатиха бирүләрен сорадылар. Ир белән хатын булу адәм баласы өчен ата-бабадан калган изге бер гамәл булса да, бу турыда тиктомалдан гына бәян итү ничектер уңайсызрак бит әле. Иртән уянып киткәндә кочагында Данәгөл булса да, бу турыда сөйгәненең әти-әнисенә әйтергә Таһир кыенсыныбрак калды. Бирегә нибары биш көнгә дәшелгән кунак кына бит ул. 120 сәгатькә!—дип исәпләп чыгарды ул кинәт. Нибары 120 сәгатькә! Кем уйлаган шушылай килеп чыгар дип. Бу таңда ул кияү егете. Гамәле юрган астына яшерә торганнардан түгел. Әмма яшьләрнең бик кыенсынып кына аларга җиткергән әлеге хәбәре Ногайбәк аганы да, Фәйрүзә апаны да кара кайгыга төшермәде. Киресенчә, ике яшь йөрәк авызыннан чыккан бу хәбәргә алар чиксез сөенделәр генә бугай әле. Ногайбәк ага, үзен ирләрчәрәк тотып, эчке кичерешләрен алай артык сиздермичә, башта җиңелчә тамагын кырды, әмма хуплавы иде бу аның.

Альберт ХӘСӘНОВ (1937) – *язучы; «Сөенеч», «Кемгә сөйлим серләремне», «Кан үче» һ. б. китаплар авторы. Лениногорск шәһәрендә яши.*

Фәйрүзә апа исә:

—Ихлас күңел белән җан тартып, берегез икенчегезне күкрәгенә сыендырган икән, изге сәгатьтә кылынган гамәл булсын, күгәрченкәйләрем, бездән хәер-фатиха, наныйларым, хәер-фатиха! Бер-берегезгә гомерлек яр булыгыз, балакайларым! Кил, аталары, утыр яныма. Яшьләргә бәхет теләп башта бер дога кылыйк. Бәхетле була күрегез, балакайларым! Гаиләгезне бизәп, безне сөендереп, ал тутырып балалар үстерергә язсын,—дип үз янына Ногайбәк аганы да дәште. Кыз бала үстергән ата-ана:

—Кызым-кызым кыз кеше,
Кызыма килер йөз кеше,
Шул йөз кеше арасыннан
Кызыма булыр берсесе,—

—дип, шушы сәгатьне көтеп яши. Фәйрүзә апа әлеге хәбәрдән соң, йоласына туры китереп бераз гына елап алырга уйласа да, яшь коярдай әлегә бер сәбәп тапмады. Бәйрәм табыны әзерләргә кереште. Өстәлгә сандыкның иң төбеннән алып эскәтернең монарчы дөнья йөзен күрмәгәнен, әмма иң затлысын, үзенә бер гаҗәеп хуш ислесен җәйде.

Укучы өчен бу кадәресе дә бәхәссез булыр. Әдәпле, тәртипле, иманлы мөселман гаиләсендә мондый изге гамәл, адәм баласының күбесе өчен гомердә бер генә була торган әлеге изге вакыйга, шәригатьнең нәкъ үзе кушканча законлаштырылырга да тиеш бит. Әйе, һичшиксез! Бу кадәресен Таһир соңыннан төшенде. Язмыш дигән нәрсә кайчакларны бер дә юктан гына холыксызланып куеп, гел нахакка гына каһәрләгән чакларны да, безнең мөселман баласы тирбәлгән бишеген, сөргән җирен, туган илен калдырырга мәҗбүр булса да, динен үзеннән калдырмаган. Ашыгычлык белән качып китәргә туры килгәндә дә, әле имчәктән аерылмаган нарасые яткан бишеккә, чиста тастымалга төреп, Коръән китабын салган.

Марсель каласының үзендә дә ислам динен тотучылар байтак икән. Булмыйча соң? Хәтта мәчетләр дә берничә. Ногайбәк ага кая киткәнен өйдәгеләргә әйтеп тормады. Әмма өс-башын бәйрәмчә киенде. Башында фетр эшләпә, өстендә затлы җилән: һәм төшке ашка, ияк очында гына бер чеметем ак сакалы тырпаеп торган, үзе кисәү сабы төсле корып кипкән, көчлерәк җил иссә күбәләктәй очып китәргә әзер бер карт ияртеп кайтты. Шушы тирәләрдә мулла вазифаларын башкаручы төрек карты иде ул. Күрер күзгә болай сөйкемле генә үзе. Өс-башы да алай фәкыйрьләрдән түгел. Башында чалмасы, аягында читек-кәвеш, кулында дисбесе. Үз кадерен, үз дәрәҗәсен дә белә төсле. Сүзен әйтергә авызын ачканчы, башта үзенә бер мәртәбә тамак кырып ала. Әлеге бабай, төрек карты, битен-кулын юып, тәһарәтен дә яңартып, өстәл янына утырды. Таһир белән Данәгөлне каршына, сәҗдәгә киткәндәй утыртып, үзе башын артка ташлап, аларга никах укыды. Шушы сәгатьтән, алар Хак Тәгалә алдында да, җәмгыять каршында да, законлы ир белән хатын булдылар. Әйе, ике яшь йөрәк хәерле сәгатьтә, ике якның да ирекле ихтыярлары белән өсләренә алган изге йөк гомерлек булсын!

Таһир бу көннәрдә тәмам башын җуйды. Көтмәгәндә-уйламаганда өстенә ишелгән бәхеттәнме? Аңа Данәгөл бүләк иткән саф мәхәббәттәнме? Әллә татлы кияү мунчасыннан шулай тәмам айнымаслык булып чыктымы? Ә бит ул бу йортка нибары биш кичкә җибәрелгән кунак. СССР Хәрби Диңгез көчләренең өлкән матросы. Бу ни бу, язмышның шулай усал шаяруымы, әллә мәрхәмәтле колачын җәюеме? Башынны да җуймаслык түгел бит. Кочагында башыңны җуеп сөйгән ярың, Данәгөлең булганда, ник шунда

дөньясының асты-өскә килми. Ногайбәк ага аны улы урынына күрде. Фәйрүзә апаның да күзеннән шатлык китми. Көтмәгәндә генә кияүле булып куюдан аларның да шатлыклары түбәдән ашкан. Ногайбәк ага «Киров» крейсеры командиры, беренче ранг капитаны Собольдән биш кичкә үзенә кунакка сорап алган татар егете Таһир Туктамышевның тагын ике киче, 48 сәгате калды. Вакыт җәядән аткан ук кебек оча. Очыш юлына калкан куеп туктатышлы түгел. Аннары бит карабка кайтасы бар. Корабка, рейдта торган хәрби крейсерга. Бу кадәресе тормышның кырыс чынбарлыгы. Әлегә соң ул турыда кем уйлаган? Хәер, дуамал булмаган, чыгырыннан чыгып дуламаган, шатыр-шотыр китереп авызлыгын чәйнәмәгән яшьлек—яшьлекмени ул!

Таһир Туктамышев өченче елын хезмәт иткән «Сергей Киров» крейсерын Урта диңгез ярларындагы иң зур сәүдә һәм хәрби портларның берсе булган Марсель каласы, кунакларны коеп яуган җылы яңгыр белән каршы алды. Алай да, совет морякларын каршыларга Марсельнең барча халкы төшкән диярсең. Кара, зәңгәр, алсу, хәтта зәгъфран сап-сары зонтиклар астында таптанып торган халыкны крейсер палубасыннан биноклъсез дә күреп була. Бер читтәрәк, өскорма астында тынлы оркестр барабан кага, дәртле марш уйный. Яңгыр койса да диңгез өсте тыныч, әлләни чайкалмый. Вак дулкыннар гына үзара куышлы уйныйлар.

Яңгыр озак бармады. Ишеп-ишеп коеп алды да, туктады. Күк йөзе кунаклар каршыларга җыелган французларның үз йөзләре төсле, шундук ачылып китте, балкып кояш чыкты. Җирле хуҗаларга сүз әйтешле түгел, көткәннәр. Кадерле кунакларын французларга хас кунакчыллык белән кабул итү өчен барын да эшләгәннәр сымак. Кара диңгездәге Совет Хәрби диңгез көчләренең флагманы, 1нче класслы крейсер «Сергей Киров»ка якорен ярга мөмкин кадәр якынрак салу өчен киң форватер булдырганнар. Портның бирге өлешендә тирбәлгән төрле вак-төяк судноларны, шхуналарны, балыкчыларның җилкәнле баркасларын—барсын да култыкка куганнар.

Крейсер якорьны ярдан нибары өч кабельтов[1] ераклыкта гына салды. Бу кадәресеме? Аңлаган кеше өчен бик зур әһәмияткә ия сәяси гамәл. Хуҗаларның кунакларына тирән ышаныч белдерүләрен һәм ихтирам итүләрен раслый торган бик мөһим дәлил. Франция НАТО хәрби блогына керә. Ә Варшава хәрби союзының башында—СССР. Ике хәрби блокның бер-берсенә йодрык янаудан башлары чыкмый, бер-бер артлы атом бомбалары сынаудан арына алмыйлар. Янәсе, берсен-берсе тыеп, кисәтеп тору өчен. Дипломатлар, сәясәтчеләр телендә паритет тоту дип атала бу.

Крейсер, чылбырларын шыгырдатып якорен төпкә җибәргә, ярдан шундук тиз йөрешле зур катер кузгалды. Катерның борынында зур флаг, Франция флагы җилферди. Аның палубасында Марсель каласы җитәкчеләре, хәрбиләр, Франция республикасындагы илчелекләр вәкилләре, кокардалы фуражкаларын басып кигән хәрби атташелар, муеннарына фотоаппаратлар аскан уннарча корреспондент. Чөнки Совет диңгезчеләренең Франциянең иң зур портына бу визитлары бүген дөньякүләм әһәмияткә ия. Бу визит бөтен дөнья җәмәгатьчелегенең игътибар үзәгендә. Шулай булмыйча соң! Чөнки алар, совет хәрби моряклары, икенче бөтендөнья сугышы тәмамлануга ук Көнбатыш белән көнчыгыш арасында ни арада гына калыккан, әмма елдан-ел ныгый, калыная һәм ямьсез күтәрә барган «Тимер пәрдә»не ертып керүчеләр. Күпләр әле менә хәзер дә моның мөмкин булуына ышанмыйлар. Чөнки капиталистик һәм социалистик дөнья лагеры лидерларының бер-берләренә үпкәләре, кискен таләпләре әйтеп тә, язып та бетергесез, һәр ике лагерь бер-беренә көтмәгәндә сугыш ачу белән яный башлады. Ике як та бер-берсеннән хыянәт көтеп, көтмәгәндә һөҗүмнән өркеп,

[1] Кабельтов – 185,2 метр ара.

шашынып коралланууларын гына беләләр. Жир шарының әле бер башында, әле икенче бер атавында атом-төш коралын сынау гадәти бер күренешкә әверелде. Бу яман шуклыкның бер чиге булмагае, Жир шары күчәреннән чыгып куймагае дип тә борчылмыйлар. Өрегеп торалармы соң? Франция үз бомбаларын Тын океан уртасындагы Атолл атауларында, СССР Төньяк боз океанының Яңа Жир утравында атна-ун көн саен сынап кына торалар. «Бу шуклыкның ахыры ни белән бетәр?» дип уйлап караган кеше юк. Һәр ике як, үз бомбасының әйләнә-тирәсендәге тереклекне мәңгегә юк итү көчен арттырганнан-арттыра гына баралар. Әгәр шунда берәр техник ялгышлык аркасында гына да чылбыр реакциясе башланса?... Күк җисеме, планета буларак Жир үзе юкка чыгачак бит. Жир шары тулы мәгънәсендә дары мичкәсенә әйләнде, һәр ике якның да кулында атом бомбалары. Янәсе, берсен-берсе тыеп тору, ягъни паритет булдыру өчен, аның баш санын елдан-ел арттыра гына баралар. Бер-беренне шунсыз авызлыклап булмый, янәсе. Ничек әле ут кабып куймый. Куйса, эш харап. Жир шары, орбитасыннан чыгып җәһәннәм түренә очачак бит!

Әйе, бер-беренә пычак, утлы корал белән янап торганда, дәүләтләр арасында татуланышып китү җинел хәл түгел. Әмма болай, бер-береннән өркеп, күпме яшәргә була? Бюджет акчасының ярты өлеше кораллануга тотыла. Бу акчага күпме хастаханәләр, уку йортлары, стадионнар, метролар, бер дигән яңа шәһәрләр салырга булыр иде. Хезмәт халкының көнкүреш дәрәҗәсе күтәрелер иде. Бу өлкәдә беренче акыллы адымны Совет һәм Франция житәкчеләре ясадылар. Аларны якынайту, үзара тату яшәү юнәлешендә әлегә беренче генә, әмма бик кыю адым бу. Французлар ризалык бирделәр. Совет ягы дуслык визиты белән Франциянең иң зур хәрби базасына үзенең флагман карабын җибәрде. Французлар аны иң югары дәрәҗәдә кабул итәргә йөкләмә алганнар. Бу визит ни дәрәҗәдә узар, анысын тормыш үзе күрсәтер.

Әлеге походка әзерлек «Сергей Киров»та бер дә галәмәт барды. «Покрасить до бела все, что красится», «Драить все, что драится», чтобы «Блестело все, что блестит» лозунглары соңгы өч ай эчендә берәүнең дә теленнән төшмәде.

Бөтен команда, экипаж членнары, крейсер палубасына моннан дүрт-биш айлар гына аяк баскан матрос егетләр дә, «Югары культура нигезләре» дигән өч айлык курслар тәмамлады. Офицерлар да, мичманнар да, гади матрослар да бу курсларда бик теләп укыдылар. Кемнең инде югары культуралы егет буласы килмәсен! Әйтик, аш өстәле артына утыргач, колга буе тәртәләреңне өстәлгә җәеп салу ярамый икән. Бу зур культурасызлык була икән. Мәскәүнең Югары дипломатия академиясеннән килгән, ябыштырып куйган төсле генә кечкенә ак сакаллы, пеләш башлы профессор агайлар шулай дип укыттылар. Ашаган чакта да бер ел ач торган кешедәй, күп капма. Читтән карап торучылар сиңа сокланырдай бәби-бәби генә кап. Синең тәлинкәңә салганны күршең ашамас. Авызыңдагы калҗаны лач-лоч чәйни-чәйни сөйләшмә. Мышный да күрмә. Син бит мүкләк сыер түгел. Бик ямьсез күренеш бу. Профессор карт үзе шулай кыланып күрсәтте. Ашап туймаган бурзай төсле, өстәл янында иреннәреңне ялама, авызыңны чапылдатма. Иптәшләрең алдында тешеңне казып утырма, синең кыек-мыек тешләрең берәүдә дә эстетик хисләр уятмый. Борыныңны йә колагыңны казып утырма. Болары да чеп-чи культурасызлык. Алдыңа куйган ризыкны яманлый күрмә тагын. Башкаларның аппетитын бозма. Ошамаса, ашама! Үзеннең бөтен тотышың белән өстәлне бизә.

Очрашкан, күрешкән чакта ханымнар, туташкайлар кулларын сиңа беренче булып үзләре сузмыйлар икән, син дә сузма. Кул биреп күрешергә

ашыкма. Әдәпсезлеккә керә. Әгәр инде туташкай күрешергә кулын суза икән, егетлегенне күрсәтеп, ана карата ихтирамыннның ихлас күнелдән булуын раслап, кул аркасыннан үбеп алырга да хакың бар. Менә монысы әдәплелек санала. Чын рыцарьлык, джентельменлык була.

Крейсерга хезмәткә алынган кичәге сукачы егетләр мондый тәртипләрне, профессор агай әйткәнчә «этикетны» каян белсеннәр? Кичә генә токарь, фрезер станокларыннан аерылган шәһәр егетләре дә шулай инде. Берсе дә барон яисә кенәз балалары түгел. Пражский корпуслар да тәмамламаганнар. Ә кемнең инде биш ел флотта хезмәт итеп, физик яктан ныгып, яраулап, чын егет булып туган авылына, яисә шәһәренә, хәрби дингезчеләрнең матур формасын киеп, бескозыркасының шаян тасмаларын җилфердәтеп кенә түгел, ә югары культурага ия булып кайтасы килмәс? Дәресләрдә профессор агай сөйләгәннәрне егетләр йотылып тынлыйлар, сендереп кенә баралар.

—Ишеттенме, имәндә икән бит чикләвек!—дигәндәй, егетләр бер-берсенә күз кысышып та алалар әле. Әйтик, театрда-мазармы, башка җирдәме, баскычтан төшкән чакта, егет кеше, профессор агай бу затны «кавалер» дип атый, туташны җинелчә генә култыклап, бер баскычка алданрак төшәргә тиеш. Туташы баскычтан төшкән чакта ялгыш кына абынып куеп, егылып китмәсен өчен. Нигә дип ул абынып китәргә тиеш әле? Юк. Цивилизацияле җәмгыять раслаган этикет шулай куша. Ә инде крейсер палубасыннан, зиннәтле сарайлар, театрлар баскычыннан менгәндә кавалер бер баскычка өстәрәк менәргә тиеш. Арттан менсә, туташының капрон оек баганасының бераз кыеграк торуын күреп, аны уңайсыз хәлгә куюы мөмкин. Чибәр туташың абынып-сөртенеп киткәндә дә синең киң җилкәнә ул таянырга әзер булсын.

—Бонжур, мсье! Бонжур, мадмуазель!—дип французча сөйләшергә крейсер егетләрен Мәскәүнең Патрис Лумумба исемендәге Халыклар дуслыгы университеты аспиранткалары, ике игезәк туташлар—Сюзанна белән Лузанна өйрәтте. Командование бу курсларны бик белеп оештырган. Планетабыз кешелек тарихында гаять авыр һәм катлаулы бер чор кичергәндә, иң алга киткән капиталистик илләрнең берсенә совет моряклары капка шакыйлар. Менә күрегез әле, без совет кешеләре, беркемгә дә сугыш белән янамыйбыз, сезгә дә чын дуслык визиты белән килдек дияргә, шул илнең телен белмә, шул халыкның һич югында бер матур җырын җырлап күрсәтмә,имеш. Сюзанна белән Лузанна бу юнәлештә нык тырыштылар инде.

—И-и, бу ике игезәк туташларның чибәрлекләрен күрсәгез икән. Шушы ике гүзәл уздырган дәресләрдә ярты крейсер егетләре дөрләгән утны голт та голт йоттылар. Ялкыны-ние белән дә, дөрләп янган утлы кисәү килеш тә. Бәлкем, шуңадыр, беренче ишеткәндә бик сәер һәм карышкандай кире тоелган бу кыен телне—французчаны үзләштерү дә җинел барды. Егетләр аеруча бер-берләре алдында сынатмаска тырыштылар. Әйе, командование крейсер экипажы өчен бу курсларны бик белеп оештырган. Бөтендөнья җәмәгатьчелегенең игътибар үзәгендә бул да, шундый җаваплы визит белән кил дә, французча бер авыз сүз дә белмә, имеш. Тавыклар көләр бу хәлдән. Булмаганны!

Крейсер палубасына кадерле кунакларны кабул иткәндә телсез әпә булып тора алмыйсың. Ә шәһәрне күрергә экскурсиягә чыккач? Франциянең башкаласы Париж урамында иптәшләреннән аерылып калса, ул матрос нишләр? СССР дан, бөек Совет иленнән килгән моряклар француз телен ипи-тозлык кына белергә тиешләр. Монысы бәхәссез, һәм аны бөтен экипаж хуплады. Өч айлык курслар уңышлы тәмамланды. Егетләрнең кайберләре үзләре дуслык визиты белән барасы халыкның телен ипи-тозлык

кына түгел, хәтта үзара шаярышырлык дәрәҗәдә үзләштерергә өлгерделәр. Чөнки хуҗалар ачык йөз белән сине үз илләренә кадерле кунаклар итеп кабул иткәндә, берни анламый авыз ачып тору килешми генә түгел, мәгънәсезлек ул!

Хуҗалар да озак аптырап тормаслар. Кемнәр килгән соң безгә? Бу бичаралар кирза итекләр төсле ангыралар лабаса. Кичә генә тау куышыннан чыккан кыргыйларны хәтерләтәләр бит болар, дигән бәяне бирергә дә күп сорамаслар.

Таһир французчаны аеруча тырышып өйрәнде. Холкы белән ул белемгә, яңалыкларны үзләштерергә омтылучан егет. Бу көннәрдә аның шатлыгысөенече күккә ашты. Әнисенә дә, сеңлесе Зөһрәгә дә хатларны яудырып кына торды. Сеңлесе Зөһрәгә хатларын «Мадемуазель Зөһрә!» дип башлап китә.

Крейсер палубасына аяк басканда Таһирның русчасы да чамалы иде. Җиденче классны үз авыллары «Салкын Алан»да саф татарча бетерде. Рус телен укытучы Шәмсруй апалары бу телне үзе дә шул чамалырак белгән булгандыр. «Пулемет» дип түгел, «пуләмәт» дип укытты. Таһир Чистай авыл хуҗалыгы техникумында укыган чакта да, укытучылар рус телен өйрәнүгә ул чаклы ук басым ясамадылар. Дәресләрдә дә, практик занятиеләрдә дә «матчасть», материал частьләрне ныклап өйрәнегез, дип тукыдылар. Әйе, Таһир Туктамышев «Сергей Киров» крейсеры палубасына аяк басканда русчадан нык аксаклый иде. Тырыш, тумыштан сәләтле егеткә, кайбер сүзләре телеңне сындырырлык кыен әйтелешле бу авыр телне өйрәнергә ике атна җитте. Ә хәзер менә французча да йөгертеп сукалый.

Француз теле укытучылары—әлеге ике гүзәл игезәкләр—Сюзанна белән Лузанна туташкайларның өстәлен егетләр һәр дәрестә запискалар белән күмәләр. Укытучыңа записка җибәрү ни дип гаеп саналсын? Син бәлкем үзең өчен бик әһәмиятле берәр нәрсәне белергә, ачыкларга телисеңдер. Пожалыста, рәхим ит, яз да, сора. Дәрес ахырына, дәфтәр битеннән ертып алып, бик пөхтәләп дүрткә-бишкә бөкләп җибәргән запискалар белән аспиранткаларның өстәлләре тула. Игезәк Чибәркәйләр бу запискалар арасыннан бер-икесен укып карыйлар да, бик мөлаем елмаеп, кире куялар. Туташкайлар аларның берсенә дә җавап бирмиләр. Чөнки аларның эчтәлекләре укып тормыйча да билгеле. Чөнки крейсер егетләре бу ике Чибәркәйгә нәрсә турында язсыннар инде?! Башларын җуеп гашыйк булулары, якыннан танышып, мәңгелек дуслар булырга теләүләре турында язалар. Хат язышып торырга адрес сорыйлар.

Сюзанна белән Лузанна туташлар да бик әдәплеләр шул. Берәүне дә үпкәләтмәскә тырышалар. Дәрес ахырында барлык запискаларны җыеп бер матур папкага салалар.

—Һәркайсыгызга җавапны сез әлеге визиттан әйләнеп кайткач бирербез,—дип елмаялар,—карагыз инде анда, безнең йөзгә кызыллык китерә күрмәгез. Урамдамы, метродамы, музейга баргачмы, французлар белән очрашканда югалып калмагыз. Без сезне бик теләп һәм шатланашатлана укыттык. Чөнки көндәлек материалны бик җиңел үзләштердегез. Бу җаваплы визиттан кайткач, сезнең белән тагын бер очрашу, күрешеп гәпләшү теләге белән китәбез. Арагызда тел өйрәнүгә бик сәләтле егетләрне күрдек. Хезмәт срогыгыз тулгач, Бомарше бөек Виктор Гюго телен әгәр ныклап өйрәнергә теләүчеләр булса, безнең университетка рәхим итегез. Күптәнге танышларыбыз итеп каршы алачакбыз. Анда безне табу бик җиңел. Патрис Лумумба исемендәге университет. Француз теле кафедрасы. Сезнең белән, хөрмәтле егетләр, сезгә карата күңелебездә иң җылы хисләр туплап, иң матур тәэсирләр белән саубуллашабыз. Безгә җибәргән запискаларыгызда күбегез адресларыбызны сорыйсыз. Безгә хатлар яза

аласыз. Аларны шатланып укырбыз. Әмма Мәскәүгә кайткач та эшләребез муеннан. Аспирантураны тәмамлыйсыбыз бар. Фәннәр кандидаты исеменә диссертация якларга жыенабыз. Хәтта бераз кызганыч, безнең барлык студентларыбыз да сезнең кебек сәләтлеләр дип әйтмәс идек. Араларында үтә ялкаулары да бар. Еш кына «неуд» алып куялар.

—Әгәр арагыздан кем дә кем, төбәп хат язарга тели икән, бер кырыс шарт. Көненә өч хаттан артмасын. Артыгын укырга просто вакытыбыз юк,—монысын бер кадәр шаяртып Сюзанна әйтте.

Кызларның бу сүзләреннән соң егетләр кают-компанияне дер селкетеп көлеп жибәрделәр. Шунда Лузанна Сюзаннага ымлап:

—Әгәр арагыздан берәрегезнең теләкләре бик житди икән, хатыгызны төбәп сеңлем Сюзаннага яза аласыз. Аның әлегә төпле генә йөргән егете юк,—диде.—Ни өчен сеңлем, чөнки мин аннан ике минутка алданрак туганмын.

Сюзанна да аптырап калмады:

—Хатны апама да төбәп яза аласыз. Мәскәү егете баскетболчы Игорь белән аларның дипломатик мөнәсәбәтләрен дә мин бик төпле һәм өметлеләрдән санамыйм,—диде. Лузанна исә сеңлесенең бу сүзләренә:—Нишләп инде?—дигән соравын гына куя алды.

Таһирга француз теле аеручa жинел бирелде. Дәресләрдә ул гел «бишле» генә алып барды. Аның күңелендә, флотта хезмәтне тутыргач, чынлап әгәр, шушы университетка укырга кирәргә дигән теләк тә туып куйды. Берәүгә дә сиздермәде генә. Сюзаннага ул да гашыйк булды. Чөнки Сюзанна үзе дә, һәр дәрестә исемлекне барлаганда:

—Безнең Таһир Туктамышев мондамы?—дип аерым интонация белән сорап куя. Бер араны дәрес барышында:—Таһир, сез Алтын Урда дәүләтенең атаклы Туктамыш хан токымыннан түгелме?—дип тә сорады әле.

—Тагир, чуешь, мадемуазель Сюзанна к твоей романтической личности проявляет особый интерес. Рискни, дружище! Обьяснись в любви!—дип, егетләр аны кыстап та карадылар. Йөз килограммлы штанганы баш очында уйнаткан Таһирга каян килсен андый кыюлык?! Кыюлык—дефицит товар бит ул. Кибеттә сатылса,аны кем генә капчыгы белән алмас иде. Сатылмый бит.

***

1921 елда Марсельдә, Франция коммунистлар партиясенең 1нче корылтае уза.

Әйе, Бөек Ватан сугышы чорында үзләренең исемен тутыкмас данга күмгән совет хәрби диңгезчеләренең матур традицияләренә мыскал тап төшерергә ярамый. Кара Диңгез хәрби флотының флагманы «Киров» крейсеры әлеге үтә дә жаваплы походка һәрьяклап әзерләнде. Боларын егетләргә политзанятиеләрдә замполит, 3нче ранг капитаны Виктор Васильевич Захаров сөйләде. Марсель каласы—Франция республикасының Лион култыгындагы иң зур сәүдә һәм хәрби порты. Бу кала моннан әле ике эра элек алты йөзенче еллар башында ук төзелә башлаган. Ягъни аның ике мең ярым еллык тарихы бар.

—Узган меңьеллыкның Урта гасырларында берсе артыннан берсе оештырылган тәре походлары,—дип сөйләде Замполит,—Марсельнең тагын да үсеп, ныгып, көчәеп китүенә зур этәргеч булган.

1921 елда Марсельдә Франция коммунистлар партиясенең 1нче корылтае уза. Корылтайдан соң коммунистлар илдә нык оешкан сәяси көчкә әйләнә. 1942 елның ноябрендә Марсельне фашистлар басып ала. Бөтен Францияне Гитлер солдатлары таптаганда, Марсель каласы коммунистлар партиясе

житәкчелегендә дошманга каршылык күрсәтү үзәгенә әверелә. Шәһәр патриотлары фашист килмешәкләргә Марсель каласын Франциянең басымчак бер почмагы итеп, мыскылларга ирек бирмиләр. 1944 елның 19 августында азатлык сөюче Марсель халкы кулына корал ала, барысы бердәм булып баш күтәрә. Ун көннәр чамасы барган канлы көрәш дәвамында ике яктан да югалтулар күп була. Әмма 28 августта шәһәр фашистлар коллыгыннан тулысынча азат ителә.

Бәйсезлеге өчен шундый корбаннар бирүдән дә курыкмаган Марсель халкына крейсер экипажы да мөмкин кадәр ихтирамлы вә игътибарлы булырга тырышты. Хуҗалар күңелендә үзләре турында иң җылы тәэсирләр калдыру—крейсер командасының иң зур теләге. Таһир—өлкән матрос кына түгел, карабтагы минерлар командасының комсомол оешмасы башлыгы. Экипажның бу изге һәм почетлы теләген тормышка ашыруда минерлар командасының да өлеше зур булырга тиеш. Таһир бу турыда исеннән бер минут та чыгармый.

Өлкән офицерлар матрослар белән политзанятиеләрне «Сергей Киров» крейсеры Марсель портына килеп якорь салгач та, көненә берне уздырып алалар. Аларның да хәле аңлашыла. Өсләрендә нинди зур җаваплылык тора бит. Иңнәрең генә түзсен. Экипажның һәр офицеры, мичманы, матросы үзләре кунакка килгән ил халкы белән иң эчкерсез, иң ышанычлы дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыру теләге белән яна. Социалистик илләр лагерен чорнап алган «тимер чаршау»ны ертып чыккан беренче карлыгачлар бит алар. Беренче карлыгачлар!

Илең, халкың тарафыннан бирелгән ышанычны аклау әллә бик җиңел дисезме? Бу көннәрдә карабта курчак өендәгедәй чисталык, тәртип. Совет карабын, СССР хәрби диңгез көчләренең флагманы «Сергей Киров» крейсерын үз ирләре белән күрергә килгән французларның чуты юк. Экипаж аларның барысын якты йөз белән каршы ала. Килегез, кунак булыгыз. Каюталарыбызны карагыз. Кашыгың басып торырлык хуш исле борщыбызны, эре ярма бөртекләре арасыннан симез ит калҗалары күз кыскан карабодай боткабызны татып карагыз, һушыгызны җуйсагыз, гаеп итештән түгел...

Карабның аш пешерүчесе, өлкән кок Саша Колядько бу көннәрдә сәнгатьчә осталыгын киң колач белән күрсәтте. Аның хуш исле борщын татып караган һәр француз башта озын итеп: –Ы-ым!—дип сузып тора. Аннары:

—Менә ичмасам бу борщ!—дип телен шапылдата Сашаның кулын кысып:—Әгәр калсагыз, сезне Марсельнең иң югары разрядлы рестораны баш повар итеп алачак...—ди.

Крейсер палубасына як-ягына каранып һәм беркадәр шикләнү хисе белән күтәрелүчеләр дә күп булды.

—Парижга таба төбәлгән атом бомбаларыгызны күрсәтегез әле. Зурлармы алар? Ничә данә алып килдегез? Трюмнарыгызга төшеп аларны үз күзең белән күрергә мөмкинме?—дип тә сорап куйгаладылар. Чөнки Франциянең һәм күп кенә күрше илләрнең буржуаз газеталары, үзләренең укучыларын бу визитны яктыртып язган мәкаләләре белән ничек кенә өркетмәделәр.

«Франция җитәкчеләре, аның хөкүмәте, дөнья җәмәгатьчелеге алдында акылга сыймаслык ахмаклык эшләде! Марсель портына якорь салган Совет крейсеры—Троя аты! Франция харап булачак. Совет хәрби диңгез флоты флагманы «Сергей Киров» крейсеры трюмнарында Парижга төбәлгән ун атом бомбасы бар! Әмма хәбәрчеләребезнең зур кыенлыклар белән кулга төшергән соңгы мәгълүматларына караганда, крейсер трюмындагы бомбаларның саны өч йөз данә! Коммунистик рухта башка халыкларга сыйнфый нәфрәт хисе белән тәрбияләнгән совет матросына команда гына

бир. Ни буласын уйлап та тормыйча кнопкага басачак. Париж, Франциянең башкаласы биш миллион халкы, дөньяда тиңдәше булмаган зиннәтле сарайлары, музейлары, театрлары, концерт заллары белән биш минут эчендә юкка чыгачак. Париж кара күмергә әйләнеп, икенче Нагасаки булачак! Французлар! Аңыгызга килегез! Әле соң түгел. Трюмнары атом бомбалары белән тулы атом карабының Марсель портын калдырып, бүгеннән үк нейтраль суларга китүен таләп итегез»—дип тә язып чыктылар.Түз генә!...

Трюмнардагы атом бомбаларын «үз күзләре белән күрергә теләүчеләр»не крейсерның аскы катларына Таһирга да алып төшәргә туры килгәләде. Кайчакларны ул, уставны бозып булса да, караб палубасына куркып кына аяк басучы кунакларның кайберләренә:

—Мадам, сезгә тирән ихтирам йөзеннән генә ачам бу серне. Сез сораган атом бомбалары менә алар! Барысы да Парижга таба төбәлгән,—дип төче су запаслары тутырылган зур алюминий бакларны күрсәтә.

Кеше бит дурак түгел. Дөрес, аның беренче реакциясе сәеррәк була. Ул шып туктап кала. Күзләрен орбитасыннан чыгарлык итеп ачып, әлеге бакларга төбәлә. Аннары, кунакларның хәтта ин шиклесе дә:

—О-о, мсье матрос, шаян егет икәнсез, юморыгызны килештерәм!—дип шаркылдап көлеп җибәрә.

Ә бер чибәр генә йөзле, кочагына песи баласы хәтле генә көчеген кыскан бер әбекәй, бик житди кыяфәттә:

—Улым, хәрби карабыгызны күрергә теләп, палубагызга аяк басучыларны урлап, кул-аякларын бәйләп ябып куя торган камерагыз кайда? Хәзер анда ничә тоткын бар? Мин Марсель каласының «Кеше хокукларын яклау» җәмгыяте вәкиле. Мин ул тоткыннарны азат итәргә килдем. Мине хәзер үк шул камера алдына илтегез,—дип тә таләп итте.

Шушы ике-өч көн эчендә Таһирга да мәшәкатьләр җитәрлек булды. Бигрәк тә беренче елларын гына хезмәт итүче егетләр белән. Аларның барысы да диярлек аның үзе кебек үк кичә генә колхоздан килгән егетләр. Физик яктан көчлеләр, болыннарда очлары күккә ашкан печән богыллары куеп, Сабан туйларында көрәшеп үскән егетләр. Кирәксә, даганы бөгәләр. Илгә бирелгәнлек, патриотик хисләре дә ташып тора. Хәрби карабта үзләре башкарырга тиешле вазифаларны да тиз үзләштерәләр. Әмма сәяси яктан әзерлекләре, уй-фикер сөрешләре һаман да чамалырак шул. Әйе, бу егетләрнең күбесе Владимир Маяковскийның:

> Ешь ананасы, рябчиков жуй!
> День последний приходит, буржуй!

—дигән шигыре принцибында тәрбияләнгән балалар. Капиталист икән, аны дөмбәсләргә, мангаен сугып ярырга кирәк дип карыйлар. Офицерлар аларга, без, Совет диңгезчеләре, Бөек Франция ярларына зур миссия—дуслык визиты белән килдек. Дөнья җәмәгатьчелеге, тынычлык сөюче көчләр алдында бу визитның әһәмияте чиксез, дип ике сүзнең берендә тукып торалар. Үзенең минерлар бригадасы белән мондый әңгәмәләрне Таһир да еш уздыра.

Шул рәвешчә ут-мәшәкать, дулкынлану-борчылу эчендә визитның өч көне узып та китте. Шатлыклы-сөенечле минутлар да күп булды. Аларын аның кем исәпкә алып торган инде. Беренче көнне төштән соң Марсель каласы мэриясе чакыруы буенча, крейсерның мичманнары, барча өлкән матрослары шәһәр ратушасына чәйгә бардылар. «Культуралы матрос», «бастырыктан озын тәртәләренне өстәлгә чыгарып салма», «ашаганда авызыңны чапылдатма», «синең алдыңдагы тәлинкәңне тартып алмаслар»,

«күп кабып ашама» дәресләре менә кайчан кирәк булды. Өстәлдә ризык бик мулдан булса да, хуҗалар профессиональ илчеләрне түгел, хәрби диңгезчеләрне кунакка дәштеләр бит. Алар сый-хөрмәтнең кадерен беләләр, аппетит юкка да зарланучылардан түгелләр. Әмма егетләрнең ашавы ашау булмады. Алларындагы салатнымы, тәмле балык кисәгенме, чәнечке очына гына эләктереп бәп-бәләкәй генә кисәкне кабалар да, алларындагы крахмалга катырган ап-ак тастымал кисәге белән авызларын сөртеп куялар.

Мәҗлес тагын да җанлы, истәлекле узсын диптер инде, хуҗалар бирегә кунакка Марсель хореография училищесы студенткаларын да дәшкәннәр. Чибәрләр инде, абау-у! Һәркайсын кашыкка сал да, кап та йот! Чәйдән соң танцылар булды. Хореография училищесы кызлары, укуларын тәмамлагач балет театры балериналары, булачак артисткалар, безнең егетләрнең алларына килеп, күптән белгән-күргән танышлары сыман мөлаем елмаеп, книксен ясап, биергә үзләре чакырдылар. Бик четерекле моментлар болар. Егетләр сиздермиләр генә, чынлыкта исә ут йотып утыралар. Берәр чибәркәй, күбәләктәй очып, каршыларына килеп биергә чакырганда аларның уч төпләренә кайнар тир бәреп чыга. Чыкмас, бар! Аягыңдагы кырык дүрт-кырык бишенче калыплы, дагалы ботинкаң белән, шушы очар күбәләкнең ялгыш кына аягына китереп бассаң, беттең бит инде. Егылып кит тә, тәгәрә дә җан бир. Мин бии белмим, дип биергә чыкмасаң да килешми. Диңгезче бул да бии белмә имеш. Өч ай эчендә аю булып аюны, ике багананы тоташтырып сузган аркан өстендә биергә өйрәтәләр. Биергә чыкмасаң, бу кыюсызлыгың аркасында Совет хәрби диңгез көчләре йөзенә кызыллык китерүең бар.

Дөрес, бу тантаналы залга, әлеге чакырулы чәйгә, «Сергей Киров» крейсеры егетләре дә Совет хәрби диңгезчеләренең кырт иткән матур парад формаларында килделәр. Өстенә калын җаймә каплап, авызлары белән су бөрки-бөрки үтүкләгән кара сукно чалбарларының стрелкалары биш адымнан сызгырып, һава ярып торалар. Егетләрнең һәркайсыннан күзенне алышлы түгел. Әмма парад формасы кидем дип кенә моңарчы кырык бишенче размер кигән аягыңа утыз бишенче размерлы ботинка кия алмыйсың, ләкин борчылулары юкка булган. Эстрада оркестры сыздырган Бөек композитор Йоһан Штраусның «Вена урманы әкиятләре» вальсына Совет диңгезчеләре һәркайсы фәрештәләргә тиң француз кызларын кочакларында очырып кына йөрттеләр. Таһирның үзен дә утлы күмер кебек янып торган карасу-көрән күзле, озын керфекле, балдак киертердәй нечкә билле бер кыз чакырды. Бу нечкә бил Таһир белән биегәндә, башкаен артка ташлап, уттай янган серле күзләрен аның йөзеннән алмады. Таһир да хатын-кыз дигән серле затның кочагында булуның үзе сәер, үзе татлы мизгел икәнен җаны-тәне белән сизеп, татып биеде бу фәрештә кызыкай белән. Якыннан танышып китсәң дә яраган булырые. Кызлар белән аралашырлык кына французча да белә. Сюзанна белән Лузанналның тырышлыклары бушка китмәгән. Житмәсә, кичә ахырындарак, хуҗалар арасыннан кап-кара костюмлы, ап-ак күлмәктән, озынча муенына «күбәләк» таккан чал чәчле бер агай:

—Хөрмәтле кунакларыбыз, соңыннан да бер-берегезгә хатлар язышып, аралашып тору өчен адресларыгызны да бирә аласыз,—дип белдерде. Аны биергә еш кына чакырган әлеге карасу-көрән йөзле кыз аңа бик ошаса да,Таһир адресын бирергә базмады. Ә башка егетләр бирделәр шикелле... Таһир базмады шул. Чөнки аларның үзара мөнәсәбәтләре бер-берләренә мөлаем елмаюдан артыкка китмәде. Моңа сәбәпче күбрәк Таһир үзе булгандыр. Чөнки совет хәрби морякларына булган бер җирләрендә адрес

биреп йөрү Уставта каралмаган гамәл. Димәк, хуп күрелми.

Икенче көнне экипаж Франция коммунистлар партиясе генераль секретаре, кин маңгайлы, кыюлыгы житеп кунган чебеннең аягы таеп китешле шома башлы, атлет гәүдәле агай, Морез Торез житәкчелегендәге француз коммунистлары делегациясен каршылады. Бу көн кунаклар өчен дә, хужалар өчен дә үзенә аерым зур бәйрәмгә әверелде. Крейсер бортында Кара Диңгез хәрби флоты көчләренең атаклы Жыр һәм Бию ансамбле дә бар иде. Кадерле кунакларга алар зур концерт бирделәр. Алар инде биеп тә, жырлап та күрсәттеләр! Совет жыр һәм бию сәнгатенең нинди югарылыкта булуын үз күзләре белән күреп, кунакларның исләре китте. Артистларның һәр чыгышын алкышларга күмеп озаттылар. Караб капитаны Соболь Франция Коммунистлары башлыгына кара ефәк тасмасына алтын хәрефләр белән «Кара Диңгез хәрби флоты» дип язылган бескозырка бүләк итте. Бу баш киеме Морез Торезга да бик килешеп тора. Йөзен тагын да тулыландырып, ачып жибәрде.

Аннары бер төркем егетләр, мэрия биргән автобусларга төялешеп, Марсельнең истәлекле урыннарын, фашистлар оккупациясе чорында Каршылык хәрәкәте отрядлары яшәгән тирән катакомбаларны карап кайттылар.

Крейсерда француз коммунистлары кунакта булган кичтә, Таһир бик сәер бер төш күрде. Кайчак шулай төшнең бик әйтеп кергәннәре дә була. Алда синең белән булачак, башыңнан узачак хәлләрнең барысы турында да алдан төшенә керә башласа, бик күпкә китәр. Барысы башына да сыеп бетмәс. Әмма кергәннәрен соңыннан уйлап карыйсың да, кара, әй, бу нәрсә, бу хәл минем төшемә нәкь шушылай булып кергән бит дип исләрең китә. Таһирның менә бу төше дә бик сәер иде. Аның түшенә, нинди кош икәнен тәгаен генә әйтә дә алмый, бик матур бер кошчык кунган имеш. Таһир аны учына алып иркәли-иркәли күкрәгенә кочты. Ул арада кошчык, нидәндер өркепме, очты да китте. Таһир аны тотарга ни омтылып карады, ләкин нәкь жырдагыча, «үрелеп тота, йөгереп житә» алмады. Кыска вакытлы гына йокысыннан шапырма тиргә төшеп уянды.

Таһир уянгач та озак уйланып ятты. Нинди сәер төш булды бу? Нинди кошчык кунды аның иңнәренә? Аның түшенә үзе килеп кунганнан соң, нигә читкә очты. Нигә Таһир аны тота алмады? Бу әллә шәһәр башлыклары аларны чәйгә дәшкән кичәдә Таһир бик яратып биегән, балерина булачак әлеге фәрештә кызчык идеме? Алда аларны яңа очрашу көтәме? Янә күрешсәләрме? Авызын ачып тормас Таһир. Адресын алыр. Үзенекен бирер. Истәлеккә башындагы бескозыркасын да салып бүләк итәр. Янә күрешсәләрме, анда күз күрер ие әле!..

***

Иртәгә совет диңгезчеләренә кунакка Франция Хәрби Диңгез көчләре академиясенең курсантлары киләчәк. Булачак офицерлар, контр, вице-адмираллар. Аларны шулай ук нык әзерлек белән каршы алырга кирәк. Таһирның минерлар командасына, карабта кунаклар булып киткәннән соң калган чүп-чардан арындыру һәм һәр яңа делегация алдыннан палубаны яңача бизәү бурычы куелды. Әлләни катлаулы бурыч түгел. Әмма академия курсантлары белән бүгенге очрашу алдыннан егетләрен жыеп бер сөйләшеп алырга жыенып тора иде. Таһир командасында Жәгъфәр Калканбаев дигән бер казакъ егете дә хезмәт итә. Чын рәссам инде. Кулына күмер кисәге алса, рәсемен не коя да куя. Флотта хезмәтен тутыргач, Мәскәүнең Суриков исемендәге югары художество институтына укырга керергә жыена Жәгъфәр. Нинди сурәт ясаса да, көлтә-көлтә юмор сала. Аның сурәтләре

янынннан шаркылдап куймыйча, эчен тотып көлмичә берәү дә уза алмый. Табигать талант дигән сәләтне бер дә кызганмый биргән аңа. Житмәсә, бер дигән иптәш әле үзе. Каютада асылма бишекләре рәттән, кай төннәрне алар керфек какмый сөйләшеп, серләшеп чыгалар. Таһир менә хәзер дә Жәгъфәрне күреп, палубаны ничегрәк бизәү турында киңәшергә уйлап тора иде. Шулчак радиотрубкадан:

—Матроса 1-ой статьи Туктамышева к капитану 1-го ранга свистать на верх!—дигән команда яңгырады. Әйе, бүген крейсерда аеруча тантаналы көн. Коллегалары, Франциянең булачак диңгез офицерлары кунакка киләчәк бит. Тәгаен шул уңай белән чакырта булыр иптәш капитан, дип уйлап алды Таһир.

Таһир икенче елын инде типсә тимер өзәрдәй дүрт йөзләп егет хезмәт иткән крейсерның берләштерелгән комсомол оешмасы секретаре да. 1нче ранг капитаны Соболь каютасында еш булгалый. Чөнки комсомол комитеты утырышлары еш кына аның каютасында уза. Әмма бу юлы Таһир нигәдер каушап калды әле. Капитан аны бер дә юктан гына дәшмәс. Бигрәк тә бүгенгедәй җаваплы көндә. Башта көзге алдына басып бескозыркасын төзәтте. Ничек килешеп тора ана моряклар киеме! Аны сизү үзе бер сөенеч! Уч төбенә тамагын кырып алды, бил каешын төзәтте, капитан каютасына ашыкты.

Әйе, карабның комсомол оешмасы эшләре белән капитан каютасында Таһирның моңарчы да булганы бар. Әмма аның төссез лак белән буялган сары төстәге имән ишеген ул һәрчак нык дулкынланып ача, бусагасыннан да әсәрләнү хисләре кичереп атлый. Флотка ул Чистай авыл хуҗалыгы техникумын «бишлегә» тәмамлаганнан соң алынса да, диңгездә инде өченче елын хезмәт итсә дә, биредә атлаган һәр адымы аңа яна дөнья ача төсле. Белеме белән механик булганлыктан, крейсерның материаль частьләрен, ул белергә тиеш техниканы да тиз үзләштерде. Ике потлы гер күтәрү буенча караб чемпионы булса да, бик нечкә күңелле ул. Ә капитан, крейсер командиры каютасы бусагасыннан атлап кергәндә ничек инде дулкынланмыйсың ди?! О-о! Капитан Собольмы?! Роман Сергеевичмы? Мәһабәт кеше ул! Советлар Союзы Герое! Аның турында бөтен флотта легендалар йөри.

—Ленинградтагы Хәрби диңгез училищесын тәмамлаган лейтенант Соболь хезмәт юлын Балтыйк диңгезеннән башлаган. Чик сакчысы катерлары командиры булган. Аннары аны Төньякка, Яңа Жир утравына күчергәннәр. Анда ул эскадра миноносецы командиры булып хезмәт иткән, дан-шөһрәтне анда алган. Американың су асты көймәсен бер бухтага куып кертеп япкан. Бер ай чыгармаган. Суларга һавалары, эчәргә сулары беткәч, нишләсеннәр, кая барсыннар? Өскә калкырга, бирелергә мәҗбүр булганнар. Бу тәвәккәл, кыю командирга Советлар Союзы Герое дигән исемне дә менә шул батырлыгы өчен биргәннәр.

1нче ранг капитаны Собольгә әле утыз җиде генә яшь. Әмма шушы сүзгә бөтен ихтирамнарын, ирләрчә кырыслык белән ягратуларын салып, аны крейсерда барысы да «Дед» дип йөртәләр. Әйе, «бабай»га нибары утыз җиде. Ә ул инде 1нче ранг капитаны. Вице-адмирал булырга да бер адым гына калып бара. Менә бу визитны уңышлы башкарып чыксалар, адмирал дәрәҗәсенә үк күтәреп куярлар. Өстәге командованиеда дә аны нык ихтирам итә булырлар. Югыйсә шушындый җаваплы визит белән Франция ярларына җибәрмәсләрие. СССР Хәрби диңгез көчләре исеменнән бит! Мәсьәләнең бу ягын «Сергей Киров»та хезмәт иткән һәр матрос аңлый. Аларның һәркайсы шушы күрер күзгә дә бик күркәм офицер, чын флотоводец кул астында хезмәт итүе белән чиксез горурлана да әле.

Командир чакырганда, шахмат тактасы артында утырган гроссмейстерлар төсле сәгатьләр буе уйланып тора алмыйсың. Бер аягың монда булса, икенчесе анын ишеге төбендә. Шалт, Мөхәммәтжан! Әмма караб капитаны ишеген шакыганчы Таһир алай да көзгегә янә күз сирпеп алды. Ай-яй, дингезче формасын әйт әле. Чын егет кешегә бигрәк килешеп тора бит. Шушы килеш очып кына авылга кайтып киләсе, әнигә күренәсе иде. Көзгегә карап дөрес эшләде. Бескозырканы чак кына кыңгыр салырга кирәк икән бит. Кыюлык өчен учына төкереп алды, тамагын кырып куйды. Әйе, мондый кып-кырыс, берсеннән-берсе җаваплы эшләр муеннан көнне командир сине бер дә юктан гына чакырмас. Ул хәлгә дә алдан ук әзер булырга кирәк.

Әледән-әле сул күзен кыскалап көзгедән үзенә карап торган чибәр егеттән Таһир канәгать калды. Ул бит конторда гына «хезмәт итәләр». Флотта «хезмәт итмиләр», аны сөяләр. Дингездә дә шулай. Дингездә «хезмәт итмиләр», дингезне сөяләр. Шуннан чыгып, музыкасы да, оркестры да башка. Флотны сөйгәндә, дингезне сөйгәндә хезмәт итү дә газап түгел, чыныгу гына. Һәр хезмәт иткән көнең тормышның ямен, тәмен татуда бер баскычка өскәрәк атлауга әйләнә. Көзгедән сул күзен кыскалап елмайган егет Таһирга нәкъ менә шул сүзләрне әйтә төсле.

Капитан каютасы карабның борын өлешендә. Шунда кылт итеп былтыргы матур хатирә исенә төште Таһирның. Узган елны крейсерның иң алдынгы матрослары белән бергә аны да Севастополь хәрби порты комсомол оешмасы конференциясенә делегат итеп сайлаганнар. Конференция делегатларын башта капитан Соболь үзендә кабул итте, егетләрне әфлисун, банан, ананаслар, тәмле чәй-конфетлар белән сыйлады. Ул чакта да, субординация дигән нәрсәне бер читкәрәк куеп, нәкъ гражданкадагыча иркенләп, бүгенге тормыш, хезмәт срогын тутырып килгән егетләрнең киләчәге турында иркенләп сөйләшеп утырганнар иде.

Капитан каютасы төбендә кизү торган матрос аны честь биреп каршы алды. «Сине көтәләр», дигән мәгънәдә ишеккә ымлады. Бераз каушау һәм чамасыз дулкынлану белән эчкә атлады ул.

Таһир, ишектән керү белән:

—Иптәш 1нче ранг капитаны, сезнең чакыру буенча 1нче статьялы матрос, минерлар командасы командиры Туктамышев!—диде. Бер тын белән әйтеп салды. Рапорты чиста, янгыравык чыкты. Флотта хезмәт итсән, авыз эчендә ботка болгатуны ташла. «Нәрсә? Ни?» дип кайтарып сорарлык булмасын.

Капитан ап-ак кительдән, эш өстәле артында. Йөзе ачык. Кәефе яхшы булырга тиеш. Өстәл өстендә бәллүр вазалар, фужерлар. Вазаларда алмалар, әфлисуннар. Капитан кунаклар кабул итәргә торамы, дип уйлап алды Таһир.

—Кер, Таһир, кер. Түрдән уз. Утыр!—диде капитан нәкъ гражданкадагы төсле итеп дусларча мөгамәләдә. Крейсер командиры кирәк чакта кырыс та була белә. Чөнки дингез—үзе гаять кырыс стихия. Сине сынарга гына тора. Ә гомумән алганда 1нче ранг капитаны Роман Соболь холкы белән бик әдәпле, ипле офицер. Карабында хезмәт иткән бар матросның исем-фамилиясен белә. Кул биреп исәнләшә. Өй хәлләрен сораштыра.

—Хатлар килеп торамы? Ярда калган чибәркәйләр онытып бетермиләрме?—дип шаяртып та ала әле.

Капитан түрдән узарга чакыра дип өстәл артына ук атларга ашыкмады ул. Җәягә тарттырган кыл булып ишек катында тора бирде. Каюта буйлап күзен генә йөртте. Уртада шомартылган затлы имән өстәл, йомшак күнле көрсиләр. Утырыйм дисән, алар эченә чумып китәсең. Әнә, ун почмакта

бер метрга бер метр пыяла аквариум. Анда аллы-гөлле балыклар жим чүпли. Аларны карап, вакытында суын алыштырып торучы матрос булса да, үзенә аерым бер тәм табып, борын эченнән бер көй көйли-көйли, балыкларны капитан үзе ашата. Бу минутлар капитан Собольнен ял сәгатьләренә керә булса кирәк. Берәр айга рейдка чыгып киткән карабның капитаны тәүлекнең, атнаның, декаданың кайсы өлешендә генә ял итсен соң? Рәхәтләнеп, онытылып дигәндәй.

Таһирның күзе икенче почмакта, фарфор чүлмәктә торган мунча себеркесенә төште. Авыз чите белән генә елмаеп куйды. Бу себеркеләрнең үзенә бер тарихы бар. Анага бала һәрчак кадерле. Авылларында әлләни бай тормыш белән тормасалар да, әнисе Таһирны онытмый. Ап-ак киндер капчыкка төреп бавырсаклар сала. Урман чикләвеге кадәр генә үзләре. Авызыңа кабу белән май булып эреп китәләр. Авылга язган бер хатында Таһир, карабта мунчабыз бик әйбәт, рәхәтләнеп мунча керәбез, дип язганые. Әнисе аңа мунча себеркеләре дә җибәрә башлады. Ун пар себеркене кысып бәйли дә, кәгазь капчыкка сала да җибәрә. Беренче тапкырында, егетләр миннән эчләрен тотып көләрләр инде дип, аларны карабка алып кайтмаска да уйлаган иде Таһир. Әнине әйтәм, тапкан инде посылка белән салыр нәрсә, дип сукранып та алганые әле. Әмма өйдән килгән мунчала бичәүкә дә кадерле. Хәтта аны да чүплеккә ташлыйсы килми. Берәр нәрсәгә кирәге чыгып куяр әле дип капчыгыңа саласың. Өеннең, үз куышыңның кадерен, изге икәнен читкә чыккач таныйсың. Ир башына акыл читтә йөргәндә керә.

Ул чакны себеркеләрне крейсерга яшереп кенә алып керде Таһир. Каютага кергәч, чишеп җибәрсәме? Биләүдән котылган нарасый төсле, кыштыр-кыштыр килеп киерелешеп, сузылып киттеләр. Һәрберсе тере җанлы диярсең. Ә каютаны Таһир печән чапкан, богыллар куйган Ашыт елгасы болыннары исе басты. Әнисе себеркеләргә йөрәк җылысын салып кына түгел, әрем, мәтрүшкә, кара карлыган, чия ботаклары кушып бәйләгән. Аларның хуш исен иснәп туешлы түгел. Карабта, тоташ металл арасында... Себеркеләрнең һәр яфрагы хуш ис тарата. Туган ягың, авылың исен!

Крейсерның мунчасы галәмәт тә шәп. Дингездән, учениеләрдән кайткач, егетләр рәхәтләнәләр бер. Шунда ләүкәсендә себеркесе дә булса, җәннәтнең үзенә эләккәндәй буласың инде. Таһирның әнисе посылкалап салып торган себеркеләргә экипаж егетләре кинәнделәр тәмам. Егетләрнең мунчаны хуш исле каен себеркеләре белән чабынып керүе турында замполит, 3нче ранг капитаны Захаров та ишеткән. Ике пар себеркене ул да сорап алганые.

—Таһир, ул себеркеләрең кулга алу белән балачакны, туган якларны искә төшерә. Мин үзем дә Волга буеннан. Муром каласыннан. Малай чакларда аларны үзем дә күп бәйләдем. Ә синекеләр аеруча хуш исле. Бер парын үзебезнең «Дед»ка бүләк иттем. Бик теләп алды,—дигәние. Ә капитаннары ерак Татарстан яклары хуш исләрен алып килгән каен себеркеләрен чәп-чәп керү өчен түгел, каютасын бизәү өчен тота ахры. Ул да туган-үскән ягын, аның урман-кырларын, хуш исле чәчкә тулы басуларын сагына булыр. Гомерен дингезгә багышласа да, авылда үскән егет. Украинаның Харьков өлкәсендә туган.

***

Таһир кереп басты, бескозыркасы сул кулында. Чак кына безелдәп кондиционер эшләгәне ишетелә. Капитанның, гадәттә карабның маршрутларын күрсәткән зур карталарын җәеп сала торган түгәрәк өстәлнең аргы очында кояш күзе чагылырдай пеләш башлы, киң җилкәле һәм дә бик затлыдан киенгән бер агай утыра. Кем икән бу? Гражданскилардан булса

кирәк. Кыяфәте шундыйрак. Өстәлдә сый-ризык, алма, төрле җимешләр. Кизү матрос әле хәзер дә керәле-чыгалы йөреп, өстәлгә ниләрдер ташып тора. Бу агай капитан Собольнең зур кунагы булырга тиеш. Таһир моны бер күз салу белән төшенде. Ләкин кем ул? Капитанның туганы-мазар булмас, берәр француз эшлеклесе йә эшмәкәр-мазар булса инде. Таһирга бигрәк тә шунсы сәер тоелды, аның ишек катына кереп басуына әлеге агай аны башыннан алып аягына тикле сөзеп карап чыкты. Дөньяны күп күргән кешенең карашы бу. Әйтерсең, коллар базарында үзенә кол сайлый. Егеткә хәтта бераз унайсыз да булып китте. Юк, шикләнү хисе артыграк бугай үзендә. Теләктәшлек, кулын сузарга, аңа таныш булмаган әлеге егетне үз кочагына алырга әзерлеген сиздергән караш иде аның йөзендә. Андый җылы карашны урамда йөргән ят песи баласы да сизә. Таһир җиде юл чатына чыгарып адаштырган песи баласы түгел түгелен дә, алай да... Шулчакны капитан Собольнең:

—Матрос Туктамышев, вольно! Килегез, Таһир, безнең янга утырыгыз,— дигән бик җылы сүзләре ишетелде.

—Рәхмәт, иптәш 1нче ранг капитаны!—диде Таһир. Шунысы да бар. Хезмәт иткәннәр белә, приказны кат-кат әйтмиләр, тикшереп тә тормыйлар. Приказ бирсүзсез үтәү өчен әйтелә. Капитан Соболь матрос Туктамышевны өстәл янына узарга приказ биреп дәшмәде дәшүен. Әмма шулай да... Таһир бескозыркасын сул кулына тоткан хәлдә өстәл янына килеп утырды.

—Таһир, бүген сез миндә кунакта. Мин сезне кунак итеп, хәзинәдә булган сый-нигъмәт белән сыйламак булам, ә сездән тартынып утырмау сорала,—диде капитан, өстәлгә ымлап. —Таһир, сез безнең кайсы яклардан әле? Әниегез бу хуш исле себеркеләрне кайсы як урманнарыннан җыеп, хасиятләп бәйләп җибәрә? Татарстаннан түгелме сез?

—Так точно, иптәш 1нче ранг капитаны. Казанга ук терәлеп торган Биектау районыннан, Салкын Аланнан. Авылыбызны иңләп аккан Ашыт елгасы буендагы болыннарның матурлыгын, иптәш капитан, мин сезне үзебезгә алып кайтып күрсәтер идем.

«Начар булмас иде ул, мин бик теләп кайтыр идем сезнең якларга кунакка» дигән төсле, капитан авыз чите белән генә елмаеп куйды. Шулчак һич көтелмәгән хәл булды. Монарчы сүзгә-нигә катышмый тын гына утырган бик горур кыяфәтле әлеге агай, кинәттән генә урыныннан торып, каршына килеп Таһирны кочып алды һәм елап җибәрде. Ике тезенә чүкте. Таһир аптырашта калды. Аңа нинди позиция сайларга? Бу елак агайны куаргамы, әллә әлегә елый бирсенме? Бәлкем, бирердә нинди дер ялгышлык килеп чыккандыр? Бу агай аны берәрсе белән бутый торгандыр. Ситуациягә ачыклык кертүне Таһир командиры авызыннан көтә. Агай исә шулчак саф татар телендә:

—Улым, Таһир, мине зинһар гафу ит! Мин дә Казаннан бит. Әти-бабаларым чыгышлары белән Әтнәдән үк!—дип куймасынмы! Әмма Таһир бераз чытаеп куйды әле: «Ак гвардияче-мазар булмасын тагын бу карт! Провокатор-мазар түгелме?» Чөнки ул үз чоры баласы, күп нәрсәгә шикләнеп карау хас аңа. Әлеге агайның капитанның күз алдында аның муенына асылынуы бик кирәгие Таһирга. Әйе, һәр мизгеле сыйнфый көрәш белән тулы чорның баласы бит ул. Тормышта һәрчак сизгер булырга кирәк дип тәрбияләделәр бит аны. Сизгер булмасаң, сыйнфый дошманнар сине хәзер юлдан яздырачаклар. Ә бу очрак шуның конкрет мисалы булып куйса? Политик сизгерлегеңне җуя күрмә, Таһир! «Сергей Киров» крейсеры палубасына басар алдыннан бер, бу походка чыгар алдыннан тагын, алар белән бик җентекләп әңгәмә уздырдылар. «Чит илләргә революциядән качып китүчеләр арасында да, Бөек Ватан сугышында әсирлеккә төшеп

кайтмый калучылар арасында да беркемем дә юк» дигән анкеталарга икеөч тапкыр кулын куйды Таһир, һәм дөресе дә шулай. Ә үз әтисе, корычтай нык Тимерҗан, егерме биш яше дә тулмаган хатыны Зифасын һәм ахактай улы Таһир белән кызы Зөһрәне ятим калдырып, Курск дугасында һәлак була. Ә бу шикле кешене ул белми дә, белергә дә теләми.

—И туган ил, туган ил! Үзеңнән читтәге улларына нигә син шулай кадерле, шулай татлы икән?—дип, әлеге агай сулкылдавын белә. Улым, туган якларыбыздан киеп килгән ботинкаң очында, олтанында бер чеметем генә балчык, туфрак кисәге юкмы сон? Мин аннан бөти тегеп күкрәк авызыма тагар идем. Сагынуга дәва юк.—Әлеге агай тезләнгән җиреннән аягына торып басты.

—О-о, капитан әфәнде, кызым Данәгөл, сез мине аңлый күрегез, берүк кичерә күрегез.

—Аңлыйм, әтием, аңлыйм,—дигән аваз килде каюта түреннән. Анда, тирән эчле йомшак креслода, йә Ходай, сабырлыгыңны бир, бер күрүдә хушыңны җуярдай чибәр бер туташ утыра икән. Таһир аны менә хәзер генә күреп алды.

—Безнең бик кадерле тагын бер кунагыбыз бар бит әле, Таһир. Ул кунагыбыз—мадемуазель Данагюль,—диде капитан.—Мадемуазель Данагюль, реверанс төшәргә каютам тар...

Йомшак кресло эченә чумып, үзенең барлыгын сиздерми генә утырган бу чибәр туташ рәссам, ахры. Утырган җиреннән торып, барысына да ватман битен күрсәтте. Анда капитан Собольнең фотога төшергәндәй коеп куйган, әмма күмер белән ясалган сурәте. Башта аны крейсер командиры өстәленә китереп салды, аннары Таһир каршына килде.

—Әйе, әтиемнең бердәнбер, ләкин бик иркә, бик тә капризлы кызы Данәгөл туташ булам,—диде дә, башта книксен чүкте, аннары кулын сузды ул.—Таныш булыйк. Мин бик шатмын, Таһир.

Бу туташны күрү белән Таһирның зиһене таралды. Әлеге походка чыгар алдыннан ни өйрәттеләр бит, имтиханнар алдылар. Югары культура этикеты буенча, кулын сузган туташның кул аркасын үбеп алырга тиеш иде Таһир. Кая ул?! Кул үбү кайгысымы соң монда? Данәгөлне күреп алу белән аның башыннан бу туташ—синең ачы язмышың»,—дигән уй жу-у итеп узды. Кайчак шулай һәркем уздыра бит үз башыннан, сөйләсәң, кеше ышанмаслык шундый сәер хәлләрне. «Каян килеп?—дип сорады Таһир үз-үзеннән. Мондый фәрештәне кочагыңда бер кочсаң, ачы язмышларына гына түзәр идең әле.»

Таһир, сикереп торып:

—Таһир Туктамышев!—диде.

Аның күзе командирында. Аларның командирлары төсле по всем статьям, по всем параметрам чын егет дөньяда тагын бармы икән? Крейсерның бөтен командасы аңа ирләрчә мөкиббән. Башкасын әйткән юк. Экипаж егетләре хәтта аяк атлауларын да аңа ошатып атлыйлар. О-о! Хәтта гәүдәләрен дә аңа ошатып җиңел, иркен һәм горур кыяфәттә тотарга тырышалар.

Диңгезчеләр арасында тагын бер хикмәт бар әле. Диңгез офицеры фуражкасын кия белү флотта шулай ук үзенә бер серле ритуал. Аны артык маңгайга төшерергә дә ярамый. Син урман каравылчысы түгел. Арткарак ташласаң, участок инспекторына әйләнәсең, чын Анискин буласың. Кыяфәтеңне бөтенләй бозасың. Бөтен хикмәт тә шунда, алтын кокардалы фуражкаң синең башыңда нәкъ үз урынында утырырга тиеш. Киң җилкәңне, корычтай нык мускулларыңны, күкрәгеңдә типкән ярсу йөрәгеңне канатландыру гына түгел, башыңда утырган фуражкаң бөтен Хәрби Диңгез флотына дан җырларга тиеш. Мондый фуражканы киярга

хакы булган барлык дингезче офицерлар исеменнән, Капитан Соболь фуражкасын нәкъ менә тиешле ноктасына туры китереп кия.

Бүген ул ялт иткән парад формасында, ап-ак ефәк кительдән. Әлеге тантана унае беләндер, биленә көмеш саплы кортигын да таккан. Карап туймаслык чибәр егет аларның капитаннары! Үз командирына гашыйк булмасаң, аның кул астында хезмәт итүнең дә рәте-чираты булмый торгандыр ул. Андый хезмәт бетмәс-басылмас теш сызлауга гына әйләнә булыр.

Капитан Соболь көзге алдына басып, сакалын төзәткәндәй итте. Ияк очларына гына әз-мәз чал куна башлаган сакал да ана бик килешә. Ин якын кешесенә мөрәҗәгать иткәндәй, капитан Соболь уң кулын Таһир иңбашына салды. Менә шуның өчен генә дә ярты гомереңне бирерсең. Крейсер командиры үзе салды бит кулын синең иңбашына.

—Таһир, сине ни өчен чакыртканымны?—диде ул.—Хөрмәтле Нугайбәк ага бик үтенеп сине бер кечкә генә булса да үзенә кунакка җибәрүне сорый. Үзең дә күреп торасың, ул бик әдәпле кеше. Префектурадан тиешле кәгазьләрен дә алып килгән. Марсельнең үзеннән ерак та түгел бистәдә үз өе белән яши икән. Үзең ничек уйлыйсың? Без бит бу илгә изге миссия—дуслык визиты белән, дусларыбызның булганын барларга, яңаларын табарга килдек. Син үзең дә минем бу тәгъдимемне кире какмассың. Сине зурлап кунак итәргә теләгән хуҗаларга рәхмәтле булып, барып кунак булып кайт.

Бу минутларда командиры авызыннан Таһир теләсә нинди приказ ишетергә әзер иде. Тик бу тәгъдимне генә түгел.

—Иптәш 1нче ранг капитаны...,—диде дә, Таһир тотлыгып калды.—Мондый ышаныч белдерүегез өчен рәхмәт... Ләкин... мин бара... крейсердан китә алмыйм. Минерлар отделениесе командиры буларак та, корабның комсомол оешмасы секретаре буларак та. Бу көннәрдә эшләр муеннан бит. Егетләр, экипаж... Кунаклар, делегацияләр...

—Килешәм, килешәм,—дип елмайды караб командиры.

—Крейсердан китә алмыйм,—дип Таһир үз сүзен кабатлады.—Минем турында егетләр ни уйламаслар.

—Беләм, беләм,—дип туры текәлеп елмайды командиры. Франциянең иң көчле хәрби дингез базасына дуслык визиты белән килгән СССР Кара Дингез хәрби көчләренең флагманы «Сергей Киров» исемендәге беренче класслы крейсер командиры өстенә нинди сынау алуын үзе генә белгәндер.

—Җавабыңның шундый буласын көттем. Хәзер тыңла: беренчедән, мин сине барлык вазифаларыңнан азат итәм, сиңа кыска сроклы ял бирәм. Икенчедән, һәм монысы иң төпле сәбәп, мондый гүзәл мадемуазельнең ихлас күңел белән чакыруын кабул итмәү безнең хәрби флотны бизәми генә түгел, аның өстенә тап төшерүе дә бар. Шулай бит, мадемуазель Данагюль?.

Әлеге чибәр мадемуазель, Таһир каршына килеп тагын книксен ясады, ихлас күңелдән чакыруын әйтте.

—Капитан Соболь әфәнде нинди киң күңелле кеше икән. Барыбер җибәрмәс дип, икеләнебрәк кенә үтенгәниек. Ә ул берсүзсез риза булды. Хәзер менә сезнең ризалык бирүегездән генә тора,—диде ул, матур, тамак төбеннән чыккан яңгыравык тавыш белән. Сөйләме дә нәкъ Салкын Алан кызларыныкы төсле. Мадемуазель Данәгөлнең кул аркасын үбү Таһирның башына да килмәде. Ә менә баягы «Бу туташ синең ачы язмышың!» дигән кисәтү күңел түреннән китмәде. Чын-чын итеп үзен сиздереп торды. Бу сорау аның миендә, бер кабынган, бер сүнгән электр лампочкасы төсле, бер кабынды, бер сүнде. Монарчы татымаган сәер бер халәт биләде аны.

—Соңгы вакытта кадерле әтиебезгә ниндидер сәер чир ияләште. Бер тора торгач, һичбертөрле сәбәпсез-нисез истерикага бирелә, өстәлгә башын сала да, елый башлый. Ничек кенә дәвалап карасак та, файдасы юк. Озын төннәрне күз йоммый уздыруының сәбәбен табиблар әтиемнең туган илен, үскән җирләрен сагынудан, ягъни ностальгия дигән чирдән күрәләр. Депрессиянең тагын да тирәнәюе мөмкин дип кисәттеләр дә әле,—дип дәвам итте Данәгөл туташ.—Мин сездән, Таһир, бик үтенеп сорыйм. Зинһар, карышмагыз инде. Курыкмагыз, тотып ашамабыз. Күршебездә генә Урта Диңгез сулары төсле күгелҗем-зәңгәр күзле, дулкын-дулкын сары чәчләре иңбашына төшеп торган бик матур француз кызы Жанна бар. Шунын белән таныштырсам гына инде. Чын диңгез бүреләренең сөяркәләре, сөйгән кызлары һәр портта булырга тиеш түгелме соң? Минем шулай дип укыганым бар,—дип елмайды Данәгөл туташ.—Совет хәрби карабының дуслык визиты белән киләсен минем әтиемнән дә күбрәк теләгән, хуплаган, аңа сөенгән, аны зарыгып көткән тагын берәр зат булдымы икән бу дөньяда. Телевидение тапшыруларының кичке чыгарылышын тыңлаган саен—караб хәтле карабта, атаклы крейсерда үзебезнең татар егетләре булмый калмас! Совет карабы Марсель портына кереп якорь салу белән барам капитаннары каршына. Ул татар егетен безгә кунакка җибәрүен капитанның аягына егылып сорармын,—дип куя торган иде. Сезнең киләсен бик ышанып, өметләнеп көтте ул.

—Таһир, мадемуазель Данагюльнең үтенечен үтәми калу мөмкин түгел. Безнең крейсер бу зур дәүләтнең дәшкән кунагы икән, ни өчен әле минем матросларым бу кунакчыл илнең аерым гражданнарының хөрмәтле кунагы булмаска тиеш?—дигән сорау куйды капитан Соболь.

—Сез, Нугайбәк әфәнде, төпле логикага таянып фикер йөрткәнсез. Алыгыз матросым Таһир Туктамышевны үзегез белән. Бүген безнең сишәмбе бит әле?—капитан Соболь өстәлендәге календарьның берничә битен ачып япты.

—Шимбәләргә, Таһир, крейсерда булыгыз.

Капитан дүрт кичкә үк җибәрә түгелме соң? Нугайбәк ага Таһирны бер кичкә сораганые. Таһир үзе ышанмыйрак торды. Ә Нугайбәк ага мең-мең рәхмәтләрен тезде.

***

Капитан Соболь фуражкасын киде, кителен төзәтте. Бу инде сүзнең шушының белән бетүе иде.

Таһир тартынып кына:—Үзем белән нәрсәләр алыйм соң? Сөт, тушонка, коры паек яздырыйммы?—диде.—Бездә кунакка буш кул белән йөрмиләр. Пешекчебез Колядько арыш ипиен бик тәмле пешерә, ашап туймыйбыз. Берәр бөтен арыш ипие алсам гына инде?...

—Нинди сүз ул, улым Таһир,—дип кулын гына селекте Нугайбәк ага.—Үзең барсаң, без бик шат. Түр кунагыбыз булып, түрдән узып, безне шатландырсаң, улым, шуннан да зур бәхет юк инде безгә. Үзеңне дә безнең нигезләргә аяк басканыңа үкенмәслек итеп кунак итәргә тырышырбыз, шулай бит, кызым? Сез яшьләргә минем халәтемне аңлау кыен. Ностальгия дигән хәерсезне. Юк, ялгыш әйтәм бит. Кеше күнелендә туа торган бу олы кичерешне. Яшьрәк чакларны тегесен җиткерим, монысын булдырыйм, дип тормыш дигән аргамакның артыннан куып җитеп койрыгыннан гына түгел, ә ялын учлап тотып яшәргә тырышканда, туган-үскән якларны, кендегем киселгән нигезне ул чаклы сагынмадым. Чөнки арасы да булмады. Ә менә хәзер өзелеп сагынам. Менә сине күргәч тә, улым, үзебезнең Әтнә якларына кайткандай, яшьлегемдә каерып-каерып атлап йөргән яшел үлән өсләренә

баскандай булдым. Әйтәм бит, сез яшьләргә мине аңлау кыен. Ә менә сезнең карабта пешкән арыш ипие белән бик тәмләп чәй эчәрмен мин... —Нугайбәк ага, аның шушы халәтен аңлап, мине үзенә кунакка алырга рөхсәт биргән капитаныбызгамы, әллә минамы рәхмәтен җиткерергә аптырап, каюта уртасында тора. Ә Данәгөл, инде күптәннән белгән танышына елмайган төсле, Таһирга йомшак кына елмая...

***

Капитан махсус катер белән аларны ярга илттерде. Портка килгән машиналарны куя торган махсус паркта дүрт урынлы зәңгәр «Ситроен» янына килделәр. Нугайбәк ага шушы җинел машинаның ишеген ачты.

—Сез, яшьләр, арттагы урыннарны биләгез,—диде ул. Үзе рульгә утырды.

Таһир Данәгөл артыннан арткы урындыкка кереп утырды. Чистай авыл хуҗалыгы техникумында укыганда ул чит ил машиналары белән мавыга иде. Техникумның китапханәсе искитмәле бит. Анда «Техника молодёжи», «Наука и жизнь» һәм тагын дистәләрчә журналлар алдыралар. Таһир шуларның берсен-бер калдырмый укып барырга өлгерә иде. Ә менә хәзер чит ил җинел машиналары арасында иң класслы саналганында баралар. Кузгалып китүләренә әле күпме генә, ә спидометр угы күзен дә йоммый йөз километрлар тирәсендә уйный. Данәгөлнең әтисе рульне кыю тота. Шәһәр читенә чыгу белән алар алларындагы машиналарны выжлатып кына уза башладылар.

—Мин машинамны камчылап тотарга яратам. Җегәрлегә булгач, нигә әле җил уйнатмаска,—диде Нугайбәк ага аларга таба борылып. Бу сүзләре белән аның сүз катуы гына булгандыр.

—Таһир, улым, хәрби хезмәттә ничәнче елыгыз? Демобилизациягә тагын күпме калды әле? Демобилизациядән соң ни белән шөгыльләнергә уйлыйсыз?

Беләсезме, бакырны, кургашны алтын арасына салсаң да, шул ук бакыр, шул ук кургаш булып кала икән ул. Әйләнә-тирәсендә нинди дәрәҗәле, барысы югары белемле, югары культуралы кешеләр, офицерлар күп. Булмаса булмый, йокмаса йокмый икән адәм баласына әдәп дигән нәрсә. Таһирдагы мәгънәсезлек, гөрбиянлык бер самосвал гына түгел, берничә вагон булгандыр. Данәгөлнең әтисенә биргән җавабын башка берәү ишетсә, оятыннан җир тишегенә керерие. Бик төксе җавап бирде ул аңа.

—Минем совет Хәрби Диңгез флотында хезмәт итүемә кагылышлы бер сорауларыгызга да җавап көтмәгез. Булмаячак. Сезнең тарафтан иң яхшысы—миңа аларны бирмәү,—диде ул.

Шул чактагы дорфалыгы исенә төшсә, хәтта бүген дә тәне чымыр-чымыр килә, ыржаеп «каз итләре» чыга. Шунда соң кешечә, әдәп белән генә, өченче елымны хезмәт итәм, дисә? Безнең илдә хәрби флотта биш ел хезмәт итәләр. Минем тагын ел ярымнар хезмәт итәсем кала. Шушы визитны уңышлы тәмамласак, командование хезмәт срогыбызны ярты елга кыскартырга ышандырды, дисә соң? Бу бит дәүләт сере түгел. «Сергей Киров»ка алганчы, Таһир башта учебкада булды. «Отважный» дигән эсминецта хезмәт итте. Шунда Козлов атлы мичман бар иде. Пешмәгәнрәк матросларны «Если матрос глуп, то это надолго!» дип орышырга ярата иде ул. Нәкъ Таһир кебекләргә төбәп әйтелгән акыллы сүз бит бу! Әйе, башыңны аңгыралык чире сарса, аннан тиз генә котылырмын димә икән. Ә менә Нугайбәк ага бөтенләй башка оннан, башкарак камырдан басылган зат, күрәсең. Тормыш диңгезендә колачны күп салган бәндә булса кирәк.

—Аңладым, улым, аңладым. Ирен кагуың белән үк төшендем,—диде

ул.—Күпме хезмәт итәсең калса да, безгә барыбер түгелмени? Исән-имин генә була күр. Исән-иминлегең турында өенә хәбәр салырга онытып куеп, эти-әниеңне ялыктырма. Ә мине эчкерсезлек белән аңлый күр. Көтмәгәндә, өмет тә итмәгәндә дигәндәй, өебезгә нинди зур бәхет ишелде бит. Татлы хисләрем тышка ташый. Ни-нәрсә турында сүз башларга да белгән юк. Каенанасына үпкәләгән килендәй, берсүзсез бару да килешми. Безнеңчә түгел.

—Машинабызда синдәй кадерле кунак барганда,—дип җөпләде аны Данәгөл.—Таһир, киреләнеп бар-ма-а...

—Кунагыбызга күңелсез була күрмәсен дип кенә башлаган сүзем иде. Берүк, әле биргән сорауларымны оныта күр,—дип дәвам итте Нугайбәк ага.—Командирыгыз сине безгә кунакка җибәрер дип соңгы минутка кадәр ышанып җитә алмадым бит, әй. Командирлар арасында да төрлеләре бар. Җибәрмим, йөрмәгез юк нәрсә белән борчып, дисә дә берни әйтә алмыйсың. Бер юлга зинһар гафу итегез дисең дә, ишегең тышкы яктан ябасың. Ышанырлык кына гамәлме соң, төптәнрәк уйласаң!—дип куйды Нугайбәк ага, уң кул бармагы белән күккә ымлап.—Чит мәмләкәттә, монарчы белмәгән-күрмәгән кешегә үз кул астында хезмәт иткән матросны биреп җибәрү өчен—моңа ай-һай зур кыюлык кирәк. Олы җанлы, кыю йөрәкле кеше икән капитаныгыз Соболь әфәнде. Ходай аңа саулык бирсен, мең ел яшәсен!

Данәгөл үрелә төшеп, кулын этисенең иңбашына салды:

—Әтием, гел әйтергә ярата торган сүзеңне әйтмәдең бит әле,—диде ул.

—Кайсысын?

—Кесә тулы акча турында.

—Бөтен дөнья җәмәгатьчелеге күз алдында, ике политик система арасына эленгән тимер чаршауны ертып, Франция ярларына килеп якорь салган совет хәрби карабы командирының кесәсе болай да буш түгелдер. Әйе, аның кесәсе дә акча белән тагын да тула төшсен!

—Әтием, 1нче ранг капитаны Соболь тиз көндә адмирал дәрәҗәсе алсын!—дип өстәде Данәгөл.

—Рәсәй безнең бөек ил!—дип куйды Нугайбәк ага.—Җирләре уңдырышлы. Ә затлы җимешләр тик уңдырышлы җирләрдә генә үсә. Капитаныгыз үз өстенә нинди зур җаваплылык алуыннан курыкмады. Ышанды. Сиңа ышанды, Таһир. Миңа ышанды. Җибәрде. Хәер, аның нинди төпле егет икәне йөзенә үк язылган. Мин, Таһир, улым, дөньяны күп күрдем. Европаны да күп айкадым. Кешеләрнең кем икәнен бер күрүдә таныйм. Капитаныгызга әле күп булса кырыклар тирәсе генәдер. Ә аңа әнә нинди крейсерны тапшырганнар. Сәяси әһәмияте дөньякүләм дәрәҗәле визитны ышанганнар.

Уң якта диңгез яры. Кайберләре борын төбендә үк, кайберләре еракта, офык читендә үк, төрле класслы кораблар күренеп китә. Сул якта берсе-икенчесенә тоташкан төзек авыллар, чирәп түбәле төзек йортлар. Тигез бетон юл буйлап «Ситроен» оча гына. Байтак араны сүзсез генә баргач, Нугайбәк ага тагын телгә килде.

—Бер-беребезне бик аз белгәнлектән, Таһир, улым, тиз генә уртак сүз табып, җанлы гәп корып җибәрүе кыен шул. Югыйсә, минем синнән бәйнә-бәйнә итеп искитмәле матур туган якларыбыз, андагы тормыш, якташлар-кардәшләрнең көн итүләре, яшәү рәвешләре турында күп нәрсәләр сорыйсым килә. Ләкин син әнә ничек кырт кисеп куйдың. Бәлкем, син «Таһир, улым,» дип дәшүемне дә килештерми барасыңдыр. Улым булуыңны да бик теләрием. Чөнки улларым юк минем. Улым буласыңмы, булмыйсыңмы, анысы Ходай кулында. Хәзергә исә, сиңа карата иң җылы

мөнәсәбәтләремне раслап, үз итеп дәшүем бу минем. Ошап бетмәсә, берүк, түзә күр. Яра-ар, әлегә хәвефләнеп чаң кага башлардай җиребез юк. Бер-беребезгә тиз ияләшербез әле, боерса. Бездә ошарга тиеш сина,Таһир. Һичшиксез ошарга тиеш. Иң якын туганнардай туганлашып китәрбез әле, боерган булса. Миннән бигрәк гөр-гөр килеп, сине сөйләштерер урында әлегә авызына су кабып барган кызым Данәгөл тырышыр. Шулай ич, кызым?

—Безне ошатмыйча, гел кәҗәләнеп кенә торса, матча астында, мин әле бүгенге көнгә кадәр шүрләгән тал чыбыгыбыз да бар бит, әтием,—диде Данәгөл.—Кунагыбызның кәефен күтәреп җибәрү өчен аны кулланырга да күп сорап тормам. Шулай бит, әтием? Командирыннан үз кулыбыз белән сорап алдык. Таһир хәзер безнең егет. Ни теләсәк, шуны эшлибез. Таһир, сак булыгыз...

Кызының бу сүзләреннән соң Ногайбәк ага эре, ак тешләрен күрсәтеп, рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

—Син, кызым, баштан ук репрессив чаралар куллану ягында. Кунагыбызны өркетә күрмик,—дип өстәде.

—Таһи-ир, син минем бераз шаяртып сөйләшүемне аңлыйсыңдыр бит, ә? Бу тилебаш мине чыбык белән «иркәләп» ала күрмәсен дип машинадан сикерә күрмә тагын, яме?—дип, Данәгөл ана төрттереп алды.—Шушындый үзе тыйнак, үзе чибәр егетнең, кан кардәшебезнең күңелен күрергә тырышырбыз инде, әтием. Соныннан карабына да кайтасы килмәс әле.

Марсель каласының бер чибәркәе, үзебезнең күрше кызы мадемуазель Жанна белән дә таныштырып куйсакмы?

Таһирмы?! Ул һаман да шул авыл гыйбады. Данәгөлнең сүзләрен килештермичә, аңа чәнечкеле караш белән карап куйды, ахры. Ә мондый карашны аннан яшерерсең, бар.

—Таһир, сез бик усал кешегә ошыйсыз. Мондый караш белән сез теләсә нинди стенаны бораулап тишәсез генә түгел, ә җимереп ишәсез. Бу чынлап та шулаймы, әллә мин нык ялгышаммы?—дип елмайды ул.—Белеп торыгыз, кем генә булсагыз да, сез безнең иң кадерле кунагыбыз. Һәрхәлдә, сезгә ошарга тырышырбыз. Иң авыр холкыгызга да түзәрбез. Әтием, рәсми белдерү ясыйм: шушы минуттан бу авыр вазифаны мин үз иңнәремә салам. У-ух! Күрәсеңме, иңнәремнең нинди киң икәнен. Ә бик нечкә дипломатия?! Миндә ул томнары-томнары белән,—дип бөтенләй шаян тонга күчте кыз.

Караб палубасына эләккән ятим песи баласыдай, автомобильнең арткы өлешендә үзенә сыеныр почмак таба алмый утырган Таһирга Данәгөл күз кысып:

—Өебездә минем усаллык дәрәҗәсен үлчи торган термометрым бар. Кайткач, үлчәп карарбыз. Нормадан югарырак булса, ике төймә дару бирермен. Хәлегез шундук яхшырыр,—диде.

—Афәрин, кызым, афәрин!—дип хуплады аны әтисе.

«Ситроен»ның арткы бүлегенә үз ирке белән кереп утырса да, Таһир сәеррәк бер халәт кичерә. Алай гынамы?! Урамнан эләктереп алып кереп, читлеккә япкан көчек сымаграк тота ул үзен. Гәрчә аны мыскал чикләүче, кысрыклаучы булмаса да. Данәгөлнең үзен шулай иркен тотып, җай килгәндә үткер генә шаяртып алуы аңа ошый. Вакыт-вакыт аңа төбәлеп карап ала. Монысы бәхәссез: Данәгөл чибәрләрнең чибәре. Ә чибәрләр янында Таһир әле техникумда укыган чакларыннан ук, ашка төшкән таракандай, үзен уңайсыз хис итә иде. Аны кыюсызлык баса, авызын ачып әйтергә мыскал сүз тапмый. Бәрәңге төя торган аңгыра, хиссез тукмакка әверелә. Менә хәзер дә, чын әгәр, машинадан сикереп калыр хәлендә ул.

Дингез яры буйлап, сөзәк үрләргә дә менеп, шундый ук сөзәк үзәнлекләргә дә төшеп, төзек юлдан ярты сәгатьләр чамасы чапкач, Ногайбәк ага трассадан бер читкәрәк чыгып туктады. Бармак очлары ачык йомшак күн перчаткасын салды.

—Әйдәгез, бераз ял итеп алыйк,—диде.—Дингездән әнә нинди рәхәт жил исә, Зюйд-вест[2] һавасы сулыйк. Биредән әнә нинди матур панорама ачыла. Урта дингезнең теге як ярындагы Алжир ярлары күренәме диярсең!

Данәгөл чыннан да шаян телле икән.

—Әтием, аяк очларына басып карасаң, биредән чыннан да Алжир ярларын гына түгел, ә дингез буенда балык тотып утырган гарәпләрне дә күрергә мөмкин. Чөнки Алжир ярларына моннан нибары ун-уникe көнлек юл,—дип куйды. Таһир шунысын сиземләде: Данәгөл белән әтисе бик дус мөгамәләдә. Бер-берсе белән бераз шаярып сөйләшүләрен дә килештерә Таһир. Болары өстенә Ногайбәк ага кызын бик ярата булса кирәк. Яраткач, бу чибәркәйнең барча капризларын да үти торгандыр. Дөрес, әлегә исә Данәгөлнең аларны күрсәткәне булмады. Әмма күрсәтми дә калмас.

Алар ялга туктаган култыктан Иске гавань, андагы караблар шахмат тактасындагы фигуралар төсле ап-ачык күренә. Гаваньда рейдта торган караблар арасында Таһир шундук үз крейсерын—«Сергей Киров»ны күреп алды.

—Әнә бит безнең крейсер! Торбасы чак кына төтенли.

—Гаваньдагы шул чаклы караблар арасыннанмы? Шул арада ничек күреп алдыгыз?—дип гаҗәпләнде Данәгөл.

—Ничек тапмасын инде, кызым?—дип сүзгә Ногайбәк ага кушылды.—Хезмәт иткән карабы аның туган иленең бер кисәге. Әгәр минем алда шундый сорау туса, гавань өстенә бер күз ташлау белән тапмас идемме? Бер сафка мең карабны рәттән бастырсалар да, минем карабым менә шушысы, дип бармагым белән төртеп күрсәткән булыр идем.

—Анда минем тормышның күп сынауларын бергә үткән хезмәттәшләрем калды... Мин аларны хәзер үк сагына башладым,—дип куйды Таһир.

—Туры сүзгә җавап юк. Алай, кызларым-егетләрем, кузгалдык. Анда Фәйрүзә җингәбезнең токмачы куермагае,—дип Ногайбәк ага машинага таба атлады. Данәгөл, Таһирны кулыннан алып, машинага өстерәде. Калма, йә адашырсың...

—Көч куллану түгел бу,—дип елмайды ул.—Токмач куеруга каршы эшләнгән конкрет адым, чара!

Таһир башта игътибар итмәгән иде, һаман да шул, кая барса да үзеннән калмаган кара сакалы, ягъни авыл гыйбадлыгы. Аның белән янәшә утырган Данәгөлдән үзенә бер татлы, жанга тынычлык, рәхәтлек биреп жылы бәрелә. Моны тоймый мөмкин түгел. Аның ал береты астыннан чыккан коңгырт-кара чәч толымнары, җилдә уйнаган булып, Таһирның битен әледән-әле сыйпап, кытыклап алалар. Хәтта чак кына чеметеп куйгандай булалар. «Йомырка баскан ана каз төсле кукыраеп бармасаңчы, валлаһи! Янында Хак Тәгаләнең җирдәге фәрештәсенә тиң зат бара. Ник аңа йөзеңне тутырып елмаймыйсың?» дип орышулары булмады микән Данәгөл чәч толымнарының болай уйнаулары?

Данәгөл толымнарын учына җыймакчы. Әмма өсте ачык машинада аларны җыярсың, бар. Ногайбәк ага да токмачларны чынлап торып куертмаска булды бит. Дүрт тәгәрмәчле айгырын камчылый гына бирә. Ә Таһир Данәгөлнең наян толымнарының аның битен янәдән һәм янәдән усал чеметеп алуларын көтә...

Мондый тизлек белән чапканда очып төшеп калуы да бар. Таһир

[2] Зюйт-вест—көньяк-көнбатыш җиле.

бескозыркасының ике тасмасын да җыеп тешләренә кысты. Аннан күрә Данәгөл дә толымнарын җыеп береты астына тыкты. Таһирга сораулы караш ташлады. Син канәгатьме, янәсе? Нигә эшләде инде моны? Кем сорады диген? Мондый иркәләүне күргән, татыган егетме соң Таһир? Данәгөлнең чәч толымнары аны ике бит уртасыннан сыйпап алуын ул гомере буена теләрие.

Техникумда укыганлыктан, Таһир армиягә яшьтәшләреннән ике елга соңрак алынды. Хәзер аңа егерме ике яшь. Шушы көнгә чаклы кая ул кызларның толымнары белән битен камчылату, хәтта аларның кулын тотарга да өлгермәде. Техникумда аның белән укыган иптәш егетләре, кызлар белән йөрү генә түгел, аларны бүлешә-бүлешә бер-берләрен дөмбәсләп бетерерләрие. Ә Таһир соңрак, күз кергәч кенә кызара торган помидор булдымы икән соң? Ул чорларда кызлар дип әлләни исе китмәде аның. Штанга күтәрде, көрәшчеләр секциясенә йөрде. Авылларына кайтып, ике җәйне Сабан туе батыры булып килде. Укыганда буш вакыты калса, районның техниклар клубында ачылган «Үзең уйлап тап» дигән түгәрәккә йөрде. Бу түгәрәк техниканы өйрәнү җәһәтеннән аңа күп нәрсә бирде. Бәлкем, шуңадыр, крейсерга эләккәч тә Таһир үзен тиз таныта алды. Әйе, флагман корабка ул күп яклы хәзерлек белән аяк басты. Тик менә хәзер генә, Данәгөл белән янәшә утыргач кына кызларның чәч толымнары нинди тылсымлы кодрәткә, сихри көчкә ия булуын тоеп, тәмам мәрткә китеп утыра. Алардан башыңны әйләндергеч татлы хуш ис килә. Төрле затлы хушбуйларның, косметика-мазарларның бередә мыскал да катнашы юк. Алардан әле яңа гына чабып покоска салган печән, явып кына узган ап-ак кар исе килгән сыман. И-и, Данәгөл! Син сихерче түгелме? Менә шушында ике кулыңнан тотып, йөзенә туп-туры карап сорарга иде дә бит үзеннән. Әмма Таһирның теле әйләнми, авызында сүз оешмый.

Ул арада төзек йортлары белән шәһәрчеккә тартым бер матур поселокка килеп керделәр. Уң якта да,сул якта да җыйнак кына кибетләр, утлар белән бизәлгән кафе-рестораннар күренеп кала. Шунда Ногайбәк ага ирләрчә матур, иркен тавыш белән җырлап җибәрде. Таһир хәтта бераз аптырап калды. Каян белә икән ул татар җырларын?

Талдин гына тартма ясар идем,
Су да буйларыннан таш тапсам.
Туган илләремә кайтыр идем,
Хәләл кәсеп итеп мал тапсам.

—Таһир, ишеткәнең бар идеме бу җырны?—дип сорады ул.—Ә менә монысын?

Агыйделкәйләрнен, әй, буенда,
Акбүз атлар йөридер ашлыкта.
Туган-үскән илдән бер аерылгач,
Булмый икән тиз генә кайтып ла.

Аннары, үз сүзләрен үзе үк җөпләп дәвам итте:
—Тормыш дигәнең, Таһир улым, шулай инде. Үз гомеремдә мин аны күп тапкырлар сынадым. Бер җырлата, бер елата ул сине. Тормышка таләбем шундый: син җырлаганда ул скрипкәсен сузып җибәрсен, елаган чагыңда башыңнан сыйпап юатсын. Ник, шулай булмыйча!

—Әтиемнең аның белмәгән җыры юктыр, кәефе булганда лирик тембрын еш яңгырата,—диде Данәгөл, аны җилкәсеннән сыпырып.—Әллә кайлардан

китапларын да таба. Безнең өйдә бөек шагыйрь Г. Тукайның әле 1910 нчы елда Япониядә чыккан шигырь китабы да бар. Кайткач, әтием күрсәтер әле.

—Мондый зур кунакка да күрсәтмәсәм!... «Йосыф илә Зөләйха» кыйссасы да бар, «Сак-сок бәете» дә. Илемнән, халкымнан читтә яшәсәм дә, мин чын татар баласы бит. Минем өчен горурлык кына түгел, зур бурыч табу...

—Мина да үземне белә башлаган яшьтән бирле әтием дә, әнием дә: «кызым, бел, син татар кызы!»—дип тукып тордылар. Таһир, менә әйт син. Ошаганмы соң мин саф татар кызына?

—Тукымыйча! Татар кызы булгач. Парижда бик бай букинист кибетләре бар. Барып чыксам, шуларны актарып кайтам. Еш кына үзебезнең татар китапларын да очратам. Бу тарафларга сез нинди ачы язмышлар белән килеп чыктыгыз икән дип гаҗәпкә калам. «Сезнен урыныгыз бүгеннән минем китап шүрлегендә, кадерле мөһаҗирләр»,—дип пышылдыйм. Күпме торсалар да, тизрәк үз дипломатыма салырга ашыгам. Бездәге китапханәләр дә бик бай. Үземә кирәкле китапларны кибетләрдән тапмасам, китапханәләрдән сорыйм. Ярты сәгать эчендә факсимиляләрен төшереп бирәләр. Алайса, тагын бер тыңла, Таһир улым.

Ничек килдегез сез безгә,
Батмаенча диңгезгә?
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт итик сезгә?

—Ишеттеңме?—дип, Данәгөл Таһирга күз кысып алды.

—Менә кайтып җитик әле. Мин сина, Таһир улым, матур җырларыбызның Татарстаныбызда ишетмәгәннәрен җырлармын. Хәтта туйдырып бетерермен. Германиядә, Берлинның үзендә яшәгән чагыбызда кибеттән ике граммафон тәлинкәсе сатып алдым. Тынлап карагач, исләрем китте. Аларга үткән сугышта алманнарга әсир төшкән татар совет солдатларының җырлары, бәетләре язылган. Менә кайда сагыш, менә кайда ул моң! Шул бәхетсезләр утырган лагерьларга кемнәрдер килгәннәр бит. Җырларын тыңлаганнар. Магнитофон тотып барыпмы, әллә студиясенә алып кайтыпмы, пластинкага яздырганнар. Менә нинди асыл затлар булган бит җир йөзендә! Дөньяны барыбер мәрхәмәтлеләр, киң күнелләләр өстери. Фиргавеннәр дә аз түгел, әмма аларның барыбер җыры кыска...

***

Шау-шу килеп яшьләр футбол тибеп яткан стадион кырына килеп чыктылар. Алар яныннан узганда Ногайбәк ага футболчыларны сәламләп,озын итеп машинасын кычкыртып узды. Аннары кисәктән генә бер тыкрыкка борылып, биек тимер коймa артыннан күренеп торган, түбәсен кызгылт чирәп белән япкан ике катлы таш йорт алдына килеп туктады. Өй кыегындагы ярым ай аларны елмаеп каршылады.

Капка каршына килеп басу белән сигнал бирүнең дә кирәге булмады. Аларны көткәннәр. Көтмичә! Машина килеп туктауга, тимер капка киң колачын җәеп, ике якка ачылып китте. Тигез итеп, шахмат тактасы рәвешендә бетон плитәләр түшәлгән ишек алдына керделәр. Аларны чәң-чәң килеп, куш йодрык хәтле генә көчек каршылады. Кунак егетнең балагыннан каптырырга да исәбе бар иде көчекнең.

—Буфалло, барысы да үзебезнекеләр бит. Бар, урыныңа кереп ят!—дип Данәгөл аңа бармак янады. Көчек оясына ашыкты.

—Кара, ничек сүз тынлаучан,—диде Таһир.

—Тыңламаса, чыбык,—диде Данәгөл, Таһирга шаян күз кысып.

—Буфалло! Исеме җисеменә тартым. Александр Македонскийның яуга йөри торган айгырының исеме түгелме соң?

—Нәкъ үзе,—дип елмайды Данәгөл.—Ошаган бит? Бөек полководецның яуга йөри торган, баштан-аяк тимергә төренгән, ут яллы айгыры һәм куш йодрык хәтле генә көчек.—Таһир да Данәгөл белән:—Нәкъ үзе!—дип килеште.

—Капиталистик белән социалистик лагерь арасына корылган «Тимер чаршау»ны ертып килгән совет хәрби матросының, моннан мең еллар элек яшәгән полководецның тормышы белән шулай якыннан таныш булуы, миндәй нәзберек зәвыклы һәм беркадәр скептик карашлы француз җәмгатьчелеге вәкилен коралсызландыра,—дип күз кысып елмайды Данәгөл.

Ногайбәк ага машинасын бизәкле ике ишеге ике якка ачылышлы парадный ишек төбенә китереп туктатты. Аннан, кояш булып балкып, үз яше өчен матур гына түгәрәкләнеп килгән бер апа чыкты. Алдына зур-зур ал-кызыл чәчәкләр төшкән алъяпкыч япкан. Таһирларның Салкын Аланнарында да бу яшьләрдәге җиңгәчәйләр алларына нәкъ шушындый эре чәчәкле алъяпкыч ябалар бит. Алда ике зур кесә. Болары мичтән кайнар таба алганда тастымаллар кул астында гына булсын өчен. Бу апай белән бергә аның колакларындагы алтын алкалары да кунакларга җем-җем килеп елмаялар.

—Минем бердәнбер нечкә билем, унганнарның унганы, булганнарның булганы, ике күзем өстендәге кара кашым, өзелеп сөйгән җаныем, авырып китсәм табибым Фәйрүзәбикә апаң шушы була инде,—диде Ногайбәк ага, үзе Таһирга күз кысып алды.—Таһир улым, колагыңа шундук киртләп куй, бу затлар белән шулай, җае чыккан саен мактау сүзләрен сибеп сөйләшмәсәң, тату яшәрмен димә.

—Чит-ят кеше бар дип тә тормыйсың, әтисе, тәмам аптыраттың бит инде шушы «нечкә билең» белән. Җир йөзендә менә минем яшькәчә җитеп яшәп кара әле, үзеңнең билең нинди булыр икән?—диде дә Фәйрүзә апай, күрешү өчен Таһирга ике кулын сузды.

—Ни дип шулай озакладыгыз? Бәлешләремне мичтән ничә алдым, ничә тыктым. Әллә ул-бу хәтәр хәлгә юлыктылармы дип тә тәмам ут йоттым. Әйдүк, әйдүк, өйгә керәбез.

—Юлдагылар май йотар, көтүчеләр ут йотар дип бер дә юкка гына әйтмәгәннәр шул инде, әнисе,—диде Ногайбәк ага, йомшак күн перчаткаларын сала-сала.—Юлыбыз уңды. Хак Тәгалә синең теләкләреңне дә тулысы белән кабул иткән. Күр, менә нинди кунак егете алып кайттык. Гренадер бит, гренадер! Үзебезнең татар егете! Таһир атлы. Ходай насыйп итте.

—Таһир атлымени?—дип сорап куйды Фәйрүзә апай, үзенә бер тирән мәгънә белән. Авыз эченнән генә ниндидер дога да укып алды.

Ногайбәк ага ике ишеге ике якка ачылган баскычка күтәрелеп, зур пеләш башын опера артистларыча артка ташлап, юк мыекларын сыпыргандай итеп җырлап та алды:

> Ай, гүзәлем, Фәйрүзәм!
> Күрешмәгәнгә ничә кич,
> Ничек йөрәген түзә?

Таһир күреп тора, агайның күңеле шат. Шушы мизгелләрдә аның күңелен биләгән шатлык, сөенеч хисләрен бик үк сиздерәсе дә килмәгән төсле бугай. Әмма алар, хуҗаның тыебрак торырга тырышуын санга сукмыйча, тышка

ыргылалар төсле. Андый минутларда кычкырып җырлап җибәрми тагын нишлисең? Таһир сизә, аның бу йорт ишек алдына аяк басуына барсы да чиксез шатлар.

—Әйе, әнисе, өебезгә бүген зур кунак алып кайттык. Безнең бурыч хәзер ана тиешле сый-хөрмәт күрсәтү. Егетебезнең безнең гаиләбездә булган һәр минуты аның күңелендә мәңге онытылмас татлы хатирәләр калдырсын.

—Тырышырбыз, тырышырбыз, Алла боерса,—дип елмайды Фәйрүзә апа.

—Әнисе, сездән яшереп-нитеп торды юк. Юлыбыз унганга, шатлыгым эчемнән ташый. Кил, үзеңне дә нечкә биленнән бер кочыймчы.

—Балалар алдындамы, картлач,—дип елмайды Фәйрүзә апай. Агай исә, Таһирга таба борылып, кинәттән генә:

—Фәйрүзә апаңмы?—дип сорап куйды.—Беренче карашка гына шулай ачык йөзле, сөйкемле күренә ул. Ә чынында үтә холыксыз, бик кәҗәле бер җан. Бер дулый башласа, Везувий вулканын уздыра.

—Уздырам, уздырам. Бер кызсам, Везувийны да, Килиманджароны да. Иң яхшысы, мине дулатмаска,—диде Фәйрүзә апа һаман да мөлаем елмаеп. Эштән вакытында кайтмасалар, пешкән ашым суынса, әлбәттә, дулыйм. Алай җиңелрәк. Алар өчен көнозын ут йотып торуларым шундук басыла.

Данәгөл, әтисе белән әнисенең бер-берләренә ихтирамнарын шушы рәвештә шаян сүзләр уйнатыбрак җиткерүләрен моңарчы да күп ишеткәндер. Ул сүзгә катышмыерак торды. Тик Таһирга гына дусларча ике тапкыр күз кысып алды. Фәйрүзә апа исә, һаман да бераз тартыныбрак, кая басарга үзенә урын тапмый торган Таһир белән:

—Ходайның бирмеш көнендә. Бисмиллалы нигезебезгә изге сәгатьтә, төкле аягың белән аяк баса күр, балам,—дип, ике кулын сузып күреште. Фәйрүзә апа үзе дә тартыну кичерә: Таһирны кочып алса—килешмәс, алмаса—егете кадерле кунак. Кайда монда урталык?

—Менә шушы тарафларда көн итеп, ипи черетеп ятмыш инде,—дип, бу юлы бераз көрсенүле тавыш белән сүзгә Ногайбәк ага кушылды. Бу сүзләрен ул булганына сөенү, горурлану, шул ук вакытта беркадәр сагыш та өстәп әйтте:

—Нигезебез төпле, хәләл! Аның һәр ташын, маңгай тиремне сыпырып эшләп тапкан акчама алып, берсе өстенә берсен сылап салып, шушы кулларым белән өйдем, һәр узган якты көнең өчен Хак Тәгаләгә рәхмәтеңне укып, шатланып яшисе генә дә бит. Тамагың тук, өстең бөтен булгач, тагын ни җитмәгән инде адәм баласына? Юк шул. Җитми икән. Туган-үскән ил һавасы җитми. Үзебезнең Идел буйларын, аның өстендә озы-ы-ын итеп кычкырткан баржа-пароход, акчарлак тавышларын сагынам.

—Чир бу, чир, яман чир синдә, әтисе. Әйтерсең пароходлар биредә юк. Әйтерсең, эшкә көн дә диңгез буена бармыйсың. Бер уйласаң, сәер инде бик!—дип куйды Фәйрүзә апай...

—Ярар, әтисе, табиб әфәнде атап әйтте бит инде, синдә ностальгия чире, диде. Туган-үскән җирне сагыну Таһир кунагыбызга да таныштыр. Әйдә, өйгә керик. Карыныгыз да ачкандыр. Минем бар сыем әзер. Өстәлебез зарыгып безне көтә булыр. Керик тә, утырышыйк.

Фәйрүзә апаның күзе Таһирда гына.

—И-и, Таһир улым! Син безгә Ходайның аяклы бүләге! Бик тансык, зерә-зерә дә тансык бүләк. Сиңа нинди сый-хөрмәтләр генә күрсәтербез инде?

Ә Ногайбәк ага исә, сүзен ирләрчә кыска тотып:

—Син, Таһир, бер дә тартынып торма, улым,—дип куйды.—Бусагабыздан кыю атлап кер, лап-лоп басып түрдән уз. «Ходайның аяклы бүләге» дидеме

әле үзенә Фәйрүзә апан? Ходай бүләгенен урыны түрдә! Әмма шушы сүзләрне үзем күнеленә сендерергә әлегә тик юлларын гына тапмыйм. Бу минем вакытлыча гына югалып калуым. Менә, тәмләп бер чәй эчеп алгач, боерса; синен бездә кунакта булуына карата, ике якнын да мәнфәгатьләрен истә тотып, махсус меморандум кабул итәрбез. Әйе, синен бездә булган минутларыннын берсе дә заяга узмасын. Алдагы тормышында кат-кат исенә төшереп, сагынып искә алырлык матур хатирәләр белән тулы мизгелләр, сәгатьләр булырга тиеш бездә кунакта узган көннәрен. Килешәсен булыр? Килешмим дип әйтергә, ягъни «Вето!» салырга әлегә сәбәп юк. Шулай бит?

Таһир, килешүен раслап, баш какты. Баш какмый нишләсен? Байлыкка, хәерчелеккә, популярлыкка күнеккән кебек, кунакчыллыкка да күнегергә кирәк бит. Шул ук вакытта башынны да җуймаска.

Беренче күрешкә үк күнеленә хуш килгән кунак егеткә тагын һәм тагын якты йөз, кунакчыллык күрсәтү нияте беләндер инде, Фәйрүзә апа да тәмам кыбырсына, килеп утырырга урын, барып басарга почмак тапмый. Гел түгәрәк өстәл тирәли бөтерчек булып бөтерелә. Бераз каушап төшүе дә сизелә. Каушамассын, бар! Уйламаганда, көтмәгәндә дигәндәй. Ерак, бераз серлерәк, әмма күнелгә якын туган иленнән килгән, монарчы барын да белмәгән бер егет бусаганны атлап керсен әле!

«Уйламаганда, көтмәгәндә» үк түгел инде анысы. Марсель портына дуслык визиты белән Совет Хәрби Дингез флотынын флагман карабы киләсен бер айлар элек белеп тордылар. Гәзит, радио-телевидение гел шул турыда гына сөйләде. Ногайбәк ага гаиләсендә дә кичләрен сүз гел шул турыда гына барды. Флагман карабы хәтле карабта, анда хезмәт итүче дүрт йөзләп матрос арасында хет бер генә булса да татар егете булмый калмас дип өметләнделәр. Аны һичшиксез кунакка чакырырга кирәклеге турында сөйләшү, кинәшләшү күп булды. Әнә бит кунак өстәле дә әзер.

Данәгөл дә алдына ука белән чигүле үрнәкләр төшерелгән матур алъяпкыч ябып алды. Дөньяда ир-егет заты булып яшәп, совет Хәрби Дингез көчләре матросы булып, бу матурлыкны күрмәү өчен дөм-сукыр булу кирәктер. Таһир да ни дип дөм-сукыр булсын?! Алдына матур алъяпкыч япкан Данәгөл бизәп куйган курчактай җыйнак, искитмәле чибәр иде. Җыеп ал да кочагында коч. Чү, әле! Үзендә кинәттән туган мондый хисләрдән Таһир хәтта бераз чытаеп китте.

Данәгөл, җинелчә генә кагылып китеп, кунак егете алдына канәфер чәчәкләре төшерелгән ташаяк тәлинкә куйды. Таһирга тартынып утырырга мыскал сәбәп калдырмаска тырыша ул. Әйтерсен, алар берсен-берсе күптән беләләр, күптәнге якын танышлар.

—Йә, әйт, карт дингез бүресе, дөресен, шунда ук җәннәткә керерсен,— дип, кулын Таһир инбашына салды.—Әнием тик сине сыйлау өчен генә өстәлгә чыгарган ризыкларнын кайсын телисен? Кайсын күбрәк яратасын? Кайсыларын тәлинкәнә өеп салыйм?

Утлы күмер өстенә эләккәч, майлы табага да тел инә, чыжлый башлый.

—Перловая каша—самая любимая еда наша!—диләр безнен карабта. Миннән, өч ел дингездә хезмәт иткән хәрби матростан, син нәрсә яратмыйсын, тамагыннан нәрсә үтми дип сорагыз,—дип телгә килде Таһир.—Әгәр инде шушы ук соравыгызны безнен крейсернен берәр матросына бирсәгез:

—Безнен тамакка куш йодрык белән кирза итек кенә сыймый торгандыр, дияр иде,—дип өстәде.

—Кызым, кызым, кунак егетебезгә бераз күнегергә ирек бир әле,—дип

әнисенең кисәтеп торуына карамастан, Данәгөл аны төрле яклап кымтырыкларга кереште.

—Алай да, «русский матрос», тартынмый гына әйт әле. Өстәлдәге ризыкларыбызның кайсыларын салыйм? Сине сыйлауны үз өстемә алам. Хәер, табындагы ашамлыкларның барын бер кат урып чыкмыйча, өстәл яныннан кузгалырмын димә. Шулай бит, Ногайбәк кенәз? Сезнең, карт дингез бүреләренең, кайнар ит сумсаларын күпләп юк итү буенча дөнья чемпионнары икәнегезне дә беләм. Шулаймы, кенәз? Хак сүз сөйлимме?

—Әллә бердәнберебез генә булганга, бераз иркәләбрәк үстердекме? Нәни чакларында еш кына үзем белән эшкә алып бара идем. Анда баргач, бар таможняны айкап чыга. Белмәгән, танышмаган кешесе калмый иде. Кил әле, кызым, үбим әле бер үзеңне,—диде Ногайбәк ага, кочагын җәеп. Хуҗаның йөзенә канәгать елмаю җәелде.

—Кенәз буласы, имеш. Ә бит ул мине кече яшеннән шулай атап йөртә. Бу сүзне ул кайда, кемнән ишеткәндер.

—Ишетмәскә соң? Безнең монда кенәз исеме йөртүче татарлар байтак. Хәтта руслар да бар,—дип сүзне Фәйрүзә апа җитәкләде.—Данәгөлебезгә әле биш-алты яшьләр генә булдымы икән? Шук кыз булып үсте ул. Франциягә күченеп килгән елларыбыз гына әле. Әтиебез, хәтерлисеңме, Парижга, Эйфель манарасын күрсәтергә алып бардың бит. Шунда аның ин биек мәйданчыгына менеп баскач, фасонлы килеш-килбәтле бер ханымга игътибар иттем. Башта, абау, үз әниемне күрәмме, дип әфсендем әле. Кыл үзе, коеп куйганнар диярсең. Ап-ак батист яулыгы өстеннән башына озын чуклы ефәк шәл бөркәнгән. Аякларында чигүле сафьян читек-кәвеш. Нык исемдә, кая да булса ашка-кунакка барганда, әнием дә шулай киенә-ясана иде. Шактый олы яшьләрдәге бу ханым, җиде-сигез тирәләрендәге шулай ук кырт өсбашлы, курнос борынлы бер малай җитәкләгән. Бар игътибары аңарда гына. Кулыннан ычкындырмаска тырыша. Мин андый чакта бик кыюсыз. Әниемә бик ошаган булса да, бу абыстайга мин кыеп сүз ката алмаган булыр идем. Ул малайны Данәгөл дә күреп алды. Барды да, борып битеннән чеметеп алды. Шундый иде ул. Малай шираулап кычкырып җибәрмәсенме? Татарчалап, бераз ачуым да чыгып:

—Кызым, Данәгөл?! Нишләвең инде бу?—дидем. Баш очында йодрыгымны да уйнаттым бугай.—Сине ияртеп дөньяга чыгарга куркыныч.

—Бу чибәр кызның исеме Данәгөл мени?! Ай-яй, тәти кыз икән. Үзе дә, өстендәге күлмәге дә нинди матур. Ә чәч толымнары! Аларны кем шулай тигез үрде? Әниендер инде. Нишләве булсын? Минем кече оныгым Искәндәрнең, аның колагын шушы көнгә кадәр килеп тешләмәгәне өчен үч алуыдыр. Шулай бит, кызым?—дип, әлеге абыстай Данәгөлне кочагына алды.

—Абау! Колагыма гына ишетеләме? Сез дә, абыстай, үзебезнең татар мыни? Биредә, Франциянең башкаласы Парижда... Эйфель манарасы төбендә...

—Татар булмыйча, кардәшем! Безнең монда, эзли китсәң, ярты Париж татар. Узган сугыштан соң калучылар күп булды. Ә мин Зөлхәбирә апаң булам, таныш булыйк. Сезне очратуыма мин дә бик шат,—дип кулын сузды Искәндәр исемле матур малайның әбисе.—Безнекеләр күптәннән биредә инде. Кенәз Йосыповлар ак патшага илчелек хезмәтендә күп еллар рәттән тугры хезмәт итеп килгәннәр. Берничә буын рәттән. Ирем Габдрахман җизнәгез дә Франциянең тышкы эшләр департаментында хезмәт итте. Хәзер ике улым дипломатлар. Шунысы зур үкенеч, менә аларны татар кызларына өйләндерә алмадык. Ике киленем дә—француз кызлары. Улларым да, ни тырышсам да, юньләп татарча белмиләр. Улларым Хәсән дә, Хөсәен дә

Сорбонна дәрелфөнунен тәмамлап, бик төпле гыйлем алдылар. Жиде-сигез телдә иркен сөйләшәләр. Тел белмичә, ничек дипломат булып булсын? Үзләре яртылаш француз булсалар да, фамилияләрен саклыйлар. Чөнки жиденче бабалары кенәз Йосыпов аларга карьера ясарга бүген дә җинеллек бирә. Хәсән белән Хөсәеннең бабалары, минем мәрхүм каенатам Әхмәт-Зыя, юкса болай ярыйсы кырыс кеше иде. Оныкларына: «Һәркөн иртән идәнгә, мин татар милләтеннән, атаклы кенәз Йосыповлар нәселеннән дип төшеп басыгыз! Шушы сүзләрне кабатлап йокларга ятыгыз! Чыгышыбыз моннан бик ерактагы Казан ханлыгыннан. Иң борынгы бабаларыбызның сөякләре шунда күмелгән. Бу турыда беркайчан исегездән чыгармагыз»,— дип кабатлап, тукып кына торды.—Хәзерге яшьләр өлкәннәрнең сүзенә бик колак салмыйлар шул...

Ике улымнан өч оныгым бар. Үзем исән чакта менә шушы малайларны әз булса да татар итеп калдырыйм дип тырышам инде. Юкса әниләре дә каршы түгел, аяк чалган кеше юк,—Зөлхәбирә абыстай оныгының кулыннан тартты.

—Искәндәр, улым, син татарча беләсеңме әле?

—Зөлхәбилә әбиемне бик-бик ялатам,—диде малай.

—Болай белгәч, әйбәт инде-е-е,—дидем мин.

Зөлхәбирә абыстайның терекөмеш бөртегедәй тере оныгы мактауны килештерде.

Мин татал, мин татал!
Татал башынны ашал.
Мин татал, мин татал,
Тотып ботыннан атал!—

дип декламация дә сөйләп алды.

—Монысы халык авыз иҗатыннан,—дип елмайды Зөлхәбирә абыстай.—Париж татарлары туган илләреннән алып килгән халык авыз иҗатын күз карасыдай сакларга тырышалар.

Зөлхәбирә абыстай редикюленнән алып миңа визиткасын сузды.

—Без, татарлар, дөнья мәдәниятенә зур өлеш керткән халык. Без бит Атилла патша оныклары. Ат тояклары астында бөтен Европаны тетрәткән Чыңгызханыбыз гына да ни тора: гозерегез төшкәндә шалтыратыгыз, юлыгыз төшкәндә чәй эчәргә керегез. Без—Атилла патшаның оныклары, кайларга чәчелсәк тә, бер-беребезнең кул җылысын тоеп яшәргә тиешбез.

—Кенәз Искәндәр, бар әле бу тәти кызга кулыңны бир. Татулашыгыз! Сау бул, безгә кунакка кил, дип чакыр.—Әлеге матур малай Данәгөл каршына килеп, үз бәясен бик белеп:

—Кенәз Искәндәр Йосыпов!—дип кулын сузды. «Кенәз» сүзен шуннан өйрәнеп кайттык бит.

—Кара, чынлап та шулай бит әле,—дип килеште Ногайбәк ага.—Шул чакта Зөлхәбирә апай, редикюленнән «Цейс» фотоаппараты алып, балаларның икесен дә фотога төшерде әле.

—Син, хөрмәтле кунак егетебез, кызымның сиңа «русский матрос» дип дәшүенә үпкәли күрмә тагын,—дип дәвам итте агай. Совет сәүдә корабларыннан Марсель портына чыккан бар диңгезчеләрне дә «русский матрос!» диләр бездә. Шушы сүзгә күп мәгънә салып. Мыскыллау, көлү дип уйлый күрмә тагын. Аерым статус һәм хөрмәт хисе белән. Башка илләрнең корабларыннан чыккан егетләрдән алар нык аерыла. Аларда күмәкчелек хисе көчле. Дөнья булгач, төрле хәлләр була. Әгәр берәрсе бәла-казага тарыса, аны бу бәладән йолып алмыйча порттан китмиләр. Искитмәле егетләр!

Кыюлык дигән кыйммәтле, кирәкле сыйфат Таһирга да инә башладымы?

—Беләсезме, өстәлдәге бу татлы ризыкларны күрү белән ике күзем дә крейсерыбызның палубасындагы көчле прожекторлар төсле яна башладылар. Миндә аларны үзйөрешле комбайн төсле бер кизәнүдә урып чыгу теләге туып куйды. Алай да бераз икеләнәм әле,—диде ул.

Данәгөл бу юлы Таһирның каршына басып, кулы белән һаваны ярды:

—Дөньяда Совет матрослары булдыра алмаган эш юк! Бу араларда сезнең турыда, и-и,ниләр генә язмадылар.

—Мактаганнардыр инде,—диде Таһир, елмаеп.

—Күтәреп мактадылар да. Совет хакимиятенә тугры булуыгызны—аеруча. Жиргә салып таптап, яманлау да житәрлек булды.

—Безнеме?!—диде Таһир гажәпсенеп.

—Сезне шул. Эчәргә яраталар. Сүз күтәрмиләр. Мәкерлеләр, үчлеләр, берни булса, сугышырга гына торалар, дип сөйләделәр. Без әтием белән, ни язсалар, берсен-бер калдырмый укып бардык. Мондый хәбәрләр белән таныша барган саен, әтием алдындагы счетның бер төймәсен шалт итеп тартып куя килде. Счет төймәсен тартып куя да, кызым, мондый унган-булган, күп кырлы холыклы совет моряклары арасында үзебезнең татар егете дә булмый калуы мөмкин түгел, дип резюме чыгара. Теләгән теләгенә үзен-үзе ышандыра, инандыра белү көче бар әтиемдә. Күп тапкырлар сынаганым бар, ни гажәп, ул теләгән нәрсә соңыннан чыннан да анынча булып чыга.

—Бары да мин теләгәнчәрәк булып бетми, әлбәттә. Алай да теләкне телибез инде аны. Анысына иренмибез,—дип куйды Ногайбәк ага. Хужа ага зал түрендәге кара-кучкыл төстәге сервантын ачып, аннан озынча буйлы бер шешә алды. Аны яктыга куеп әйләндереп карады. Тышына ябыштырылган ялтыравык кәгазьләрдән күренгәнчә, аның эчендә бик затлы сыеклык булырга тиеш. Агай, цирк артистлары осталыгы белән, әлеге шешәнең төбенә гөп итеп сугып алды. Шешәнең бөкесе читкә очты.

—Доннер ветер! Шайтан алгыры!—дип куйды агай. Таһир, майн һерц, шпрехен зи ин дойч? Ферштейн? Алманча беләсеңме? Бераз гына булса да анлыйсыңмы?—дип сорады.

—Найн! Юк. Нихт ферштейн! Берни дә анламыйм,—диде Таһир.—Атнасына ике генә сәгать булса да, бишенче-жиденче классларда немец телендә ярыйсы сукаларга өйрәндек. Берни булса, малайлар «Гитлер капут» дип кенә жибәрәләрие. Әмма барыбыз да яратып өлгергән немец теле укытучысы Камилә апабызның егете самолет белән кайтып, Казанга алып китте. Бөтен авыл белән кул болгап озатып калдык. Камилә апа бүтән кайтмады, аның урынына яңасы килмәде.

Моңарчы кушылып китәргә жае чыкмыйрак торган Фәйрүзә апа да телгә килде:

—Егетләр шулай алар, шулай. Яратып йөргән кызлары булса, аларга йөгәнне киертергә генә торалар,—дип, Таһирның сүзен жөпләп, куәтләп куйды.

—Сигез-тугыз-унынчы сыйныфларда немец теле кермәде. Немец теле өчен бирелгән сәгатьләрдә мәктәп ишек алдын себердек, карын көрәдек, бозын чаптык,—дип дәвам итте Таһир.—Шулай итеп, безнең Гете, Шиллер, Гейне телен өйрәнүебез, «иһ бин найн дер Брехт!»—«Мин тукран түгел!»дән артмады. Ә ишәк түгеллегенне теләсә ничек расла хәзер.

Кунак егетенең бу сүзләреннән рәхәтләнеп көлешеп алдылар.

—Бу визитка чыгар алдыннан барыбызга да француз телен өйрәттеләр. Мондый бай телне өч ай эчендә генә әлләни тирәнтен үзләштереп булмый

торгандыр. Әмма «Марсельеза»ны французча жырлыйбыз. Луи Арагон шигырьләрен шагыйрьнең үз телендә тынлап карадык. Экипажыбызның барлык егетләре дә французчаны Марсель урамнарында адашып калмаслык дәрәҗәдә сукалыйлар. Тел өйрәнү кешенең үзеннән дә тора икән,—дип тә өстәде Таһир.

—Менә монысын булдырганнар! Акыл белән эш иткәннәр!—дип хуплады Ногайбәк ага Совет хәрби диңгез көчләре җитәкчеләрен.—Монысына мин дә ике куллап кул куям.

Хуҗа агай әлеге шешәдән өстәлдә торган нечкә билле бәллүр фужерларга, ничектер бер дулкынлану белән, чия, кызгылт-карасу төстәге сыеклык салды.

—Төшкән күңелләрне дә күтәреп, аңкауга ябышкан телләрне дә йомшартып җибәрә торган көч-кодрәте бар бит шушы зәхмәтнең. Таһир улым, нигезебезгә төкле аягың белән кил! Күрешү, танышу хакына! Чәкештердек! Әл гаязе Билла! Моны тоту язык түгел. Хыянәт, кеше чагу кебек гөнаһлардан, иң түбән сыйфатлардан Ходай сакласын!—диде ул.

Әйе, мондый чакта ык-мык килеп, кәнфитләнеп, карышып тору кыланчыклык, тирән мәгънәсезлек булыр иде. Бигрәк тә, утны-суны беркадәр инде кичәргә өлгергән совет хәрби флоты матросы өчен. Бу минутта Таһир үзе дә нәкъ шулай уйлады.

Фужердагы затлы эчемлекне төбенә хәтле тотып куйгач, шуның сихәтен бөтен тәненә тараткандай иреннәрен чәпелдәтеп алгач, Ногайбәк ага ике кулын күкрәге өстенә куеп:

—Улым, Таһир, тормыш дигән нәрсә болай бит ул,—дип озын гына монолог тотарга ниятләгәние. Аны Фәйрүзә апа бүлдерде. Кырт итеп түгел. Сүз барышына уңай белән генә килеп кереп:

—Әтисе, исемдә-хәтеремдә чакта шуны әйтмәкчием,—диеп.

Бүлдергәнне бик үк өнәмәсә дә, Ногайбәк ага, кесәсеннән кульяулык чыгарып пенснәсен сөртә башлады.

—Йә, йә, хәтереңдә чакта ни әйтмәкче идең? Хәтереңә сылтама, нечкә бил. Хәтереңәйбәт синең. Синдәге хәтер менә миндә булсамы?! Хәйләкәрлек тә синдә бер букча.

Әмма дә ирен ишетмәмешкә салыныбрак, Фәйрүзә апа болай диде:

—Гаиләбез тормышында бүген иң истәлекле көн. Һәм ул иң бәхетле көннәрнең дә берсе булсачы,—диде.—Таһир, син безгә Ходайның иң көтмәгән җирдән биргән бүләге. Бер Ходаем, алдына тез чүгеп, бил бөгеп сиңа табынган колың мин синең. Бу теләкләремне изге минутларыңа туры китереп безне мәңгегә туганлаштырсаңчы!

—Stop! Stop maschina!—дип туктатты аны Ногайбәк ага.—Син, әнисе, нечкә билем, капчыгыңда булганнарның барысын берьюлы чыгарып селкемә әле. Башта без кадерле кунагыбыз белән ирләрчә дуслашып өлгерик. Үзең күреп торасың бит, кунак егетебезнең тартынып утыруын бер рюмка коньяк кына җинә алмавын. Спортчылар теле белән әйтсәк, үлчәм категорияләре туры килми. Әйдә әле, Таһир улым, тагын берәрне тотып куйыйк.

—Әлбәттә, әлбәттә! Vorwarts!—дип куәтләде әтисен Данәгөл.—Югыйсә мин данлыклы Совет хәрби флоты матросларын идән астында үскән бәрәңге сабагы төсле хәлсезләр, төссезләр, кыюсызлар икән дип нәтиҗә ясарга да күп сорамам. Кунак егетебезне сыйлауны шушы минуттан тулысы белән үз өстемә алам.

—Баш өсте, кызым, баш өсте. Күптән вакыт,—дип аны әнисе дә куәтләде.

Кыскасы, әйткән сүзендә нык торып, Данәгөл аны кыстады, Таһир да идән астында үскән бәрәңге сабагы хәленә калырга тырышмады. Танышу,

көрешү, мохиткә ияләшү хакына Ногайбәк ага белән рюмкаларны да ярыйсы чәкештерделәр. Әмма, Франция ярларына дуслык визиты белән килер алдыннан, офицерларының «Үз-үзенне ничек культуралы тоту» буенча уздырылган әңгәмәләре бик ярап куйды әле ана. Тәлинкәгә турап куйган ипине чәнечке белән алуның бернинди калыпка сыймаслык культурасызлык, әдәпсезлек икәнен яхшы хәтерли. Юкса Чистай техникумында укыган чакларында чәнечкене бер кадау белән алдына берьюлы дүрт сынык кара ипине каптырырга күнеккән егет бит Таһир. Сул кулында крахмалланган тастымал аның. Бер кашык капкан саен әлеге тастымалны иреннәренә китерә, авыз кырыйларын сөртеп ала. Белмәгән, күрмәгән жиргә кунакка килеп, данлыклы Кара дингез хәрби флотына кызыллык китереп утырмас бит инде. Замполитлары, 3нче ранг капитаны Захаров өстәл артында Таһирның бүгенге тотышын күрсә, һич икеләнми «бишле» куяр иде. Алай гынамы? Таһирның үзен шулай күркәм, әдәпле тотышына СССРның Франциядәге гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе Трояновскийның да исе китәрие.

—Афарин, Туктамышев, син үзеңне профессиональ дипломатларга тиң тотасың!—дияр иде. Шундый кым-кырыс арада Таһирның башына шундый уйлар килеп торуын әйт әле син!

Ногайбәк ага кызарыбрак, тулыланыбрак, матураебрак китте. Ярыйсы бушый төшкән шешәгә ымлады:

—Бу затлы эчемлекне Бразилия ярларыннан килгән бер штурман бүләк иткәние. «Иң кадерле кунагыңны сыйларсын», дигәние. «Иң кадерле кунагымны көтеп мин аны биш ел сакладым.

—Биш кенә ел микән, әтисе?—дип аны Фәйрүзә апа куәтләде.

—Йә, ничек, Таһир улым? Кодрәте бар сыман. Анысын үземнән сизәм. Бераз шифасы бармы соң? Тартынып утыруың иркенәйдеме? Безнең тарафларга күнегә, ияләшә төшәсеңме? Әллә тагын берәрне тотып куйыйкмы?

Фәйрүзә апа:

—Шөһрәт, артыгын кыстама. Сезгә күбрәк булып куймагае,—дип, Таһир тәлинкәсенә тәмледән-тәмле ризыклар өюен белде.

—Әнием, бер дә күп түгел әле. Әтием башка чакны коньякны тел ачкычы дип мактый. Дөресме икән? Бу эчемлекнең бармы икән соң андый кодрәте? Чөнки аларныкы түгел, минем дә телем түгел, хәтта аның биге дә ачылмады әле,—дип Данәгөл барысын көлдереп алды.

—Басып алу, талау, кол итү нияте белән үз жирләренә аяк баскан Испания конкистадорларын Америка индеецлары «Төссез битлеләр» дип атаганнар. Минем битем дә нәкъ элекке, төссез хәлендә. Хәтта бит уртам да кызармады. Юкка төссез битле булу бүгенге политиклар, дәүләт эшлеклеләре арасында бик югары балл белән бәяләнә.

—Кызым, бүгенге мәҗлесебез көндәлек тормышыбызда моңарчы татымаган зур вакыйга, олы тантана, олуг бәйрәм булганга шулайдыр. Менә мин үземне дә түтәлдән генә өзгән кыяр төсле саф хис итәм,—дип җайлап кына әйтеп куйды Ногайбәк ага.

Өстәл этажында хуҗаларның тырышлыгы белән үзеннән-үзе туган жылы мөгамәләгә туры китереп, Ногайбәк ага үзенең тормыш юлын искә төшерде. Бүгенге Шөһрәт Ногайбәк хәленә басканчы Лаеш шулпасын күп шупырган икән. Унике яшьлек малай чагында, Идел буенда колхозлашу чорында барган ачлыктан качып, әтиләре бөтен гаиләсен Финляндиягә алып чыгып киткән. Анда да аларны колачын җәеп кем көтеп торган, диген. Кара сакалың кая барсаң да үзеңнән калмый бит.

Ногайбәк ага ваба чиреннән бер-бер артлы дөнья куйган әти-әнисен

Хельсинки зиратында жирли. Ят жирләрдә япа-ялгыз калган бу татар үсмеренен чит телләр өйрәнергә сәләте зур була. Кыска гына арада, базарга чыгып бәхәсләшерлек дәрәжәдә финчә, шведча, алманча гөрләтеп сөйләшә башлый. Ат караучы батрак булып ялланган үткен малайга мәрхәмәтле фин хуҗасы исәп-хисапчылар курсын тәмамларга булыша. Егет тиз арада бухгалтер һөнәрен үзләштерә, счет төймәсен биетеп кенә тарта башлый. Бик үткер, зиһенле, зирәк акыллы, баскан җиреннән ут чыгарып йөргән бу татар егетен фин хуҗасы үзенең олы кызына өйләндереп, кадерле кияве итәргә дә тели. Әмма егетнең күңеле башкада—кара каш, озын толым, нечкә билдә. Казаннан бергә чыгып, Хельсинкигә бер парахутта килгән озын Кадыйр кызы Фәйрүзәкәйдә аның күзе.

Ногайбәк ага «кһм», «кһм» дип тамагын кырып алды.

—Аш өстәлебез тулы ризык, өй эчебез тулы шатлык. Алайса, берне җырлап та биримче,—диде ул.—Әнисе, сиңа багышлыйм бу җыруымны. Ногайбәк ага матур тенор белән җырлап та җибәрде:

Карурманга кердем, ай, кич кенә,
Сандугач баласы-ла ай өч кенә, өч кенә.
Безнең җаныкайны сорасагыз:
Төскә чибәр, буйга кечкенә, ай, кечкенә.

Кош кына булып очар идем, ай,
Канат кына ясап булмайдыр, булмайдыр.
Сурәтләрең ясап куяр идем, ай,
Җанын кушып кына булмайдыр, булмайдыр.

Ашыйсың килсә, ай, шикәр кап,
Баллы шикәр йөрәк талдырмас.
Ярны сөйсәң, матурын сөй, ай,
Матур ярлар хәтер калдырмас, ай, калдырмас.

Бакчаларда гөлләр, ай, үсәдер,
Арасыннан былбыл үтәдер, үтәдер.
Сөйгән ярың матур, зирәк булса,
Гомерләрең рәхәт үтәдер, ай, үтәдер.

Табында тынлык урнашты. Келт, келт, келт. Каршы як стенадагы сәгатьнең генә гомернең һәр минутын зур төгәллек белән санап барганы ишетелә.

Бер дә көчәнмичә, бик матур тавыш белән, Фәйрүзә апа җыр башлады:

Өстенә лә кигән күлмәгеннең
Билгенәе тиң лә үзенә.
Иртәнгә дә кояш, кичке ай тик
Күренәсең лә минем күземә.

Кистем генә агач, булды кыйгач,
Эчләреннән чыкты сандугач.
Оҗмахларда үскән хур кирәкми,
Күз алларымда ла син булгач.

Берара янә тын утырганнан соң Фәйрүзә апа:

—Без кая гына барсак та үзебездән иске җыр китапларын калдырмадык. Борынгы җырларны җырлап шулай еш юанабыз. Таһир улым, чират

синдә. Туган якларыбызда халык жырлый торган яна жырларны жырлап күрсәтсәнче,—диде.—Отып калырыек.

Тайир ни дип әйтергә дә белми аптырап калды. Авылда чакта, механика мастерскоенда, трактор астында ятканда, үзе дә сизмәстән әллә нинди матур жырлар жырлап куя иде. Үзенә күрә тавышы да бар иде. Әмма «соло» жырларга туры килер дип башына да китергәне булмады.

—Булмый миннән. Кыймыйм. Оялам,—диде ул.

—Жыр ул егет күнелендә өзелеп сөйгән ярыннан аерылгач, башына кайгы-сагыш төшкәч, үзеннән-үзе туа. Тавышын да ачыла, моңы да килә,—диде Ногайбәк ага.—Ләкин андый хәлгә калырга язмасын.

Ногайбәк ага бик белеп әйткән икән. Егет күнелендә жыр эчке дөньясын сагыш баскач туа икән. Ул чакта Тайир анын бу сүзләренә игътибар гына итеп житкермәде.

—Шөһрәт, сон, сөйләп бетер инде. Суоми илендә күргәннәребезне. Матур ил ул. Әле дә сагынып искә алабыз,—диде Фәйрүзә апа.

***

—Финляндия—карлы-бозлы ил. Кеше аяк басмаган калын урманнары да, иксез-чиксез күлләре дә житәрлек. Озын кыш эчендә бердәнбер транспорт — ат кына. Яшь каеннан чана табаннары каерү остасы озын Кадыйр агайны финнар күтәреп кенә йөртмиләр. Берсенә мул итеп товар төярдәй йөк чанасы ясап бир. Икенчеләренә кунакка йөрердәй түрле чана кирәк. Кадыйр агайның әлегә эшләре бик көйле бара. Чана табаннары каеру буенча мастерской да ачып жибәрә. Тимер миче гөрләп янып тора. Мичкәләрдә су кайный. Ялланып эшләүче сигез егет чана табаннарын каерып кына торалар. Әмма бу дөньяга берәү дә мәңгегә килмәгән. «Бердәнбер кызымны үзем исән чакта ышанычлы кулга тапшырып калдыру мәслихәт гамәл булыр иде», дигән борчу төшә чана табаннары каеру остасы, вак фабрикант Кадыйр агай башына. Уналтысын тутырып унжидегә әле яна гына чыккан кызы Фәйрүзәне үзендә исәп-хисап эшләрен бик оста алып барган егерме ике яшьлек Шөһрәткә биреп, аны бик теләп кияве итә.

Куенында сөйгән ярын. Тормышнын арт ягына тибеп яшә. Юкса, кодрәтенне биреп, маңгай тиренне иренми түгеп, рәхәтләнеп мая тупла, байы. Юк шул. Сугыш башланып китте. Финляндия Германия яклы булып, үз жиренә немец дивизияләрен кертте. Фашистлар илдә террор урнаштырып, СССРга теләктәшлек белдерүдә гаепләп, Суоми илендә эмигрантлар хәлендә көн иткән русларны, шул исәптән Русиядән килгән башка халыкларны да эзәрлекли башладылар. Шул исәптән озын Кадыйр агайны да алып китеп утрауга яптылар. Имеш, шушы илдәге немец командованиесе өчен стратегик корал саналган чана табаннары каеруын, фабрикант хужасы, шуны яхшы белә торып, киметкән. Саботаж, янәсе. Кадыйр аганы тоткыннар лагереннан үпкәсенә нык салкын тигән, шешенгән хәлдә генә чыгаралар. Анын мастерское бөтенләй бөлгенлеккә төшә, ябыла.

Немецлар жинелгәннән сон, Финляндиядә яшәгән берничә татар гаиләсе бәхет эзләп Бельгиягә күчәргә ният итәләр. Аларга яшь кәләше белән Шөһрәт Ногайбәк тә кушыла. Ә бәхетне анда да берәүгә дә әрдәнәләп өеп куймаганнар. Әрдәнәдән үзенә ошаганын үрелеп кенә аласы түгел.

Ногайбәк ага шул елларда өстенә төшкән йөкнен бөтен авырлыгын жилкәсендә уйнаткандай, киерелеп, көрсенеп куйды.

—Бәхет дигән нәрсәне инде таптым, менә эләктердем дигәндә, кулыннан ычкына да куя. Күп сөйләдем бугай. Әллә, Тайир улым, тагын берәрне тотып куйыйкмы?

—Ул елларда кая карама эшсезлек. Адәм баласынын башы эт бәясе

тормый. Булмаган җиребез, күрмәгән михнәтебез калмады. Әле дә ярады, Ходай безне бер-беребездән аермады,—дип, Фәйрүзә апа иренең сүзен җөпләде.—Ә Данәгөлебез Алманиядә туды. Аның теле дә алманча ачылды. Өйләнә-тирән, мохитең гел алманнар булгач...

Фәйрүзә апа кырыйлары матур итеп кулдан чиккән алъяпкычын күзләренә япты:

—Данәгөлнең абыйларын, улларыбыз Нурулла белән Хәсбиулланы Бельгия белән Германия зиратларында җирләдек. Картлык көнебездә бердәнбер таянычыбыз—шушы кызыбыз инде...

—Күр, Таһир! О-О! Мин менә нинди ышанычлы таяныч!—дип Данәгөл күкрәкләрен киереп, мускулларын уйнатып куйгандай итте.

—Шөкер, бирегә килеп урнашканга да унсигез еллар бар инде,—дип дәвам итте Ногайбәк ага.—Марсель портындагы консуллыкта төрек, урыс, фин, гарәп, алман, инглиз, швед телләре буенча тылмач булып эшлим. Эшем әйбәт. Безнең Марсель—Урта диңгездәге ин зур портларның берсе. Караблар бик күп керә. Товар әйләнеше зур. Миңа да эш житәрлек, саулык кына булсын. Төркия карабын гына озатабыз, Бельгия, Канаданың йөк ташучы теплоходлары килеп житә. Ике арадагы сәүдәгә кагылышлы документларны эшкәртеп кенә өлгер. Эш сәгатеннән калып эшләсәң, капитаннар үзләре өстәмә түли. Башыңнан сыйпап, аркаңнан сөеп кенә торалар, чөнки бер генә сәгатькә алдан төялү яисә алдан бушатылу да аларга зур табыш китерә. Ничә ел эшләү дәверемдә күп карабларның капитаннары мине танып беләләр, портка аяк басу белән җәтрәк мине эзләп табалар. Кыскасы, Таһир улым, безнең монда яшәргә була. Әллә көннән-көн олыгаеп баргангамы, Казаныбызны гына сагынам менә.

—Адәм баласы михнәткә түзә, рәхәткә генә түзә алмый,—дип сүз кыстырып куйды Фәйрүзә апа.

—Анда хат салыр, сәлам җибәрер кешебез дә юк. Әмма үземне һаман Казан баласы саныйм,—дип дәвам итте Ногайбәк ага.—Кабан күле, Болак буйлары бүгенгедәй күз алдымда. Әйе, адәм баласы михнәткә генә түзә, рәхәткә түзә алмый ди шул китап. Рәхәткә түзә алмаудандыр инде бу сагыну.

—Сугыштан соң туган илгә кайту нияте белән дә йөргәниек,—дип сүзгә янәдән Фәйрүзә апа кушылды.

—Аны әйтүе генә җиңел,—Ногайбәк ага тамагын кырды.—Сугышта алган яра-җәрәхәтләрне бергәләп төзәтәсе урынга, Көнбатыш белән Көнчыгыш ике арага әнә нинди «Тимер чаршау» элеп куйды. Берсе артыннан берсе гайрәтлерәк хәрби союзлар калыктылар. Дөнья бер-берсенә ике лагерьга бүленде, ике як та котырып кораллана башлады. Китте атом-төш коралын берсеннән-берсе уздырып сынау. Мондый шартларда туган илгә кайту ниятең булуы турында берәрсенә әйтеп кенә кара: кайта да алмассың, монда да яшәтмәсләр. Әнә шул «Тимер чаршау»ны ертып, безгә дуслык визиты белән киләсегезне ишетүгә, бөтен Франциядә миңа миннән дә күбрәк шатланучы булдымы икән? Караблар белән көн саен эш йөртәм бит. Крейсер хәтле крейсер экипажында нужәли бер татар егете дә булмас икән дип баш ватам. Була калса, ничек тә үземә кунакка алам, туйганчы бер үз телебездә сөйләшермен дип үз алдыма бурыч куйдым.

Әдәпле зат икән командирыгыз. Ул минем халәтемне беренче сүземнән соң ук төшенде.

Каударланып, каушый-каушый гына житкергән гозеремне: «—Я понимаю Вас! Понимаю Вас»,—дип кенә тыңлады. Чак кына елмаюы да ни тора! Сине дә безгә берсүзсез җибәрде. Ул егеткә крейсер белән генә түгел, күптән инде эскадра белән командовать итәргә вакыт. Хәер, бу зур, бик почетлы урын аны күптән сагына булыр. Контр-адмирал, хәтта флот

адмиралы булыр көннәре алда әле ул чибәр җанның, һичшиксез булачак. Мин әйткәние диярсез.

Янә дә өстәп, кулын йодрыклап өстәлгә салып:

—Капитаныгыз гына түгел, сезне монда алып килгән крейсерыгыз да ошады миңа,—дип куйды Ногайбәк ага. СССР ның бөтен хәрби көче, дөнья җәмәгатьчелеге алдында какшамас авторитеты чагыла аның йөзендә. Якорьларын ике якка салып куйган, мин синайтим. Гавань уртасында утырса да, чайкалу түгел, селкенми дә. Кыя башына кунган горур бөркет кебек утыра ул анда. Аның тирәсендә чайкалган шхуналар, баркаслар йомычкадай гына.

—Баядан бирле шуны сорамак булам. Ә Сергей Киров кем соң үзе? Исемен флотның флагман карабына биргәч, гади генә зат түгелдер инде? Без, мондагылар, ике арага «Тимер чаршау» элеп куйганнан соң СССР турында хәбәрләрне аз ишетә башладык. Шулай бит, кызым?

—Сталинны беләбез,—дип җөпләде аны Данәгөл.

—Берлинны алган Жуковны. Ә Киров кем?

—Ул бик зур һәм бик дәрәҗәле дәүләт эшлеклесе булган.

—Булган? Хәзер исән түгелмени?

—Аны дошманнары атып үтергәннәр.

Фәйрүзә апа, хуҗабикәләргә хас беркатлылык белән:

—Сездә дә булып тора икән андый хәл-лә-әр,—дип куйды.

—Башка чакны агаң ул хәтле күп сүзле түгел ул. Бүген башы тәмам күккә тигән. Сине очрату шатлыгыннан. Сөйләсен, Таһир улым, син аны түзеп тыңлый күр инде. Сыйланырга да онытма. Кызым, сүзендә нык тор, сыйла кунагыңны,—дип, Фәйрүзә апа үзе дә кунакны сыйларга тырыша. Алдына бишбармак, пылау, Казан кабартмалары куя. «Аша, аша!»—дип кыставын белә. Шулай кыстагач, ашамый да булмый. Бу хәтле тәмле ризыкларны Таһир кайчан күргән диген. Әмма чаманы да онытып җибәрергә ярамый. Югыйсә шартлап куюың да бар. Әйе, сыйланунын да бер чиге була.

Хуҗалар да кунак егетләренең хәлен аңладылар. Ногайбәк ага кулындагы тастымалы белән иреннәрен, авыз читләрен сөртте:

—Нигә әле ашау белән генә булышабыз? Булмаса, өстәл артыннан кузгалып, бераз хәл җыеп алыйк,—диде.

—Әтисе, бик вакыт, бик вакыт,—дип, аның тәкъдимен Фәйрүзә апа да хуплады.—Истәлекле фотоларыбыз да күп. Әнә ничә альбом.

—Кызым, менә нәрсә,—диде хуҗа.—Кунак егетебезгә башта йорт-җиребезне, өй-каралтыларыбызны күрсәтеп кер. Бакчага алып чык. Авыл жирендә үскән егет бит. Җирне сагынгандыр. Карабында швабра айкап туйгандыр, кулына көрәк тоттыр. Берүк, кызым, алдыңа шундый максат куй, бездә булган һәр минуты Таһирнын күңелендә мәңге онытылмас матур хатирәләр калдырсын. Бөек Франция, Марсель каласы безнең икенче ватаныбыз. Булганына шөкер кылып, күрше-күләннән ким яшәмибез. Баш өстебездәге түбәгә, аш өстәлебездәге әлеге нигъмәтләргә—барысына без шушы мәрхәмәтле илгә бурычлы.

Данәгөл башына Таһирның бескозыркасын киде. Көзге алдына барып басты.

—Килешәме?—диде. Үзе үк:—Килешмәскә!—дип бәяләде. Әтисе алдына килеп үрә басты. «Тыңлыйм һәм берсүзсез буйсынам коры җир гаскәрләре контр-адмиралы кенәз Ногайбәк әфәнде!»—дип уң кулын чигәсе янына куйды, үзе Таһирга күз кысып алды.—Әгәр инде хөрмәтле кунагыбыз күңелсезләнә, карабын сагынып шыңшый башласа, мин аның колагын борырмын. Юк, борынын чеметеп алырмын. Бик авырттырып. Таһир, әйт, шыңшымассыңмы? Бәлки, борыныңны хәзер үк чеметеп куяргадыр? Профилактика өчен?

—Юк, юк, шыңшырга исəбем юк əлегə,—диде Таһир, борынын учы белəн каплап.

Уйламаганда, һич көтмəгəн жирдəн, вакыйгалар өере 1нче статьялы өлкəн матрос Таһир Туктамышев өстенə əнə ничек ишелделəр. Тайфун, цунами булып бит! Көчле дулкыннар ялгыз йомычка кисəген ничек бөтереп алса, ихтыярын юкка чыгарса, бу вакыйгалар да егетне шулай бөтерделəр. Синең иң башында бер генə түгел, берсеннəн-берсе акыллырак берьюлы биш баш утырса да, аларга бəя биреп, анализлап бетерешле түгел. Бер Таһир юклыктан гына крейсерда берни үзгəрмəс. Ныклы тормыш мəктəбе узган утыз-кырыклап өлкəн офицер, типсə тимер өзəрдəй матрос егетлəр телəсə нинди сынау алдында да югалып калмаячаклар. Алар бит 1нче ранг капитаны Соболь егетлəре! Капитаны исенə килүгə Таһирның йөзенə ирексездəн жылы елмаю жəелде.

Алай да карабта бүген эш муеннан булачак. Иртəнге якта экипаж егетлəре белəн якыннан танышырга Франция Коммунистик яшьлəр делегациясе килергə тиеш. Бу турыда алдан ук килешенгəн. Кабул итү программасында «Килəчəк безнең яшьлəр кулында» дигəн темага политик дискуссия дə булачак. Анда Таһирның комсомоллары да чыгыш ясаячак. Дискуссиядə катнашучылар Совет хəрби карабының үзешчəн, əмма бик талантлы художнигы, казакъ егете Жəгъфəр Калканбаев рəсемнəре белəн танышачаклар. Мондый тəкъдимне 3нче ранг капитаны Замполит Захаров кертте. Жəгъфəрнең рəсемнəрен бик килештерə ул.

—Службаң тулу белəн, Жəгъфəр Ленинградтагы Суриков исемендəге югары художество училищесына юлламаны үзем бирəм,—ди ул, егетнең яңа рəсемнəрен күргəн саен. Ə Жəгъфəрнең дулкынлануын сөйлəп бирешле түгел. Рəсемнəремне андый зəвыклы кунакларга күрсəтергə оялам, тартынам дип карыша.

Карабы, иптəшлəре, иртəнге көн турында уйлаганда, Таһирның күңел түре, көтмəгəндə генə кемдер кагылып киткəн гитара кылыдай зы-ы-ың итеп куйды. Совет хəрби матросларын Франция илчелегендə кабул итү тантанасында алар алдында чыгыш ясаган Марсель хореография училищесы кызлары да, мондый үзлəре бик чибəр, үзлəре бик əдəпле егетлəрнең хезмəт иткəн карабларын да барып күрергə телибез, дигəннəрие. Крейсерга алар да иртəгə килергə тиешлəр бит. Аны кат-кат чакырып биегəн күбəлəктəй жиңел кыз аеруча исендə калды Таһирның. Серле карашы, авыз чите белəн генə серле елмаюы, тал чыбыктай нечкə биле белəн...

Крейсер палубасына аяк басу белəн ул Таһирны сорар инде. Таһир аңа крейсерларының бөтен почмакларын, хəтта трюм төплəренə яшергəн «атом бомбаларын» да күрсəтергə ышандырганые. Таһир булмагач, сəерсенер инде. Ə үз караблары палубасында очрашудан соң, хат язышып торырга Таһир бу чибəркəйнең адресын сорамакчы иде...

«Булдым, күрдем, зур кунак булдым. Кунмыйча булмас. Ə менə иртəн бəлкем миңа карабка кайтып китəргəдер. Дуслар, иптəшлəр алдында да уңайсыз бит. Алар анда ут йота булырлар. Ə мин монда бəлеш бөклим. Хəл иттек. Иртəгə крейсерга кайтам!» дип уйлап куйды Таһир.

Кунак егете кинəттəн генə уйлар диңгезенə чумды бит əле. Тырышып-тырышып каршы як ярга колач салмак була. Чыгып житə алырмы? Карабын сагынып елап ук жибəрмəгəе.

Данəгөл книксен ясап, аны кулыннан алды, бакчага алып чыкты. Сука белəн дə, трактор белəн дə жир сөргəн егет лəбаса Таһир. Бер күз сирпү белəн чамалады. Алар чыгып баскан бакчаның мəйданы əллəни зур түгел. Күп булса биш-алты сутыйдыр. Əмма ялт иткəн. Жирдə сынык ботак кисəге дə юк. Таһир авыл хужалыгы техникумын тəмамлаган егет. Тиешле бəяне бирү өчен бакчага бер күз салу житте аңа. Бу бакчаны бик уңган-

булган, тәртип һәм пөхтәлек яратучы кешеләр карый. Чия, слива, йөзем куакларының артык ботаклары киселгән, төпләре йомшартылган. Аскы буйлары акшарланган.

—Әтием бөтен буш вакытын шунда уздыра,—диде Данәгөл. Беләсеңме, Таһир? Биредәге һәр агачның да исемнәрендә нәкь минеке төсле «Гөл» кушымтасы бар. Менә бу бөтен ботакларын төрле төстәге һәм зурлыктагы алмалар сарган агачның исеме Фаягөл. Бу каражимеш—Гөлшат. Әнә теге бераз картаебрак килгән чиябезнең исеме Назлыгөл. Ә менә Фаягөл ботакларында беләсеңме ничә төрле сорт алма үсә? Унике төрле!

—Ничек инде ничә төрле сорт? Гадәттә бер агачта бер сорт була. Мина агрономия дә беркадәр таныш.

—Юк шу-ул, хөрмәтле матросым. Фаягөл ботакларында унике төрле сорт. Ышанмасаң тотып татып кара. Әтиемнең кулы бик җинел. Ул һәр ботакка башка төрле сорт ялгый. Әнә, күр, төрле ботаклардагы алмаларнын зурлыгы да аерыла, тәме дә башка. Алай гынамы? Бу анын бик яраткан хоббие-шөгыле.

—Кызык! Чынлап торып бик кызык бит, әй,—дип куйды Таһир. Фаягөл исемле алмагачның төрле ботакларыннан берничә алма өзеп алды.—Төсләре, зурлыклары белән генә аерылмыйлар, хуш исләре дә һәркайсыныкы үзгә. Бу турыда ишеткәнем дә, укыганым да бар иде, ләкин бу әлегә алдынгы теория генә дип саный идем. Хәзер менә үз күзем белән күрдем. Әгәр дә гомер эчендә мина да бакча үстерергә туры килсә, үзем дә кулланырмын бу ачышны. Гаҗәп бит!

Данәгөл аны янә кулыннан алды:

—Тырышсаң, әгәр күңел салсаң, нигә үстермәскә. Безнекеннән күпкә матур бакчалар үстерерсең әле. Безнең Франциядә җир бик кыйбат тора. Ә сездә ничек? Таһир, синең үз җирең бармы? Синең гаиләң, якыннарың тамакларын ничек, кайда эшләп туйдыра?

Данәгөлнең бу соравын Таһир юньләп аңлап та бетермәде бугай. Авыл мәктәбендә укыган елларны еш кабатлаган: «Завод-фабрикалар—эшчеләрнеке, җир—крестьяннарныкы» дигән сүзләр күнеләнә килде. Аларның авылы Салкын Аланда җир бер тиен дә тормый бугай ул. Өй артларында утыз сутый чамасы бәрәңге бакчалары бар. Аны азсынсаң, әнә басуга утырт. Хет гектар җир ал. Бәрәңге жиренне сөрергә атың булсын да, төбендәге алабута белән чәнечкеле билчәнне утарга бер өй бала-чагаң гына булсын. Бөкрең чыкканчы азаплан, кыскасы. Алай да Данәгөлнең бу соравына:

—Җирем бар. Бар җирем, җитәрлек,—дип җавап бирде Таһир. Авыллары исенә төшкәч, йөрәге жу-у итеп китсә дә. Анда ни хәлләрдер инде? Әнисе билсез калган. Көзен ындыр табагында лабогрейка белән икмәк суктырганда биленә салкын тидергән. Сеңлесе Зөһрәне колхоз үгезе сөзгән. Юкса, колхозның иң алдынгы сыер савучысы иде. Хәзер нишли торгандыр? Ут йотып, ни авыр хәлдә яшәсәләр дә, әнисе хатка аларның барысын да язмый инде. Хат язып аны борчысынмени? Нигә языйм, ни дип баламны борчыйм, дия торгандыр.

—Алмаларны мин дә ялгый беләм,—дип, Данәгөл Таһирны бик еракка киткән уйларыннан аерды.—Телисең икән, Таһир әфәнде, хәзер өйрәтәм. Тик бер шарты бар. Бу эш иртә яз башында, агачлар кышкы йокыларыннан уянган чорда эшләнергә тиеш.

***

Бакчадан кергәч, Фәйрүзә апа янәдән чәйгә дәште.

—Кызым, кунагыбызга остаханәнне дә күрсәт инде,—диде Ногайбәк ага.—Таһир, диңгез күренешләре, бәлкем, туйдыргандыр да сине. Ә менә кызым аларны ясап туймый. Айвазовскийны да уздырып җибәрмәсә инде!

Таһир, залга керү белән, өй диварларын бизәгән берничә зур картинага күз салган иде. Дингезнең матур, сокландыра торган чаклары. Тәмам башын җуеп котырынган күренешләр дә бар. Аларны дингезне белгән, сөйгән, аның көч-кодрәте алдында баш игән талантлы кеше ясаган булырга тиеш. Бу картиналарның авторы менә кем, Данәгөл тоташ икән ләбаса.

—Остаханәгә сәфәр иртәгә,—диде Данәгөл, кырт кисеп.

—Ярар, ярар, кызым. Иртәгә дә өлгерерсез. Кунагыбызны талчыктырмыйк. Иртәгә дә көн бар, боерса,—дип Фәйрүзә апа кызының сүзен хуплады.

Таһир тиз сиземләде, бу гаилә патриархат кануннары белән яши. Гаилә башлыгының әйткән сүзе башта гомуми җыелышка куелып, аннары гына расланмый. Әйтелгән—мәсьәлә хәл ителгән. Хәер, тормыш эчендә күп тапкырлар сыналган, гаиләнең башка әгъзаләре тарафыннан ихтирам ителгән башлыкның, үз өстенә җаваплылык алып бирелгән күрсәтмәләре, ни дип әле дебатлар кузгатырга тиеш?

Тагын бер тапкыр тәмләп кенә чәйләгәннән соң, Ногайбәк ага авызкулын сөртеп, тастымалын өстәлгә салды:

—Йәгез, балалар, мондый тәмле аш-сыйдан соң бер дога!—диде. Таһир—комсомолец. Корабларында комсомол оешмасы секретаре. Монарчы догалар белән эш иткән егет түгел. Әле дә ярады, югалып калмады. Өстәл яныннан торып китәр алдыннан укый торган доганы кайсы татар баласы белми инде аны? Кем соң әби кочагында үсмәгән, ул догаларны әбисе авызыннан ишетмәгән?...

«Балам, бар ашаган ризыгыңны шайтан йотып бара күрмәсен. Бисмилланы әйтеп китәргә онытма» дип кайсы ана баласына ул догаларны өйрәтми инде. Биш кат пионер, биш кат комсомол, биш кат коммунист булса да, татар кешесе өстәл яныннан «әпәрен» әйтми китми инде. Татар баласы өчен монысы беркая язылмаган, әмма берсүзсез үтәлә торган закон.

Әлеге доганы Таһирның ничек итеп килештереп укыганын Ногайбәк ага колакларын торгызып тыңлап торды.

—Алай-й-й! Кыһым, кыһым. Совет яшьләрен динсез диләр. Безнең монда сезнең турыда ниләр генә сөйләп бетермиләр. Шул кадәресен белгәч, тагын ни кирәк?—дип канәгать калуын белгертте. Кунак егете авызыннан әлеге доганы ишеткәнгәме, аның кәефе күзгә күренеп тагын да күтәрелеп китте. Үзенә бер тәмле дәрт белән ике кулын уып алды.

—Иртәгә, кызым, өчәүләп балыкка барыйк әле без. Югыйсә кайчаннан бирле ышандырам, һаман җай чыкмый. Җәй эчендә тәмам симереп беткән кефаль, скумбрияләр су төбендә безгә үпкәләп яталардыр. Шәһрәт агай тәмам онытты безне, дип үзара зарланышалардыр әле.

—Ни булды безнең Ногайбәк агабызга?—дип борчыла булырлар әле. Картының сүзен Фәйрүзә апа күтәреп алды.—Дингездән генә тотып кайткан балыкны кыздырырга үземнең дә кулым кычытып тора әле. Узганындагын әйтәм, нинди зурларны тотып кайткан идегез.

—Әнисе, безне беләсең бит инде. Кызым белән нигә, нәрсәгә алынсак та, зурдан куптарырга яратабыз. Балыкны да шулай. Вак балык каба башласа, барыгыз, үсә торыгыз, дип кире дингезгә җибәрәбез. Ә син, Таһир, ничек? Кармак белән балык каптырырга хирысмы?—диде ул.

—Ашыт елгасы буенда үс тә, балык каптырырга яратма, имеш! Кытыршы тәңкәле алабугаларны, кызыл канатларны, хәтта беләк буе чуртаннарны да ярга тартып чыгарган чаклар күп булды.

—Оho-hо-hо! Беләк буе чуртаннарны!—дип елмайды Данәгөл.—Болай булгач, Адмирал, балыкчы икәненә ышанам. Иртәгә сынап та карарбыз.

—Ул чакта, балалар, иртәгә безгә иртәрәк топ-топ басарга туры киләчәк. «Суга барсаң, иртәрәк бар, соңга калсаң болгана...»—дип Ногайбәк ага

борын эченнән генә көйләп тә алды.—Димәк, башкайларны да йомшак мендәргә, «бай-бай»га иртәрәк салу хәерлерәк.

Суга барсаң иртәрәк бар, соңга калсаң болгана.
Жаның сөйгән ярың белән яшәсәң иде дөньяда.

—Бу җырны еш җырлап куябыз, Таһир улым,—дип җырның ахырын Фәйрүзә апай җырлап тәмамлады.

Таһирга урынны беренче каттагы үзе иркен, үзе аулак, чиста, саф һавалы, ярты өлеше пыяла тәрәзәле верандага җәйделәр. Диварларда, алтынга манылган матур рамнарда да диңгез күренешләре төшерелгән сурәт-рәсемнәр. Егетнең флотта хезмәт итүенә өченче ел китте. Карабта караватлар юк, ике-өч ярусл ы асылма ятаклар. Кара диңгезнең бер араны гына булса да тын калып, уйга чумган чагы бармы икән? Хәтта җилнең кабызган шырпыны сүндерерлек көче булмаган көннәрне дә. Якорьда торган карабыңны да бер көйгә чайкалдыруын, тирбәтүен белә. Бер көйгә сине дә бишектә тирбәлгән нарасыйдай тирбәтә. Башта егетләр бу тирбәтүгә күнегә алмый тинтерәделәр, йокысызлыктан интектеләр. Менә шулардай соң, шушы тәмле хуш исле мендәргә чумып, кош мамыгыннан сырган юрган астында яту бөтенләй сәер. Йоклап китеп тә булмас төсле. «Үзем монда булган белән, күңелем әллә кайларда», дигән җырдагы төсле, күзен йому белән янә крейсерлары исенә төште Таһирның. Анда ни хәлләр икән? Таһирны еш искә ала булырлар. Таһирның минер егетләре, Совет крейсерын күрергә килүчеләрне ярга чыгып каршы алырга, карабка хәтле озатып куярга тиешләрие. Крейсерны, совет матросларын күрергә яр буена кемнәр генә килсә дә, аның егетләре югалып калмаслар анысы. Минерлар отделениесе моңарчы крейсерда иң алдынгы бүлек булып саналып килделәр. Тик менә аның бу бер дә көтелмәгән ялы гына аның егетләрен бераз каушатып куймаса инде. Үзе теләп түгел бит. Каушамаска тиешләр...

Шундый уйлар белән үзен тәмам тынычландырып, Таһир инде йокыга талып килә иде.

—Тук, тук, тук!—ишек шакыдылар. Яткан җиреннән бераз күтәрелә төшеп Таһир:

—Мөмкин! Мөмкин! Рәхим итегез!—диде. Ишектә Данәгөл күренде. Аның өстендә бик матур затлы халат, аягында йомшак башмаклар. Кулында стакан.

—Бездә шундый тәртип, Таһир. Йокы алдыннан бер стакан җылы кефир эчәргә теләмәүчеләрне почмакка бастыралар. Минем үземә күп тапкырлар почмакта торырга туры килде. Ә син ничек? Карышмассың бит? Карышсаң, әнә, почмак буш. Әнием әйтүенчә, җылы кефирның файдасы бик зур. Ул безнең эчәкләрне йомшарта икән.

—Димәк, эчкә кергән азыкны үзләштерү процессы интенсиврак барачак,—диде Таһир үзе.—Йокы алдыннан бер стакан кефир эчәргә мин ике куллап «За!»

Данәгөл тулы йөзенә елмаеп, стаканны Таһирга сузды.

—Сүземнең баналь яңгыравыннан куркам, әмма сезнең кулдан мин бер касә агу эчәргә дә әзер,—диде Таһир.—Бу сүзләремне зинһар сүз уйнатуга саный күрмәгез.

Шулай диде дә, шушы сүзләрне ишеткән колакларына ышанмый, туктап калды. Аларны Таһир әйттеме соң? Мондый сүзләр аның авызына каян килде әле?

—О-о, Таһир!—дип бот чапты Данәгөл.—Кирәк чакта син комплимент эзләп кесәңне капшап тормыйсың икән. Хуплыйм. Активыңа бер очко

өстим. Егет кешене бизи торган сыйфат.

Бу минутларда янында утырып торган әлеге жан иясе Таһирга шул кадәр дә якын, үз тоелды ки, әйтерсең, алар бер-берләрен күп еллар буе белгәннәр. Озак еллар аерылышып торганнар да, менә хәзер бер-берләрен сагынышып күрешкәннәр. Шуны раслагандай, Таһир Данәгөлгә текәлеп, карашы белән бер көлтә нур, жылылык бөркеп карады. Шул ук вакытта, менә кул сузып кына учына алышлы, әлеге жан иясе аның өчен әле юньләп таныш та булмаган күк жисеме, метеоритмы, кометамы, әллә монарчы беркем тарафыннан ачылмаган планетаның үземе?

Таһир кече яшеннән шундый булды. Бер-бер бик кирәкле гамәлне кылганчы да, тегеләй итсәм ничек булыр, ә болай итсәм ничек килеп чыгар дип, фәлсәфә корырга яратты. Менә бу очракта нинди фәлсәфә инде тагын? Янында үзенне белгән хисләрдән башынны жуярдай гүзәл утыра. Ул инде күптән балигъ, хисләре ташып торган егет. Юньләп таныш булмаган күк жисеме дип торма, ал да куенына тык. Менә шундый чакта бераз гына кыюлыгын да булса икән. Ә монысы Таһирда бөтенләй юк. Алай да? Әлеге күк жисемен биленнән кочып алсаң? Нишләрие икән? Кит, жүләр! Акылындамы син, Таһир? Ярыймы соң?!

—Нишлисең? Оятсыз!—дип куйса? Шунда Ногайбәк ага килеп керсә? Беттем диген инде. Битенне ике кулың белән капла да, идәнгә тәгәрә. Дуңгыз икәнсең, дип орышып ташларлар. Сине командирыңнан шулай оятсыз кыланыр өчен сайлап алдыкмы, жир бит, диярләр. Жиде төн уртасында пыраклатып урамга куып чыгарырга да күп сорамаслар. Карабына кайтырга иртә житкәнне, таң атканны көтәсе дә калмас.

Данәгөл Таһирның юрганын төзәтте.

—Урының унаймы, адмирал? Тагын бер мендәр китермимме? Бишек жыры жырларга түгелме сиңа? Тәмле төшләр сиңа! Иртән сөйләрсең. Мин аларны бик оста юрый беләм. Берәр нәрсә кирәк булса, кыңгырау менә монда.

Инде верандадан чыккач, аның ишеген яртылаш ачып, Данәгөл янәдән:

—Тук, тук, тукран, тукылдатып утырам!—диде.—Советча тәрбия алган, тыйнак, әдәпле кунагыбызга симпатиям бермә-бер артты. Таһир, син гранит кыя төсле ышанычлы егет икәнсең. «Үзебезнең татар егетләре!» дип әтием бер дә юкка гына өзелми икән.

Берни аңламаган Таһир:

—Нидән чыгып мондый югары бәя бирәсең, матурым? Ихлас күңелдән булсаң, мин бик шат,—диде.

—Бу минутларда синең урыныңда безнең француз егетләре булсамы?! Ботакларында утырган асыл кошнымы?! Куеннарына бөтәрләп кенә тыккан булырларые. Синең белән, Адмиралым, дөм караңгы мәгарәгә дә курыкмый, шикләнмичә керергә була икән. Тыныч йокы, тәмле төшләр, Таһир!...

Менә сиңа мә! Данәгөлнең бу сүзләрен ничек аңларга тиеш соң ул? «Бөтәрләү» турында сүзнең булуы да мөмкин түгел. Ялгызым калдырма, тагын биш кенә минут булса да янымда утыр, дип үтенергә булган. Менә анысы кирәк иде. Ишетмәсәң, ишет, ике колагың тишек. Матрос Туктамышев башына гына сыешлы булмады аның бу сүзләре. Аларның төп мәгънәсенә чын гросс-адмирал башы да тиз генә төшенеп өлгерә алыр иде микән әле?...

*Ахыры киләсе санда*

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШКАН ТАТАР ӘДИПЛӘРЕ

## Маннур Саттаров



1920 елның 29 ноябрендә Татарстанның Кама Тамагы районы Абыз (Менгличево) авылында туа.

Башлангыч белемне туган авылында ала. 1936 елда Олы Карамалы урта мәктәбенең сигез классын бетереп, Казан педучилищесына укырга керә һәм аны 1938 елда тәмамлый. Бер ел Семипалат шәһәрендә башлангыч класс укытучысы булып эшли. 1941-45 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша, орден һәм медальләр белән бүләкләнә.

Беренче шигырьләре мәктәптә укыган елларында «Яшь ленинчы» газетасында һәм «Пионер каләме» журналында басыла. «Мылтыклы шүрәле» дигән беренче шигырь китабы 1982 елда дөнья күрә. Маннур Саттарның күпчелек шигырьләре «Чаян» журналында басылып чыкты һәм вакытлы матбугат битләрендә басыла килә, әсәрләре филармония һәм үзешчән сәнгать башкаручыларының репертуарларына кертелгән.

## Идрис Туктаров *(1896–1982)*



1896 елның 20 сентябрендә хәзерге Башкортстанның Благовар районы Булышлы (Балышлы) авылында туа.

Башта Беренче Бөтендөнья, аннары исә гражданнар сугышында катнаша.

1932-1935 елларда Идрис Туктаров—Казан дәүләт педагогия институты студенты. Институтны тәмамлагач, әүвәл Татарстанның Яшел Үзән шәһәрендә рабфакта һәм ФЗӨ дә укыта, аннары 1941-1943 елларда «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында корректор хезмәтендә була. 1943 елның маенда фронтка китеп, 1945 елның октябренә кадәр артиллерия гаскәрләрендә гади солдат була, Совет Армиясе белән Германия җирләренә кадәр сугышчан юл уза. Ул—өч сугыш ветераны.

Сугыштан соң Идрис Туктаров прозаик һәм тәрҗемәче буларак таныла.

## Сәхаб Урайский *(1907–1957)*



Сәхаб Урайский (Сәхабетдин Камалетдин улы Мәүлютов) 1907 елның 21 декабрендә хәзерге Ульяновск өлкәсенең Кече Кандал районы Иске Кызылсу (Татарское Урайкино) авылында туа. 1927-1930 елларда Самара шәһәрендәге татар-башкорт педагогика техникумында укый. Аны тәмамлагач, ике ел Урта Идел буе татар совет-партия мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта, ә 1932-1938 елларда Самарада татар телендә чыга торган «Колхозчы» исемле өлкә газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. Шул ук елларда

(1934-1936) ул СССР Язучылар берлеге һәм комсомолның Үзәк комитеты каршында ачылган әдәби курсларда укып кайта.

1938 елда Сәхаб Урайский Казанда «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасы редакциясендә эшли башлый. 1941-1945 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә һәм, автотранспорт батальонының сәяси житәкчесе буларак, сугыш хәрәкәтләрендә катнаша.

Сугыштан соң Сәхаб Урайский халыкта киң популярлык казанган жырлар ижат итә, шагыйрь буларак танылa.

## Әхмәт Фәйзи *(1903–1958)*



1903 елның 11 мартында Уфа шәһәрендә туа.

Әүвәл мәдрәсәдә (1911-1915) укый, аннары Уфадагы рус-татар мәктәбендә (1915-1917) һәм инкыйлабтан соң, 1917-1921 елларда, татар гимназиясендә (урта мәктәптә) белем ала. Гимназиядә укыган елларында үзенең беренче шигырьләрен һәм пьесаларын яза.

1928-1930 еллар арасында Әхмәт Фәйзи Мәскәү, Казан шәһәрләрендә, Татарстанның Арча төбәгендә матбугат һәм мәгариф оешмаларында эшли, ә 1931 елда Мәскәүгә күчеп, шуннан соңгы гомеренең күп өлешен профессионал язучы сыйфатында уздыра.

Ватан сугышы башлангач, Ә. Фәйзи үзе теләп фронтка китә һәм Волхов, Карелия, Дүртенче Украина фронтларында чыккан газеталарда хәрби хәбәрче булып хезмәт итә.

Сугыштан соң Әхмәт Фәйзи күренекле әдипкә әверелә.

## Демьян Фәтхи *(1906–1943)*



1906 елның 10 октябрендә хәзерге Ульянов өлкәсе Чардаклы районы Татар Колмаеры авылында туа. Башта үз авылларында укый, аннан Самара шәһәрендәге Татар-башкорт педагогия техникумында белем ала. Шунда укыган чагында шигырьләр яза башлый. 1926 елда Казанга килеп, татрабфакка укырга керә. Шул елларда ул көндәлек матбугатта актив язышa. 1929 елда инде аның «Тальян» исемле беренче шигъри жыентыгы, аннан соң озак та үтми, «Бояр урманында» (1930), «Металл тавышлары» (1931) дигән жыентыклары басылып чыга.

1941 елда ул фронтка китә. Сталинград янындагы сугышларда катнаша, берничә тапкыр яралана; совет гаскәрләре белән бергә, дошманны куа-куа, Украина чикләренә кадәр барып житә һәм 1943 елны Кантемирово (Воронеж өлкәсе) янындагы сугышларның берсендә батырларча һәлак була.

## Сибгат Хәким *(1911–1986)*



1911 елның 4 декабрендә Татарстанның хәзерге Әтнә районы Күлле-Киме авылында туа. Сугышка чаклы Татарстан китап нәшриятында балалар әдәбияты секторында мөхәррир, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында әдәби хезмәткәр булып эшли.

1942 елның маеннан хәрәкәттәге армиядә: әүвәл укчы взвод, соңыннан рота командиры сыйфатында Ржев яны һәм Курск тирәсендә барган сугышларда катнаша. 1944 елның язында Саратов шәһәрендә хәрби-сәяси курсларны тәмамлаганнан соң, 1945 елның маена кадәр Молдавиядәге чик буе гаскәрләренең округ хәрби газетасында инструктор булып хезмәт итә.

Сугыштан соң Сибгат Хәким күренекле шагыйрьгә әверелә.

## Мәхмүт Хөсәен *(1923–1993)*



1923 елның 15 апрелендә хәзерге Казакъстан Республикасының Көнбатыш Казакъстан өлкәсе Жанакала төбәгендәге Урда авылында туа. 1941 елда Кызылъяр шәһәрендәге татар урта мәктәбен тәмамлап, берникадәр вакыт пионерлар оешмасында тәрбияче, жирле газета идарәсендә әдәби хезмәткәр, «Экпенды» дигән сәнәгать артелендә мәдәни эшләр житәкчесе булып эшли. Сугыш башлангач та, үз теләге белән фронтка китәргә гариза бирә. Әүвәл аны Үзбәкстандагы Әндижан шәһәрендә тизләтелгән мөддәтле артиллерия училищесында укыталар. 1943 елның гыйнварыннан алып 1944 елның декабренә кадәр Мәхмүт Хөсәен башта взвод, соңыннан артиллерия батареясы командиры сыйфатында фронтның алгы сызыгында була, бернечә тапкыр яралана, шәхси батырлыклары өчен Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Мәхмүт Хөсәен танылган шагыйрьгә әверелә.

## Гали Хуҗи *(1912–1966)*



1912 елның 17 октябрендә Татарстанның Апас районы Карамасар авылында туа. 1932—1941 елларда «Кызылармеец» газетасында—әдәби хезмәткәр, республика яшьләр газетасы «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») идарәсендә—җаваплы сәркәтип һәм баш мөхәррир урынбасары, 1941-1942 елларда комсомолның Татарстан өлкә комитетында пропаганда буенча секретарь вазифаларын башкара.

1942 елда Гали Хужи үз теләге белән фронтка китә һәм сугышның ахырына кадәр Беренче Украина фронтында татар телендә чыккан «Ватан намусы өчен» исемле газетаның жаваплы сәркәтибе булып хезмәт итә.

Сугыштан соң Гали Хужи танылган шагыйрьгә әверелә.

## Афзал Шамов *(1901–1990)*



1901 елның 4 мартында Татарстанның Яшел Үзән районы Татар Танае авылында туа.

1919 елның декабрендә ул үз ирке белән Кызыл Армия сафларына баса. Башта ул татар кызылармиячеләрен укырга-язарга өйрәтә, ә 1920-1921 елларда Украинада акгвардияче Врангель гаскәрләренә һәм Махно фетнәчеләренә каршы барган Гражданнар сугышы хәрәкәтләрендә катнаша.

1931 елның мартыннан 1943 елның февраленә кадәр Казанда Татар дәүләт нәшриятының матур әдәбият секторында жаваплы редактор һәм өлкән редактор булып эшли. 1943 елның февралендә ул үзе теләп фронтка китә һәм Бөек Ватан сугышында хәрби газеталарның үзхәбәрчесе булып хезмәт итә, фронт матбугатында күпсанлы хәбәрләр, репортажлар, очерклар язып бастыра.

Сугыштан соң Афзал Шамов танылган әдипкә әверелә.

## Шамил Шаһгали *(1920–1987)*



1920 елның 9 июнендә Башкортстанның Чакмагыш районы Калмашбаш авылында туа. Яшьли ятим калып, балалар йортында тәрбияләнә. 1941 елның маенда Свердловск хәрби училищесына укырга китә. 1942 елның февраленнән ул—хәрәкәттәге армиядә: гвардияче рота командиры сыйфатында сугышларда катнаша, ике тапкыр яралана, Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы, III дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Шамил Шаһгали драматург буларак таныла.

## Сәет Шәкүров *(1917—1989)*



1917 елның 14 декабрендә Татарстанның Балык Бистәсе районы Балыклы Чүкәй авылында туа. 1934-1938 елларда Казан театр техникумында укый.

1942 елда ул армиягә алына, Ленинград хәрби ветеринария училищесында укый һәм фронтның алгы сызыгына җибәрелә. Германия җинелгәч, Көнчыгышта Япониягә каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, каты яралана.

Сугыштан соң Сәет Шәкүров драматург буларак танылу ала.

## Габдулла Шәрәфи *(1926—1997)*



1926 елның 29 июлендә Татарстанның Биектау (элекке Дөбъяз) районы Кече Битаман авылында туа.

Ватан сугышы башлангач, Габдулла Шәрәфи, укуын ташлап, эшкә урнашырга мәҗбүр була. Аннары—җиде елга сузылган солдат хезмәте. Ул Япониягә каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, совет гаскәрләре составында Монголия далаларын, Гоби чүлен, Хангал тауларын кичә.

Сугыштан соң Габдулла Шәрәфи прозаик буларак танылуга ирешә.

## Исмәгыйль Шәфиев *(1913—1943)*



1913 елда Башкортстанның Кыйгы районы Үрге Кыйгы авылында туа. 1935—1937 елларда Ерак Көнчыгышта армиядә батарея командиры булып хезмәт итә. Армиядән кайткач, Казан укытучылар институтында укый, соңыннан Татарстанның Сарман районы Зур Нөркәй авылына укытучы итеп җибәрелә.

Исмәгыйль Шәфиев көндәлек матбугатта басылган лирик шигырьләре белән сугыш алды елларында үзен өметле яшь шагыйрь итеп танытып өлгерә. 1941 елның язында ул Татарстан китап нәшриятына (ул вакытта Таттосиздат) бастырыр өчен үзенең беренче шигырьләр җыентыгын да тапшырган була, ләкин сугыш башлану сәбәпле, җыентык дөнья күрми кала.

Исмәгыйль Шәфиев Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә һәм лейтенант-танкист сыйфатында күп кенә сугышларда катнаша. Ул 1943 елның 17 сентябрендә Смоленск өлкәсенең Кузьмиченко авылы янында батырларча һәлак була.

Аның фронтта чагында язган шигырьләре фронт газеталарында һәм Казанда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы битләрендә басыла.

## Әхмәт Юныс *(1916—1976)*



1916 елның 15 октябрендә Татарстанның Кукмара районы Әсән Елга авылында туа. 1931 елда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, хезмәт эшчәнлеген башлый: башлангыч мәктәптә балалар укыта, мөдир булып эшли, 1935-1937 елларда Чиләбе өлкәсендә—укытучы, Донбасс шахтерлары арасында пропагандист була. Шул чорда эшчеләр тормышына багышланган беренче шигырьләрен яза.

Ватан сугышы елларында Әхмәт Юныс башта Апас районының Чүрибураш МТСы политбүлегендә эшли, аннары, армия сафларына китә, 1942-1943 елларда «Ватан намусы өчен» исемле фронт газетасы редакциясендә үзхәбәрче булып хезмәт итә.

Сугыштан соң Әхмәт Юныс шагыйрь һәм тәрҗемәче буларак таныла.

# «СӘЛӘТ»—СӘЛӘТЛЕЛӘРГӘ

*Татарстанның яшьләр белән эшләү һәм спорт министрлыгы каршында менә инде дистә еллар сәләтле татар яшьләренең «Сәләт» дигән оешмасы эшләп килә.*

*«Сәләт» шагыйрь һәм галим, яшь буынны тәрбияләү өлкәсендә зур җәмәгать эшлеклесе Җәүдәт Сөләйман проекты һәм җитәкчелегендә соңгы елларда татар яшь талантларын тагын да үстерү, аларга яңа иҗади мөмкинлекләр ачу максатында бик күп чаралар үткәрә. Нигездә бу чаралар җәй көне, татар халкы тарихында атаклы урын тоткан җирләрдә тәрбия һәм ял, иҗади остаханә рәвешендә яшьләр лагерьлары итеп оештырыла. Шушы лагерьларда яшәү чорында яшь сәләтләр белән бик күп тәрбия, иҗади остаханә, сәламәтлек ныгыту чаралары үткәрелә. Анда спорт залларыннан алып зур әдәби-сәнгати әһәмияткә ия булган, бөтен сәләтле яшьләр дә катнашкан, табигатьтә үткәрелә торган театраль күренешләр аеруча игътибарга лаек. Журналда тәкъдим ителә торган «Кыйбла» әсәре әнә шул зур театраль чараны үткәрү өчен язылган әдәби сценарий итеп иҗат ителгән. Табигатьтә үткәрелә торган әдәби, сәнгати, милли, театраль чара буларак «Кыйбла» сценарие зур максатлар куя торган талантлы әсәр. «Сәләт» оешмасының изге һәм файдалы эшен күрсәткән бу әсәрнең «Сәләт» проектының аерылгысыз өлеше икәнлеген ассызыклап әйтәсе килә.*

*Киләчәктә бу әсәр аерым китапчык итеп зур тираж белән басылып чыкса, аны Россиядә һәм Татарстаныбыздагы яшьләр лагерьларына таратырга мөмкин булыр иде. Яшьләр оешмалары аны, театрлаштырып, үз чараларында файдаланырлар иде.*

**Гәрәй РӘХИМ,**
*Татарстанның Г. Тукай исемендәге*
*Дәүләт премиясе лауреаты.*



# Сөләйман

## КЫЙБЛА

БИЛӘР[1] ДАСТАНЫ

*Күк Тәңре[2], Җир-су, Умай[3]!*
*Көч иңдер, Куәт иңдер!*

*Балалар Хуҗалар Тавы[4] итәгендә, Изге Чишмә[5] тирәсендә — төркем-төркем урнашып тыңлыйлар. КЕРЕШтә «Дөнья яратылу» күренеше: ерактан, күктән, чак кына сизелерлек, тын гына, салмак кына көйле тавыш килә: А-а-алә-әм, А-а-ал-ә-м, А-а-алә-әммм...*

*А-а-аалләә-әәминнн... Тавыш көчәя бара. Шул фонда Сөләйман[6] сүз башлый. Күктән килгән тавыш шулай ук әкрен генә ерагая һәм югала. Күктә Коръәндә язылган, мәгънәләре аңлатылмаган хәрефләр теземе (рун, гарәп, кирилл, латин әлифләрендә) күренгәләп тора: АЛМ, С, АЛМС, АЛР, АЛМР, КХЙ'АС, ТХ, ТСМ, ТС, ЙС, С, ХМ, 'АСК, К, Н. Хәрефләр, сүзләр көйле бер фон тудыра, Сөләйман шул фонда сөйли.*

**Кереш**

**Сөләйман:**

**Әлеф-ләм-мим[7]—**
**Аллам!**
**Тәүге сүзең—Аләм.**
**Чиксез галәм—тәүге хасиләт*.**
**Бисмиллахи рахман иррахим,**
**Әлһәмдуль илләһи**
**Раббиль галәмин[8].**
**Иңсен күктән изге хасият*.**
**Һәр йолдызың—**
**изге сүзгә мөнбәр*,**
**Җир бакчаңда кырлар-болыннар,**

* тәүге хасиләт — иң элек хасил булган (яралтылган), иң элек бар булган нидер, нәрсәләр
хасият — игелек, изгелек
мөнбәр — трибуна

Җәүдәт СӨЛӘЙМАН (1955) — *шагыйрь, галим; «Мин минсез дөньяда», «Казык», «Кизләү» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт һәм М. Җәлил премияләре лауреаты. ТФА академигы. Казанда яши.*

**Хакыйкать вә мәхәббәтең чәчеп—**
**Рәхмәтләме Сиңа балаңнар?**

**Бу язмалар түгелдер сер эзләү,**
**Җиһан серен, Тәңрем, беләлмәм.**
**Йомгак очын эзлим-ялгыйм диеп,**
**Кәлам* суза фәкыйрь Сөләйман.**

**Кем мин—татар,**
**кемнәр каны миндә?**
**Кемнәр җаны миңа үрелгән?**
**Аждаһадан[9] —канат, Барыс[10]—холкым,**
**Яшәү дәртем минем—Бүредән[11].**

## 1 өлеш

*Хуҗалар тавы. Төн. Кошлар сайравы. Ара-тирә кәккүк авазы яңгырый. Төрле яклап Ияләр тавышы ишетелә башлый. Аерым-аерым да, берьюлы да. Төрле-төрле шәүләләр. Агачлар арасында ухылдау, елга буенда су чәчри, яр буйлап ут өермәсе... Бер якынаеп, бер ерагаеп Кам[12] барабаны тавышлары, шул якта шәүләләр уйный, адәм заты шәүләләре дә чагыла. Яфракларны шомлы шаулатып, вакыт-вакыт йә кискен, йә салмак кына җил исеп куя. Җил тавышы көчәя бара. Ияләр тынып кала...*

**Җ и л :**

**Чү! Хуҗалар! Ия-рухлар!**
**Ш-ш-ып! Бер мизгел түзегез-з!**
**Халык җыелган аланга,**
**Күрсен күңел күзегез!**

**С ө л ә й м а н :**

**Бөек Күкләр йомышчысы,**
**Иялэр дусты—Ил-кам[13].**
**Тукта берсәк* камлавыңнан*—**
**Замана суга тамтам*!**

*Барабаннар. Яктырткычлар халыкны яктыртып-күрсәтеп ала. Ара-тирә Иялэр нәрсә хакындадыр бәхәсләшеп—шаулашып ала. Сүз башлангач тавышлар салмак кына югала.*

*Сөләйман Аланга җыелган халык белән таныштырып үтә. Үзләре турында ишеткәч һәр төркем җанланып ала, күңеленә тулган хисләрен белдерә—кычкырыпмы, сызгырыпмы—җаннары кушканча.*

**С ө л ә й м а н :**
*Скифлар[14] төркеменә мөрәҗәгать итеп:*

**Скиф иленнән килгән халык,—**
**Сез—татарның тамырлары!**
*(Скифлар: Урра! Скиф—Иске Өв! Борынгы Йорт!)*

---

* кәлам – сүз,сөйләм

берсәк (миш.) – әз генә,әзгә генә (бер сәк – секунда – сек-ун[д]а (уно – бер): шул ук бер тамыдан түгелме икән?)

камлау – рухлар белән аралашу хәленә,халәтенә керү ритуалы (тамыры: Кам – рухани)

тамтам – бәрмә музыка коралы,зур барабан,гонгның бер төре

*Һун-Сөннәр төркеменә мөрәҗәгать итеп:*

**Һун–Сөн[15] халкы илчеләре—**
**Сездә—татар Бәгырьләре!**
*(Һуннар: Урра! Һун-Сөн! Яшәсен!)*

**Атилладан[16] килгән төркемгә мөрәҗәгать итеп:**
**Сез татарның үзәгеннән—**
**Дәште–кыпчак[17] вәкилләре!**
*(Кыпчаклар: Урра! Дәште-Кыпчак—Атилла!)*

*Күк Түркләр[18] төркеменә мөрәҗәгать итеп:*

**Татар канлы, татар җанлы**
**Бөек Күк Түрк ул–ирләре!**
*(Күк Түркләр: Урра! Күк Түрк! Күк Тәнре!)*

*Болгарлар[19] төркеменә мөрәҗәгать итеп:*

**Биләр халкы, Болгар халкы!—**
**Сез татарның Йөрәгендә!**
*(Болгарлар: Урра! Биләр—Болгар! Биләр—Болгар!)*

*Урдадан килгән төркемгә мөрәҗәгать итеп:*

**Алтын Урда[20]—Алтын Бишек!**
**Яши татар күңелендә!**
*(Урда илчеләре: Урра! Алтын Урда—Алтын Бишек!)*

**Күз яшьләрен, моң–зарларын**
**Әле бүген тойгансыман!**
**Казан ханы илчеләре—**
**Бөек Казан каласыннан!**
*(Казан ханлыгы[21] илчеләре: Урра! Казан ханлыгы!)*

*Сәлкешләр төркеменә мөрәҗәгать итеп:*

**Җиде өлеш—җиде кисәк,**
**Ул—бер бәгырь, җиде дәүләт,**
**Җиде дәүләт тажы булып—**
**Кыйбла булып үсә—Сәләт[22] !**
*(Сәлкешләр: Урра! Сәләт—Кыйбла! Сәләт—Дәүләт!)*

**Сөләйман:** *(барча халыкка мөрәҗәгать итеп):*

**Бу мизгел гади түгелдер!**
**Ун гасырга бер генә!**
**Татар рухы, канатланып,**
**Кайтты Биләр җиренә.**

**Җиде дәүләт илчеләре**
**Җыен тота мәйданда.**
**Кайда кыйбла? Саумы бәгырь?**
**Бармы өмет баланда?**

**Татар хәлләрен кем әйтер,**
**Узып Хуҗа–рухлардан?**

**Татар рухын кем җиткерер**
**Кыйбласыз оныкларга?**

**Җиде дәүләт күген күргән—**
**Җиде кат корган күген,**
**Күк Иясе, Тәңре кушып,**
**Биләрдә кунак бүген!**

**Күк иясе:**

**Җиде дәүләт күген күрдем**
**Җиде катлы күкләрдән.**
**Җиде күкләр—изге китап,**
**Утлы**
**йолдыз-сүзләрдән!**
**Халык эзе—өзелмәс җеп**
**Күккә ашкан җаннардан,**
**Өмет тулы изге аһәң*—**
**Сезгә Тәңре-Алладан.**

**Сөләйман:**

**Җыен тулы булмас иде,**
**Җил иясе килмәсә,**
**Күргәннәрен, белгәннәрен**
**Безгә сөйләп бирмәсә.**

**Җил:**

**Җи-и-ил җил җил-л-л мин,**
**Җи-и-л мин, җил мин.**
**Җил-җилбезәк, җил-давыл да,**
**Мин—күп йөзле, күп кыллы.**
**Кемгәдер йомшак канат мин,**
**Кемнеңдер соңгы тыны...**

**Күк иясе:**

**Җилләр исә, җилгә—җилләр кыйбла,**
**Курай тишекләре—йолдызлар...**
**Галәм көйли—җилләр хәбәр сөйли,**
**Татар моңын суза кубызлар.**

**Җил:**

**Хәтта мин анык әйталмыйм:**
**Кайдан төрки яңгыры?**
**Ул заман каян иссәм дә**
**Күрдем төрки яугирен...**

**Сөләйман:**

**Ияләргә хуҗа Ия,**
**Тау иясе—карт Корык[23],**

* аһәң—моңлы тавыш, яңгыраш, моңлы аваз

**Биредә ул—баш Ия бит,**
**Алкышлыйк, каршы алыйк.**

*(Барча халык: Тау иясе! Тау иясе!)*

**Тау иясе:**

**Тау иясен чакырдыгыз,**
**Сүзем минем шул булыр,**
**Иңнәремдә күк капусы,**
**Бәгырем аһ-зар тулы.**

**Кайчакларда мин, Корыкны,**
**Кырыс диләр, усал диләр,**
**Иң юаш зат булыр идем,**
**Үз хәленә кайтса Биләр.**

**Сөләйман:**

**Яр иясе—яр буеннан,**
**Ул да безнең җыенда.**

**Яр иясе:**

**Күрсәм иде Биләр таңын**
**Яр буеннан, уенда.**

**Ярга килде газиз халкың,**
**Мин йоттым күз яшьләрен,**
**Ярга ятты газиз халкың,**
**Мин сакладым эзләрен.**
**Тирбәдем Биләр тәхетен,**
**Тараттым аһ-зарларын,**
**Тузып барган ташларыма**
**Кайтыгыз, балаларым,**
**Кайтыгыз, балаларым...**

**Җил иясе:**

**Бөек иде бу халык,**
**Горур иде бу халык,**
**Җиде күктән куәт алып,**
**Җиде ил корган халык.**

*(Сөләйман сүз башлагач, тавышлар тына)*

**Сөләйман:**

**Әй, Хуҗалар! Ия-рухлар!**
**Тоясыздыр—тантана!**
**Җиде дәүләт—җиде субай,**
**Нигез—татар халкына.**

**Татар варисы (бала):**

**Җиһан ир син, Атилла!**
**Үлемсез кыпчак бабам!**

**Ул бит синең замана,**
**Ул бит минем замана,**
**Ул бит безнең замана!**
**Шушы чордан күңелемдә**
**Татар таңы аллана...**
**Әйтче, Атилла бабам,**
**Юл күзләгән балаңа,**
**Кайда булды илгә кыйбла**
**Син яшьнәгән заманда?**

**Атилла:**

**...Һәй, бәгъре исән татар!**
**Һәй, огълан, ерак балам!**
**Мин синең кыпчак бабаң!**
**Бишенче йөз—далада.**
**Бу заманнар—җирдә—**
**кыпчак!**
**Бөркет—хуҗа**
**һавада!**
**Мәшрикъ-Мәгърип* арасында**
**Ялгап күккә ялларын,**
**Очты атлар, төрки аты—**
**Таратып чиксез далага**
**Һун-кыпчак хыялларын.**

**Бу заман каян баксаң да—**
**Төбәлде күзләр Миңа!**
**Дәүләтем—дөнья үзәге,**
**Мин**
**үзем**
**идем—**
**Кыйбла!**

**Ияләр (барысы бергә)—**
**Күк иясе: Бөек иде бу халык,**
**Җил иясе: Горур иде бу халык,**
**Тау иясе: Җиде күктән куәт алып,**
**Яр иясе: Җиде ил корган халык.**

**Яр иясе:**

**Алтын Урда—Олы дәрья,—**
**Йөзләп халык—елга,**
**Татар булып туды шунда**
**Төрки-кыпчак-болгар.**
**Дәрьяларны диңгез итте,**
**Диңгезләрне—дәрья.**

**Күк иясе:**

**Җирдә—Чыңгыз чоңгыллары,**
**Оя арты—оя!**
**Дәште-кыпчак далаларын**
**Текте күкрәгенә.**

* мәшрикъ-мәгърип — көнчыгыш-көнбатыш

Бизәк чикте Урда-илгә
Болгар җепләреннән...

**Тау иясе:**

Нигезләре тирән, тымат* булгач,
Ник соң тузды йортың, и татар?
Ник соң шулай җир-су, кыйбла диеп,
Болыт булып, һаман шул аһ-зар?

**Сөләйман:**

Җиде дәүләт бер үк язмыш күрде,
Үзе кыйбла булды һәр дәүләт.
Татар йорты үсә-туза торды,
Бер—җәһәннәм булып, бер—җәннәт...

**Җил иясе:**

Табигатьтән иңгән самимилек,—
Әйткән сүзне—
аткан ук диде.
...Күршесенең чуклы сүзләреннән
Ил башына йөгән хуш килде.
Туган белән туган арасына
Ат кылы да сыймый дигәндә—
Төтен булып керде дошман-шымчы...
...Татар һаман шул ук биләүдә...

**Сөләйман:**

Гади булды, артык гади булды,
Үзәгендә иде самимилек—
Гөлчәчәк тә чәнечкесе барга
Үсә бит ул затлы гөл булып.
Татар горур, татар тырыш, саллы,
Күңелдә—дәрт, сөю—йөрәктә!
Халык булып мәңге яшим дисәң,
Чәнечкеле дә бул син—кирәктә!

**Җил:**

...Ш-ш-шанлы Биләр,
Бөек Биләр—
Гүя Коръән сүрәсе.
Саф Чирмешән[24] суларында
Унынчы йөз шәүләсе...

## 2 өлеш

*Иялəр уйный, көлешә. Инде шомлы түгел, дустанә.*

**Нәркис:**

Чирмешән борма-борма,
Су Иясе, син кайда?

* тымат—миш.: нык, таза

**Чишмә иясе:**

**Тау битендә чылтыр-чылтыр,**
**Мәхәббәт Алиһәсе,**
**Мин—былбыл да, тал-чыбык та,**
**Изге Чишмә иясе.**

**Ай кызы килгән суга,**
**Челтер-челтер таңкәсе,**
**Тау битендә ай юлы—**
**Таңчулпан көянтәсе.**

**Кызлар:**

**...Без-без без идек**
**Без унике кыз идек,**
**Базга төштек, май ашадык,**
**Келәткә кердек—бал ашадык,**
**кара сыерның каймагын**
**кап та йот—**
**Һоп!**

*(Көлгән тавыш):*

**Хи-хи-хи-хи!**

**Кызлар:** *(дәррәү көлгән тавышлар):*

**Хи-хи-хи-хи! Хи-хи-хи-хи!**
**Хи-хи-хи-хи!**
**—Нәркис, Нәркис оттырды!**
**—И Нәркис[25], гүзәл наный!**
**Көлешми-серләшмичә**
**Бер мизгел түзәмени!**

**—Әйдәгез, кызлар, суга!**
**Нәркис куучы була!**

**Хи-хи-хи-хи! Хи-хи-хи-хи!**
**Хи-хи-хи-хи!**

*(елгада су чәчрәгән тавышлар...)*

*Су сибешеп бию (кызлар биюе).*
*(Бию вакытында фон итеп салмак кына үтемле тавыш белән түбәндәге текст яңгырый)*

**Сөләйман:**

**Бу риваять Биләр заманыннан,**
**Биләр кыйбла булган чорлардан.**

**Тау иясе:**

**Тау башында Мәрҗән[26] шәһәрендә**
**Гомер итте хаҗи Тырышмал[27].**
**Кызлары да үсте,**

көлүләре
Йөрәккә май булды, җанга—бал.

**Җил иясе:**

Уникe кыз үсте энҗе-мәрҗән булып,
Уникe ай җирдә—берьюлы.
Һәр үткән көн—шатлык тулы дәрья,
Һәр аткан таң—бәхет каюлы.

**Яр иясе:**

Уеннарда тиңсез иделәр,
Биесәләр—аккош сокланды.
Җырларына гүзәл кызларның
Сандугачлар кушты моңнарын.

*(бию тәмамлана)*

**Су иясе:**

Уникe кыз су буенда—
Йөзләре—кояш-айдан,
Уникe кыз—йолдыз-йолдыз,
Ияләре соң—кайда?

**Нәркис:**

Су иясе—ник тиясең,
Егетем бар, кит-кит!
Нечкә бил сиңа түгел,
Су булып читкә сибел!
Чәч бөртеге—бер чара,
Коткарса—шул коткара.
Сиңа миннән алтын чәч,
Су Иясе, мә,—Ядә-ә-әч!

**Тау иясе:**

Уникe бөртек энҗе—
Берсеннән-берсе чибәр,
Уникe бөртек энҗегә
Йолдызлар гашыйк диләр.

**Атилла:**

...Йолдызлар гашыйк диләр дә,
Кайда соң егет-бийләр?

**Тау иясе:**

Сөюдән күпләр җүләр,
Албасты аулый диләр,
Әнә, аудан кайтып килә,
Җырлый-җырлый, мәҗнүннәр.

*(«Бөрлегән» җыры көенә тиз темпта, житез, сугышчан—татар егетләре биюе)*

**Унике кыз:**

Без-без-без идек,
Без унике кыз идек...

Күк йөзендә йолдызлар,
Карагыз, егет-кызлар,
Унике йолдыз, ул—без,
Иң яктысы—күрегез!

Әйдәгез, бер күрешик,
Нурга-кул һәм кулга-нур!

**Тау иясе** *(Сәлкешләргә мөрәҗәгать итеп):*

Әй, егетләр, кызлар!
Күпме гасыр
Көттек сезне, сез килгәнне бире.
Кулга-кулмы? Әйдә! Булыйк бергә!
Фатыйхасын бирә Биләр җире!

*(Яшьләр кулга-кул тотынышып, кулларын күккә сузалар)*

**Ияләр** *(барчасы—яшьләргә):*

Сез—хуҗалар Болгар-Биләр-җирдә,
Хуҗа булып алга үтегез!
Изге Чишмә сезне күптән көтә—
Суларыннан авыз итегез.

*(Балалар-яшьләр Изге чишмә суларыннан учлары белән авыз итәләр)*

**Сөләйман:**

Җир ананың изге күкрәгеннән
Саркып чыга сафлык, чишмә булып.
Татар балалары, татыдыгыз
Ана сөте сыман чишмә суын.

**Яр иясе:**

Әйтер идем, ярдан китә күрмә,
Адашырсың, диеп, и бала!
Әмма беләм—тамырың ярда булса—
Җан җепләрең күккә чорнала.

**Күк иясе:**

Күктә—ирек, күктә чиксез киңлек,
Иң якын җир күккә—тау башы.
Әйдә, татар, әйдә биеклеккә,
Синдә бүген Тәңре карашы.

**Җил иясе:**

Әйдә, татар, әйдә тау башына,
Биеклеккә юллар текә ул.

**Җил-давыллар чыга калса җирдә,**
**Дөнья карабына җилкән бул!**

**Тау иясе:**

**Чишмә суы изге тамырлардан—**
**Сез шул судан авыз иттегез.**
**Безнең белән бергә, хуҗа булып,**
**Тау башына рәхим итегез!**

## 3 өлеш

*Тау башында. Балалар истәлекле таш тирәсендә. Еракта алмагачлар, куаклар, агачлар—анда тормыш кайный, барча күренешләр. Шәһәр, манаралар. Аерым бер җирдә ярым-айлы Алмас-хан[27] төрбәсе. Тирә-як яхшы күренә, сөйләнгән күренешләр мөмкин кадәр шул куаклыкларда, кырларда, күктә, урманлыкта чагыла.*

**Сөләйман:**

**Җил-җил**
**җил исәдер лә,**
**Җир-җир**
**җир оча бирә,**
**Чор-чор**
**чор үтәдер лә,**
**Чаң-чаң**
**чаң суга йөрәк.**

**Гасырга-гасыр ята,**
**Гавам имтихан тота,**
**Файдалан бу форсаттан—**
**Кыйбланы барла,**
**татар!**

*(тирә-якта зур жиде учак кабына)*

**Татар варисы (бала):**

**Болгар-иргә ни кирәк?**

**Алмас хан:**

**Болгар-иргә Ил кирәк,**
**күңелгә—Канун кирәк,**
**Җан аша кергән канун—**
**көчле илгә шул терәк.**

**Бала:**

**...Әй, бабам син, Алмас хан,**
**хәнҗәр, җәнҗал алмас хан.**
**Иң бөек эш ни булыр?**

**Диде бөек Алмас хан:**

**Иң бөек эш шул булыр—**
**Гауга, бәхәсләр тыныр,**

**Биләр—Пайтәхет* булыр.**

**Бала:**

**Иң тугъры эш ни булыр?**

**Алмас хан:**

**Иң тугъры эш шул булыр,**
**Биләр-йортта таң туыр,**
**Сәбәбе—Ислам булыр.**

**Бала:**

**И мәгърур болгар бабам—**
**Уйларың авыр, тоям.**
**Кальбеңдә* төрки тамгасы,**
**Төрки катламда ояң.**

**Ислам гөмбәзе тимәсме**
**Төрки җепселләреңә?**
**Төрки тамыр киселмәсме**
**Ислам шәкелләреңдә?**

**Алмас хан:**

**И балам, аңлыйсыңдыр,**
**утлы дәва бу.**
**Көмеш йөгән**
**мәгъруp Болгар баласына.**
**Әмма бүген**
**Дин дә түгел,**
**Ден дә түгел,**
**Сайлау бара—**
**Яшәү белән**
**Үлем**
**арасыннан...**

**Сөләйман:**

**«Алла бөек!», «Аллаһе акбәр!»—**
**Җир тетрәде алкыштан,**
**Ислам нуры Идел-йортта,—**
**Нишан басты Алмыш-хан.**

**...Алмас әмир төрбәсенә Ай үзе кунган сыман,**
**Дәвам итте олы туй—Болгар-ил туган заман.**

*(Күренешләр, мөмкин булган кадәр, ерактагы куаклыкларда чагыла)*

**Алмас хан:**

**...Кызыл Таудан[28] баккан идем,**
**күрдем сихри манзара:**

* Пайтәхет – башкала: пает (миш.) тәхет, түбә тәхет, ягъни башка тәхетләрне (калаларны) үз түбәсе (яклавы) астына алган тәхет (кала).

кальбең – йөрәгең

**Бер-бер артлы, өч тәсбихтай,**
**Ап-ак чәчкәдә—кала.**
**Затлы тәсбихлар теземе—**
**Кала тирәли үрләр,**
**Тәсбих төймәләре булып—**
**Акбүзатта яугирләр.**

**Бу шәһәр генә диярсең—барча дөнья сыйган,**
**Бу дәүләт кенә диярсең—куәт салган җиһан.**
**Сәүдә юлы үзәгендә Бөек шәһәр—Биләр,**
**Мәшрикъ-мәгъриб кисешендә кыйбла шәһәр—Биләр!**

*(Еракта БАЗАР күренеше, туар* кыстау авазлары (..ефәк, ефәк..., ат сатам, ат... алка—йөзек—беләзек..., алка—йөзек—беләзек...), азан тавышы янгырый...*

*Кинәт барысы да өзелә. Шомлык. Нидер булырга тиеш сыман, куркыныч якынайганнан-якыная бара...)*

## 4 өлеш

**Сөләйман:**

**Бу бөек сер—татар яши**
**Җиде сүнеп җиде янган учак сыман.**
**Җиде буын үтер-үтмәс—**
**Сайлау:**
**Яшәү белән**
**Үлем арасыннан...**

**Нәркис (кызлар кушыла):**

**—...Без-без без идек**
**Без унике кыз идек...**

**...Без көлешеп йөргәндә**
**Кинәт килде җил-давыл,**
**Ябырылды илбасар—**
**Өс-аслы дошман явы.**

**—Таңрем-Аллам дия-дия,**
**Каргыш чиктек дошманга,**
**Хода, коткар дия-дия**
**Укыдык таңнан-таңга.**

**—Дошман көче—кылганда*,**
**Ятсын кылган тузанга,**
**Янсын кылган далада,**
**Яусын ләгънәт һавадан.**
**Кылган көче көл генә,**
**Кирәк бер әфсен генә.**
**Очсын җилгә көл булып,**
**Югалсын төтен булып.**
**Әфсен-төфсен, тьфу-тьфу-тьфу!**
**Дошманга булсын агу!**

---

* туар—товар (татарда: мал-туар сүзендә кулланышта)

* кылган—йомшак себеркәч чәчкәле дала үләне, рус.: ковыль

**Каныңа үтеп керсен,**
**Дошман-явыз җан бирсен!**

**Унике кыз:**

**...Без-без без идек**
**Без унике кыз идек...**
**...Бардыр, Тәңре, бер сәбәп,**
**Бардыр гаеп кайдадыр,**
**Ал, Син безне, күкләргә,**
**Безнең күңел айдадыр.**

**...Без-без без идек**
**Без унике кыз идек...**

**Унике сын булганчы,**
**Унике йолдыз булыйк,**
**Гүр катына ятканчы,**
**Ай-кояшка кыз булыйк...**

*(Унике кыз биюе)*
*Кызлар биегәндә кинәт чапкын килеп керә, яралы, хәле беткән.*

**Чапкын:**

**Афәт килде Болгар-илгә, Биләр—утта!**
**Ахырзаман! Илне кыра явыз дошман...**

*(Яу килүен әйтеп, үзе хәлсез калып егыла.*
*Кызлар яуга әзерләнә, дошманга каршы чыга, дошман белән көрәш-бәрелеш күренеше, кызлар тигезсез сугышта камалып дошман кулына төшәләр, дошман аларны җиргә терелäй күмәргә җыена).*

**Унике кыз:**

**Без-без-без идек,**
**Без унике кыз идек.**
**Базга төштек—ишелде,**
**Келәткә кердек—сүтелде.**
**Күккә мендек—күк кочты,**
**Мәңгегә күккә очтык.**

*(Кызлар күккә ашкан күренеш. Нәркис үзе генә очынып-бәргәләнеп биеп кала. Бу күренешләр бию рәвешендә башкарыла. Шул вакытта түбәндәге сүзләр яңгырый).*

**Җил иясе:**

**Унике кыз үсте энҗе-мәрҗән булып,**
**Унике ай җирдә берьюлы.**

**Яр иясе:**

**Уеннарда тиңсез иделәр,**
**Биесәләр—аккош сокланды.**
**Җырларына гүзәл кызларның**
**Сандугачлар кушты моңнарын.**

**К ү к и я с е:**

Афәт* килде берчак калага,
Дошман явы кырды ирләрне.
Унике кыз керде сугышка,
Сакларга дип газиз җирләрен.

**Т а у и я с е:**

Әсир итте дошман кызларны,
Тау өйдертте туфрак ташытып,
Тере килеш күмү нияте
Сылуларны, кара үч йотып.

**С ө л ә й м а н:**

Унике кыз йолдыз булып ашты күккә,
Мәңгелек йорт итте кызлар ай тирәсен.
Кыйсса булып һаман яши шигырьләрдә,
Күккә ашкан изге кызлар хатирәсе.

**Н ә р к и с:**

Әйт, Чишмәм, әйт, мәрҗәнем,
Кайда минем сөйгәнем?
Ул су булса—яр булыйм,
Ул чык булса—нур булыйм.

**Ч и ш м ә и я с е:**

Син йолдыз булдың күктә,
Сөйгәнең—зәңгәр чишмә.
Чишмә суы—көмештән,
Сөю балкый инештән.

**Н ә р к и с:**

Аһ, чишмәм, моңлы чишмәм,
Мәңгелек ярым, иркәм!
Чылтыр-чылтыр авазың—
Мәхәббәт чыңы икән.

Ай нурлары нечкә кыл,
Кылларны сөю чиртә,
Ай нурына төрелгән
чыңлавыңа ни җитә!

Хуш, сөйгәнем, хуш, чишмәм,
Хуш мәңгегә, хуш, иркә-ә-әм!

*(Сүзенең соңгы иҗекләре кайтаваз булып яңгырап, тына барып, юкка чыга. Нәркис күккә аша.)*

*(бию тәмамлана)*

---

* афәт – зур кайгы-хәсрәт

**Нәркис һәм башкалар (халык зары):**

**—Мең ике йөз утыз алты[29]**
**Күзләр иде Биләрдә,**
**Бәхет тулы гөлбакча**
**Калды сыкрап сөйләргә.**

**—Таш өстенә таш төште,**
**Уклар акты болыттан,**
**Гүя җилләр кылычтан—**
**Кырды илне берочтан.**

**—Биләрсуга карамыйм,**
**Биләрсулар кып-кызыл,**
**Хәлләр ни дип сорамыйм—**
**Мәңгелектә ул-кызың.**

**—Төштә күргән төш иде—**
**Өн булса да бик разый...**
**Тузып меңгә атылды**
**Бөек Биләр йолдызы.**

**—Очты болгар очкыны,**
**Дүрт як—кыйбла чаклары,**
**Меңәр чакрымнар үтеп,**
**Кабынды учаклары.**

*(М. Шәмсетдинова иҗат иткән «Дәрьяларда ай-кояш бар, ай-кояш» дигән моңлы көй уйный тора, яшьләр-балалар тау башыннан әкрен генә, тын гына аланга Чишмә янына төшәләр)*

## 5 өлеш

*Караңгылык. Шом. Минор. Балалар таудан төшеп баштагы урыннарына урнашалар.*

**Сөләйман:**

**Җиде гасыр узган мизгелдә**
**Янә сайлау**
**татар баласына.**
**Соңгы кабат язмыш сайлата**
**Яшәү белән**
**Үлем арасыннан.**

*(Әкрен генә йолдызлар җиргә төшеп тиеп яктырып-яктырып киткән сыман. Яктылык арта бара. Мажор артканнан-арта бара.)*

**Атилла:**

**...И балалар!**
**Бөек Атлар Рухы**
**Ак юл итә безгә ялларын.**
**Йөзләп гасыр**
**Җирдә татар Рухы,**
**Күңелләрдә—Сәлат Аланы.**

**И балалар!**
**Киләчәктә түгел,**
**Бүген, сезнең,**
**Бүген—көнегез!**
**Киләчәктә түгел,**
**балачакка**
**бүген хуҗа,**
**Хуҗа—үзегез!**

**Бүгенгегез сезнең—**
**киләчәк көн**
**сезнең балаларга.**
**Бүгенгене—**
**Бүген күрегез!**
**Һәр буында**
**яши икән татар—**
**дөрес төшкән, димәк, эзегез.**

**Сөләйман:**

**Татар рухы,**
**Бөек Татар рухы!**
**Әдип Әлмир[30] күргән сәламең.**
**Фатыйханнан ныгый,**
**Кыйбла булып үсә**
**Татар иле—Сәләт аланы.**
**...Изге җиргә**
**Изге туган илгә,**
**Сәҗдә кылыйк Бөек Биләргә!**
**Тамчы-тамчы**
**Акыл, моң-рух җыйыйк,**
**Татар җаны булган җирләрдән!**

*(прожекторлар уты күккә бер ноктага юналтелә—Изге Чишмә төрбәсе өстендәге ноктага—шул ноктада сигез канатлы мәңгелек билгесе сурәтләнә)*

**Иярләр:**

**Җайлый-ялгый өзгәләнгән җепселләрне,**
**Тоташтырып мәңгелекне мәңгелеккә,**
**Сәләт көе—Бөек Биләр кочагында,**
**Хыял-йолдыз, кыйбла булып, зәңгәр күктә...**

**Сәләт маршы:**

**Тәңре, синнән үткен зиһен сорыйм,**
**Кояш, синнән—рухи чисталык.**
**Сәләт—дәүләт, Сәлкеш—яңа татар,**
**Аң-фәһемгә гашыйк бу халык.**

**Биек таулар, чиксез дәрьялардан**
**Талган чакта адәм баласы—**
**Көмеш сулы талгын чишмә булыр,**
**Җиләс Алан булыр дәвасы.**

**Җир-йорт безгә очар канат бирде,**
**Кыйбла булды Сәләт аланы.**

**Җан җепләре бәйли сәлкешләрне,**
**Якын итеп ерак араны.**

**Рәхмәт Тәңрем, Татар теле өчен,**
**Татар теле—Җиһан ачкычы.**
**Сакла, Тәңрем, сакла Сәләт илен,**
**Хакыйкатьнең тәүге баскычын.**

*Тәмам.*

*Алкышлар, утлар уйный, бер ноктага җыела, күтәренке музыка.*

## АҢЛАТМАЛАР

### Кереш

[1] Казаннан көньякка таба 150 километрда, хәзерге Алексеевск районы җирендә урнашкан, IX-XIII гасырларда Болгар иленең башкаласы булып, заманында дөньядагы иң зур шәһәрләрдән булган Бөек Биләр шәһәре. Үзенең мәйданы һәм халык саны буенча Константинополь шәһәреннән кала Аурупада икенче шәһәр була.

[2] Борынгы төркиләрдә Күкне символлаштыручы, кешеләр, халыкләр язмышын хәл итүче иң югары илаһи көч – Алла.

[3] Тәңредән соң Олуг көч (миш.: Амый).

[4] Биләр шәһәре (бүген – Биләр авылы) янындагы тау шулай атала. Тау авылның төньяк-көнбатышында. Риваятьләр буенча шул таугa Биләрдә яшәгән изгеләр күмелгән.

Бер риваятькә караганда,Биләрнең 40 кызы шул тауда кальга төзеп,шәһәрне дошманнардан саклаганнар, шунда һәлак булганнар. Шуңа да бу тауны кызлар тавы дип тә йөртәләр. Икенче бер риваятькә караганда, бу таугa дошманнар 12 кызны терелэй күмергә теләп, кызларның үзләреннән туфрак ташытып тау өйдерткәннәр, шуннан кызлар тавы атамасы калган.

Безнең фикеребезчә,Хуҗалар тавының исеме Тәңречелек,мәҗүсилек,төрлеияләргә табынуга барып тоташа. Тау иясе,ягъни хуҗасы,су иясе,ут иясе һ.б.-лардан тауны Ияләр,ягъни Хуҗалар тавы дип атаганнар.

[5] Хуҗалар тавы итәгеннән агып чыга торган көмеш сулы чишмә. Бер риваять буенча,Хуҗалар тавына урнашкан Мәрҗән шәһәре башлыгы Тырышмал хаҗи, кызларының дошман кулыннан һәлак булуын күреп, шул таудан аска сикерә,шуннан Изге Чишмә тибә башлаган,имеш.

[6] XX-XXI йөзләрне тоташтырган заманда яшәп иҗат иткән татар шагыйре,әлеге кыйссаның авторы.

[7] Әлеф-Ләм-Мим (ӘЛМ), Алеф-Ләм-Мим (АЛМ). Бу өч гарәп хәрефен сүз итеп укыганда АЛӘМ, ягъни, татарчалап (әдәби телдә) әйткәндә – ГАЛӘМ килеп чыга.

Безнең фикеребезчә, бу – Аллаһы Тәгалә иң элек ГАЛӘМне хасил кылуына ишарәдер. Христианнар тәгълиматындагы: «Сначала было слово» дигән хәбәрне дә искә алсак, бу тәүге СҮЗне – АЛӘМ дип фараз кылырга нигез бар сыман.

Бу өч хәрефкә карата башка кайбер фикерләрне түбәндә күрәсез:

1) Әлиф ләм мим – мәгънәсен Аллаһ үзе генә беләдер.

Коръән тәфсире (Ногмани) татар телендә. Нурулла хәзрәт Мофлюхунов тәрҗемәсе. 1992. Казан,4нче бит.

2) Алм *.

* Аз,люди,мысл'те.

КОРАНЪ. Переводъ съ арабского языка Г.С.Саблукова в двух томах. Казань. 1907. Репринт. воспр. изд.1907. – М.: СП «Дом Бируни»,1990. – С. 5.

3) Три сокращенные буквы, о значении которых ведется много споров. В арабском алфавите 28букв и 29сур Корана начинаются с той или иной комбинации букв. Фонетический анализ их показывает, что в них представлены все виды артикуляционных звуков. Здесь,очевидно,какая-то символика, секрет которой со временем, несомненно,будет найден.

Порохова Валерия: Коран. Перевод смыслов и комментарии. 1996. – С.664.

Валерия Порохованың тәрҗемә китабында башка кайбер хәрефләр тезмәсенә дә аңлатмалар бирелә, берничәсе аңлатмасыз гына китерелә:

Алеф-Ләм-Мим-Сад (АЛМС), Алеф-Ләм-Ра (АЛР), Алеф-Ләм-Мим-Ра (АЛМР), Каф (Кафи: Самодостаточно)-Ха (Хади: направляющий)-Йа (Йад: Рука Вершащая Все)-'Айн ('Алин: Всезнающий)-Сад (Садик: Верный)) (КХЙ'АС),Та-Ха (ТХ), Та-Син-Мим (ТСМ), Та-Син (ТС),Йа-син(Йа инсан) (ЙС),Сад (Даут вә Сөләйман турында) (С),Ха-Мим (ХМ), 'Айн-Син-Каф ('АСК), Каф

(указание на апокалипсическую направленность Суры) (К). Нун (Чернила или то магическое перо, которыми записывались откровения) (Н).
[8] рус.: Во имя Аллаха милостивого,Милосердного,Слава Аллаху,Владыке всех миров.
[9] Канатлы елан. Борын-борыннан татарда изге саналган.
[10] Ак Барыс кавеменнән килгән Бөек Болгар дәүләте тамгасы.
[11] Төрки халыкларның изге тотемы.

## 1 өлеш

[12] Борынгы һун-төркиләрдә дин башлыгы,иялəр-рухлар белән кешеләр арасында арадашчы булган.
[13] Баш кам, ил буенча дин башлыгы. Рухландыручы,иң нечкә дулкыннарны тибрәндерүче. Безнең фикеребезчә, шуннан алынып кулланышка кергән татар сүзе – Илһам (Вдохновение).
[14] Скифлар иле (б.э.-га кадәр VIII-III гасырлар, Кара диңгез буе). Безнең фаразыбызча,иске эв = иске өй (йорт),борынгы (элгәреге) йорт мәгънәсендә. Әйтик, мисал өчен, бүген дә шул мәгънәдә кулланылучы атамалар: Иске Казан, Иске шәһәр (Төркия). Ягъни скифлар иле төркиләр өчен иске йорт.
[15] Һун-Сөн иле (б.э.к. һәм безнең эраның II-III йөзләре, хәзерге Төньяк Кытай,Тува,Енисей (Урхун) елгасының югары агымы тирәләре, моннан 2 мең еллар элек Урта Азия, Әфганистан, Пакистан, Төньяк Һиндстан җирләрен берләштергән Кушан империясе төзиләр). Һун-Сөн (русчасы: гун) төшенчәләрен Көн-Кен, ягъни кояш төшенчәсеннән килә, көнгә, кояшка табынучы халыкны шулай атаганнар дип фаразлау мәгънәле күренә. Ул заманнарда шул җирләрдә яшәгән халыкның Тәңречеләр булып,Кояшка табынганы билгеле.
[16] IV-V йөзләрдә яшәгән (395-453), Байкал күле тирәләреннән Урта диңгезләргәчә сузылган Бөек кыпчак дәүләтенең патшасы булган Атилла хакында сүз.
[17] Атилла чорында иң зур көч туплаган төрки-кыпчак иле – Дәште Кыпчак (Кыпчак даласы) (б.э. III-V гасырлары, чикләре: Көнбатышта – Алып таулары, Дунай (Истр) елгасы башланган җирләр, көнчыгышта – Байкал күлен узып, көньякта – Босфор, Кавказ Таулары,төньякта – Мәскәү, Ока елгалары).
[18] Күк Түрк каганаты (б.э. VI-VII гасырлары, хәзерге төньяк Монголия җирләрендә урнашкан, Каспий диңгезеннән Корея култыгынача җир биләгән).
[19] Урта Идел Болгар дәүләте (VII гасыр урталарында – Бөек Болгар дәүләтен (башкаласы – Фанагория) төзүче Кубрат ханның улы Кодрак хан өммәте Идел-Чулман-Зөя буена килеп урнаша, IX-XIII гасырларда Идел буенда Бөек Болгар иле үсә).
[20] Алтын Урда дәүләте (XIII-XIV гасырлар, Көнбатыш Себер,Төньяк Хорезм, Идел буе Болгар ханлыгы, Кырым, Төньяк Кавказ, Дәште Кыпчак кырә, Урыс кенәзлекләре буйсына).
[21] Казан ханлыгы (XV-XVI гасырлар).
[22] Сәләтле татар балаларын туплаучы Алан, Клуб, Фонд.
[23] Биләр шәһәре янындагы Кече Чирмешән елгасы. Элеккеге атамасы – Җаушер. Безнең фикеребезчә, Яу җире,ягъни яу булган җиргә ишарәдер.

## 2 өлеш

[24] Тырышмал Хаҗиның иң чибәр кече кызы.
[25] Риваять буенча,Хуҗалар тавы башында Тырышмал хаҗи идарә иткән шәһәр исеме.
[26] Хуҗалар тавына урнашкан Мәрҗән шәһәре башлыгы.

## 3 өлеш

[27] Алмас-Алмуш-Алмыш хан – X гасырда Болгар дәүләтендә Ислам динен дәүләттәге төп дин итеп кабул итүче хан.
[28] Биләргә Алексеевскийдан килеп керү ягында, Хуҗалар тавыннан көньяк-көнчыгыштагы тау.

## 4 өлеш

[29] 1236 нчы елның көзендә, бер еллап камап торганнан соң, Батый хан гаскәре Биләр шәһәрен яулап ала һәм яндырып юк итә.

## 5 өлеш

[30] Сәлкешләрнең рухи киңәшчесе.

Рәмзия
Габделхакова

# ТАУ АРТЫНДА КОЯШ БАР

РОМАН

***

Юлдан борылып авыл урамына килеп кергәнче үк һәр кайтучыны иң беренче булып зират каршы ала. Элек, әни исән чакта, аңа әлләни игътибар иткән юк иде. Каберлек тарафына күз дә салмый, рәшәткәләренә ышкылып диярлек, ашыга-ашкына гамьсез генә үтеп китә идем. Койма белән әйләндереп алынган бу биләмә күнелдә бернинди сагыш уятмый, эчендә каен, сирень, миләш, чыршылар үсеп утыргангамы, бары матур тын бакча булып кына тоела иде. Без, бала-чага, җәй көннәрендә анда кереп чәчәктер, җиләктер җыябыз, агачларга үрмәлибез, куаклар күләгәсендә эссе кояштан качып, серләшеп ятабыз. Каберлеккә күз-колак булып торучы Фәсхетдин бабайның безне ни өчен ачулануын аңламыйбыз, кулына тал чыбыгы тотып куып йөрүеннән кызык табып көләбез, бер аягына аксап йөрүче бичара картны ирештерәбез, үртибез...

Хәзер аңлыйм, каберлек—шул ук авыл ул. Авыл халкы әкрен генә шунда күчә бара. Кемдер чират белән, кемдер чиратсыз... Тик чиратсыз китүчеләрне беркем гаепләми, киресенчә кызганалар гына. Әнине шунда калдырганнан бирле каберлеккә карашым үзгәрде. Фәсхетдин бабайның, артыбыздан бәддогалар укый-укый, ни өчен куып йөргәнен хәзер инде яхшы аңлыйм: зират уен мәйданы түгел, анда адым саен кемнеңдер соңгы куышы—мәңгелек йорты. Гәрчә аны вакыт җир белән тигезләп куйса да, хуҗаларын борчып, каберләрне таптап йөрергә ярамый.

Каберлеккә башка яулык бәйләп, гаурәтләрне каплап, ару тән белән генә керү тиеш. Әбием бу турыда әллә ничә тапкыр кисәтте. Минем өстә исә чалбар белән кыска җиңле футболка гына. Сумкамнан кофтамны алып кидем, Фатыйма апаның бүләге—ал төстәге ефәк яулыкны башыма бөркәндем. Әйберләремне капка төбендә калдырып, каберлеккә аяк бастым. Керү белән борыныма сагындырган тансык ис—яшь үлән, җиләк исләре килеп ягылды. Балачактан таныш үзебезнең авыл һавасы...

—Исәнмесез, авылдашлар,—дидем мин әкрен генә.

Нигә шулай дидем, үзем дә аңламыйм. Исән кеше монда ята димени?! Элек әнинең кабере кырыйда иде. Ә хәзер эчтә калган. Ул рәттә

*Ахыры. Башы 4 санда.*

яна каберләр пәйда булган. Бу тыныч төтенсез авылга тагы кемнәрдер күчкән...

Мин яна каберләргә күз салмый, туп-туры әнинекенә юнәләм.

—Исәнме, әни, мин кайттым...

Кабер өстендәге чыршы чардуган биеклеге булып үскән. Тик ул шундый сыек, кайбер ботаклары бөтенләй шәрә калган. Яңа ел бәйрәме өчен киселгән чыршы түгел, тамырлары жылы жир куенында югыйсә, ни житми икән соң аңа?

Карашымны шул чирләшкә чыршыга төбәп, тезләремне кочып, куе йомшак чирәм өстендә утырам. Еламыйм да, берни уйламыйм да. Гүя үзем дә бер жансыз мәетмен. Нигә шулай? Әллә әнием миңа рәнжеп ятамы икән?

—Кичер мине, әни...

Юк, күңелдә бернинди дә жавап юк... Әллә нинди авыр бушлык. Йөрәгемә үзем дә анламаган шом үрмәли. Каберлектәге тынлык та шундый шомлы. Башыма бик сәер уйлар килә: бәлки бу кабердә әни бөтенләй юктыр да...

Кабер өсте дә күптән каралмаганга охшый, чыршы биеклеге булып чүп үләннәре үскән. Чардуган буяулары кубып-кубып төшкән дә, ала-кола булып шыксызланып калган. Таштагы язу да уңган... Онытканнар әнине... Аптыраганнан карашым янәшәдәге кабергә төшә, ул да чүп үләненә күмелеп утыра. Аның да чардуганы ала-кола... Әллә соң безнең авылда кабер өсләрен карап, тәрбияләп тору гадәте беткәнме?! Кем ята икән бу кабердә? Кызыксынып таштагы язуны укыйм: Мидхәт Габделбарый улы Солтанов... 20. 08. 1942—23. 01. 1992... Кем соң әле ул Мидхәт? Минем әти дә Мидхәт исемле, ләкин ул үләргә тиеш түгел. Юк, минем әти берничек тә үлә алмый, яшь бит әле ул... Алайса, кем соң ул Мидхәт? Безнең авылда башка Мидхәт юк лабаса...

Бер кулым белән әнинең, икенчесе белән әтинең кабер чардуганына чытырдатыпябышкан килеш катып калам. Мин кеше түгел, мин—таш. Беркайчан айнымаска, шулай ташка әйләнеп, бу дөньядан мәңгегә югалырга кирәк. Әни белән әти янында калырга. Ничек тә айнымаска... Тормыш, ташла мине! Үлем—юатучым, коткаручым, ал мине, ал тизрәк үз кочагыңа!

Мин—таш, мин—таш, мин—таш...

Шулчак каршымда сары шәүләләр пәйда була. Бер-берсенә ике тамчы судай охшаган алты-жиде яшьлек малайлар. Әллә бер генәме, күземә шулай ике булып күренәме? Әллә болар жиргә жибәрелгән фәрештәләрме? Әрвахлар йортында ни булмас... Эчемә жылы керә: бер дөньядан икенчесенә күчеш башланды... мин китәм... мин котылам... Озакламый барысы да үтәчәк, барысы да бетәчәк... Алда—мәңгелек тынлык, мәңгелек тынычлык...

—Апа, исәнме.

—Апа, исәнме.

«Фәрештәләр» миңа ашыгыч битараф караш ташлап каберләр артында югалалар.

Шул ике сүз мине айнытып жибәрә, таш булып каткан миемә ук булып сораулар килеп кадала: «Кемнәр болар? Нишләп йөриләр биредә?»

—У-у, карале, нинди зур жиләк, Айратның колагы хәтле.

—Алдама, андый жиләк булмый.

Мин кабат фани дөньяга кайтам. Сары футболкалы бу чебиләр бернинди фәрештә түгел, каберлеккә жиләк жыярга кергән малайлар гына. Аларны күргәч, Илнар искә төшә. Кайда ул хәзер, кем белән? Әти үлгәч, Кифая киткәндер, Илнар әби белән калгандыр... Ә әби? Ул исәнме соң? Бәлки инде ул да...

Бу куркыныч уй мине урынымнан кузгата, кабаланып яна каберләрне карый-тикшерә башлыйм, курка-шикләнә ташка уелган исемнәрне укыйм:

Маһинур әби... Лотфулла бабай... Сәкинә әби... Рабига апа... Бәрәч, Рабига апа... Кифаяның әнисе ич бу. Димәк, ул да... Йә, Алла, шул арада күпме кеше китеп барган. Ә бусы кем? Бу кабердә бернинди таш та, язу да юк. Кем кабере бу? Кемнеке? Эчем жу-у итеп китә, әгәр әбинеке булса?!

Башымнан әти турында караңгы уйларны куа-куа, бакчалар артыннан өйгә ашыгам. Әлегә мин әти турында уйламаска тиеш! Әлегә мин бу хәсрәтне аңларга, кабул итәргә әзер дә түгел. Аннары, аннары... Башта әнемне күрергә кирәк.

Безнең бакчада кемдер эшли, бәрәңге күмә бугай. Кифая дисәм... Юк, аңа охшамаган, Кифая озын буйлы, җыйнак гәүдәле иде. Ә бу апа юан, тәбәнәк тә. Бәлки берәр туганы кайткандыр? Аның белән тигезләшкәч, кычкырып исәнләшәм:

—Исәнмесез, апа!

Хатын, эшеннән туктап, башын күтәрә:

—Исәннәр әле.

Табак битле, шешенке күзле бу апаны минем гомердә дә күргәнем юк. Кифаяның мин белмәгән берәр туганы булса гына. Димәк, ул монда, беркая китмәгән.

Мин өйгә таба атлыйм. Кинәт веранда ишеге ачыла да, аннан чиләк күтәргән таныш түгел бер абый килеп чыга. Чак кына өстемә юынтык су эләкми кала, вакытында читкә ыргылып өлгерәм. Йә инде, башында акылы булган бәндә шунда пычрак су түгәме, ишек төбенә чәчеп үрчетмәсәң дә, авылда чебен-черки житәрлек. Шулай да, абый белән итагатьле генә исәнләшәм. Тик ул сәламемне алып вакланмый, миңа канәгатьсез караш ташлый да, кабат өйгә кереп китә. Бигүк айнык түгел, ахры.

—Кем син, танымыйм. Ник безнең бакча аша йөрисең?

Бакчадагы хатын эземә басып артымнан кергән икән.

—Ә сез кем?

—Вәт, Ходай бәндәсе, мин түгел, син миңа килгән бит. Кемгә килгәнеңне беләсеңдер.

—Мин Кифая апаларга килдем.

—Шулай диң аны. Ату, син кем, имеш... Кифая апаңнар биш былтыр күчеп китте ләбаса. Инде без кайтканга өченче жәй.

—Киттеләр?! Кая?

—Наратка бугай.

—Ә әби? Ул кайда?

—Белмим. Монда бернинди әби дә юк иде.

Гүя башыма китереп сугалар: «Билгесез кабер әбинеке... Кабер өстенә таш куярга да кеше булмаган...» Мин, хәлсезләнеп, бакча рәшәткәсенә сөяләм. Кайдандыр бик ерактан ят тавышлар ишетелә:

—Рубис! Рубис дим! Су алып чык әле, монын төсе китте бит.

—Өйгә алып кереп яткырырга кирәк. Йөрәк чирле булмасын.

—Егыла инде, тот әле, Рубис! Вәт, жәфа!

***

Әни анда... Әти анда... Әби анда... Янгураз да анда... Улым да анда... Ә мин... Мин ник монда? Нигә яшәргә? Яшәүнең ни яме, ни мәгънәсе бар? Кем өчен, ни өчен яшәргә? Мин кемгә кирәк? Илнаргамы? Ул минем дөньяда барлыкны да оныткандыр инде. Аның бит әнисе бар... Кифая аны үзе белән алып киткән.

Чынлап та, нигә яшәргә? Ләкин үлеп тә булмый бит...

Уйларыма чуалып, аңгыра карашым белән өй эчен айкап, ят урын-жирдә ятам.

Бу—минем туган нигезем. Бу—минем үскән йортым... Диварлар шул ук, идән-түшәм шул ук, тәрәзәләр дә шул ук. Җиһазлар, әйберләр генә башка. Һәм... ис башка. Йортларның да үз исе була икән. Бу йортта безнең ис калмаган... Хәтта өстемә япкан җәймә-мендәрдән дә, бөтен җирдән дә башка ис, ят ис килә. Хуҗалар мине түр бүлмәдәге диванга кертеп салдылар да, һушыма килү белән кулыма бер чынаяк су тоттырып янымнан китеп тә бардылар.

—Тәгәрә, хәл җый,—диде хуҗа апа.—Мин бакчага чыгам, көн бозылганчы бәрәңгемне кәтмәнләп бетерәсе бар.

Алар чыгып киткәч, мине уй басты. Баш тулы уй, авырлыгына чыдар әмәлләр юк, хет ярып бушат. Алар эзлекле түгел, гүя алмаш-тилмәш сикереп уйныйлар. Уйның әле берсе, әле икенчесе өскә чыга. Барысын да бишкуллап тотып төбе-тамыры белән йолкып алып, еракка болгап атасы, тизрәк шулардан котыласы килә. Ниемә кирәк шул хәтле уй?! Кайдан килә алар? Мин берни турында да уйларга теләмим ләбаса.

Әти нишләп үлде икән? Ул бит исәнлегенә зарланмый иде. Ни булды икән аңа?

Әгәр урамга чыксам, беренче очраган кеше миңа барысын сөйләп-аңлатып бирер иде. Тик мин әлегә беркемне дә очратырга теләмим. Мин куркам... Үз авылыма кайтып, кеше күзенә күренергә куркып качып ятам. Мин үземнең туган җиремдә качак хәлендә... Нигә алай? Чөнки беренче очраган кеше үк күземә туп-туры карап, йөземә бәреп сорау бирәчәк:

—Син кайда олагып йөрдең? Ник әтиеңне озатырга кайтмадың? Ник берниңди хәбәр бирмәдең? Ник якыннарыңны кайгыга салдың?

Мин бу сорауларга җавап бирергә әзер түгел. Гаебем артык зур. Мин бит хәтта әтинең хатын да җавапсыз калдырдым... Болай буласын белгән булсаммы...

«Авыл халкы киң күңелле, күп нәрсәне аңлый, кичерә. Бел, кызым, авыл халкы бурларны һәм ялкауларны гына яратмый». Кайчандыр әни шулай дигән иде. Мин угры түгел, ялкау да түгел кебек... Әллә угрымы? Мин бит әтиемнең тынычлыгын урлаганмын. Аның үлеменә мин гаепле булсам? Ничек яшәргә? Бу гаеп, бу гөнаһлар белән ничек яшәргә?! Ай, башым, бичара башым, шартлый бит инде хәзер. Нишләргә? Әллә, караңгы төшү белән беркемгә дә күренеп тормыйча авылдан чыгып качаргамы? Тегеннән кач, моннан кач... Мәңгелек качак булып гомер кичерергәме? Үз илендә урын тапмаган кеше кайда сыя?!

Юк, болай ярамый. Бар кыюлыгымны җыеп, урамга, авылдашларым каршына чыгып басарга кирәк. Ничек теләсәләр, шулай гаепләсеннәр, ниңди җәза бирсәләр дә риза. Ни югалтам, нәрсәдән куркам соң әле мин? Таш бәреп үтерсәләр, сөенер генә идем әле. Тик андый җәза юк шул, хәзер сүз белән генә үтерәләр. Тик бу котылу түгел. Сүз кайчакта үлемнән дә куркыныч. Җаның гына үлә, ә тәнең еллар буе үзенә урын тапмыйча, җир өстендә аптырап-каңгырап йөри. Ул тәндә баш та бар бит әле. Баш булган җирдә тынычлык була димени. Аны уй басса, акылдан язуың да бар.

Нидер эшләргә кирәк. Авылдашлар каршына басып, җавап тотар өчен бер-бер нәрсә уйлап чыгарырга кирәк.

Уйла, Наргизә, үзеңне акларлык берәр әкият уйлап чыгар.

Димәк, шулай... Син авылга кайтырга юлга чыгып бастың. Очраклы машинага утырдың. Аның Женя икәнен әйтү кирәкмәс. Бу оятсыз бәндә сине урманга алып керде, көчләмәкче булды. Сез бик озак тарткалаштыгыз. Шулай булдымы? Булды. Син егылдың, аңыңны югалттың. Шуннан инде берни дә хәтерләмисең. Имеш, исеңә килгәч, кабат юлга чыккансың. Кемдер сине каядыр утыртып киткән, үзенең хатыны иткән. Син шунда яшәгәнсең.

Аннары... Синең улың туган... Болар дөреслеккә якынмы? Якын. Аннары ул машинага тапталып үлгән ди... Улың чынлап та үлде бит, бусы да дөреслеккә туры килә. Бу хәсрәттән синдә шок булган. Шуннан соң, имеш, югалган хәтерең дә кайткан. Син кинәт барысын да исенә төшергәнсен. Һәм шунда ук җыенып авылга кайткансың...

Менә шундый кечкенә генә, матур гына ялган. Минем башка чарам юк, алдашырга туры киләчәк. Ничек инде йөз ертып, әтигә, Кифаяга үпкәләп киттем, бер хәбәр бирмичә Кыргызстанда качып яттым, дип әйтмәк кирәк? Мине кем аңлар? Аңламас, чөнки әтинең дә, Кифаяның да минем алда бер гаебе юк.

Иһ, әти исән булса... Ул исән булсамы! Алдына тезләнеп, башымны җиргә бәрә-бәрә, гафу үтенер идем. Каеш белән тотып ярса да, телемне тешләп, каршы дәшмәс идем. Мин әтидән теләсә нинди җәзаны да алырга риза. Нигә китәргә ашыктың син, әтием, нигә кызынны көтмәден?! Мин сине сагынып кайттым бит! Ничекләр яшим хәзер сездән башка?!

Буа ерылды, сулкылдап-сулкылдап еларга тотындым. Күздән кайнар яшьләр күбрәк аккан саен, башым җиңеләя сыман тоелды.

Шулай елый-елый йоклап та киткәнмен...

***

Мине ис уятты. Кыздырган бәрәңге исе. Шул ис борынымны иркәләп-үртәп, ашказанына хәтле үтеп керде дә, тегесе ду килеп ашарга дәгъвалый башлады. Үлеп ашыйсым килә! Фатыйма апаның беркайчан да бәрәңге кыздырганы юк иде. Каян алды икән шул хәтле бәрәңгене? Минем инде йөз ел буе кыздырган бәрәңге ашаганым юк.

Шул ис йокыдан айнырга, күземне ачарга мәҗбүр итте. Бүлмәдә дөм карангы иде. Миңа бик куркыныч төш керде. Авылга кайтканмын икән. Имеш, каберлеккә кергәнмен. Имеш, анда әтинең кабере дә бар, ул үлгән икән... Йә, Алла, әле дә ярый төш кенә, әле дә ярый уяндым! Фатыйма апа тизрәк ашарга чакырсын иде. Шундый нык ашыйсым килә! Әллә, чакырганын көтеп тормый, үзем чыгыйммы икән? Сәгать ничә соң? Иртәме бу, кичме? Уянгач, торырга кирәктер инде.

Мин урынымнан кузгалдым. Шулчак ишек ачылган тавыш ишетелде. Ниндидер ят, тупас тавыш кемнедер ачулана иде:

—Кыбырсыма әле шул хәтле, өлгерерсең. Ачка бетүең түгелдер. Туймас бирән булдың инде чисти!

Куркуымнан куырылып, кабат урынга сеңдем. Кем бу? Нишләп йөри ул бездә? Кемне шулай ямьсез итеп ачулана?

—Пересс! Пересс дим! Буталма аяк астында!

Шулчак мин айнып киттем. Төш түгел бит бу, төш түгел... Барысы да чын, өн ләбаса. Авылга кайтуым да, әтинең үлеме дә, бөтенләй чит кешеләрдә йоклап ятуым да... Ник уяндым, йоклаган килеш үлеп китмәдем икән? Ник кенә уяндым мин?!

—Мачыдан үч алма, аның гаебе юк,—диде ир тавышы.—Бу кызый бездә кунамы?

—Кунар инде, төнгә каршы куып чыгарып булмас.

—Чишендереп китмәсә ярый ла... Аның уенда ни икәнен кем белә? Әллә нинди бәндә.

—Кайгырма, мин сораштым-белештем инде. Элек бу йортта торган Мидхәт кызы икән ул.

Мин сагайдым. Белешкәннәр... Димәк, кемдер мине күргән, таныган. Качып ятудан мәгънә юк. Минем турыда хәбәр урамга чыккан, бер кеше белгәнне хәзер инде бөтен авыл беләчәк.

—Нурсинә кереп күрде, таныды. Шул үзе, ди. Жиде ел элек югалган булган,—дип дәвам итте хатын.—Үлгән дип уйлаганнар. Нәстә дип кайткандыр...

—Алай булгач, юлдан язган бер зимагур инде. Күз-колак булырга кирәк. Әллә кемнәрне асрап ятып булмас монда.

—Иртәгә, таң тишеге белән чыгарып җибәрәм мин аны. Хәзер йоклый әле, йоклаганда зыяны тимәс лә. Әйдә, картым, ашап алыйк әле. Тук корсакка йокы тәмле була.

Мине ашарга чакырмадылар... Калак чыңлаган, авыз чапылдаган тавышларны тыңлап кына «ләззәтләнергә» насыйп булды. Алай гына тамак туйса икән ул...

Шулчак теге җәй искә төште. Кифаяга үчләшеп йөрүләрем... И-и... мин аны да юксынам икән бит... Ни дисәң дә үз кеше, болар кебек җиде ят түгел. Кайда икән хәзер Кифая апа? Җүләр... Мең кат җүләр мин! Үпкәләп, көйсезләнеп ни кыландым бит. Имеш, безнең йортта чит хатын йөри... Менә хәзер бу төксе бәндәләр урынында Кифая апа йөрсә сөенер генә идем әле. Ни дисәң дә үз кеше. Их, ул чаклар... Хәзер менә ул бәхетле көннәрне сагынып еларга гына калды. Әби исән, әти исән, Илнар да шунда уралып йөри. Кифая апа да караңгы чырай күрсәтмәде ләбаса, ни карашы, ни сүзе белән рәнҗетмәде. Йорт та үзебезнеке! Бар кадерен юк белә, дип әбекәем юкка гына әйтмәгән икән. Югалткач кына булганнарның чын бәясен аңлыйсың. Тик соң була шул... Соң була! Шул кирәк сиңа, тәкәббер кызый, үз өеңдә кеше ашаганга селәгәеңне йотып ят инде хәзер. Яхшылап тотып яручы булмаган бит шунда, болай кыланып, кысыр хәсрәтенә буылып йөрмәс идең. Әй, дивана кыз...

Мин бу йортта кала алмыйм, башка бер минут та кала алмыйм. Урамда кунсам кунам, тик монда түгел!

Күземнән тәгәрәгән яшьләрне кулым белән сөртеп алдым да, тегеләр каршына чыгып бастым. Икесе дә, ашауларыннан туктап, сагаеп-шикләнеп миңа төбәлде. Абый белән сеңел диярсең, бер-берсенә ничек шул хәтле охшашкан болар?!

—Син йокламыйсыңмыни?—Апакай миңа шикләнеп тә, куркып та карап куйды. Сөйләшкәннәрен ишеткән дип уңайсызланды, ахры.—Утыр табынга, тамагың ачкандыр.

Хәзер! Шундый сүзләрдән соң тамактан ризык үтәме?!

—Рәхмәт, ашыйсым килми. Мин китим инде.

—Кая?

—Туганнарыма.

—Туганнарың бармыни? И-и, алайса...—Апакай җиңел сулап куйды, табак бите майлаган кебек ялтырап, яктырып китте.

Ул мине турыга хәтле озата чыкты, артымнан капканы шапылдатып бикләп тә куйды. Котылдым дигәндер инде.

Ә мин, бакча коймасына сөялдем дә, караңгы тәрәзәләребезгә текәлдем. Алар миңа ятим бала кебек боек, шундый җәл булып тоелды, гүя мин чыгып киткәнгә үпкәләп-рәнҗеп елыйлар иде. Бабамнардан калган нигез бу, әтием үзе салган йорт, койма-капкаларны да ул корган, бакчадагы һәр агач-куакны әбием, әти-әнием утырткан. Бу нигездә аларның эзләре уелып, тирләре тамып, кул, күңел җылысы сеңеп калган. Үзләре исән булмаса да, рухлары биредә яши. Бу йортта мин бишектә тирбәлгәнмен, тәүге адым атлаганмын, шунда бәхетле, ваемсыз балачагым үткән... Ватан шуннан, туган нигездән, туган йорттан башлана... Туган йорты булмаган кеше Ватанның ни икәнен аңлыймы, аның кадерен беләме?! Шуларны уйлап мин тирән сагышка биреледем, күңелем әрнеп-сыкрап үрталде: үз йортыңда сиңа урын

булмасын, имеш... Күзеңне ачкач та, жылы кочагына алган туган нигез жанга бигрәк якын, аны бер дә ятларга бирәсе килми икән шул. Фатыйма апа юкка гына юл буе сыкрап-сагышланып кайтмагандыр.

Хәсрәт тулы башымны иеп, әкрен генә урам буйлап атлап киттем. Менә хәзер, төн уртасында кем ишеген шикләнми-курыкмый шакый алам да, кемгә килеп керә алам? Кемгә булсын, балачак дустым Риммаларга! Ул авылда түгелдер, әлбәттә, ләкин аның әнисе Фәрдия апа мине үз кызыдай якын күрә иде. Без ике йортны бер итеп аралашып яшәдек. Уены да, эше дә, күңел ачулар да гел бергә булды. И ваемсыз бәхетле балачак... Әниле чак... Тик менә... Фәрдия апа исәнме икән соң? Әгәр ул да үлгән булса...

Таныш капканы сак кына ачам. Тәрәзәләр караңгы. Димәк, йоклыйлар. Төн уртасында кеше борчып йөрү килешмәс, әллә шунда, баскычта гына үткәримме бу төнне? Сумкамнан жылы кофтаны алып, аркама салдым да веранда ишегенә сөялдем. Менә шулай, йорт саклаучы тугры эт сыман ишек төбендә утырыйм әле. Карашым меңләгән йолдыз сибелгән төнге күккә төбәлә. Галәм белән чагыштырганда жир шары бигрәк бәләкәй икән шул, кайсы почмагына барып бассаң да баш очында шул ук йолдызлар балкый. Моңлы-хисле жаннарның мәңгелек юлдашы алар. Югыйсә юатмыйлар да, жылытмыйлар да, жиргә салкын, саран нурларын түгеп балкыйлар гына. Бар эшләре шул. Күләмме мин, елыйммы—йолдызларга барыбер. Аларның әтиләре дә, әниләре дә юк... Берни тапмыйлар, тапмагач югалтмыйлар да... Йолдызларга рәхәт, бүген кайда кунармын да, иртәгә кай тарафка юл алырмын икән, дип баш ватмыйлар...

Мин инде йокымсырап киткән идем. Аркама кемдер төрткәнгә уянып киттем. Тырышып-тырышып этә дә этә бу. Нигә этәләр мине, кемгә комачаулыйм? Аннары аңлап алдым: кемдер эчке яктан ишекне ачмакчы була икән, ә мин аны терәп утырганмын.

Кулына комган күтәргән Фәрдия апа килеп чыкты. Мине күрүгә кычкырып жибәрде:

—Әстәгъфирулла, кем бу?

Мин урынымнан сикереп тордым:

—Исәнме, Фәрдия апа. Мин бу, Наргизә. Мидхәт кызы.

—Кит аннан! Кешеме соң син, әллә өрәкме?

—Кеше...

—Нурсинә әйткән иде шул. Мидхәт кызы кайткан икән, дигән ие. Ышанмадым. Булмас, мәйтәм, исән булса, жаны булса, бер кайтып күренер ие. Атасын озатырга булса да кайтыр ие.

Ачулана. Рәнжи. Гаепли. Ә мин... Мин дәшмим, түзәм... Ни дип акланыйм? Башны иярга дә, түзәргә кирәк! Безнең йортка килеп урнашкан чит кешеләр мине тиргәмәде. Аларның мине гаепләргә дә, сүгәргә дә хаклары юк. Ә Фәрдия апаның бар. Кыйнаса да, каршы бер сүз дә әйтә алмыйм.

—Чәй куйыймммы?—дип сорады Фәрдия апа, өйгә кергәч.

—Әйе.

—Тегеләр эчермәдеме?

—Юк.

—Юктыр шул. Аларныкы—учлаган. Тажикстаннан кайтканнар. Балалары юк, кеше хәлен аңлаучылар түгел. Гомер буе үз алларын катыклап яшәгән халык. Кифаяны әйтер идем, тапты бит йорт калдырыр кеше! Яхшы түлиләр, имеш.

—Безнекеләр кая китте соң?

—Наратка. Шунда квартир алды бит Кифая, яхшы эшкә дә урнашкан. Әнисе дә, Мидхәте дә үлгәч, никтер китәргә ниятләде шул. Һич тә

җибәрәсебез килмәде дә бит. Яхшы күрше—дөнья бәясе ул. Болар белән ботка пешми. Капкаларына хәтле биклиләр бит, гомердә булмаганны! Беркем белән аралашмыйлар.

Мин дәшми генә тыңлыйм, чөнки авыз буш түгел. Ачыгуым җиткән икән, яхшы түгел дип тә тормыйм, алдымда ни бар, шуны умырам гына.

—Аша син, аша. И, бала... Әтиенне дә күрми калдың инде. Шул хәтле көтте бит сине бичара. Хәсрәтеннән суырылып төште тәмам. Рәзе шулай ярый инде, башсыз! Бала-чага дип юкка гына әйтмиләр шул. Чага, ничек кенә чага... Җелегенне суыра. Кайларда йөреп беттең соң син, җәфа капчыгы?

Фәрдия апаны алдау оят. Ләкин оялып булса да, күземне аның үткен карашыннан яшерә-яшерә, уйлап чыгарган әкиятемне сөйлим. Белмим, әллә ышанды, әллә ышанганга сабышты, кире кайтарып берни сорамады.

—Ярар, буласы булган, чумасы чумган. Үткән эшкә—салават. Алдагысы хәерле булсын. Калганын иртәгә сөйләшербез. Ятып йоклыйк әле. Иртүк көтүгә торасы бар. Төн уртасында кеше куркытып йөрисен. Аны баштук үземә килергә ярамаган. Чит кешеләр түгел ич,—дип сукрана-сукрана сүзгә нокта куйды Фәрдия апа.

Бу йортта миңа рәхәт иде. Бу йортның исе миңа балачактан таныш, күңелемә тансык иде.

***

Икенче көнне мин барысын да белдем. Яхшысын да, яманын да. Бер шатлыклы хәбәр бар: әби исән! Әтинең вафатыннан соң Миндар абый аны үзләренә Әлмәткә алып киткән икән. Әбинең исән булуы миңа җан өрде, күңелгә канат куйды. Югыйсә теге билгесез кабер котны алып гел күз алдымда тора иде. Ул кабер әле ике атна элек кенә туксан өч яшендә вафат булган Хөсниҗамал әбинеке икән. Аның беркеме дә юк иде, ике улы да, ире дә сугыштан кайтмаган. Түбән очтагы иң кырый кечкенә генә бер йортта япа-ялгызы яшәп ята иде. Кабер ташын куйдыруны Авыл советы үз өстенә алган икән.

Без Фәрдия апа белән бәлеш салырга җыенып йөрибез. Ул ит турый, мин бәрәңге әрчим. Минсалих абый эшкә чыгып киткәндә йоклаган идем, ул мине күрми калган. Фәрдия апа ана берни әйтеп тормаган. Ләкин авылда мин кайтканны беләләр, телләрендә мин генә ди, имеш. Авылда шулай бит, иң яңа хәбәрләр көтү куган чакта бөреләнә башлый, төшкә гөрләп чәчәк ата, кичкә җимешләре әзер була...

—Сине мактаучы юк анда,—дип «юатты» мине Фәрдия апа.—Тетмәнне тетәләр, түз генә.

—Чәйнәрләр дә туктарлар әле.

—Римма күрсә, егылып китәр инде. Исән булуына өметләнмәде ул. Аның дус кызын юлда мәсхәрәләп үтергәннәр иде бит.

—Мин дә чак үлмәдем инде...

—Анысына ышанам,—ди Фәрдия апа.—Түлке хәтер югалттым дип кешегә сөйли күрмә. Барыбер ышанмаслар, Мидхәт кызы акылыннан язган икән, диярләр. Кайтырга оялып йөрдем дин лутчы.

—Ярар, шулай итәрмен, Фәрдия апа. Римманың хәлләре ничек соң? Кияүгә чыкмадымы?

—Чыкты!

—Кемгә?

—Югары авыл егетенә. Кияү яхшы. Уллары бар бит инде, Алмазыбыз бар. Әй, ул бала, күрсәң, терекөмеш белән бер. Барыбызны да әпипәгә биетә түлке, зырмали китерә. Римма бер атнага бездә калдырып киткән иде, кулдан бөтен эш төште, көне буе шул баланы каравыллап йөрдем.

Көтү көтеп тә болай арыган юк иде. Аңа чыдарга! Риммага Ходай ярдәм бирсен, биш бала үстереп тә андый хикмәтне күргән булмады.

Римма кияүгә чыккан, улы бар... Бәхетледер ул, дөньясы түгәрәктер. Эчтән генә аннан көнләшеп тә куйдым. Ә мин?! Ә минем хыяллар җимерелгән инде... Киләчәгемне күз алдыма да китерә алмыйм. Әтием исән булса бу кадәр хафаланмас та идем. Теге чакта, хатын алгач та йөгереп кайтасым калган икән! Хат белән бергә әтинең тынычлыгын, өметен, киләчәген дә яндырганмын бугай... Аныкын гына түгел, үземнекен дә. Ата-анасын рәнҗеткән баланың бәхетен җен урлыйдыр, мөгаен.

—Фәрдия апа... әтигә ни булды соң?

—Йөрәк белән кинәт китеп барды ул, сеңлем. Инфарык дигәннәр, замана бәласе инде. Шул ике чир кыра бит хәзер халыкны: рак та инфарык... Синең өчен дә хәсрәтләнде, бик бетеренде инде. Теш кысып йөргән белән түгел, кайгы дигәнең барыбер кайчан да булса йөрәккә китереп бәрә ул. Лутчы кешегә, кешегә булмаса, учына сөйләп бушан.

Мин гаепле... Әтинең үлеменә мин гаепле...

—Гөлзадә артык яраткан икән Мидхәтне, тәки алып китте бит үзе янына, Кифаяга калдырмады. Алай дисәң, күрәчәген булса, сәбәбе табыла инде аның,—ди Фәрдия апа. Әллә мине юатырга теләп кенә шулай әйтәме.—Аннары партиясе беткәнгә дә бик борчылды Мидхәт. Гомер буе тырыша-тырыша төзегән йортың бер мизгелдә ишелеп төшсен әле, борчылырсың да шул. Авызыннан шул сүз төшми иде бит, партия дә партия... Коммунистларны тәмам әүлиягә санап йөрде инде беркатлы җан. Андагылар барысы да Мидхәт кебек булса, бетмәс тә иде ул партия, илдә әллә кайчан коммунизм булыр иде. Артык чисный булды шул мескен, аның кебекләрне бармак белән генә санарлык. Елсин кулына калгач, ил бетә, дип көенгән. Шуңа бара да инде, бик белеп әйткән Мидхәт. Сугыш чукмарлары бит болар, җыен сәрхуш! Кара син, Чичнәдә ни кыланалар бит! Таптылар дошман, үз халкын кырып ята, иблис!

Миндә дөнья кайгысы юк. Күңелгә шом уралган, зиһен чуалган, уй-фикерләр җептән өзелеп җиргә сибелгән сәйләннәр хәлендә. Үз язмышым кыл өстендә. Ни йортым, ни барып сыеныр почмагым, ни таяныр, ярдәм кулы сузардай туганнарым юк.

—Фәрдия апа, нишлим икән мин хәзер? Кая барыйм икән?

—Кая барасың? Кифая янына билгеле! Синең урын анда инде, йортыгызны сатып квартир алды бит. Дөрес, үзләренекен дә сатты. Ике йорт акчасы кереп китте, әле ул да җитмәде, дип торган иде. Урамда кала алмыйсың инде хәзер, балакаем, барасың да торасың. Ничек тә сыярсыз әле.

Әйтергә генә ансат, Кифая апа мин юньсезне тансыклап тора ди. Бусагасыннан да үткәрмәс әле. Их, әтием... Никләр генә безне ташлап, шулай иртә киттең соң син?! Әби янына, Миндар абыйларга барсам да якты чырай күрүләр насыйп булмастыр, анда аждаһа сыман ыжгырып торган Хәмидә апа бар. Әби анда үзе дә, энәле телен аркылы тешләп, ыспай песи булып мыштым гына утырадыр...

—Наргизә, син башта Сәлим янына да барып кара әле.

Мин бәрәңге әрчүемнән туктап, Фәрдия апага текәләм. Ничек инде, нишләп инде... Нишләп әле мин Сәлим янына барырга тиеш ди?! Башка барыр урыным юк, зинһар, мине кияүгә ал, бергә яшик дипме?

—Ногман абзыең пенсиягә чыккач, малайлары янына калага китте бит. Аның урынында Сәлим калды. Кеше хәленә керә торган бик ипле бала. Сабакташлар да түгелме соң әле сез, бергә укыдыгыз бугай?

Сәлим? Авыл Советы рәисе?! Булмас ла. Ул бит әле шундый яшь! Шундый җаваплы зур эшне ничек ышанып тапшырганнар аңа?!

—Аның белеме дә юк бугай бит...—дим гаҗәпләнеп.

—Бар, нишләп булмасын ди. Казанда укып йөрде ул. Авыл хуҗалыгы буенча. Эшли-эшли укыды. Икзамнарга әзерләнергә әтиен булышкан.

Икеләнеп кенә сорыйм:

—Өйләнгәндер инде ул?

—Юк, тәки ялгызы кангырып йөри шулай. Авылда калырга теләүче кызлары юк бит анын, барысы да шәһәргә таю ягын карый. Кемнең тирес арасында батып-чумып йөрисе килсен?! Авыл тормышы нужалы шул.

Димәк, Сәлим өйләнмәгән... Шул гомер һаман ялгыз. Сәер... Ә бит ул кайчандыр мине яраткан иде... Хәзер оныткандыр, хисләре сүрелгәндер инде, ничә ел үтте бит. Минем кайгы түгелдер анда. Мин дә алай Сәлим дип өзелмәдем. Сагынудан бигрәк, үткәннәр, авыл турындагы сагышлы уйларга ияреп-уралып кына күңелгә адашып килеп керә, үзенең дөньяда барлыгын, кайчандыр тормышымда булуын искә төшерә иде.

—Кифая янына бармыйм дисән, авылда буш йортлар бар барын. Әнә, Хөснижамал астайның йорты бөтенләй иясез калды. Күршеләре Габдрәхим бакчасын үземә алам, йортын абзар итәм, ди икән. Булыр да, комсызлыгы житәрлек. Хуҗа табылганчы, сөйләш Сәлим белән, кечкенә генә булса да, үз почмагың булыр.

—Башта Әлмәт, Наратякларын әйләнеп кайтыйм әле мин. Илнарны, әбине күрәсе килә. Аннары карармын,—дигән идем, Фәрдия апа ул ниятемә каршы төште:

—Сузма, сеңлем, калган эшкә кар ява. Сәлим белән хәзер үк сөйләшеп, хәл итеп кит.

***

Һәм мин киттем. Гаепле башымны иеп, Сәлим янына, Авыл советына киттем. Кеше-кара күзенә чалынасым килмичә, Фәрдия апалар бакчасы аша су буена төшеп, кычыткан баскан тар тыкрык буйлап аръяк урамга чыктым.

—Көндез аны барыбер урында тота алмассың, кичке якта чыгарсың лутчы,—дигән иде Фәрдия апа.—Караңгы төшкәч,—дип тә өстәде.

Көне буе мин аларда качып яттым. Фәрдия апа минем хакта беркемгә әйтмәгән. Шуңа күрә авыл халкы «зимагур кызны» китеп барган дип белә. Бу турыда катык оеткысы сорап кергән Карга Мәмдүдәсе дә әйтте:

—Мидхәт кызы Даимәләрдән төн уртасында чыгып киткән икән. Зимагурлыкка бер өйрәнгәч, нәмәкаенә урын тапмый йөри инде хәзер. Шәһәрдә бандитлар шайкасына эләккән икән ул, шулар беркая җибәрмәгән ди. Бурлыкта йөрткәннәр. Дөньясын төяп кайткан, үзеннән дә зур сумка күтәргән иде, ди Даимә. Партурык кызлары шулай була инде ул, хи-хи-хи...

Ну сибә борчакны! Бу әкиятне үзе генә уйлап чыгардымы икән?! Жен ачуым чыкса да, иренемне тешләп түзәм. Тынны да чыгарырга ярамый. Мәмдүдә апа мине күрми, шуңа күрә теленә ни килде шуны лыгырдап утыра. Гомергә шул булды инде ул. Берәр гайбәт таратасың килсә, Мәмдүдәгә сөйлә, аңа эләксә, колхоз радиосына эш тә калмый, дип әйтмәсләр иде аны. Мәмдүдә апа мине, ә мин исә ду китереп аны сүгәм. Кызганыч, тетмәсен тетkәнне үзе генә ишетми.

Ә Фәрдия апа аңа каршы бер сүз әйтми, ышанган, шаккаткан булып, тел шартлатып утыра:

—И-и, шулаймыни?! Кара син аны!

—Ишеттеңме?—диде ул, Мәмдүдә апа чыгып киткәч.—Юри сөйләтеп утырдым. Үзең турында ни әйткәннәрен белеп тор, авыз ачып йөрмәссең.

Элеккеге «домприжи»ның бер почмагында хәзер Авыл советы икән.

Ә икенче почмагында Сәлим үзе яши. Энесе өйләнгәч, бу шулай «башка чыккан». Энесе өйләнгән, ә бу—юк. Зәйнәбе белән борчагы пешмәгән, күрәсең.

Күренмәс итә торган башлык юк шул, кешеләрдән күпме качсам да, кәҗә тыкрыгында очрады берсе. Каршыма килүче ул ир-атны куркып-шикләнеп көттем. Кем булыр бу, ни дияр? Иңе болай да бер адымнан артмаган тыкрыкны арлы-бирле инләп, уңга-сулга чайкала-чайкала килүче кеше шыр исерек Әрекмән Гомәре булып чыкты.

Минем янга килеп җиткәч, ике кулын да канат кебек җәйде дә, йөземә аракы, суган исләре бөркеп:

—Эләктеңме, кошчыгым!—диде.

—Эләктем, абзый, эләктем,—дидем мин.

—Вәт шулай диген... Эләгәсез шул, эләктереп торабыз... Их, алмагачлары, сайрый сандугачлары!

Мин җинел сулап куйдым. Дөньясы түгәрәкләнгән Госман абзыйның кайдадыр югалып йөргән Мидхәт кызында бер эше юк иде. Ул мине танымады да бугай.

Кунак йортының капкасын ачып кергәндә, Сәлим баскыч төбендә тәмәке тартып утыра иде. Мине күрде, бик озак дәшми генә текәлеп торды. Аннары тәмәкесенең көлен кагып, әле кичә генә күргәндәй, бик тыныч, битараф кына:

—Син китмәдеңмени?—дип сорады.

—Кая китәргә тиеш соң мин?

—Монарчы кайда йөрдең соң? Вәт шунда китәсең инде!

Балачак-яшьлек дустымнан мондый сүз ишетү бер дә рәхәт түгел иде. Аның күңелендә минем өчен урын калмаган бугай... Тик сабыр, Наргизә! Ни дип кочак җәеп каршыларга тиеш соң әле Сәлим?! Ничә еллар буе бер хат-хәбәрең булмасын да, ә ул сине уйлап-сагынып утырсын, имеш...

Горурлык бездә дә җитәрлек, ялынырга җыенган кеше юк. Каш астыннан гына сабакташымны күзәтәм. Безнең күрешмәгәнгә ун еллап гомер үткән икән. Вакыт дигәнең Сәлимне үзгәрткән, ныгыткан, аңа ирләр кыяфәте кергән: җилкәләр киң, беләкләр таза, яңаклар тулып тора. Өстендә диңгезче тельняшкасы. Бәлки флотта хезмәт иткәндер.

—Ярый, алайса, иптәш Гайнуллин, киңәшегез өчен зур рәхмәт. Сез боергач, китәрбез инде,—дип сөйләнә-сөйләнә капкага таба борылдым.

—Кыланма, Наргизә! Бала-чага түгелсеңдер, җитдиерәк булырга вакыт. Гомер буе кәҗә кебек сикереп йөри алмассың.

Минем тагы хәтер кала. Күр, ничек кылана берәү! Түрә булган икән. Күземә генә карап, тугры ялчым-сакчым кебек артымнан чапкан көннәрен оныткан.

Шулчак идарә ягындагы ишек ачыла, аннан, кулларын алъяпкыч итәгенә сөртә-сөртә чуар күлмәкле таныш түгел бер апа килеп чыга:

—Булды, энем, юып-җыештырып бетердем, мин китим инде. Сыерым көтүдән кайтмаган иде.

—Бар, бар, Асия апа.

Монардан тагы ниләр ишетермен икән дип, коймага сеңәрдәй булып басып торганда, ни хикмәт, апа, мине күрмичә, сәламемне дә алмыйча, бушлыкны сөзгән кебек яныннан үтә дә китә. Сәлим, уйларымны сизгәндәй:

—Курыкма, сине танымый ул. Читтән кайткан кеше,—ди.—Йә, сөйләп җибәр инде, классташ, ни йомыш белән килдең?

—Урамда сөйләшикмени?

Сәлим урыныннан кузгала:

—Бар, кантурга керә тор, анда ачык. Мин хәзер, киенеп кенә чыгам.

Кантур, имеш... Элек монда рәт-рәт карават тезелгән иде... Шунда Женя белән биегән идек... Уф, әби әйткәндәй, адәм ыстырамы, искә дә төшерәсе килми хәтта, уйласам да тәнем куырылып, күнелем өшеп китә...

Хәзер бу бүлмәгә бөтенләй башка, эшлекле төс кергән: уң якта китап шкафлары тезелгән, түрдә өстәл-урындыклар тора, диварда тонык карашлы Ельцин портреты.... Өстенә күлмәк-костюм кигән Сәлим керә, өстәл янына үтә. У-у, түрәләр кыяфәте бар монда, яшьтәш, сабакташ димәссең дә.

—Сәлим... Исемен белән генә дәшсәм ярыймы?

Сәлим елмая. Баягы усал, кырыс кыяфәтенен эзе дә юк. Күрүче, ишетүче булса дип кенә шулай кыланганмы әллә.

—Ну, канишны, Наргизә. Сорап торасың тагын. Кайларда югалып йөрдең син, юньсез кызый? Бөтен авылны утлы табага бастырдың бит, әй. Бу кадәр башсызлыкны көтмәгән идем синнән.

—Шулай шул, тилелек шул... Сәлим, әйдә бу турыда сөйләшмик, яме. Болай да авыр мина, бик авыр... Мин әтинең үлгәнен белмәдем бит. Белгән булсам, очып кайта идем. Белгәч, каберен күргәч...—Мин тынып калдым. Чөнки кинәт кенә күнелем йомшарып, күзләремә яшь тулды. Сәлим каршында һич тә мескенләнеп, елап утырасым килмәгән иде, ниһаять, иренемне кысып булса да, бераз тынычландым кебек. Дулкынлануымны сиздермәс өчен карашымны өстәлдә тәгәрәп яткан карандаш кисәгенә төбәп, сүземне дәвам итәм:

—Мин хәзер кая барып сугылырга да белмим, Сәлим. Барып керер, сыеныр почмагым юк. Үзең беләсең, йортыбызда чит кешеләр тора. Фәрдия апа Хөснижамал әбинең йортын сорап кара дигән иде дә...

—Наргизә! Син авылда яшәмәкче буласыңмы әллә?

Сәлим тавышында гаҗәпләнү дә, шатлык та бар кебек. Башымны күтәреп күзләренә төбәләм:

—Кая барыйм соң? Туган авыл бит...

—Бик шәп булачак бит бу, Наргизә! Әгәр монда калам дисен икән, мин бит сиңа...

Мин түземсезләнеп Сәлим авызына текәләм. Нәрсә тәкъдим итәр, ни дияр? Ләкин аның җөмләсе ярты юлда өзелеп кала.

—Хөснижамал әбинең йорты беткән инде аның. Түбәсеннән су үтә, нигезе черек... Бөтен җире сәләмә. Ул йортта яши алмыйсың син, аны өр-яңадан төзергә кирәк. Кайда эшләргә җыенасың соң, Наргизә, мәктәптәме?

Мин иңнәремне сикертәм:

—Әлегә белмим...

—Мәктәптә укытучылар җитми. Кайтмыйлар, тормыйлар авылда. Былтыр Җиһан апаны ата-аналар белән үгетли-үгетли эшләргә чак күндергән идек. Башкаларына түзәрсең, математика да укымасалар, шыр надан кала бит балалар. Рәхмәт инде, алтмыш яшендә булса да ризалашты. Ә быел, булмый, исәнлегем юк, ди.

—Мин математик түгел.

—Соң, башкасын укытырсың. Урыс телен, әдәбиятны. Әнә, Ясирә апа пенсиядә килеш аптыраганнан эшләп йөри. Җитми укытучылар, балалар җәл. Авыл баласы болай да кимсенеп үсә. Син кал, кал гына, Наргизә! Эш табылыр.

Авылда яшәргә ниятем булганга Сәлимнең балаларча сөенеп утыруы күнелне җылытып җибәрде: мин монда кемгәдер кирәк икән әле!

—Эш табылыр...—дим.—Тик син бит һаман әйтмисең, Сәлим, кайда яшим соң мин?!

Сәлим уңайсызланып башын ия, яңаклары алсуланып китә. Карашын читкә төбәп, тамак кырып куя:

—Менә шунда инде... минем янда... Сыярбыз.

«Фәрештәләр җирдә яшәми»,—дип кем әйтте соң әле? Мин үзем бугай... Ә бит ялгыш фикер булган! Менә ич шуларның берсе, күзгә күренмәс ак канатларын култык астына кыстырып, каршымда утыра түгелме? Җил кызы Наргизәнең—бернинди өмет-вәгъдәләр бирмәгән килеш, исәнме-юкмы икәнен дә белми!—кайдандыр-кайчандыр кайтып янына киләсен сабыр гына көткән дә көткән ди берәү...

Сәлимнең сүзе йөрәгемә май булып ятса да, сер бирмим. Уң кулымны күтәреп, балдагымны күрсәтәм. Күр, янәсе, хуҗабыз бар!

—Куркытма,—диде Сәлим.—Балдаклы булу—ирле булу дигән сүз түгел әле. Ирең булса, нишлим, кайда яшим дип аптырап, елап утырмас идең.

—Ул бар иде!

—Женямы? Кая китте соң ул?! Аттылармы әллә?

Женя исемен ишеткәч тә чирканып куйдым. Җәтмә корып, җирәнгеч оясында үз корбанын көтеп утыручы кап-кара симез үрмәкүч булып тоела миңа бу исем. Шуны уйлап-янып, көтеп-газапланып яшәгән ай-елларым, яшьлегем жәл. Мәхәббәтнең күзе сукыр диләр. Ут күреп, ялкын кочагына атылган сукыр күбәләк мин инде ул.

—Нигә аны атарга тиешләр әле?

—Атмыйлар шул! Дүрт-биш ел бирәләр дә, вәссәлам, кире чыгаралар... Белмисеңмени әле син?—Сәлимнең йөзенә ачу-нәфрәт катыш әрнүле елмаю кунды.—Алайса сөен-горурлан: җанкисәгеңне НТВ каналы күрсәтте, батырлыгын бөтен ил күрде.

—Батырлыгын?! Нишләгән соң ул?

—Гаражына кызлар алып килеп, затсыз киналар төшереп яткан. Анысы гына җитмәгән, бер мәктәп баласын мәсхәрә иткән. Тәмам азган, имансыз. Ярый әле теге чакта...—Сәлим сүзен әйтеп бетерми төртелеп калды.—Фәрештәң кебек саклап йөрдем бит мин сине.

Ул шулай диюгә, Женя белән печән өемендә аунаган җәйге караңгы төн искә төште. Шул чактагы хәлләр өчен оялудан битемә гена түгел, җаныма ут капса да, уңайсызлануымны Сәлимгә сиздерәсе килмәде. Бер гөнаһы юк кешедәй тыныч, битараф күренергә тырышып:

—Син идеңмени ул?—дип сорадым.

—Безнең кызларга кагылма дип, малайлар белән җыйнаулашып ярдык без аны. Жәл, аз эләккән, акыл керерлек булмаган. Андый хәшәрәтләрне вакытында сытарга кирәк.

—Женяны инде мең ел күргәнем юк.

—Бәхетең...—диде Сәлим.

Әйе, бәхетем... Женя кулыннан исән-имин котылуым бәхет. Әмма теге чакта минем куркаклыгым аркасында ерткыч тиешле җәзасын алмый калды. Явызлыкның юлы вакытында бүленмәсә, ул таулардагы ташкын сыман үрчи, көчәя бара. Әгәр шул чакта шәһәрдән чыгып качмыйча, эшне судка җиткергән булсам, бәлки, бу кансыз бәндә әллә кайчан төрмәдә утырыр, башка беркемгә зыяны тимәс иде...

Нигә дип Женяны искә төшерде инде Сәлим?! Үткәннәр белән дә җанны кыйнамаса, башка хәсрәтем юкмы? Тормыш юлыма кара күләгә булып сузылып яткан бер килбәтсез зат булды инде ул Женя. Аның дөньяда барлыгын бөтенләй-бөтенләй онытасым килә! Болай да ялгыш-хаталарым өчен күпме вөҗдан газаплары кичерәм, эчем-тышым ут ләбаса. Ялгыш өстенә ялгыш, үкенеч өстенә үкенеч... Ник тормышымның рәте-чираты юк? Әллә дөрес яшәмимме? Әнә бит Сәлим нинди акыллы, төпле. Аның бер үкенече юктыр, тормышы бер эздән җайлы гына барадыр. Үзе теләгәнчә, алдан ниятләгәнчә. Тик ул да никтер һаман ялгыз... Чынлап та, нигә ялгыз

соң ул, Зәйнәбе кайда икән?

Сәлимгә генә ирештерергә димәгән, мин дә аның авырткан сөяленә басып алыйм әле:

—Ә син нигә Зәйнәбенә өйләнмәдең? Шуның белән бик кайнар мәхәббәт куерта дигәннәр иде бит. Әллә борып җибәрдеме?

Сәлим башын чайкап, авыз ерды:

—Белмәгән нәрсәң юк синең, Наргизә. Берәрсенең мунча башында шыпырт кына безне күзәтеп, качып ятмагансыңдыр бит?!

Аннары карашы монсуланып китте, башын читкә борып:

—Соравына җавап шул: Зәйнәп мине көтмәде,—диде.—Урладылар аны. Миннән башка да кызыгучылар булган. Акыллы,чибәр кыз иде, әрәм китте. Хәзер ире белән ике бала үстереп ята.

Зәйнәпне мактап, шундый асыл кызны кулдан ычкындыруына үкенгән сыман сөйләвенә көнчелегем килде бугай:

—Яраткан иденмени?—дип сораганымны сизми дә калдым.

—Насыйп булмагандыр, күрәсең...

Сәлимнең йөзенә эчкерсез елмаю кунды:

—Менә... тугры кияү булып... синең «фронттан» кайтканны көтеп утырырга калды. Тәки җибәрмисең бит мине үзеңнән, Наргизәкәй, магнит кебек тартасың! Балачакта ялгыш колагыңны тешләгәнмен, ахры. Чыгасыңмы миңа кияүгә?

—Белмим...—дидем мин.

Сәлимнең шулай кистереп соравына, җитди тәкъдименә бу мизгелдә генә җавап бирергә әзер түгел идем, шуна да сүзне икенчегә борган булдым:

—Авылны бик сагындым, Сәлим. Су буйларында йөрисем, талымны күрәсем килә. Тик урамга чыгарга, кеше күзенә күренергә куркып ятам. «Кара йөз»ләрдәге Галимә кебек... Ничек кайтырга инде хәзер, Сәлим?

—Озатып куйыйммы соң?

Мин шатланып ризалаштым. Урамда берәрсе очрый калса да, янымда ул булгач, төпченмәс-бәйләнмәс. Ни дисәң дә Сәлим шырдый-бырдый кеше түгел—рәис, җитәкче! Мондый дусларың булу ярый шул. Ә бәлки ирем дә булып куяр... Әйтте бит, кияүгә чыгасыңмы, диде. Җавабын кистереп әйтә алмасам да, шул сүзе күңелне җылытып-иркәләп тора. Наргизә кемгәдер кирәк, мине яратучы-тансыклаучы бар...

Кычыткаңнарга чагыла-чагыла, су буенда чишмә җырын, бакалар талашканын тыңлап йөрдек. Әллә кайда, айлар-еллар артында, бик-бик еракта калган җәйге бер кич, шул сукмак буйлап көлешә-көлешә кайтып баручы әти белән Кифая апа, әтинең аңа: «Мин сине гомер буе күтәреп йөртер идем»,—дигән сүзләре искә төште... Мине кем күтәреп йөртер икән? Тукта, Сәлимне сынап карыйм әле! Тавышыма-йөземә төчелек чыгарып, сузып кына назланып дәшәм:

—Сәәлиим... Инеш аша күтәреп чык әле мине...

Сәлим, мизгел дә икеләнеп тормыйча очыртып күтәреп ала да, «ых» дигәнче теге ярга чыгарып та бастыра.

—Җиңел бит син, Наргизә. Гомер буе күтәреп йөрсәң дә була. Әгәр юанаймасаң.

—Юанайсам, суга ташлыйсыңмы?—дип шаяртам мин.

—Бер күтәргәч, ташлап булмас инде, ничек тә түзәрбез,—ди Сәлим.

Талым үз урынында икән! Сөенеп кочаклап алам үзен. Балачак кичерешләре уянып, күңел иләсләнеп куя. Түзмим, туфлиемне салып атам да, мәче кебек өскә үрмәлим. Ә үз оямa кереп утыргач, күңелгә сагыш урала, никтер елыйсы килә...

—Әй, кызый, кая югалдың? Төш инде, нишлисең анда?—дип кычкыра Сәлим.

Ә мин дәшмим, учым белән йөзем каплап тын гына сулкылдыйм. Елар өчен аулак шәп урын бу, беркем күрми, комачауламый. Мин үземне кызганам, үткәннәрне юксынам. Ул чакта әни дә, әти дә исән, дөньябыз түгәрәк иде...

Һаман төшмәгәч, тавыш-тыным булмагач, Сәлим үзе яныма менә.

—Әллә елый инде берәүләр? Синдә дә йөрәк бармыни?! Мин инде сине җансыз дип уйлаган идем.

Ул мине юатырга теләгәндәй инемнән кочып ала. Көчсезлегемне ана белдерәсем килмичә, яшь аралаш көлгән-шаярткан булам:

—Персидәтел башың белән агач башында йөрмәсәң соң...

Ә үзем суыктан куырылган чеби кебек аңа сарылам. Назга, җылыга сусап, кемгәдер сыенырга теләгән мизгелем иде шул. Сәлим чәчемнән сыйпый-сыйпый үзенекен сөйли:

—Ялгызың тилмереп йөрмә инде, Наргизә, житәр. Әйдә өйләнешик тә, бергә яшик. Ник бәхетеңне һаман читтә эзлисең син? Чык миңа кияүгә. Бергә җинелрәк булыр.

—Мин уйлармын, Сәлим. Тик син ашыктырма, яме...

***

Минем Наратта булганым бар. Шуңа күрә Нефтьчеләр урамын бик тиз таптым. Йортны да, квартирны да таптым. Анысы авыр булмады. Тик менә тапкач, ишек төбенә килеп баскач, әллә нигә куркып-каушап калдым. Билгесезлек өркетә иде. Илнарның кабул итмәвеннән, чит-ят күрүеннән курыктым мин. Энем—бу дөньяда бердәнбер якын кешем, туганым, газиздән газизем, соңгы өмет-шатлыгым. Әгәр аны да югалтсам, миңа бу җирдә буталып йөрисе дә юк. Ул чагында яшәүнең бер мәгънәсе калмый.

Кыңгырау төймәсенә басарга кыюлыгым житмичә, баскыч тоткасына сөялеп торганда, каршыдагы ишек ачылып китте. Аннан чүп чиләге күтәргән кечкенә башлы, шакмак гәүдәле бер әби килеп чыкты да, минем тарафка сынаулы-шикле караш ташлап аска төшеп китте. Ул кире менгәнче миңа тизрәк кереп китәргә кирәк. Югыйсә юк-бар сорау биреп, төпченә башлавы бар: «Кем син, кемгә килдең, нишләп монда торасың?..» Шәһәр карчыкларын беләм инде, алар эттән дә болайрак сак-уяу, ишекләре төбендә күренгән һәр ят кешедән шикләнеп: «Милисе!»—дип кычкырырга гына торалар.

Үземә кирәкле квартирның кыңгырау төймәсенә үреләм. Кыңгырау тавышы, ишек аша ишетелеп, елмаерга мәҗбүр итә: «Мияу-мияу-мияу...»

Кемдер сак кына басып ишеккә килә, йозак ачкычын бора... Каршымда Кифая апа пәйда була. Бер мизгел эчендә аңардагы үзгәрешне чамалап алам: ябыккан, суырылган, йончыган, картайган...

Кифая апа бер сүз дәшми, миңа текәлгән килеш тораташ катып басып тора. Аннары әкрен генә артка чигенә. Кулы белән генә «кер, үт» дип ишарәли. Киеренке тынлыкны үзем бозам:

—Исәнмесез, Кифая апа.

«Әйт инде, ни булса да әйт! Карашың белән үтерәсең ич. Ачулан, сүк рәхәтләнеп, тик болай карама миңа...»

Ниһаять, бер сүз ишетәм:

—Кереп утыр.

Мин диванга, ул каршыдагы кәнәфигә урнаша, кулларын кушырып, туп-туры күземә текәлә. Карашымны яшермим, үги анама сынап карыйм: күзләрендә сөю балкышы сүнгән, тормышы җиңелләрдән түгел икәне борчулы йөзенә язылган... Элек биленнән булган озын чәчләре малайларныкы кебек кып-кыска калган, алар хәзер кара түгел, бакыр төсендә. Чаларганга буяп йөридер, әнә бит чигәләрендә, буявы уңганмы,

буялмый калганмы, көмеш чәчләре ялтырап тора...

Сизәм, күрәм: Кифая апаның минем белән сөйләшергә теләге юк. Йөзе карангы, карашы төксе. Чакырылган, көтеп алган кадерле кунак түгел шул мин. Ләкин болай, бер-берсен өнәмәгән мәчеләр сыман сырт кабартып утырып та булмас. Нидер әйтергә, сөйләшергә-аңлашырга кирәк, күңелдәге төерләрне кабат учлап, баш иеп чыгып китәр өчен килмәдем ич монда.

—Мин авылда булдым, Кифая апа, барысын да беләм...

—Белми кая барасың...

—Курыкма, синең өстә яшәргә килмәдем. Илнарны күрәсем килә.

—Шулаймыни?!

—Кифая апа, беләм... мин гаепле...

—Мидхәтне кайтарып булмый.

—Кайтарып булмый... Әнине дә, әтине дә кайтарып булмый... Йорт та юк... Иң башта зиратка кергән идем, Рабига апаның каберен күрдем. Менә шулай, Кифая апа... Әнисез калуның, ятимлекнең ни икәнен хәзер син дә беләсең. Тик синә ничә яшь тә, миңа ничә...

Кифая апа кисәк урыныннан кузгала:

—Ярар, сүз белән тамак туймас. Чәй куйыйм, ачыккансыңдыр. Киләсеңне белгән сыман күп итеп кыстыбый пешергән идем.

Ул шулай дигәч, күңел җылынып китә. Үз йортыма, якын кешеләремә кайткан сыман тоела башлый. Карашым белән бүлмәне айкыйм. Квартир ят булса да, монда безнең йорт исе. Һәр нәрсә таныш, күңелгә якын: китап шкафы, сервант, түгәрәк өстәл, диван... Җансыз әйберләр дә шулай якын, үз булыр икән. Өйдә тынлык. Кифая апаның савыт-саба шалтыратуы, су агызган тавышлар гына ишетелә. Балалар кайда икән? Илнар кайда?

—Наргизә, табынга кил.

Мин авылдан алып килгән күчтәнәчләрне өстәлгә тезәм. «Буш кул белән барып кермәссең, яхшы түгел»,—дип Фәрдия апа йомыркалар, авыл каймагы, сөт, үзе пешергән күмәчне биреп җибәргән иде. Кифая апа «рәхмәт» әйтеп аларны алып куя.

—Илнар кайда соң, Кифая апа?

—Лагерьда алар, Дилбәр дә, ул да. Үзем ял алып, квартирны ремонтларга ниятләгән идем.

—Ә-ә...—Мин сүземне әйтә алмый тукталып калам. Бәрәч, кечкенә малайның исемен дә белмим ич!

Ни гаҗәп, Кифая апа мине сүзсез дә аңлый:

—Данис бакчага йөри әле. Быел укырга керергә җыенабыз.

Әнекәем! Кайчан гына туган малай инде мәктәпкә бара! Туганнарымнан читтә, әтине, әнемне күрми узган ай-елларымны кызганып, йөрәгем тагы бер кат сыкрап куя. Ни калган иде инде миңа җиде-ят җирләрдә?! Әби әйтмешли, тилебәрән орлыгы ашаган нәстәкәй!

Данисны алырга бакчага бергә бардык. Үзем теләп иярдем. Әтинең улын тизрәк күрәсем килде. Каршыма гүя кечкенә Илнар йөгереп чыкты, шул ук карлыган күзләр, куе керфекләр, түгәрәк йөз, туры кашлар. Данис башы-аягы белән әти малае иде! Әнисенә тамчы да охшамаган. Шуңа күрә бер күрүдә үз иттем, кочып аласым, йомшак яңакларыннан үбәсем килде. Ләкин энекәш миннән ятсынды. Их, адым саен үкенеч тә, үкенеч, шул гомер качып йөрмәгән булсам соң... Ул чагында әтигә охшаган бу сөйкемле малай «Апа!» дип миңа килеп ягылыр иде! Тагын бер якын туганым булыр иде. Бу дөньяда туганнарың күп булу начармыни?!

Минем кичерешләрне Кифая апа сизде, улын үз иткәнне дә аңлады бугай. Шуңамы, карашы җылынып китте. Ана күңеленә юл бала йөрәге аша сузыла икән.

—Улым, бу синең Наргизә апаң,—диде Кифая апа.

—Ә син кайдан кайттың?—дип сорады Данис.

—Ерактан, бик ерактан.

—Син самолетка утырып кайттыңмы?

—Юк, поезд белән. «Тыкы-тыкы-тыкы-тыкы» дип җырлый торган шундый озы-ын, зу-ур машина.

—Ә минем поезд күргәнем бар. Без әни белән вокзалга барган идек.

Данисның кулын бер яктан Кифая апа, икенче яктан мин тоткан. Данис безне берләштерде, шул кечкенә генә кеше, үзе дә белмичә, әрнүлеүпкәле ике ятим күңел арасына күпер салып куйды. Данис—әтиемнең улы, энекәшем, туганым. Ул да минем кебек үк Солтанов фамилиясен йөртә. Шулай булгач, аның әнисе дә миңа чит-ят булырга тиеш түгелдер.

—Ә син миңа нәрсә алып кайттың?—дип сорап куйды кинәт Данис.

Оятымнан җир тишегенә кереп китәрдәй булдым. Вәт, башсыз, кем инде сабый янына буш кул белән килә? Кесә ягы такыр анысы, әллә ни сибелер җай юк. Шулай да баланың күңелен күрергә кирәк.

—Әйдә, кибеткә керәбез, мин сиңа туңдырма алып бирәм. Үзең яратканны.

Туңдырма янына берничә киндер-сюрприз да өстәлде. Йомырка эченнән машина килеп чыккач, Данисның күзләре очкынланып китте, авызы колакка җитте. Ә өйгә кайткач, ул мине үз «байлыгы» белән таныштырды, киндер-сюрпризлар белән шактый зур тартма шыплап тулган иде... Әтиемнең төпчеген бик яраттым, үз иттем бит әле мин. Кифая апа күрмәгәндә генә әле чәченнән сыйпап, әле куеныма кысып, иркәләп-үбеп алам. Тик малайга минем мәхәббәт тансык түгел, кагылсам, ризасызлык белдереп ыңгыраша, читкә этә башлый. Чөнки аны яратучы-назлаучылар бу ят ападан башка да җитәрлек.

Әгәр исән-сау булып, вакытында туса, Янгураз белән безнең улыбызга өч яшь булыр иде... Шул турыда уйласам, бәгырьгә яшь төелә.

Данисны йоклаткач, Кифая апа белән бик озак сөйләшеп утырдык, үткәннәрне искә төшереп, елашып та алдык. Соңлап булса да, бер-беребезне аңладык кебек. Язмышлар уртак, икебез дә үз парларын мәңгелеккә җуйган сыңар канатлы яралы кошлар...

—Наргизә, теге чакта син мине аңларга теләмәдең, гаепләдең генә... Беләм, миңа үч итеп шулай иттең. Бәлки, чынлап та, ул чакта үзем дә артыгын кыланганмындыр. Нишлим соң, үләргә җитешеп яраттым бит Мидхәтне. Гомерем буе аны гына яраттым, башка беркемгә күңелем ятмады. Көнче кешеләрнең сүзе генә аерды бит безне. Аңлашасы урынга, янәсе үч итеп, беренче очраган кешегә иярдем дә киттем... Яшь чакта кан кызу, алдын-артын уйлап тору юк. Ирем үлгәч, ичмасам, күз алдымда булыр, һәр көнне күреп, хәлен белеп яшәрмен дип авылга кайткан идем. Менә ничек килеп чыкты... Тыеп булмый ул хисне, Наргизә, берничек тә тыеп булмый. Кайнар күмер өстенә төшкәндәй бәргәләнәсең. Син әле аңламыйсың, синең алай яратып караганың юктыр.

—Бар, Кифая апа... Минем дә яратып караганым бар.

Һәм мин аңа Янгуразым турында сөйлим. Кифая апа сабыр гына тыңлый.

—Күргәнсең икән син дә... —ди.

Аннары, башын учлап уйланып торганнан соң, күземә туры карап әйтеп куя:

—Наргизә, китмә син беркая да, яшик шунда бергә. Миңа да җиңелрәк булыр. Уңайсызланма, бу йортта синең дә өлеш бар. Чит кешеләр түгел, сыярбыз.

***

Шулай итеп, мин Кифая апа янында калдым.

Икәү җиң сызганып квартир ремонтларга керештек. Беркайчан болай дәртләнеп, тәмләп-ләззәтләнеп эшләгән юк иде бугай. Мин бит гашыйк булдым! Үз энемә, Даниска! Һәр иртәне аны бакчага илтәм, кичен барып алам. Шул бала белән аралашу минем өчен җан рәхәте. Кочаклап йокламыйм гына инде үзен. Кифая апа көлә:

—Үзеңә бала табар вакыт җиткән, әниләр инстинкты уянган синдә,—ди.

Бәлки шулайдыр да... Яшь бара бит, ә табигать дигәнең барыбер үзенекен итә ул.

Ремонтны йокы бүлмәсеннән башладык. Җәйге аяз күк сыман зәңгәрсу обойлар ябыштырып чыккач, бүлмә иркенәеп, янарып киткәндәй булды.

—Икәү булгач, рәхәт шул. Ялгызым ничек ерып чыгармын дип кот очып торган иде. Минем бәхеткә кайткансың икән,—ди Кифая апа.

Аның сүзе йөрәгемә май-бал булып ята. Әле дә кайттым, әле дә килдем дип сөенәм.

Сөйләшә-сөйләшә икәү тәрәзә буйыйбыз.

Кифая апа зарланып та ала. Ялгызына өч бала белән җиңел түгел. Наратка килеп урнашырга аны Миндар абый күндергән, танышы «Наратнефть» тә эшли икән. Шуның аша Кифая апаны яхшы эшкә, кантурга урнаштырган.

—Авыл җирендә бакча тотмый, мал асрамый яшәп булмый. Берьялгызым ничек тартыйм? Булмый ул миннән. Колхоздагы хезмәт хакы да ташка үлчим, тиеннәр генә түлиләр. Өч баланы аякка бастырасы бар. Барысын уйладым-үлчәдем дә, күчәргә тәвәккәлләдем инде,—дип акланды ул миңа. Йортыбызны сатканга үзең гаепле сизә, ахры.

—Ике йорт, сыер, бозау хаклары менә шул ике бүлмәле квартирга керде дә китте, Наргизә. Әле анда да кеше искесенә кереп утырдык, балконы да юк. Быел гына ремонтка акча арттыра алдым. Син дә эшкә урнашсаң, бергәләп җиңелрәк булыр иде. Житкереп бетерә торган түгел, бер тишекне ямыйсың, икенче җирдән сыпылып чыга. Ашау белән генә түгел, балаларны кешечә киендерәсе дә килә.

Кифая апаның сүзе күңелгә канат куйды: мин биредә артык җан түгел, туганнарыма кирәк! Әгәр син кемгәдер кирәк икән, димәк, яшәвеннең мәгънәсе бар, дөнья буйлап куып йөртүче, алга өндәүче максатың бар.

—Кая урнашырмын икән соң, Кифая апа?

—Хәзер халык сатуда, базарда инде. Исең китмәсен, сезнекеләр дә, хәерчелектән качып, шунда чыгып басты. Түләмиләр бит мәктәптә. Сатар өчен академик булу кирәкми, акча саный белсәң, шул житә.

Билгә алъяпкыч ябып, бөеремә таянып базарда сатып торуымны күз алдыма китердем. Һм, ярыйсы күренеш... Башыңа төшсә башмакчы булырсың. Тик ни сатармын икән? Күлмәк-ыштаннар, чәй-кәнфит, тавык-балык... Шулчак Ният базары искә төште: «Бу йокку кел! Сотиб олинг, гузал!» «Канча туради?» Бик күңелле эш булачак бу, кулдан килер кебек.

—Анда да тора салып чыгып булмыйдыр бит, Кифая апа, товары кирәк, урыны...—дим.

—Алары синең кайгы түгел. Безнекеләр кара халыкка ялланып эшли. Товар да, урын да аларныкы, бөтен базарны шулар басты инде.

—Сәер... Тегеннән урыс-татарны кудылар да, хәзер үзләре монда хуҗа булып йөриме?! Алай дигәннән, Фатыйма апаларның хәле ничек икән, хат язам дигән иде бит ул. Ә хат авылга киләчәк.

—Кайгырма, барыбер монда җибәрәчәкләр аны,—ди Кифая апа.—Минем адрес бар анда, пучты кызларына калдырдым.

Анысы хак, кирәк булса, эзләп табарлар. Кифая апаның адресын миңа Сәлим биргән иде.

—Әбине дә күреп кайтасы иде,—дим мин.

—Мин ялда чакта бергәләп барырбыз.

—Үземне генә җибәрергә куркасынмы?

—Куркам да шул. Сиңа эләгәчәк, белеп тор.

—Ничек анда сыйды икән әби, Хәмидә апага якын килерлек түгел иде бит?

—Миндар абый исән чакта сыяр анысы. Ул исән булсын, дин. Уф, Наргизә, башым әйләнә, буяу исенә исердем, ахры. Ташла, артыбыздан куучы юк, сөтләп чәй эчеп алыйк әле.

***

—Ял көнне лагерьга бергәләп барырбыз. Илнарны күрерсен,—дигән иде Кифая апа.

Ниһаять, түземсезләнеп, дулкынланып көткән бәхетле көн килеп җитте.

Түгәрәк эчендә әйләнүче тиен кебек бер үк сукмакларда буталып йөрим бугай мин. Менә кабат унсигезенче җәемә кайтып, кайчандыр үзем эшләгән лагерь капкасы төбендә басып торам. Хәзер бирeдә минем энем ял итә.

—Сез шунда көтеп торыгыз, мин аларны чакырып киләм,—дип китеп барды Кифая апа.

Данис тик тормый, шәп кенә чыбык табып алган да, шунын белән кычыткан-әрекмәннәр кыйнап йөри. Ни кызыгын табадыр. Малай-шалайга ватарга-җимерергә булсын. Мин тирә-якны күзәтеп, теге җәйне искә төшерәм. Менә шунда Әхсән исемле егет белән тарткалашып басып торган идек... Мине эзләткән, көткән арада, койма тактасына пыяла кисәге белән кыра-кыра, алдап әйткән исемемне—«Гөлнара» дип язып куйган иде... Ул исем генә түгел, коймалар да юк инде хәзер. Аларны тимер рәшәткәгә алыштырганнар. Корпуслар шул ук. Таганнар да шул ук. Үткәннәр белән очрашу күңелгә моң-сагыш сала, гомереңнең мәңгелеккә китеп югалган көннәрен кызганып-юксынып куясың...

Карашым лагерь ягына юнәлә. Асфальт җәйгән киң сукмак буйлап Кифая апа килә. Бер ягында Дилбәр, икенчесендә Илнар. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш, башка кеше була алмый. Әгәр урамда күрсәм, мин Дилбәрне генә түгел, Илнарны да танымый үтәр идем. Икесе дә тартып үстергән кебек ябык-озыннар, муен озын, кул-аяклар озын... Үсмер чакта берара шыксыз үрдәккә охшап каласың бит.

Аларга каршы атлыйм. Дулкынлануым чамасыз.

—Илнар!

Мин энемне кочып алам, шатлыклы да, әрнү-үкенечле дә хисләрне тыя алмый, сулкылдап елап җибәрәм. Илнар уңайсызланып кочагымнан аерыла, кызарган-бүртенгән йөзен читкә борып, иренен чәйни. Мин аны йотылып күзәтәм. Үзгәргән Илнар, җитдиләнгән. Борын астында йомшак төкләр куерып, каралып киткән кебек. Минем энекәшкә дә мыек чыгып килә... Ул миңа карамый, дәшми. Аның күңелендә ниндидер көрәш бара, күрәсең: кабул итәргәме бу зимагур апаны, әллә әзрәк үпкәләргә, якты чырай күрсәтми газапларгамы.

Дилбәр безгә кызыксынып карап тора. Кифая апа Илнарны үз итеп иненнән кага да:

—Апаң белән иркенләп сөйләшегез, улым. Без Данисны барлап килик әле, урманга кереп китмәсен тагын,—дип кызы белән бергә капкага таба юнәлә.

Апалы-энеле, кулга кул тотынышып, сукмак кырындагы эскәмиягә килеп

утырабыз. Илнар аптырап калган кебек, үзен ничек тотарга белми. Бәлки мин аның өчен бөтенләй югалганмындыр, ул мине күңеленнән күптән сызып ташлагандыр. Балаларның хәтере кыска, алар бары тик хыянәтне генә гомер буе оныта алмый. Ләкин мин бар, исән, минем буласым, туганлык жепләрен кабат ялгыйсым килә! Шуңа күрә күзләренә текәлеп, энем күңеленә юл эзлим, аңа якынаерга телим. Тик кирәкле сүзләрне таба алмыйм.

—Илнар... Энем! Зинһар, үпкәләшмик, туганнар булып калыйк. Бу дөньяда синнән дә якын кешем юк.

Илнар миңа карамый гына сорап куя:

—Син хәзер безнең белән яшисеңме?

—Сезнең янда, Илнар, сезнең белән бергә. Кая барыйм тагын? Без Данис белән дә дуслаштык инде. Ул сиңа охшаган, гел синең бәләкәй вакытың инде. Әти малае.

—Әти сине көтте, эзләде.

—Беләм.

—Син кайда йөрдең соң?

—Майлысуда, Фатыйма апаларда яшәдем.

—Әти анда хат язган иде... Фатыйма апа алдаган икән. Ул бит, Наргизә бездә юк, дип жавап биргән.

—Аны ачуланма, энем. Фатыйма апа түгел, мин шулай алдап яздым... Хәзер үзем дә бик үкенәм... Дөрес эшләмәдем шул, алай кирәк булмаган. Тик үкенүдән файда гына юк, әтине кайтарып булмый...

—Әти сагындыра...—Илнар читкә борылып, күзләрен сөртеп ала.

Минем дә күзгә яшь тыгыла, энемнең каршына тезләнеп, кулларын кысам:

—Без хәзер гел бергә булырбыз. Мин сине... сезне башка беркайчан ташламам. Үпкәләмә, кичер мине, энем.

Илнар кулын тартып ала. Дәшми. Һаман читсенә, ятсына бугай. Үсмер чакта шулай кыргыйрак буласың инде. Мин исә аннан карашымны алалмыйм, энемдә әти чалымнарын күреп шатланам. Соңгы арада әллә нишләдем әле. Артык нечкәреп киттем димме, күздән яшь тамарга гына тора.

Энем олыларча бик житди итеп әйтеп куя:

—Әле ярый әни... Кифая апа бар. Яхшы кеше ул.

—Мин беләм, аңладым. Ул үзе мине Наратта калырга күндерде.

—Син аңа авыр сүз әйтмә, яме, апа. Рәнжетмә әнине.

И бала! Теге чактагы кыланмышларымны һаман онытмаган икән әле.

—Юк-юк, Илнар, рәнжетәмме соң?! Син борчылма, без Кифая апа белән дуслаштык, аңлаштык инде.

***

Юлга аласы төенчекләрне алдан хәзерләп, ишек төбенә чыгарып куйдык та, идән буярга керештек.

—Яхшы булды бу, зур эш эшләнде. Без кайтканчы кибеп тә куяр,—диде Кифая апа.

—Уф, бөтен жиремнән ацетон, буяу исе килә. Ялгыш бер очкын төшсә дә, учакка әйләнәм бит хәзер,—дип көлдем мин.

—Алла сакласын диң, шулай янып үлүчеләр бар. Үзем дә исердем бугай, тизрәк урамга чыгыйк.

Өчәүләп вокзалга юнәлдек. Исәбебез—бер-ике кич Әлмәттә кунак булып кайту. Ике куянны берьюлы тотмакчы булабыз: идән дә кибә тора, әбине дә күреп кайтачакбыз. Әбине бик сагындым, тизрәк күрәсем килә.

Ачуланса ачуланыр, анысына гына түзәрбез. Үзе әйтмешли, үз бакчаңда үскән кычыткан чакмый ул.

Кифая апа юлда сөйләп килде: Миндар абыйларда март аенда гына туй мәшәкатьләре булган, Венераны кияүгә биргәннәр икән. Уфага ук китеп барган. Хәзер өчәү генә яшәп яталар. Миндар абый да, Хәмидә апа да эшли икән, әби көне буе өйдә ялгызы.

Без килгәндә Хәмидә апа өйдә иде. Сменалы эшкә күчкән икән. Ул Кифая апаны бик ачык каршы алды, Данисны да аркасыннан кагып сөйгән булды. Ә миңа мыскал да игътибар юк. Ләм-мим. Әйтерсең, мин кеше дә түгел, әйтерсең лә, күзгә күренмәс бәндә, бары бушлык кына. Күрмәсә-сөйләшмәсә тагы, аның янына килмәдем лә! Шуңа да, Хәмидә апа янында озын-озак тоткарланмыйча, тизрәк әби бүлмәсенә уздым.

Миндар абыйларның квартиры өч бүлмәле. Венеранықында хәзер әби яши икән. Аяк очына гына басып, бүлмәгә кердем. Әби өстенә мамык шәлен ябынып, караватта ята иде. Бер кулын маңгаена куеп, күзләрен каплаган, икенчесе күкрәк өстендә. Нечкә бармаклары хөрмә төшләрен ефәк җепкә тезеп үзе ясаган дисбесен кысып тоткан. Күнелгә мөлдерәмә тулган шатлык хисләрен көчкә тыеп, бүлмә уртасында тын гына басып торам. Әбинең йокысын, тынычлыгын бүләсем килми. Ләкин ул янында кемдер барлыгын барыбер сизде, сискәнеп, башын күтәрде. Миңа бераз текәлеп торганнан соң, тыныч кына:

—Син кайттыңмыни, кызым?—диде.

Әбинең тавышы элеккечә кырыс түгел, йомшак, көчсез иде.

—Кайттым, әби...

—Кияү ни хәлдә соң? Ул да кайттымы?

Башта аңламый тордым, аннары башка барып җитте:

—Әби, мин Венера түгел. Мин—Наргизә бит...

Әби кулын селтәде дә, кабат йөзен каплады. Аннары:

—Әй шул саташуларым...—дип әрнү белән ыңгырашып куйды.—Раббым, акылымнан да яздырма инде. Ләхәүлә вәлә куәте иллә билләһи галиил газим...

Мин карават янына килеп чүгәләдем дә, йомшак кына әбинең иңеннән, беләгеннән сыйпадым:

—Әби, син саташмыйсың, бу мин, Наргизә. Мин чынлап та кайттым!

Әби тагын калкынды, тоныклар күзләре бик озак миңа төбәлеп торды:

—Ник кайттың? Син бит Мидхәтемне үтердең. Ни йөз белән каршыма килдең, тилебәрән орлыгы ашаган нәмәстәкәй?—Бу сүзләрне ул элеккечә ярсып, кычкырып түгел, пышылдап, әрнеп әйтте.

—Әби...

Ул миңа сүз әйтергә дә ирек бирми, кисәк бүлдерде:

—Кая, торырга булыш әле миңа. Билемне кузгаттым. Әле дә таралмый инде бу кортлы сөякләр. Картайган да калҗайган шул...

Мин әбине аркасыннан кочып торгызам да, артына мендәр салып, диварга сөяп утыртам. Үзем аның янына, карават читенә урнашам. Сагынган карашым газиз, кадерле йөзгә төбәлә.

Әби картайган... Кечерәеп, бөрешеп калган. Йөзенә кадәр ябыккан, тире дә сөяк кенә, борыны, ияге очлаеп тора. Шәһәр һавасы килешмәгәнме, әллә хәсрәт җиле кагылгангамы, бу йөздән нур качкан, саргаеп, төссезләнеп киткән кебек. Хәтта куе кашларына кадәр агарып, күзенә салынып төшкән.

—И-и Алла... Ничекләр генә яшәп бетәргә бу дөньяда...—дип ыңгырашты әби. Ахрысы, бик сызлана иде.

Бераз хәл җыеп утыргач:

—Авылда булдынмы әле син?—дип сорады.

—Әйе. Әтинең каберен күрдем... Мин бик үкенәм, әби.

Ләкин әби сүзләремне ишетми дә:

—Йорт исәнме анда?

—Исән.

—Теге килмешәкләр тирескә батырмаганмы? Бөтен нәрсә урынындамы?

—Урынында, әби, кайгырма.

—Бакчаны карыйлармы?

—Карыйлар, мин кайтканда бәрәңге күмәләр иде.

Әби ачынып уфтанды:

—Әй, Раббым! Иректә көннән гомер иткән йортынны ташлап кит инде. Сатмаска иде дә бит, тынламады Кифая! Ходай ярдәм бирер иде әле. Авылда ни хәлләр бар? Үлем-китем юкмы?

—Хөснижамал әби үлгән.

—Котылган икән бичаракай. Ул да рәхәт күрмәде инде. Күршеләр исәнсаумы? Кемнәрне күрдең?

—Исәннәр иде. Мин Фәрдия апаларда кундым. Ул сиңа сәлам әйтте. Онытып та торам, хәер итеп чәй дә җибәргән иде.

Әби бисмилла әйтеп, чәйне алды да, учларын йөзенә китереп дога кылды. Шулчак үз бүләгем дә искә төште. Ният базарыннан әбигә атап шәмәхә чәчәкләр сибелгән, ялтыравыклы яшел яулык алган идем, шуны әбигә суздым.

Әби аны әйләндереп-әйләндереп карады:

—Бигрәк матур. Яшьрәк чакта шундый яулыклар булса икән ул... Кайчан, кая гына бәйлим инде мин моны? Дөньяга чыгасым бармы, көне-төне шул таш капчыкта бикләнеп ятам. Әниеннең рәнҗүләре төшкәндер инде, картлык көнемдә рисвай булдым.

Шулай да яулыкны пөхтәләп төреп, түшәк астына тыгып куйды үзе.

—Әби, иялдәштенме инде монда?

—Калганына түзәрлек тә, убырныйлары бик ипсез, һич җайлаша алмыйм шуңа. Таһәрәтләнгәндә суны түгеп бетерәм. Хәмидә ачулана аннары.

Әби үпкәләгән сабый төсле иренен турсайтып куйды. Аннары оятыннан качар урын тапмагандай башын боргалап, идәнгә төбәлде:

—Адәм ыстырамы! Өйдә йомышлап ят инде...

Әбием миңа шундый кызганыч булып тоелды. Күңелем нечкәреп аны кочаклап алдым. Ул башта кымшанмый, таш курчак кебек катып утырды да, ахыр чиге сабырлыгы бетеп, мине йомшак кына этеп җибәрде. Төчеләнергә яратмый торган кырыс гадәте һаман калган икән. Ә минем аңа сыенасым, иркәләнәсем килә. Үзеңне каккан кешегә әллә ныграк та тартыласың инде.

Әби миңа, язмышыма бөтенләй битараф икән, хәлемне дә сорашмый дип эчтән генә үртәлеп-үпкәләп торганда, сүз, ниһаять, миңа күчте:

—Син кайда инде хәзер? Атаңнан качып йөри торгач, үзең дә йортсыз калдың бит, зимагур.

Без әби белән озак кына сөйләшеп утырдык. Соңрак Кифая апа кереп, ул да сүзгә кушылды. Ләкин әби аңа әлләни ачылып китә алмады, йортны сатканга үпкәсе зур иде, ахры. Аның каравы Данисны күреп сөенде, күңелендә булган бар җылы, бар наз шул бәхетле җанга элəкте, аны аркасыннан кага-кага: «И-и, гел улым инде бу бала, ошаса да ошар икән әтисенә! Мидхәтемне күргәндәй булдым»,—дип такмаклады.

... Киткән чакта әби, күзләремә мөлдерәп карый-карый, кулларымнан тотып ялварды:

—Бөтен өметем синдә, балакаем, калдырма мине монда. Сагынуларга

түзәр чамам юк, якты дөньяның бер яме калмады. Зинһар, алып кайт авылга! Соңгы сулышымны алыр өчен булса да алып кайт. Андый-мондый хәл булса, әтиең янына җирләрсез.

Әби миңа беренче тапкыр «балакаем» диде...

***

Шулай итеп, без бер оя булып яши башладык.

Минем өстә ике бурыч: берсе тизрәк эшкә урнашып, гаиләгә акча кертү, энекәшләрне кайгырту, икенчесе—әбине авылга алып кайту. Ләкин боларның икесен бергә берничек тә бәйләп булмый... Авылда эш бар, торыр җирем юк. Монда торыр урыным бар, эш тә табармын. Тик бу авыл түгел, һаман шул ук шәһәр, шул ук таш йорт, шул ук «убырный»... Шулай да әбигә безнең янда җинелрәк, рәхәтрәк булыр кебек, ни дисән дә, көне буе ялгызың тилмереп яту түгел. Аннары гомер буе бергә яшәгән үз кешеләр. Кифая апага:

—Әллә әбине үзебезгә алып кайтыйкмы?—дигән идем, ул кашын җыерып:

—Кит аннан, юкны сөйләмә!—диде.—Кая инде монда, болай да туалетваннага чират торабыз ләбаса. Әнигә тынычлык кирәк. Торган урыны бик яхшы! Үзенә аерым бүлмә, улы янында.

Анысы дөрес инде. Хәмидә апа явыз булса да, Миндар абый «әни» дип өзелеп тора. Ул исән чакта әбигә кадер-хөрмәт тә, тәрбия дә булыр. Урыны түрдә. Өс-башы чиста, тамагы тук... Пенсиясе килеп тора. Ләкин әби бәхетсез. Әбинең күзе яшьле...

—Наргизә, башыңа артык бәла алма, зинһар. Әбиең яшисен яшәгән, ашыйсын ашаган инде. Карчыклар турында уйлаганчы, балаларны кайгыртыйк. Хәзер бит укыту да түләүлегә әйләнеп бара.

Әйе, тизрәк эшкә чыгарга кирәк. Артык тамак булып Кифая өстендә ятып булмас. Мин туп-туры район мәгариф бүлегенә юнәлдем. Әлегә базарга чыгып басарга уйлаган кеше юк.

Хәзер бакчаларда татар төркемнәре ачылган, туган телне яхшы белгән тәрбиячеләр кирәк икән. Мин сөенә-сөенә ризалаштым. Түләү аз булса да, бакчада эшләүнең бер яхшы ягы бар, сер түгел, ашау-эчү шунда үтә. Дөрес, бөтенләй бушка түгел, аның өчен хезмәт хакыннан күпмедер тотып калалар, тик ул әлләни сизелми.

Исәп-хисап эшләрен белсән, бәлки безгә дә урнаша алыр иден, дигән иде Кифая апа. Тик Миндар абый кистереп әйтте, нефть оешмаларында кыскартулар булачак, махсус белемең булмаган килеш, анда борын тыгасы да юк, диде.

Өйрәнгән-белгән эш дип, мин кабат бакчада эшли башладым.

Фатыйма ападан күптән көткән хат килде. Авылны әйләнеп килеп житкән тәки.

«Исәнме, Наргизә!

Ниһаять, сиңа хат язарлык хәбәрләр булды кебек. Мәш килеп урнашып йөрдек бит әле. Кеше өстендә озак яшәп булмый, Әнәс белән бер бүлмәле фатирга кердек. Кыйбат инде түлке, ай саен биш йөз тәңкә умыралар. Безнең йорт саткан акчага монда бер телевизор гына алырлык.

Эшкә урнашу авыр, җүнле эше юк. Бөтен җирдә ябылу да кыскарту. Эшләгәннәре дә айлар буе акча алалмый интегә. Әнәс үз ишләрен тапты, базарда үзбәк малайлары белән фруктылар сата. Әрсезлеге ярап куйды. Бөтен өмет Әнәстә хәзер. Минем аркада өйләнми дә калыр инде ул бала, утыз биш яшендә дә үз оясы юк. Кем уйлаган шул хәлдә калырбыз дип. Хан сарае кебек йортны бушка диярлек калдырып киттек. Әй бу дөньялар,

кешечә яши башлагач кына, болганды да куйды.

Рамиләләрнең бер хат-хәбәре юк. Үзем язган идем, җавап күренми әле, килерме, белмим. Дөньясы буталган заман бит.

Россия гражданствосы булмагач, прописка табып булмый. Пропискасыз гражданство алып булмый. Әкияттәге саескан хәлендә калдык, башны алсаң—койрык ябыша, койрыкны алсаң—баш... Кая барсаң да майларга, акча төртергә кирәк. Минем пенсия юллар вакыт җитә, ана хәтле ничек тә гражданство аласы иде инде. Сабир җайларбыз дигән була.

Үзем әлегә эшләмим. Больницада медсестра эше бар барын. Тик сменалы, төнлә дә эшләргә кирәк. Башканы табалмасам, шунда чыгармын, мөгаен. Акчасы ташка үлчим инде түлке.

Татарстанга кайткан булсак, лутчырак буласы икән. Анда, ни дисәң дә, үзебезнең халык. Качакларга ярдәм күрсәтәләр, акча да бирәләр, имеш. Хәерле булсын инде. Хәзер кабат кузгалырга бернинди рәт юк.

Безнең соңгарак калып кайтуыбыз хәерлерәк тә булган икән, сеңлем. Фирганә чуалышыннан соң ук халык бөтенләй шыр-ялангач чыгып киткән. Минсылу атлы бер хатын белән танышкан идем, барысын ташлап, товар вагоннарына төялеп кайттык ди. Җитмәсә, юлда да талаганнар үзләрен. Элек мондый хәлләрне кинода гына карый идек, сугыш вакыты диярсең. Элек тып-тыныч яшәгән халык әллә нишләде, бер-берсенең бугазына ябышырга гына тора, әллә ахырзаман җитүе хакмы икән? Алла сакласын.

Синең хәлләр ничек соң, туганым? Мидхәттән әләккәндер инде. Ярар, анысына гына түзәрсең, ни дисәң дә чит кеше түгел, үз атаң. Кифаясы котыртып тормаса, җайланыр. Син кайтып төшкәч, анысы кара коелгандыр инде. Үги ана янына сыюлары ай-һай гына шул, Ходай ярдәм бирсен.

Энең, әбиең ни хәлдә, исән-сау торганнармы? Илнарга сәлам әйт дисәм, ул мине хәтерләмидер дә инде. Гөлзадә исән вакытта рәхәтләнеп аралаша да алмый калдык. Һаман вакыт җитмәде, җитмәсә ара да ерак. Хәерле булсын инде, гомер үтеп бара. Үз иленнән аерылма икән ул.

Сеңлем, бик сагындым үзеңне, бергә яшәгәч, гел үз кызыма әйләндең. Хәлләреңне әйтеп хат яз, яме. Адрес әлегә шул булыр. Күрешергә насыйп булсын, амин!»

Хат мине сөендерде. Әнәс югала торган малай түгел, әрсезнең бәхете алдан йөри. Үз квартирлары булмавы гына начар. Күпме акчалары кеше баетуга китеп бара.

Фатыйма апа әтинең үлгәнен башына да китерми, әлбәттә. Әни дә, әти дә иртә киттеләр шул... Кем әйтте соң әле, Фәрдия апа бугай, Гөлзадә Мидхәтне артык яратты, шуңа күрә Кифаяга калдырмады, барыбер үзенә тартып алды, диде. Ләкин әти миңа, әбигә, Илнарга, Даниска да кирәк иде. Кифая апага да кирәк иде ул. Ике ирдән ике ятим бала кочаклап кал әле. Җитмәсә, үгиләре дә синең өстә булсын. Юк, мин кат юк, Кифая апа язмышы кирәкми миңа. Бәхетле булып яшисе иде! Тик ничек бәхетле булырга? Бәхетле булыр өчен нишләргә кирәк?

***

Хезмәт хакы алган көнне кибетләргә сугыласы иттем. Замана үзгәргән, хәзер алар «магазин» гына түгел, һәркайсының үз исеме бар: «Алтын ай», «Якташ», «Яз», «Ак каен»... Исемнәре дә матур, җисемнәре дә. Безнең яклар да баеган хәзер. Базар тулы әйбер, кибет киштәләре сыгылып тора. Элек акча бар, алыр нәрсә юк иде, ә хәзер киресенчә. Ни телисең—шул бар, акча гына юк, дип уфтана халык. Җор күңелле кешеләр, кибеткә кереп чыккач, музейда йөрдем әле, дип шаярткан була.

Үземә берни алмадым. Акчаны тулаем Кифая апага кайтарып бирергә

ниятләдем. Бер казанга ике тәкә башы сыймый диләр. Баш бухгалтер да, кассир да ул, үзе карасын.

Шулай да, акча алган көнне буш кул белән кайтып керәсе килми. Малайларны сыйлыйм, шатландырыйм дип ике пакет тәм-том җыйдым. Төянеп кайтып килгәндә, яныма бер җинел машина килеп туктады да, 25-30 яшьләрдәге ир, тәрәзәдән генә үрелеп:

—Утыр, апасы. Сумкаларың авыр күренә, бик арыгансың, ахры, көчкә атлыйсың,—диде.

Хәзер! Теләсә нинди машинага утырырга башыма тай типмәгән лә. Бер кат пештем инде сезнең брат белән, бер утка ике тапкыр кермиләр. Моны ишетмәмешкә салышып кызу-кызу атлый бирәм. Тротуар кырына килеп туктады бу. Машинасыннан чыкты да, каршыма килеп басты:

—Яхшылыкны аңламыйсыз икән, матурым. Мин сиңа чын күңелдән булышмакчы булам бит, валлаһи газыйм!

Егет кулын күкрәк турысына куеп, йотардай булып миңа төбәлә. Бу йөздә иң беренче урынны мыек тота. Чем-кара, куе, бик шәп мыек. Икенче урынны кашларга биреп булыр иде. Өченче урынга йомры борын лаек. Шулар арасыннан күзләрне чамалап табалсаң бик яхшы. Күзләр әллә кайда, куе, калын кашлар астында, еракта, тирәндә. Алар серле упкын кебек алдый, үзенә чакыра, суыра, йота... Бу егеттә сихер бар, моннан ераграк булу яхшы.

Егетне күрмәгән-ишетмәгәндәй юлымны дәвам итәм.

—Кыланма инде, апасы, әйдә, утыр. Момент өеңә кайтарып куям!

—Рәхмәт, мин кайтып җиттем инде.

—Алдама, җитмәдең әле! Йортың кайда икәнен бик яхшы беләм мин!

Дәшмим, туктамыйм. Бәйләнер-бәйләнер дә, өмет юклыгын аңлагач, кул селтәп китәр әле. Күргән инде аның кебек сагызларны.

—Вәт киребеткән кызый! Сине ашарга җыенган кеше юк, шул хәтле кыргый булмасаң,—дип мыгырдана-мыгырдана басып кала егет.

Кайткач, ванна бүлмәсенә кердем дә озак кына көзгегә карап тордым. Картаясың, Наргизәкәй җанкисәк... Вакыт синең өчен генә туктап тормый, быел егерме җиде тула бит. Синең кебекләр, әнә, бәби үстерәләр инде. Бакчаңа балаларын алырга дип үзеңнән дә яшь әниләр килә... Янгураздан башка беркем кирәкми дисең дә, гомер буе аны уйлап, ялгыз яшәрсеңме?

Үз-үзем белән бәхәскә керәм: юк, мин ялгыз түгел, энекәшләрем бар, мин аларга кирәк. Әнә бит, күчтәнәчләремә ничек сөенделәр, бүген бездә бәйрәм булды.

Анысы шулай. Ләкин энекәшләрең үсәр, матур кызлар киләксенә башлар. Һәркайсы үз тормышын корыр. Ә синең үз ояң кайда булыр соң, Наргизә? Гомерең буе Кифая апаң янында яшәрсеңме? Әлегә матурлыгың бар, кызый, яшьлегең дә мәңгегә хушлашып офык артына китмәгән. Шөкер, егет-җилән күзе төшәрлек әле үзеңә. Ә тагы биш-алты елдан әйләнеп караучы да булмас. Карт кыз булып утырып калырсыңмы? Энекәшләрнең үз малай-кызлары үсәр, Наргизә апаларының кирәге дә калмас... Этелеп-төртелеп кадерсез җан булып йөрерсеңме?

Юк, миңа андый киләчәк кирәкми. Тотам да Сәлимгә кияүгә чыгам!

Шундый карар-исәп белән йокларга яткан идем, төшемдә тагын Янгуразны күрдем.

Имеш, кып-кызыл мәк чәчәкләре тирбәлеп утырган дала икән. Күк йөзе үтә күренмәле пыяла кебек, шундый чиста, бер болыт әсәре юк. Еракта зәңгәр томанга төренгән таулар тезмәсе күренә. Мәк чәчәкләре арасында Янгураз белән икәү басып торабыз.

—Син ничек кайттың соң, Янгураз? Син бит үлгән идең. Җир астыннан чыгып буламыни?

Янгураз дәшми, елмая гына.

—Син башка китмисеңме, югалмыйсыңмы? Миңа синнән башка шундый авыр, Янгураз.

Янгураз миңа төбәлә дә кып-кызыл мәк чәчәкләре суза...

Шунда төш өзелә.

Бу төшне мин инде ничәнче тапкыр күрәм. Һәр төштә бер үк сүзләрне кабатлыйм: «Син ничек кайттың, Янгураз? Бу юлы чынлап та кайттыңмы?» Һәр төшемдә Янгураз бер аваз сүз дәшми...

Барган идек без ул далага. Офыкларга кадәр сибелгән кып-кызыл эре-эре мәк чәчәкләренә шаккатып карап торган идем. «Аларны җил чәчеп үстерә. Һәм җил җыеп та ала»,—дип көлгән иде шул чакта Янгураз. Аннары Фатыйма апа сөйләде, ул мәкләрне яшел килеш җыеп алалар да, анаша дигән наркотик ясыйлар икән... Кем үзе өчен, ә кемдер сатып, табыш ала.

Их, Янгураз, ник син төшләремә кереп, мәк чәчәкләре сузасың миңа?! Мәк чәчәгенең гомере бары бер көнлек кенә ич. Кояш белән бергә уянып, бар дөньяны балкытып нурлар чәчеп утыра да, кичен ут-таҗларын коеп, гап-гади үсемлеккә әйләнә. Янар чәчәк урынына имән чикләвеге кадәр генә өлгермәгән әче җимеш кала. Шул яшел җимеш афьюн икән... Гөл-Чәчәк урынына башны әйләндерә, акылдан яздыра торган агулы афьюн... Мәхәббәт үзе дә афьюн булып, гашыйк кеше колга, акыл-ихтыярын җуйган зомбига әйләнәме әллә? Шулайдыр, мөгаен. Берәрсен шашып сөйсәм, акылымнан язып, тәмам диванага әйләнәм ич. Үз юлымнан, дөньямнан ваз кичеп, чит биләмәгә кереп югалам да, шунда саташып, адашып йөрим. Женя белән дә, Янгураз белән дә шулай булды...

... Бер уянгач тиз генә йоклап китеп булмый, әйләнәм, борсаланам. Без, өч хатын-кыз, йокы бүлмәсендә, ә малайлар түрдәге диванда йоклый. Дилбәр әнисе белән бергә ятарга теләмәгәч, җәелмәле карават алып кайтып бирдек. Кичтән бездә урын җәю, ә иртән шуларны җыю мәхшәре башлана. Менә шулай ду килеп яшибез. Башкалар белән мөнәсәбәтләр яхшы, Илнар да хәзер минем белән якын итеп, үз итеп сөйләшә. Тик менә Дилбәр белән генә һич уртак тел табып булмый. Якын да килми, әйтерсең мин аның үги анасы. «Игътибар итмә, бу яшьтә шулай кыланалар инде алар»,—ди Кифая апа. Үзең нинди идең соң, дип тә өстәп куя...

Бүген дә минем күчтәнәчләргә кагылмыйча, «Я не хочу!» дип фырылдап икенче бүлмәгә кереп бикләнде.

Әй, йокы качкан башка әллә нинди уйлар үрмәли башлый инде. Төн—уйларның уенга чыгар вакыты, ахры. Котыра-сикерә рәхәтләнеп бииләр.

***

Торган гына түгел, эшләгән урынны да белә икән, бакчадан чыккан җиремә Кара каш, кара мыек мине көтеп тора иде инде.

—Такси подан, пажалыста, прашу, матурым,—дип елмая.

Каршына басып, турыдан ярып сорадым:

—Ни кирәк сезгә?

—Башта утыр, аннары сөйләшербез.

—Әйтмисең икән, бигайбә, без җәяү йөрергә өйрәнгән!—дидем дә, кырт борылып, эре генә китә башлаган идем, бу мине куып җитеп, беләгемнән эләктереп алды:

—Алайса, телефоныңны бир.

—Безнең телефон юк.

—Алайса, үзең шалтырат. Менә шул номерга.

Кара каш, кара мыек миңа уч төбе хәтле генә кәгазь сузды. Күңеле булсын, бәлки башка бәйләнмәс дип аны алган булдым.

—Түлке шалтырат, әбизәтелне!

—Ярар.—Бу бәйләнчектән тизрәк котылырга кирәк иде...

—Ник шалтыратмадың?—диде ул миңа икенче көнне.

Мин куркуга төштем, йә Ходаем, җүнле бәндә түгел, чирледер бу... Каян гына, нигә генә очрады соң миңа? Ачуымнан өзгәләнеп кычкырдым:

—Ни кирәк сезгә миннән? Ни кирәк?! Зинһар, бәйләнмәгез, минем ирем, ике балам бар!

—Юк! Ялганлама, бернинди ирең дә, балаларың да юк. Мин беләм.

Хәлсезләнеп бакча коймасына сөялдем:

—Сез маньякмы соң әллә? Ник болай эзәрлеклисез мине? Кешечә сөйләшеп буладыр ич.

—Үзең бит кешечә сөйләшергә теләмисең, матурым. Утыр машинага дим, һаман киреләнәсең.

—Ник мин синең машинаңа утырырга тиеш?

—Шулай кирәк!

Юк, моның белән кешечә сөйләшеп булмый. Ләкин мин аның турында барыбер ни дә булса белергә тиеш. Башка чарам калмаса, милициягә үк барырга туры килмәгәе, Алла сакласын.

Сагаеп кына сораган булам:

—Ичмасам танышыйк инде, кем соң сез, кайда эшлисез?

Ләкин тыныч кына бирелгән бер зыянсыз сорауга да җүнле җавап ишетергә насыйп булмады. Кара каш мыскыллы елмаеп:

—Мин бит сиңа любуй исемне әйтә алам, шуңа ышанырсыңмы? Любуй эшне дә атый алам,—диде.

—Ярый... алайса, болай итик, ммм... исемсез иптәш. Мин синен машинаңа утырам...

Кара кашның мыеклары өскә күтәрелде, мыек астында энҗе тешләре балкыды.

—Тик бер шартым бар. Машинаңа утырганны дустым күреп калырга тиеш. Номерыңны язып, сине хәтерләп калырга тиеш.

Ризалашмас дигән идем, шундук бик шат тавыш белән:

—Күптән шулай диләр аны! Булды, сөйләштек, матурым!—диде бу.— Чакыр дустыңны. Кирәк булса, аны да өенә илтеп куям.

Шулай иттек. Кофе төсендәге «Жигули» машинасына утырып китүемне, егетнең төс-кыяфәтен бергә эшләүче Светлана күреп-карап калды. Нишлим, башка чарам юк, шикләнәм, куркам. Куркам да, шул ук вакытта бу сагыздан да тизрәк котыласым килә.

Вакыт кичкә авышкан иде инде. Машина Әлмәт юлына чыгып, шәһәр кырындагы кирпеч йорт янына килеп туктады. Мин егеттән җавап көтәм. Миңа нинди сүзе, ни йомышы бар икән моның. Ул исә юл буе ләммим сүз дәшмәде. Йорт каршына килеп туктагач та, берни әйтми, машинасыннан төшеп, ишекне ачты.

Урынымнан кузгалмый ачу белән:

—Йә, әйт сүзеңне,—дидем.

—Тукта, ашыкма, башта өйгә керик.

—Андый сөйләшү булмады.

—Курыкма инде шулкадәр, Ходай бәндәсе! Ай-яй, тәмам котыңны алганнар, куян кебек калтырыйсың. Сине ашарга җыенган кеше юк ла. Әйдә, төш тизрәк, миңа китәргә кирәк.

—Ә мин?

—Син каласың, матурым. Хәзер дүрт ягын кыйбла. Мин үз бурычымны үтәдем.
—Төшмим! Кайтарып куй мине хәзер үк!
—Кайтаручылар булыр. Мин китердем, бигайбә.
Шыр тиле бит бу, психавыру, нишләгәнен үзе дә белми. Ничек машина йөртә түлке, кайсы җүләре бу диванага права тоттырган диген?! Икенче кат бер үк капкынга килеп каптым бит ангыра баш, бар икән дөньяда бер уңмас, бәхетсез җан. Туктале, Наргизә, нәрсә дип моның машинасына ябышып утырасың әле син, төш яхшы чакта. Әнә бит, әйтеп тора, китәм, ди, дүрт ягың кыйбла, ди. Әллә юлны табалмассыңмы. Шул котылу бит инде ләбаса. Утырдың, килдең, Кара кашның күңеле булды... Күрәсең, чире шулдыр. Үзе теләгәнне эшләде, башка бәйләнмәс.
Мин машинадан төштем. Ул утырды. Авызын ерып, көлеп китеп барды. Светлананың тырыша-тырыша номер язып калулары юкка гына булды. Бу егет миңа тырнак очы белән дә кагылмады, гомер аяк басмаган таныш түгел аулак бер урамда ялгызымны бастырды да калдырды. Ерагайсын, күздән генә югалсын тизрәк, мин дә әкрен генә калага таба атлармын. Күз күргәндә юлны табарбыз.
Шулчак мине сискәндереп, кирпеч йортның тимер капкасы шыгырдап ачылды да, каршымда 40-45 яшьләрдәге үзе озын, үзе чандыр бер апа пәйда булды.
—Сез Наргизәме?—дип миңа эндәште.
—Әйе.
—Алайса, керегез, сезне көтәләр.
Бу хатынның исемне белүе бер аптыратса, шушы мәһабәт йортта кемнәрнеңдер мине көтүе бөтенләй гаҗәп иде. Кабаланып сорадым:
—Кем көтә? Нигә көтә?
—Анысын кергәч күрерсез.
Һаман урынымнан кузгалмый, икеләнеп торуымны күреп, ул тамак кырып куйды, кыенсынып кына:
—Хуҗабыз баласына тәрбияче эзли иде...—диде. Аннары карашын читкә төбәп:
—Шикләнмәгез, бу йортта сезне начарлык көтми, монда тәртипле кешеләр яши,—дип өстәде.
Тәртипле, имеш... Тәртипле кеше шулай итәме?! Баласына тәрбиячене шулай куркытып, «богаулап» китертмәсә, кешечә сөйләшеп булмый идеме? Котымны алдылар тәмам, чирләп егылуың бар. Бай дигәч тә... Керәм дә йөзенә бәреп әйтәм хәзер. Кыланмасыннар, кимсетмәсеннәр кешене.
Шулай да, бу житди апаны күргәч күңел тынычланып китте. Аның артыннан иярдем. Капкадан ишек төбенә хәтле асфальт юл җәелгән, ике якта да аллы-гөлле кашкарый чәчәкләре үсеп утыра. Бигрәк матур, күзгә, күңелгә рәхәт. Бу ишегалды авылдагы йортыбызны, әни карап-тәрбияләп үстергән чәчәк тулы бакчабызны искә төшерде. Мондый гүзәл гөлләр үскән җирдә начарлыкка урын булмас дип, ят йортның авыр ишекләрен ачып эчкә үттем.
Байларның байларча шул, ишек төбеннән үк күренә. Карашым белән стеналарны айкап чыгам. Алар нарат такта белән эшкәртелгән, урман исе, нарат исләре аңкып тора. Иркен булгач, кием элгечләре дә аерым, ике таякка болан мөгезләре кигереп куйганнар да, вәссәлам, бик җайлы элгеч килеп чыккан. Коридор буенча ике якка дүрт ишек уелган. Хатын, кулы белән шуларның берсенә, түрдәгесенә күрсәтеп, үтегез, диде.

***

Мин кергәндә хужа, бүлмә уртасындагы купшы кәнәфигә утырып телевизор карый иде. Экранда бер көтү ир чирәмле кыр буйлап берберсен этә-төртә туп артыннан чаба. Футбол-хоккей дигәннәрен гомергә аңламадым инде мин, ир-ат халкы кай җиренә мөкиббән китәдер? Бу да шул фанатларның берсе бугай, кергәнемне сизмәде дә. Утырган урыныннан кинәт алга калкынып, кулларын тезенә шапылдатты: «Давай, давай! И-иих, пешмәгән!» Хуҗаның тавышы көр, колакларны яңгыратырлык иде. Үзе дә футбол кыры буйлап чабамыни! Мин аның стадион хәтле кин аркасына ачу белән карап тордым. Байлар, имеш! Үзләре үк мәҗбүриләп «конвой» белән китергән кешегә тамчы да игътибар юк. Уен беткәнен көтеп, сәгать буе бусагада таптанып торыйммыни хәзер?! Алайга китсә, исәнләшмихушлашмый, чыгып та китәрмен әле! Сезнең алда эреп төшәргә җыенган кеше юк, әфәндем! Хәерче булсак та, бездә дә горурлык җитәрлек. Кем әйтмешли: «Йортыбыз читән булса да, сортыбыз бүтән!» Шулай да үземнең мондалыгымны сиздереп, коры гына:

—Исәнмесез!—дигән булдым.

Хужа миңа таба борылды...

Көтелмәгән хәлдән кычкырып ук җибәрдем:

—Булат?!

Ул торып басты, каршыма килде.

—Әйе, бу мин, Наргизә. Онытмагансың икән әле.

Вәт сиңа мә! Бар икән күрәселәр.

—Булат, нигә болай... куркытып... Кешечә булмый идеме?

—Гафу ит, шулай килеп чыкты инде. Үзен бит...

Булат кулындагы пультның төймәсенә басып, телевизорны сүндерде. Эчтән генә сөенеп куйдым: әһә, мин футболга караганда мөһимрәк икән әле!

—Йә, исәнме, Наргизә. Әйдә утырып сөйләшик.

Вакытында әйтте, утырмасам, егыла идем. Битем учлап, башым чайкыйм:

—Үтерә яздыгыз бит, ни уйларга белмәдем. Нигә кирәк булды инде бу кәмит?!

—Кәмит түгел, Наргизә, сине күрәсем, сөйләшәсем килде.

—Кешечә дә сөйләшеп буладыр бит, Булат. Мин җансыз уенчык түгел ләбаса. Шулай куркытып китермәсәң...

—Алай булырга тиеш түгел иде лә... Вилсурга әйттем, каршыма китереп бастыр шул кызны, мәйтәм. Ул сине ничә көн сагалап йөрде, үгетләде. Үзең киреләндең бит һаман.

Каршымда кайчандыр миңа ярдәм кулы сузган дустым торса да, күнелдәге ачу болыты таралырга ашыкмый. Кеше белән шулай уйнарга, шаярырга ярый димени?! Ни уйларга белмәдем бит.

Кашымны җыерып, аның сүзләренә эреп төшмәвемне сиздерәм:

—Синең балаңа тәрбияче кирәкмени? Ә нигә мин? Наратта башка тәрбияче калмаганмы?

Булат елмая:

—Ызначыт, калмаган. Ызначыт, син кирәк.

Мин усаллашуымны дәвам итәм:

—Булат, күрәм, син баегансың, зур кеше булгансың. Тик, зинһар, балаңны карарга башка кеше тап! Минем үз эшем дә җитәрлек.

—Үпкәләшмик әле, Наргизә, рәнжеткән булсам, гафу ит. Әйдәле икәүләп, рәхәтләнеп бер кич утырыйк. Яшьлекне, үткәннәрне искә төшерик. Бар иде бит яшь чаклар, кесә тулы борчаклар, иеме, Наргизә?

Булат кулымнан тотып торгыза да, житәкләп аш бүлмәсенә алып керә. Ә анда мине капка төбендә каршы алган апа табын корып маташа.

—Калганын үзем карармын, апа. Рәхмәт сиңа,—Булат хатынны иннәреннән кочып каршыма китереп бастыра:

—Таныш бул, Наргизә, бу минем бертуган апам Әминә булыр. Охшаганмы миңа?

Мин әле озын буйлы хатынга, әле шкаф хәтле Булатка карыйм да:

—Охшаган!—дим.

Икесенең дә йөзләре кояш кебек балкый.

—Иң яраткан апам ул минем! Калган туганнар читтә, әти белән әни авылда, без Наратта ике генә бөртек калдык.

Әминә апа безнең белән хушлаша:

—Мин китим, сез иркенләп сөйләшегез. Булат, духовкага тавык тыккан идем, сүндерергә онытма.

Табын янында икәүдән-икәү утырып калабыз. Булат терсәкләрен өстәлгә куеп, башын бармакларыннан корган күпергә салган да, йотылып күземә төбәлгән. Шундый яратып, иркәләп карый, карашы белән жылы, йомшак мамыкка төрә. «Акчарлак» ресторанында бергә үткәргән кич искә төште. Ул чакта да күземә генә карап тора, миннән өметле жавап көтә иде. Әллә һаман гашыйк инде? Күрешмәгәнебезгә күпме гомер үткән ләбаса.

—Бер сорау биримме, Наргизә? Ачуланмыйсыңмы?

—Биреп кара.

—Син нигә балдак киеп йөрисең?

Ирем юк икәнне белә, шуңа сорый.

—Ул бик кадерле кешем, киявем бүләге.

—Кайда инде хәзер ул кияү?

Булатның күзләрендә ниндидер киная, көлү чагыла кебек. Мин карашымны яшереп, башымны иям:

—Үлде ул...

Булат йөзеннән мыскыллы елмаю кача. Ул шундук житдиләнеп кала:

—Гафу...

—Без бары алты гына ай яшәп калдык.

—Берүк гафу итә күр... Белмәдем. Ачуланма, дустым, ярана кагылдым.

Булат урыныннан торып, суыткычтан шешәләр чыгарды:

—Нәрсә салыйм? Виномы, коньякмы, аракымы?

—Берсе дә кирәкми, Булат. Мин синең янда озак утыра алмыйм. Өйдә югалтырлар.

—Алай булмый инде. Очрашу хөрмәтенә шәраб булса да күтәреп куйыйк. Ә өйдә кем көтә сине?

—Үги анам, балалар...

—Ярар, алар мужик түгел, көтсәләр дә була.—Булат минем бокалга кызыл шәраб, үзенекенә коньяк сала.—Дустым, мин сине ике атна элек үк күргән идем инде. Бик эре генә атлап тротуардан бара идең, ә без машина белән үтеп киттек. Нужэли Наргизә, мәйтәм. Әллә охшаган кеше генәме дим. Син булып чыктың. Дәшәргә кыюлык житмәде. Теге чакта яратмыйм, хуш, дип китеп бардың бит. Вилсурга куштым, минем личный шофер ул, белеш, мәйтәм, кайда тора, кайда эшли. Килерсең дигән идем. Синең белән иркенләп сөйләшер өчен хатын белән кызны Кара дингезгә, курортка озаттым бит. Хәзер как раз бархатный сезон анда, рәхәтләнсеннәр, мәйтәм. Ә без Наргизә белән, яшьлек дус белән иркенләп бер сөйләшеп утырырбыз, мәйтәм. Их, дускаем, икәүләп урам себереп йөри идек бит без, ә! Сагындыра хәзер шул чаклар. Йөз сум акча ала идең, кесәңә сала идең—синнән бәхетле кеше юк! Керәсең ысталовайга, ике паднус тутырып ашарга аласың: гуляш,

пилмән, каймак... Хөррият бит, малай, ә! Ә хәзер... Акчанын да кызыгы юк, тормышнын да. Бөтен нәрсә бар, күрәсендер—йорты, машинасы, мебеле, чурты... Өстәл тулы ризык. Ул кызлар... Үзләре килеп асылына. Акча исен бик тиз сизә ул чукынчыклар. Алланын кашка тәкәсе булдым бугай мин, барысы да күктән ишелеп төшкәндәй артык җинел килде. Бәяләр уйнап тора, акча явып тора... Ике кибет хуҗасы хәзер абзаң. Ну кызык юк. Юк! Ник алай ул, Наргизә?

Булатны тынлаган саен күңелдә ризасызлык, бу кешегә карата үпкә-рәнҗү хисләре арта, җан үртәлә. Башкасы булмаганнан аптырап, үзенә кысыр хәсрәт уйлап чыгарган да, мин аны юатып утырырга тиеш икән.

Кызык юк, имеш. Менә безгә кызык...

—Шуны сорар өчен мине чакырдынмы? Мин психолог түгел, Булат. Үз проблемаларым да җитәрлек.

Булат өстәл аша кулыма сузыла, бармакларымны назлап кысып сорый:

—Әйт, нинди проблемаң бар, җаным?

—Сиңа нигә?

—Вәт кызык син! Мин бит монда кечкенә кеше түгел, абзанда көч-гайрәт бар, Аллага шөкер! Күп нәрсә эшли алабыз. Әйт кенә, ни кирәк сиңа?

Мин Булатның чиста итеп кырылган шома, тук йөзенә, очкынланып торган зәңгәр күзләренә дәшми генә карап торам. Бу күзләр мина мутланып, нидер көтеп-өметләнеп карый кебек. Бу күзләр артына яшеренгән күңел бик татлы, ләззәтле дөньяда йөзә кебек... Мин белгән Булатмы соң бу? Әллә тышкы кыяфәте генә аныкымы? Мин белгән Булатта масаю, кылану дигән нәрсә, тәкәбберлек тамчы да юк иде. Мин белгән Булат матур күңелле, эчкерсез, әдәпле кеше иде...

Ирен читем белән кинаяле елмаеп сорыйм:

—Алтын балык булдыңмыни? Әллә чуртанмы?

Булат кычкырып көлеп җибәрә:

—Ә ни аермасы бар? Алтын балык булды ни дә, чуртан балык булды ни. Икесе дә бер балык башы түгелмени?! Әйдә, синенчә булсын, мин—алтын чуртан ди. Йә, ни телисең, дускаем?

Мин белгән Булат болай ямьсез итеп көлми иде... Ул күз алдымда үзгәреп, котсызланып бара: яңаклары чөгендер төсенә керде, күзләре томанланды. Исерде бит бу. Күрәсең, мин килгәнче үк «репетиция» ясап куйгандыр. Исерек кешедән яхшылык көтмә инде. Исергәч, чит кешедә түгел, үз туганына, хәтта үз-үзенә дә ышаныч калмый... Ишетеп түгел, күреп беләбез. Яхшы чакта таярга кирәк моннан.

—Теләгем шул, хөрмәтле алтын чуртан: син мине хәзер үк өемә кайтарып куй!

Булат башын чайкап, нык итеп кулымны кыса:

—Юк, бу теләкне үтәмибез. Бусы ин-ин соңгы теләк булырга тиеш!

***

Уйламаган-көтмәгәндә безгә Сәлим килеп керде. Юк йомышын бар итеп, шикәр заводына чөгендер китерүче машинага утырган да килгән. Балалар мәктәптә иде, без өйдә Кифая апа белән генә, беребез өй җыештырып, икенчебез кер юып маташа. Шул чакта ишек «кычкыра»: «мияу-мияу...»

Ачсак, авыз ерып Сәлим басып тора!

—Исәннәрмесееез! Керергә ярыймы?—ди.

Ярамыймы соң, дусларга ишек ачык, урын түрдән.

—Гаепләмәсәгез, килдем әле. Хәлләрегезне белеп чыгыйм дидем.

Хәл белүче кунагыбыз бик юмарт булып чыкты, җилтерәтеп ике

капчык бәрәнге кертеп куйды, сумкасыннан ит, күпереп торган авыл ипие чыгарды:

—Болары—күчтәнәч. Ипине әни махсус сезгә атап пешерде. Күргән-белгәннәрдән кайнар сәламнәр тәяп килдем.

Бар эшебезне ташлап, йөгерә-чаба түргә табын корырга керештек. Кифая апа белән без диванда, Сәлим каршыбызда утыра. Сүзгә-сүз ялгана торгач, әңгәмә әкрен генә җанланып китте.

—Авылда ни хәлләр бар?

—Авыл урынында да анысы...

Сәлимнең карашына монсулык инә, тавышы боеклана:

—Рәүф абый малае Рамилне кайтардылар бит әле...

Без тиз генә аңламыйбыз:

—Кайдан? Нигә?

—Чечнядан инде. Әле былтыр көз генә авылдан үз аягы белән чыгып киткән иде... Һаҗәр апа йөрәк белән егылды. Болай да исәнлеге шул чама гына иде.

Вакыйгалар кабатлана, язмыш-фаҗигалар, әрнү-югалтулар кабатлана... Шул мәгънәсез сугышларны оештырып, кеше балаларын ут эченә тыгучы кансыз бәндәләрне җир йөзеннән себереп куасы иде!

Сәлимдә дә шул ук уйлар икән, минем башта кымырҗып яткан фикерләрне кычкырып әйтә:

—Рамил алтын бәясе егет иде. Болай да авылда калырга атлыгып торучы юк. Яшьләр шәһәргә кача. Әнисе гел-гел чирләп торгач, Рамил беркая китмәде, калхузда калды, тракторга утырды. Ул бармаганнан гына армия ишелмәс иде әле, калдырсалар да була иде. Ә авылда эшләргә кеше юк. Бер кирәкмәгәнгә кан коеп йөргәнче, басуларга чыгарасы иде барысын да, чөгендер, бәрәнге үстерсеннәр иде. Файда булыр иде ичмасам!

Сәлим үпкәләгән-гаепләгән төсле миңа карап куя. «Син дә качтың» диюедер инде.

—Авыл бетә... Бетә гөрләп торган «Шатлыгыбыз»... Дөресе, бетерәләр. Уйлап карагыз, дүрт ел элек безнең фермада өч йөздән артык терлек иде. Быел ике йөзгә дә тулмый. Тугыз трактордан бишәү калды. Калганнарын запчастькә сүттеләр. Җиде машинаның өчесен генә курыкмыйча юлга чыгарып җибәреп була. Калганнарын хет бүген утилгә озат. Техника җитмәгәч, биш йөз гектарга якын җир сөрелми-чәчелми калды. Ел саен хужы да хужы. Сөтне өч тиенгә алалар, ун сумга саталар. Дәүләт үзе иң оятсыз спекулянт ул. Ит-сөт саткан акча бензинга да җитми. Бөтен уңыш кредит түләүгә китеп бара...

Сәлимне мондый халәттә күргәнем юк иде әле. Җыелышта доклад ясыймыни. Аның әрнеп-ярсып сөйләвен авыз ачып тыңлыйбыз. Туган авыл язмышы өчен шул хәтле янса да янар икән кеше. Яшь чагында ук, моннан беркая китмим, дигән иде шул. Тәки сүзендә торды, сабакташлардан ул гына авылда яшәп калды. Тик авылны югалу-бетүдән саклап калыр өчен ул нишли ала? Кифая апа белән без нишли алабыз?!

—Быел мәктәпне унбер бала тәмамлады, беренчегә өчәү килделәр. Озакламый инде берәү дә булмаячак...—дип зар-моң түгүен дәвам итте Сәлим.—Ел үтмәс борын авылда унлап кеше үлде, ә туучы юк. Озакламый Шатлык авылы җир йөзеннән бөтенләй югалачак...

Сәлим сөйләгәнне җөпләп, Кифая апа моңсу гына әйтеп куйды:

—Авылны шәһәр йота...

—Шәһәр генә түгел, зират та бик яхшы йота, Кифая апа. Кырыла гына халык,—дип өстәде Сәлим.

Бу дөньяда йөз ел яшәгән картлар сыманрак сөйләшә башлаган әле ул.

Хәер, элек тә шулай иде. Ләкин үз яшьтәшеннән мондый өметсез сүзләр ишетү авыр. Күңелгә әйтеп бетергесез сагыш, шом кереп тула: Шатлык жир йөзеннән югалса, аның белән бергә әниле, әтиле үткәннәрем, бәхетле балачагым, яшьлек эзләрем дә мәңгегә югалачак бит... Туган йортым да югалачак... Бары хәтер генә калачак.

Уйларымның авылга сәяхәте гел ерактан, йолдыз белән тулы иксез-чиксез галәмнән башлана. Караңгы галәмдә миллионлаган тереклекне кочагына алып, кечкенә генә жир шары әйләнә. Уйларым ана якыная. Менә бусы—безнең ил, Россия, бусы—Татарстан, республикам. Ә бу нокта, энә очы кадәр генә шундый нәни нокта—минем Шатлыгым... Күз алдыма бер кешесез буп-буш авыл, ташландык йортлар, әни белән әтинең каберләре килеп баса. Әгәр авылда бер кеше дә калмаса, зиратның бөтен коймаларын умырып-урлап бетерәчәкләр, кабер өсләрен мал-туар таптап йөриячәк... Юк-юк, бетмәсен авыл. Ләкин кем сакларга тиеш соң аны? Туктале, Наргизәнең әти-әнисе каберенә кайтасы бар, зиратны саклап торыйк, каберләрне тәртиптә тотыйк әле дип, кем генә әйтер икән?! Үз бурычыңны кемгә йөкләргә? Туган авылыма Караташ язмышын теләмим мин. Ул кышлакны тау басты, ә безне нинди тау басар? Кагылмагыз, тау астында да тормыш бар... Өстә генә түгел, түбәндә дә тормыш бар!

Уйларымны Кифая апаның әрнүле тавышы бүлә:

—Балык башыннан чери, өстәгеләр ни кылана, күреп торабыз бит. Халыкның гомер буе жыйган акчаларына хәтле сыдырып алдылар. Демократия дигәннәре акыртып талау гына булды бугай... Бездән генә тормый шул, Сәлим. Беркая китмичә, үз авылыңда яшәп-эшләп ятар идең дә, түләве юк бит аның, нужасы гына муеннан. Балаларның киләчәген дә уйлыйсың. Гади халык кына берни кыра алмый, энем. Син дә алай йөрәгенә якын алма. Кирегә киткән дөньяны төзәтеп бетерә алмассың барыбер...

—Алай димә, Кифая апа, битараф булырга ярамый. Мин хәзер Ватанның ни икәнен аңламыйм, бездән сорап торучы булмады, тарттылар да алдылар. СССР юк, Рәсәйме ул хәзер, быдымы-ысыңгымы, ләкин бит туган жир бар, ул бер генә. Мин болай уйлыйм, Кифая апа: безнең бабайлар завуд та, фабрик та тотмаган, гап-гади игенче булган. Ачтан үлмәгәннәр бит, яшәгәннәр, бер көтү мал асраганнар, унышар бала үстергәннәр. Чөнки жирләре булган, ә жир—иң зур байлык ул! Үз жиребезгә үзебез хужа булу кирәк, менә шул! Аны ташлап качмаска, ябышып ятарга, теләсә кемнән талатмаска кирәк. Яратырга, сакларга, кадерләргә! Бабай гел әйтә иде, жиргә баш игән бәндә ачтан үлми дип. Жир—авыл кешесенең Алласы да, кыйбласы да ул, Кифая апа. Сәждә дигәннәре дә мәжүсилектән калгандыр әле, бер уйласаң, жиргә тезләнеп баш ию бит инде ул...

Мин Сәлимне шаккатып тыңлыйм. Менә сиңа мә, философ икән бит ул, әллә нинди ачышлар ясап ята. Сәждә кылуны әбием Аллаһыны олылау, аңа рәхмәт уку дип аңлаткан иде. Ә Аллаһ күктә яши бугай... Хәер, кем күргән дә, кем белгән... Ә бәлки, Сәлим хаклыдыр да, кешеләрне күк түгел, жир туендыра ләбаса, суны да, икмәкне дә ул бирә.

Үзенә текәлеп елмаеп утыруны күрепме, Сәлим кинәт тынып калды. Хуплау-аңлау көткәндәй, бер сүз дәшми күземә карап торды. Мин исә:

—Әйе шул... шулай шул...—диюдән уза алмадым.

Сәлим сүзне башкага күчерде:

—Наргизә, син Әлмәткә бардыңмы әле?

—Әйе, Кифая апа белән бергә барып кайттык.

—Миңниса әбине күргәнсеңдер, хәлләре ничек? Шәһәргә ияләшкәнме, зарланмыймы?

—Зарланмыймы соң! Телендә авыл гына, бик сагына.

Кифая апа урынынан кузгалды:

—Сез иркенләп сөйләшегез, мин берәр нәрсә әзерлим әле,—дип кухняга чыгып китте.

Артык колак юклыктан файдаланып, сорап калырга ашыктым:

—Сәлим, авылда мине чәйнәүдән туктадыларны әле?

—Синең кысыр хәсрәт ди анда! Авылны башка кайгы басты, Наргизә... Һаҗәр апаның хәле бик авыр диләр.

Аның уйламый әйткән сүзләренә хәтерем калды:

—Андый кысыр хәсрәтне үзенә күрергә язмасын...

—Син мине аңламадың. Сөйлиләр дип эчен поша бит. Сиңа аннан ни зыян да, ни файда югыйсә. Сөйләмәгәйләре, баш исән булсын дин.

Ул бераз дәшми торганнан соң, сүзне башкага борды:

—Сезнең күрше Хөҗҗәт бабай үлде. Малайлары йортны сатмакчы була икән. Урыннары яхшы, иркен. Нык әле ул йорт, алтмышынчы елларда гына салынган. Теләсәң, шунда яшәп, кырына әкрен генә яңаны да төзеп булыр иде. Күп тә сорамыйлар үзләре. Алыргамы, ничек уйлыйсың?.

—Үзенә кара инде, Сәлим.

Тавышым битараф, салкын чыкты бугай. Моны Сәлим дә сизде, сораулы-ялварулы, шул ук вакытта үпкәле дә карашын мина төбәде. Бер мәл күзгә-күз карашып дәшми утырдык. Тынлыкны Сәлим бүлде:

—Мин бергәләп уйларбыз дигән идем шул...

Карашымны тәрәзәгә күчердем:

—Ашыктырма, Сәлим.

—Гомер уза, Наргизә. Без дә мәңгегә килмәгән.

Шулчак Кифая апа чыгып, сүзебезне бүлде, казылык белән бергә кыздырылган күкәйне авылдагы кебек табасы белән алдыбызга китереп куйды:

—Чәй белән генә тамак туймас. Син юл кешесе, Сәлим. Аш өлгергәнче шуны булса да капкалый тор әле.

—Рәхмәт, Кифая апа. Ашыйсы килгән иде, анысы хак. Юлда машинаның тәгәрмәче җибәрде. Ярты сәгатьләп шуның белән маташтык.

Безнең арада шундый җинел, эчкерсез мөнәсәбәтләр, әйтер сүзләрне үлчәми, иләк аша чыгармый гына иркенләп сөйләшәбез. Чөнки без авылдашлар. Безнең үткәнебез уртак, танышларыбыз уртак, борчулар да уртак. Без бер-беребезне ярты сүздән аңлыйбыз. Теләсә ни турында уртага салып сөйләшә, киңәшә алабыз. Шуңа күрә Сәлим бу өйдә, бу табында ят кеше түгел. Аны әни дә ошата иде, моннан бик күп еллар элек, мине олы юлга озата чыккан көнне (әниемне исән килеш соңгы тапкыр күргән көн иде ул...) васыять әйткәндәй, Сәлим белән бергә булыгыз, дигән иде... Туганым кебек якын кеше, бик яхшы ышанычлы дус ул Сәлим. Ләкин гомерлек ярым, ирем булсын өчен болар гына җитәме икән? Җитәме?! Юктыр, мөгаен. Ә бәлки җитәдер дә...

...Мин Сәлимне озата чыктым. Чыккач та, ишек төбендә байтак сөйләшеп тордык. Ул мине аңлады кебек...

—Иртә олыгайган Сәлим. Шул яшьтән үк бөтен дөнья кайгысын иңенә салмаса соң... Рәхәтләнеп кызлар кочып йөрер вакытта. Мине сагынып килүе түгелдер, синдә өмете-фәлән юктыр бит?

Мин кергәндә Кифая апа табын җыеп, өстәл сөртеп йөри иде. Керүемә шул сорауны бирде. Мин яшереп маташмадым:

—Өмете-фәлән бар...

—Начар малай түгел. Төпле, ышанычлы кешегә охшап тора. Тик авылдан мәңге китмәячәк инде. Үзең ничек уйлыйсың соң?

—Әлегә белмим.

—Уйла, синең дә яшь бара...—диде Кифая һәм шундук башка сүзгә сикерде:

—Яхшы булды әле бу. Рәхмәт яугыры, бәрәнге, ит алып килгән. Мәгънә белә торган кеше икән. Наргизә, бер киенгән-җыенган, керләрне дә элеп кер әле.

Сентябрь ахыры булса да, көннәр коры, аяз тора. Зәп-зәңгәр күктә алтын кояш елмая. Аңа яз ни дә, көз ни, галәмне инләп йөргүен белә. Әбиләр чуагы шулдыр инде. Керләрне элеп бетергәч тә, өйгә керәсе килмичә, ишек төбендәге буш эскәмиягә барып утырдым. Хәзер балалар да кайтыр инде, өчесе дә беренче сменада укый. Шулай дип уйларга өлгермәдем, башын иеп, алга сөрлегеп атлаучы Илнар да күренде. Озын буеннан кыенсынып шулай бөрешеп-бөкрәеп йөриме, әллә модасы шулмы. Искәргәнем бар, урамда очраткан яшь-җилкенчәкнең күбесе сөзәргә җыенган үгез кебек шулай алга сөрлегеп атлый. Илнар никтер җиргә иелде, ботинкасының шнурын рәтләде, ахры. Подъездга борылганда мин аны яныма дәшеп алдым:

—Илнар, Сәлим абыең килде.

Энемнең йөзенә шатлык кунды:

—Ул бездәме?

—Юк, китте.

Сөенеч балкышы мизгел эчендә сүнде, кашлар җыерылды. Энем үртәлеп сорады:

—Ник мине көтмәде инде?

—Вакыты тыгыз иде.

Илнар кабат ботинкасына иелде:

—Табаны купты, нишләргә инде хәзер, апа?

Ботинканың авызы ярыйсы ук ачылган, хәтта көрән оекбашына хәтле күренеп тора.

—Яңаны алырга кирәк,—дидем мин..

—Акча юк бит. Ремонтлап буламы икән моны?

Акча юк... Мин дә ярдәм итә алмыйм, хезмәт хакымны тулаем Кифая апага кайтарып тоттырдым. Бәлки бер туфлилык кына калгандыр? Булмаска да мөмкин, бу елда гына базарга чыгып, Дилбәргә өр-яңа куртка алып кайттылар.

—Кышкы киемнәрең бармы соң, Илнар?

—Бар да... Куртканың җиңе кыскарды түлке. Хәзер андыйны кимиләр дә әле, бөтенесе күнне кия. Мин дә шундыйга кызыгам.

—Кызыккач, алырга кирәк,—дидем мин бик ышанычлы итеп.

Энем миңа карап моңсу гына елмаеп куйды. Тиз арада гына яңа курткалы буласына ул, әлбәттә, ышанмый иде.

***

—Моны сезгә бирергә куштылар.

Эштән чыккан җиремә каршымда кабат Кара каш, кара мыек басып тора. Хәер, аның исеме бар—Вилсур. Ул миңа конверт суза, мин аны шундук сумкама тыгып куймакчы идем, Вилсур, ризасызлык белдереп, башын чайкады:

—Җавап белән кайтырга куштылар.

Куштылар-куштылар... Куштан дигәннәре шул сүздән килеп чыкмагандыр бит?! Кеше кушканны гына эшләп йөрсәң, куштанга да әйләнерсең шул...

Конвертны ачкач, күзем маңгайга менде, анда таслап салынган меңлекләр ята иде. Шунда ук кечкенә генә кәгазь кисәге дә бар. Аны алып тиз-тиз генә күз йөртеп чыктым: «Наргизә, мин сүземдә тордым. Син дә вәгъдәңне

үтәрсең дип ышанам. Якшәмбе, көндезгә уникедә китәм. Өйдәгеләргә әйтеп кит. Бу акчага үзеңә бер затлы күлмәк ал. Матур аякларыңны чалбар астына яшереп йөрмә.»

Теге көнне: «Өйдә көтәләр, югалталар, озак кайтмагач, борчылырлар»,— дип шыңшый-үгетли торгач, Булат тәки күнде. Шалтыратып Вилсурны чакырды. Мине машинага утыртып, алай гына түгел, мичтә алсуланып пешкән симез тавыкны да бөтен килеш кулыма тоттырып, бик хөрмәтләп озатып җибәрде. Шул чакта, башка вакытта иркенләп очрашырбыз, дип вәгъдә биргән идем. Түземлеге озакка җитмәгән, миннән бернинди хәбәр булмагач, атна да үтмәс борын чакыру җибәргән. Югыйсә үзем шалтыратырга тиеш идем, шулай килешкән идек. Тик һаман яхшысынмыйча суздым да суздым, Булатның номерын җыя башлау белән, миңа кызлар үзләре асылына, дип мактанып-көлеп утыруы искә төшә дә, трубканы кире куям.

Биргән вәгъдәне үтәргә кирәк, шуңа күрә Вилсурга:

—Җавап уңай дип тапшырыгыз,—дидем.

Юл буе үз-үзем белән сөйләшеп кайттым.

Күлмәк ал, имеш... Булатым-канатым, син дә кызлар аягы карап йөрисеңмени әле? Шул аяклар арасыннан чалбарлы Наргизәне ничек күреп алдың икән? Күлмәк-итәккә карый чалбар җайлырак шул, дустым. Уңай да, җылы да. Бер киюдә ертылып чыга торган капрон оек түгел инде. Аларны җитештереп азапланасы да юк, барысын җыеп чүплеккә чыгарып яндырасы гына. Бик яхшы яна алар, чытырдый-чытырдый яна. Аякны да шәп яндыра түлке, түз генә.

Затлы күлмәгем бар ла анысы. Майлысуда торган чакта тектергән идем. Бакчабызда Яңа ел бәйрәме алдыннан ата-аналар өчен концерт оештырдык, шунда Янгуразны да чакырган идем. Кызын шундый матур бии, карарга кил, дидем. Киләсеңә һич шикләнми, махсус аның өчен, аңа матур, сөйкемле күренер өчен, кып-кызыл атластан, ялкын телләредәй елык-елык килеп уйнап торган мул итәкле күлмәк тектердем. Аны минем өстемдә күргәч, кызлар «ах» итте: «Чудо, прелесть! Кармен булгансың бит!»—дип сокландылар.

Тик Янгураз безнең бәйрәмгә килмәде. Ситараның Кар кызы булып бөтерелеп-бөтерелеп биюен кысык күзләрен дымландырып Сиражетдин бабай гына карап утырды...

Шуннан соң мин ул күлмәкне башка беркайчан да кимәдем. Гомердә бер генә тапкыр киелә торган ап-ак туй күлмәге кебек ул сандык төбенә төшеп ятты...

Янгуразны сокландырырга теләп тегелгән күлмәкне Булат янына киеп барачакмын, күңеле булсын. Ул биргән акчаны куярга бик яхшы башка урын бар. Ни уйласа уйлар, кире кайтармыйм мин аны. Соңгы акчасын чыгарып бирмәгәндер әле, байлыгы белән шапырынып утырды бит. Ә безнең, кирәкми, дип борын чөярлек рәтебез юк. Кирәк, бик кирәк безгә акча! Энемне шатландырыйм әле. Иртәгә үк икәү базарга чыгып, аңа яңа куртка, ботинка сайлаячакбыз. Ур-ра, яшәсен юмарт Булат! Байлар белән дус булырга кирәк!

***

—Киләсеңә ышанмаган идем,—дип каршылады мине Булат.—Бу юлы Вилсур куркытмадымы үзеңне?

Мин көлеп җавап бирдем:

—Юк, ул пиратка күз ияләште инде хәзер.

Плащымны салып, каршына килеп баскач, Булат башын чайкап:

—Да-а... Сиңа карарга да куркыныч, малай,—диде.—Сәхнәгә генә

менгереп бастырасы бар үзенне. Әллә телевидениены чакырыйкмы? Мәскәүдән данлыклы артистка килде диярбез. Тәки ышанырлар.

Мин каушап:

—Ярар-ярар, арттырма,—дип мыгырдандым.—Әминә апа мондамы соң?

—Монда, борчылма.

Булат кухня ягына борылып, аваз салды:

—Апа! Күрен әле бер. Наргизә сине сагынган.

Кулларын алъяпкыч итәгенә сөртә-сөртә, Әминә апа килеп чыкты.

—Исәнмесез, Әминә апа.

—Әнекәем! Кем бу? Сөбханалла! Тфү-тфү, күз тимәсен, матур да инде үзең! Бүген сездә туймы әллә? И-и, Ходаем, сиңа карап телемне йоттым бит, Наргизә. Исәнләшергә дә онытып торам. Саумы-саумы... Кул бирмим инде, йә затлы күлмәгеңне пычратырмын.

Бу юлы табын түрдә, олы бүлмәдә корылган иде. Шунысына сөендем: Әминә апа безнең белән бергә утырды. Бервакыт каш астыннан елмаеп:

—Булат син дип саташты инде тәмам,—дип куймасынмы.

Хатынлы-балалы ирнең мәхәббәте белән нишлим мин? Алай дисәң... Янгураз кем иде соң?! Хатыны да, баласы да бар иде. Ә син Янгураз дия-дия дөньяңны онытып чаптың бит, кызый.

—Яшьлек мәхәббәте онытылмый икән ул, апа,—диде Булат.

Әминә апа күңелле генә көлеп куйды:

—И-и, энем! Ирләрнең яшьлеге гомерлек инде аның. Кабергә кергәндә дә «кыж-кыж» дип ыңгырашырлар ди.

—Шулай булырга тиеш тә! Сокланырга да ярамагач, кызлар нәрсәгә?

Шаярып-көлешеп, юк-бар сөйләшеп утырдык. Бәйрәм-тантана табыны түгел, гап-гади төшке аш булып чыкты бу. Әминә апа ике арада чабып йөри. Ә мин үземнең купшы кызыл күлмәгем белән кыймылдый да алмый утырам. Йә, нәрсә дип кидем инде мин моны?! Көлкегә генә калдым бугай.

Ләкин чәй эчкәч, Әминә апа каядыр китеп югалды. Без бүлмәдә икәү генә калдык. Булат күземә серле генә карап куйды да:

—Биибезме?—диде.

Кунак—хуҗаның ишәге. Ризалык белдереп, урынымнан кузгалдым. Булатның кайнар кулы билемә ятты. Мин калтыранып куйдым. Күптән наз күрмәгән тәнемнең тыйнаксызлыгына оялып, кызышып киткән йөземне Булатның күкрәгенә яшердем.

Бүлмәгә татлы, назлы моң таралып, безне үз кочагына төреп алды:

—Уятучым бит син, юатучым,
Аңлатырга җитми сүзләр генә.
Бик еракта янган сүнмәс учак кебек
Нинди моң бар синең күзләреңдә?

Бер-беребезгә сыенып, әкрен генә бүлмә уртасында әйләнәбез. Билемнең Булат кулы кагылган турысы ут булып яна. Аның учындагы кулым да мичкә тыккан кебек. Хыянәтче тән! Син мине оятка калдырма тагы.

Бераз тынычлангач, башымны күтәреп:

—Бигрәк матур җыр. Кем җырлый моны?—дип сорадым.

—Ошыймы? Миңа да ошый. Рамил Миндияр җырлый. Тавышы бик йомшак, назлы, әйеме.

—Сүзләре дә искиткеч.

Йөземне Булатның кайнар сулышы пешереп үтте:

—Үзеңә багышлана дип уйла. Синең өчен махсус сайлап куйдым.

Шундый сүзләр миңа багышланамы? Бик күп булмасмы соң? Шаярма минем белән, Булат әфәнде. Хатының белән кызың кайткач, ни диярсең?

Магнитофоннан агылган ифрат моңлы, назлы тавыш безне сихерләвен дәвам итә:

Ай юлыннан сагынып кайтыр өчен
Күпер салыйк килер елларга!

Бу сүзләрне язган кеше үзе дә берәрсенә үлеп гашыйктыр, мөгаен. Ярата белмәгән, күңеле буш кеше мәңге болай яза алмас. Сайлый белергә генә кирәк, сүздә икән бөтен хикмәт, бөтен тылсым, бөтен көч! Мәхәббәтне шулай да, «яратам» дип күкрәк какмыйча да, тәгәрәп еларлык итеп аңлатып була икән... Мондый сүзләрне ишеткән кыз егетенең куенына кар бөртеге кебек эри дә төшә инде.

Булат колагыма иелә:

—Наргизә, чык миңа кияүгә.

Сискәнеп китеп, аның кочагыннан аерылам. Әйтәсе бөтен сүзем карашыма язылган. Күзләремнән чәчрәгән нәфрәт очкыннарын Булат сизми калмагандыр. Ап-айнык килеш шулай шаяралар димени? Минем йомшарып китүемне сизеп, көлмәкче, кимсетмәкче буламы?!

Монда инде аңлашулар, үпкә белдереп, үгет-нәсихәт укулар кирәк тә түгел. Сүзсез дә аңлашыла... Мин кырт борылып ишеккә таба юнәләм. Эчке кичереш-дулкынланудан йөрәгем калтырый, иренем дерелди... Нинди хурлык! Мине кем дип белә?! Сулкылдап җибәрмәс өчен иренемне тешлим.

Мине Булат куып җитә, беләгемнән тотып, үзенә бора:

—Ашыкма инде, Наргизә! Син бит әле белмисең! Бернинди хатыным да юк минем. Ышанмасаң, Әминә ападан сора...

***

Көзге каникулда Илнар белән Әлмәткә бардык. Миндар абыйлар белән сирәк-мирәк телефоннан хәл белешеп торабыз торуын. Ләкин күңел ана гына канәгать түгел, әбинең үзен күрәсе килә. Юл уңае базарга кагылып, күчтәнәчләр алдык. Илнарның инде бер ел әбине күргәне юк икән. Ул алай юксынмый да бугай. Мин кыстаганга гына иярде. Күн курткасы үзенә харап килешә инде, күкрәк киереп йөри хәзер. Урламасыннар гына. Мәктәпләрдә андый хәлләр булгалый. Әле безнең бакчада да бер хатынның ишек төбендә калдырган өр-яңа итеген алыштырып киткәннәр. Яшенә буылып, урлаучыны каргый-каргый, кемнеңдер сәләмәсен киеп кайтып китте. Ертык тишектән көлә, хәерче ярлыныкын урлый.

Без килгәндә әби өйдә үзе генә иде. Мин моңа бик шатландым. Чөнки Хәмидә апа янында гаепле кеше сыман аяк очында басып йөрергә, һәр сүзеңне үлчәп сөйләргә кирәк.

Әби ишекне ачты да, кызу-кызу кабат бүлмәгә кереп тә китте.

—Тилвизордан Сантыбарбыр карый идем әле. Аңлап кына бетерә алмыйм түлке. Идынны үтермәкче булалар, ахры. Кина бетсен дә, чәй эчәрбез,—диде.

И ул «Санта-Барбара»... Ун ел бара бугай инде, ачуым бер килмәгәе. Мәзәкләр дә чыгарып бетерде халык. Имеш, бер урыс хатыны, фатирын, бөтен әйберен сатып, Санта-Барбара шәһәренә күчеп китәргә җыена икән. «Анда нишләрсең соң, беркемне белмисең бит»,—дигәч: «Беләм, барысы да үзебезнеке, булышырлар әле»,—дип җавап биргән ди, имеш. Тагы бер хәлне

кызык итеп сөйләделәр. Имеш, берәүләр шул сериалны карап утырганда, фатирларына угры кергән дә, шыпырт кына кухняга үтеп, суыткычтан күңеленә ошаган бөтен тәм-томны сыпырып чыгып киткән икән...

Инде бу чир безнең әбигә дә йоккан. Урысча яхшылап анламаган да килеш, телевизорга кереп китәрдәй булып, шул сериалны карап утыра. Көннәр буе ялгызы нишләп бетсен инде.

Әбинең башында үзем бүләк иткән яулыкны күреп, күңелем күтәрелде. Димәк, ошаткан. Юлда тамак ачкан иде, хуҗалар өйдә булмаганнан файдаланып, кухняга уздым. Үзебез алып килгән күчтәнәчләр белән табын корып, чәй эчәргә утырдык.

Әби барыбызның хәлләрен җентекләп сорашты. Бу юлы аның кәефе яхшырак иде. Ахрысы, ул да Хәмидә апа өйдә булмаганда үзен иркенрәк сизә.

—Әби, билең җайланмадымы?—дип сорадым.

—Бамбингы сөртә торгач, җибәрде, Аллага шөкер.

Әби, кулындагы конфетны йөзенә үк китереп, әйләндереп-әйләндереп карый:

—Бигрәк йомшак кәнфит алгансыз. Бу теге каруфка түгелдер бит?

—Шул, әби, коровка. Тәмле конфет ул.

—Рәхмәт, балалар, сыйладыгыз-зурладыгыз. Авылга кайтканыгыз бармы соң?

—Юк. Беркөн Сәлим килгән иде.

—Ниләр сөйли? Ни хәлләр бар анда?

Мин Сәлимнән ишеткән хәбәрләрне әбигә җиткердем. Ул баш чайкый-чайкый тыңлады: «И Алла, ахырлары хәерле булсын, Һаҗәргә Ходай ярдәм бирсен», «Хөҗҗәт тә үләр икән, заманында дөньяны дер селкетеп торучы әзмәвердәй ир иде. Әҗәл барыбызны да тигезли шул»...

—Безнең йорт ни хәлдә? Сәлимнән сорамадыңмы?

—Сорадым. Урынында, диде.

—Ут-фәлән чыгармасалар ярар иде. Ниндиерәк кешеләр тора соң анда? Бик пырдымсызлар, эчеп-фәлән йөрүчеләр түгелме?

—И әби, кем торса да, киткән инде ул йорт. Янса да, янмаса да безнеке түгел.

—Алай димә, безнең нигез ул. Йорт иясе бар бит әле.

Мин көлеп куйдым:

—Бичурамы?

Кечкенә чакта әй куркыталар иде дә соң шул Бичуралары белән. Суны капламасаң, Бичура тыгылып кулын юа, имеш, савыт-сабаны юмый калдырсаң, Бичура килеп ялый икән... Авызыңны зур ачып иснәсәң, Бичура тыгылып, телеңне тартып ала... Әмма куркуның да чиге була. Куркуларымнан туеп, ахыр чиге мин ул Бичурага каршы үзем ау башладым. Күпме сагаладым мин аны! Юк, ник бер күзгә күренсен. Берсендә савытларны юмый калдырып, төне буе шуларны Бичура килеп ялавын көтеп утырдым. Утыра торгач, йоклап киткәнмен, күрми калдым. Хәер, килмәгән дә иде бугай ул, савытлар урыныннан кузгалмаган, ялаганга бер дә охшамаган иде. «Нинди соң ул Бичура?»—дип әбинең башын катырып бетерә идем. «Йөдәтмә, үзе турында күп сөйләгәнне яратмый ул»,—дип котыла иде әби.

Ләкин аны күрүче бәхетле җан булды. Миңа түгел, бер кичне бездә куна калган Риммага күренгән ул. Шул турыда сөйли-сөйли Римма хәлдән тайды:

—И кыз, белсәң! Төнлә нәрсәдер кыштырдаганга уянып киткән идем, мич арагыздан ап-ак күлмәкле бер кыз чыкты да, минем янга килеп басты. Үзе матур шундый. Кулымнан тотты да, әйдә минем белән, дип

үзенә тартыпмы-тарта. Курыктым да, кыз! Котым ботыма төште. Көчкә ычкындым. Бисмилла, дигән идем, керде дә китте янадан. Бисмилладан курка икән Бичура.

Ул чакта мин Риммага ышанган идем. Мич арасында ап-ак күлмәк киеп йөрүче кызны минем дә бик күрәсем килгән иде. Ләкин бу Римманың әкияте генә булып чыкты....

—Көлмә,—ди әби.—Бар ул йорт иясе. Риза түгел Бичура яна хуҗалардан. Без киткәнгә хәтере калган аның. Шуна күрә һәр төнне төшемдә йортыбызны күрәм дә инде. Кайтып, Бичураны үзегез белән ияртәсе бар. Яхшылап, олылап чакырырга кирәк аны.

Илнар әбигә гаҗәпләнеп карый:

—Ничек була соң ул, әби, яхшылап, олылап?

—Киткәндә, себерке белән бөтен йорт эчен, почмакларны сөрткәләп чыгарга кирәк. Шунда әйтәсен инде: «Хөрмәтле йорт иясе, әйдә безнең белән, без сине ботка пешереп көтәбез»,—дисен. Яна урынга килгәч, тары боткасы пешереп, һәр почмакка бер кабарлык кына шуны куярга кирәк. Аша, Бичура, безнең йортыбызны сакла, бергә яшик, дисен аннары. Шуна күнеле була инде аның. Йорт иясен рәнжеттек шул, чакырмадык, ияртмәдек үзебез белән.

Әбинен сүзләре Илнарны тәмам әсәрләндерде, ул аның авызына кереп китәрдәй булып карап тора:

—Әби, кая алып килергә соң аны? Монда, синен янгамы, әллә безгәме?

—Үзегезгә! Монда кирәкми. Монда ана сан булмаячак. Хәмидә мәгънә белүче түгел.

Илнар мина борыла:

—Әйдә, апа, авылга да кайтып килик. Бичураны чакырырбыз.

—Кайтсагыз, яхшы булыр иде шул. Кабер өсләрен дә карап, чистартып килерсез,—ди әби шатланып.

Мин гаҗәпләнеп сорыйм:

—Кая, кемнәргә кайтыйк? Кем көтә безне анда?

Әби исә һаман үзенекен сөйли:

—Бер кичкә кер мичкә, урын табылыр әле, кайтып килегез. Камәрия апагызны күрмәссезме. Сыйдырмас микән мине, барыбер ялгызы яши. Заманында бик якын дуслар идек. Чыбык очы булса да карендәшләр дә. Сөйләшеп карагыз әле.

Сөйләшеп карагыз... Ничек?!

Камәрия әби безнең авылның иң карт кызы. Әби-кыз... Яшь чагында ул харап чибәр булган диләр. Авылда бер чибәр булса да, аны бирәү дә кияүгә алмаган. Ул гомере буе әнисе белән яшәгән. Хәзер япа-ялгыз. Бик чибәр булган Камәрия апа... Ләкин телсез гүзәлне берәү дә гомерлек яр итәргә теләмәгән.

Телсез Камәрия белән мин ничек сөйләшим дә, ничек анлашыйм ди?! Әбинең күнеле булсын өчен, ярар, дигән булам. Барыбер берни килеп чыкмаячак, Миндар абый әбине шунда кайтарамы соң инде?! Анасын ташлаган дип күзен ачырмаслар.

—Камәриягә дә ялгызы авыр, бер-беребезгә иптәш булыр идек. Минем озак яшисем калмагандыр. Авылда җан бирәсе иде...

—Юкны сөйләмәле, әби!—дим ачуланып.—Әле бит сина сиксән дә тулмаган.

—Сиксән күп инде ул, балакаем, бик күп инде. Шул гомер яшәргә кешедән оят. Улың кабердә ятсын да... Әй, бу дөнья, картлар үлем көтә, яшьләр үлеп китә...

Мин әбине юатмакчы булам:

—Әти булмаса, Миндар абый исән.

Әби дә авыр сулап, уфтанып куя:

—Мидхәтем якынрак иде шул. Гомер буе бергә яшәдек. Ул киткәч, йөрәгем күмергә әйләнде.

Илнар гүя безне ишетми дә, күзләрен очкынландырып:

—Кайтыйк әле, апа! Авылны сагындым мин,—ди.—Дусларны күрәсе килә. Айратларда кунар идем. Кайтыйк әле, апа!

Ләкин без авылга кайтмадык.

Чөнки Сәлимгә бирәсе җавабым әзер түгел...

***

Булатның хатыны чынлап та юк икән... Ләкин булган ул!

—Әкәмәт көнләшә иде. Җитмәсә бергә эшлибез, котыртып торучылар да бар. Соңга таба һәр адымны тикшерә башлады. Җанга тиде тәмам.

Аерылышу сәбәбен Булат шулайрак аңлатып маташты.

Минем алда акланырга теләде бугай, ләкин аклану урынына каралу килеп чыкты. Көнләшкән икән, димәк, сәбәбе булган. Сөйләгәннәр, котырткannар—утсыз төтен булмый. Тиктомалга баласын күтәреп җылы йортын, җитеш тормышын ташлап китми кеше. Хатын аерган иргә, гәрчә ул фәрештә булып күренсә дә, барыбер шикләнеп карыйсың. Янгураз авыру хатынына да тугры иде әле. Үзем әрсезләнеп тагылмасам, аңа хыянәт тә итмәс иде, мөгаен. Хәер, кем белә... Кеше күңеле карурман.

Минем урында башка берәү булса, Булатның ялгыз, ирекле булуына сөенеп кул чабар иде. Ә мин бу хәбәрдән никтер аптырабрак калдым.

—Ә кызың... Хатынны ташлап та, аерып та була, ә баланы... Аны нигә ятим итәргә иде?!

Булат күземә туры карап баш чайкады:

—Син нәрсә инде... Мин бит хайван түгел. Бала ятим итәргә башыма тай типмәгән. Булса икән ул...

Булат бар әрнүен шунда җыеп сытарга теләгәндәй йодрыкларын төйнәде.

—Ярый... Тыңла алайса, Наргизә. Ялганнан башланган тормышның барыбер хәер-бәрәкәте булмас. Ул көнләшүләр, гайбәтләр... Барысы да туфта, дустым, чүп кенә. Төп сәбәп шул: бала юк. Хатынның күренмәгән-йөрмәгән җире калмады. Хәзер, әнә, икенче ире белән кыз үстереп ята. Гаеп миндә булган... Менә шундый хәлләр, дускаем...

Саимә апаның киңәшен оныткан юк: үземне Булат хатыны урынына куеп карыйм. Янгураз белән безнең арада шундый хәл килеп чыкса, мин нишләр идем икән, сөйгәнемне ташлар идемме? Юк, мәңге юк! Авырлык килгән саен ярың ташлап качсаң, ул чагында нинди мәхәббәт тә, нинди гаилә була ди ул?! Димәк, нәтиҗә шул: бу йортта мәхәббәт тә, гаилә дә булмаган...

—И юкны сөйләмә инде, Булат! Яратса, китмәс иде. Кирәк булса, баланы тәрбиягә дә алып була ич.

—Син дә мине яратмыйсың, Наргизә...

Анысы хак, яратмыйм. Элеккечә янып-шашып, акылдан язардай булып яратулар башка булмас та инде. Тянь-Шань тауларының кар-балчыклы ташкыны астында Янгуразым белән бергә минем өлешкә тигән мәхәббәт тә күмелеп калды бугай... Ләкин гомер буе ялгыз да яшәп булмас, күңел төбендә сибелеп калган барлы-юклы хисләрне җыйнап, кемнедер якын итәргә, кушылырга, үз оянны корырга кирәк.

—Теге чакта «яратмыйм» дип йөзгә бәреп әйттең бит. Шул сүзең белән

үтерден, йөрәккә кадалып калды чисти. Бу юлы очраткач, һаман ялгыз икәнеңне белгәч, өметләнгән идем. Шулай да, юк дияргә ашыкма әле син, Наргизә. Башта уйла, яме. Яхшылап уйла. Мин көтәрмен.

Шулай диде Булат. Озын-озак уйлыйсы, эреләнеп-ялындырып торасы юк та кебек. Сырланып-сайланып йөрер вакытлар үтеп бара. Егерме җиде яшьлек кыз өчен Булат менә дигән кияү! Хәер, хәзерге кызлар ушлы, чакыручы булса, мондый ирдән баш тартмас, унҗиде яшьлекләре дә йөгереп килеп җитәр иде. Ләкин Булат мине ярата, гомер юлын бары минем белән генә үтәсе килә, аңа башка беркем кирәкми... Үзе шулай диде, исәпләре үтә җитди. Хәтта вәгъдә билгесе итеп, якут кашлы йөзек белән алкалар бүләк итте. Күзем бик кызса да, мин алардан баш тарттым, Булатны өметләндерәсем килмәде. Ләкин ул үгетли-үгетли күңдерде:

—Ихлас күңелдән бирәм... якын итеп... Бер истәлек булсын. Ал, Наргизә. Чын күңелдән бит, валлаһи. Сиңа бүләк бирү минем өчен шатлык кына. Ошыйдыр бит?

—Ошый. Бик матур. Рәхмәт. Тик...

Булат йөзекне бармагыма кигерде дә, мине үзенә тартып, назлы итеп кочып алды. Кайнар сулыш бөркелгән иреннәре яңакларыма кагылгач, башым әйләнеп китте... Янгураз назларына сусаган тәнем, үзен алдый-алдый, Булат кочагына сеңде. Мине Булат түгел, Янгураз үбә, бу аның иреннәре, бу аның куллары дип саташып, дөньямны оныттым... Хыял белән чынбарлык буталды, башым уйлау сәләтен югалтты. Дөрес, әлегә безнең арада берни булмады. Ләкин барыбер... Мин Булатка өмет бирдем. Дуслык чиген бозып, тыелган якка үттек. Үттек, тик мәхәббәт ярына житә алмадык. Дуслык белән мәхәббәт ярлары арасында такталары убылып төшкән асылмалы күпер чайкалып калды...

Булат—менә дигән кияү... Йорты бар, байлыгы бар. Үзе дә төшеп калганнардан түгел. Язмышыңны Булат белән бәйләсәң, уңасың, Наргизә! Казанда урам себереп йөрүләрең юкка булмаган икән. У-у-у, нинди рәхәт тормыш көтә мине! Мине генә түгел, Илнарны, Данисны да. «Нәрсә киим дә, нәрсә ашыйм?» кайгысы калмаячак. Бай хатыны булып, өскә затлы туннар киеп, һаваланып йөрисе көннәр алда икән әле. Сөен, Наргизә! Киерелеп ачылган бәхет капкалары аша бии-бии, җырлый-җырлый кер! Алтын туегызны үткәргәндә, табын түренә утырып, күкрәк киереп мактанырсыз: «Безне себерке белән көрәк таныштырды, намуслы хезмәт кавыштырды!»—диярсез.

Үз-үземне шулай үртәп, яшь аралаш көлеп ятам. Башымда уйлар өере футбол уйный... Туктале, Наргизә, үзеңне гаепләргә ашыкма алай! Ә нигә әле син Янгуразга тугры булырга тиеш ди?! Кем ул сиңа? Җиде ят кеше. Җирдә юк кеше... Ә мин бар, мин исән, мин яшим! Нәрсә дип үз-үземне битәрләп ятам соң?

Тауга менгән саен офык киңәя, кояш якыная. Алга атлаган саен үткәннәр ерагая. Ераграк киткән саен үткәннәрнең асылы ачыла, барысы да уч төбендәге кебек ачык күренә башлый. Кояшка таба атласаң, күләгән артта кала. Күләгә алга чыкмаска тиеш. Ул алга чыга икән, димәк, син караңгылыкка таба атлыйсың...

Женя мине яратмаган, кәмит уйнаган, беркатлылыгымнан көлгән. Мин моны соңга калып булса да аңладым. Дөресе, тормыш үзе аңлатты. Ләкин Янгураз да мине яратмаган... Ул Тамарасын яраткан, сөйгәне өчен утка-суга гына түгел, хәтта гүргә дә барып кергән. «Үзең кул сузмасаң, сине күрми үтәр идем»,—дип әйтте түгелме соң?!

Ә мин яраттым... Әгәр күңелдәге хисләр очкынга әверелсә, тоташ ялкын булыр идем. Утка очкан күбәләк кенә түгел, мин үзем ут идем, дөрләп янган

учак идем. Женяга булган хисләр кара күмергә әйләнде, алар тапталган, югалган, онытылган. Ләкин Янгуразны яраттым, үлеп яраттым. Кызы Ситара белән, Сиражетдин әкәсе, чирле Тамарасы, кыскасы, бар дөньясы белән колачлап, сөю тулы күңелемә сыйдырдым. Янгураз өчен мин дә утка-суга төшәргә дә, гүргә керергә дә әзер идем.

Ә хәзер... Күңелем гүя гөлсез калган шәрә болын, игеннәре җыеп алынган ялангач кыр, бары җәяүле буран гына йөгергән карлы дала. У-у-у, нинди салкын, нинди буш бу күңелдә... Мин беркем өчен дә көнләшмим, берәүне дә яратмыйм. Йөрәгемнең алтын тәхете бары берәү өчен генә булган, күрәсең. Беренчем, иң кадерлем, бердәнберем өчен... Тылсым, наз тулы мәхәббәт бакчасына мине тәүге тапкыр алып кергән шул яр, таулар улы Янгураз гына алтын тәхетемнең мәңгелек хуҗасы, йөрәгем патшасы булып калырмы икән?! Ә калганнар... Алар бары вәзир генә... Вәзирләр гадәттә патшадан акыллы була. Ләкин барыбер патша булмый. Янгуразны таулар урлаганнан соң, күңелемнең кайсыдыр почмагында мәхәббәт нурлары сибеп утырган серле сандык шапылдап ябылды. Татлы хыяллар көл булып җилгә сибелде.

Ләкин яшәргә кирәк! Яшәр өчен уйларга, хәрәкәтләнергә, тормышта үз юлыңны эзләргә, таяныр ноктаңны табарга кирәк.

Башымда уйлар туп уйный...

Булат миңа чит кеше түгел. Яшьтән үк хисләрен белдергән, бергә булыйк дип тәкъдим ясаган дус. Яхшы дус! Ышанычлы дус! Хәзер дә карашы үзгәрмәгән, хисләре сүрелмәгән. Теге көнне ул мине машинасы белән подъезд төбенә хәтле озатып куйды. Хушлашканда кочагына алып иренемнән суырып үпте:

—Онытма, мин җавап көтәм,—диде.

Булат начар кеше түгел. Әллә соң... тәвәккәлләргәме? Яшь бара, гомер үтә. Ә Сәлим? Ул да җавап көтә... Ул да галәмәт яхшы кеше, ул да ышанычлы дус!

Балачакта, чәчемне тарап үргәндә, әни:

Кызым, кызым кыз кеше,
Кызыма килер йөз кеше.
Шул йөз кеше арасыннан
Сайлап алыр бер кеше,

—дип такмаклый иде.

Йөз булса, бөтенләй акылдан язарсың, әле монда ике имән арасында да адашып йөрим. И-их... Әгәр яратсам, болай икеләнер, баш ватар идеммени?! Бернигә карамый, ике дә уйламый, күзем йомып сөйгәнем артыннан атылыр идем! Кая чакырса, шунда йөгерер идем!

...Уйлар тубы Булат белән Янгураз тирәсендә әйләнде-әйләнде дә, авылга таба тәгәрәде, тупылдап Хөҗҗәт бабайлар ишегалдына килеп төште.

Хөҗҗәт бабайлар бездән ике йорт аша гына тора иде. Әтиеннең бисмилласы юк, дип, әби мине аларга тавык суйдырырга кертеп җибәрә иде. Капканы ачып ишек алдына аяк басарга өлгермисең, тәрәзәдә Сәкинә әбинең уч кадәрле генә түгәрәк йөзе күренә. Димәк, сиңа тавыгыңны култык астына кыстырып көтәргә генә кала. Ялындырып-көттереп, вәкарь генә басып, тамак кыра-кыра, кулындагы үткен пычагын салмак кына сыпыра-иркәли, Хөҗҗәт бабай чыга. Бабайны күрүгә әлегә хәтле синең җылы куеныңда тәмләп йокымсырап утырган тавык үзен ни көткәнен чамалап, тыпырчына-бәргәләнә, разбуй салып кычкыра башлый. Ул гына түгел, мин үзем дә куркам, пышылдап диярлек Хөҗҗәт бабай белән исәнләшәм. Ләкин сәламемә җавап юк. Чөнки: «Тавык—кош, хатын-кыз кеше түгел,»—бу

сүзләрне бабайдан еш ишетергә туры килә иде. Шуна күрәдер, Сәкинә әби, безгә кергән саен, Хөжжәтем генә исән булсын, Хөжжәтемнән калырга язмасын, анардан башка егылып үләргә генә кала, дип безелди иде. Теләге кабул булган, бер ел эчендә парлашып китеп барганнар...

Мин кечкенә чакта Хөжжәт бабай ферма мөдире булып эшли иде. Кышын чанасына, җәен арбасына баһадир генералдай аягүрә киерелеп басып, аты-ние белән яшен кебек чаптырып китүләрен без бала-чага кызыгып карап кала идек. Башка чана-арбаларга үрмәләп-эләгеп була, ә моныкына якын килә торган түгел. Күрергә дә өлгерми каласын.

Хөжжәт бабайларнын йорт-каралтысы балкып тора, бөтен жирдә тәртип. Турылары ялап алгандай чип-чиста, коймалары парадка тезелгән солдатлар кебек тип-тигез.

Әгәр Сәлим шул йортны сатып алса, шунда яшәп китсәк, мине ни көтә? Алты почмаклы шәп йортын булу белән генә түгел әле. Абзарында мөгрәп сыер-бозавын, ишек төбенә аяк басуга сукрана-сукрана сырып алучы мәнге ач тавыкларын, егерме биш сутый бәрәнге бакчан көтә сине, Наргизә җанкисәк. Болар гына аз булса, бәхетен тулырак булсын өчен жәй буе «күнел ачарга» бирәр гектар чөгендер жире биреп куюлары да бар. Аягында ялтырап торган матур кәлүш, өстендә сырган бишмәт булыр. Комач кызыл күлмәгеннен купшы итәкләрен жилфердәтеп, көтү куарга чыгарсын... Язын-көзен тездән саз ерып мәктәпкә йөрерсен. Ямьле су буйларына төшеп бозлы суларда керләр чайкарсын...

Йә, кем инде иркле көннән авылга кайтып нужа куа? Анда рәхәт булса Кифая апа өч баласын ияртеп чыгып качмас иде.

Үлчәү тәлинкәсенен Булат ягы баса...

Тик шул чакта күз алдымда бер-берсенә сыенган ике ятим кабер пәйда була... Ташларына сонгы сулышыма хәтле йөрәгемдә сулкылдап әрнисе ике газиз исем уелган. Колагымда әбиемнен боек тавышы янгырый: «Зинһар, алып кайт авылга! Сонгы сулышымны алыр өчен булса да алып кайт. Андый-мондый хәл булса, әтиен янына күмәрсез». Әбинен васыяте минем өстә.

Кичер мине, авылым. Шатлыгым—жан әрнүем, мәнгелек сагышым... Авылкаем, татлы ярам... Уйларым, моннарым сина илтә, юлларым сина илтә...

Тыгыз туп булып йомарланган уйлар әкрен-әкрен генә сүтелә-тарала башлый. Тәнем гүя мамыктай жинел болытларга әверелеп, эри-эри томанлы йокы дөньясына кереп китә. Шулчак каршымда туган йортым, ике бүлмә арасындагы ак мичебез пәйда була. Мич башында аякларын селкеп, әби әйтмешли, жен атындырып, ап-ак күлмәкле бер кечкенә кызчык утыра. Анын зур кара күзләрендә эре-эре яшь тамчылары жемелди. Кызчык еламсырап, нәни кулларын мина суза. Өн белән төш арасындагы йомшак бишектә тирбәлә-тирбәлә уйлап куям: «Римма алдамаган, йорт иясе Бичура чынлап та шундый икән... Ул Янгуразнын кызы Ситарага охшаган икән...»

### Сонгы сүз

Мин инде арып-изрәп йоклап киткән идем. Бу төн минем өчен михнәтле дә, шатлыклы да булды. Бар авырту-газапларны онытып, дөньянын үзе хәтле зур шатлыгымны күкрәгемә кысып йоклап китүемне сизми дә калганмын. Шундый тәмле, рәхәт йокы булды ул.

Төшемдә авылны, үзебезнен йортны, балачагымны күрдем. Яз көне икән. Бакчадагы алмагачлар ап-ак чәчәккә күмелеп утыра. Турыбызга яшел келәм чыгарып жәйгән кебек. Яшеллекнен нәфис, гүзәл чагы. Жәйнен дә балачагы.

Мин таганда атынам. Миңа шундый рәхәт, гүя очам. Мин тауларга таба очам. Көчлерәк атынган саен шул тауларга якынаермын төсле. Югыйсә алар шундый якында кебек. Ләкин никтер барып житеп булмый. Алар минем өчен мәңге серле булып, мәңге үзенә чакырып торачак зәңгәр таулар. Таулар артында кояш бар! Таулар артында тормыш бар! Тормыш бөтен жирдә бар. Жир шары тормыш өчен яратылган.

—Кызым, ашарга кер,—дип чакыра мине әни.

Әни шундый шат, шундый матур, яшь. Анын өстендә язның бар төсләрен үзенә жыйган, энже чәчәкләр сибелгән яшел сатин күлмәк. Әнинең елмаеп йөри торган көннәре. Әле Кифая апаның ире үлмәгән, әле ул авылга кайтмаган... Әлегә әнинең бар бәхете үз янында.

Ул жәйне миңа унбер яшь тулган иде. Бу яз да, бу көн дә минем тормышымда булган иде. Мин төш түгел, төшемә килеп кергән үткәнемне күреп ятам.

Без әни белән өйгә керәбез. Шул арада әнием назлап-яратып мине чәчемнән иркәләп ала: «Акыллым син минем!». Анын куллары шундый йомшак, кояш нурлары кебек жылы.

Әти дә, әби дә өйдә. Ак ашъяулык япкан өстәл янында утыралар.

Менә әни алдыбызга табасы белән бәлеш китереп куя:

—Бәлешем унды. Болай булгач, кызыбызның тормышы да уначак.

Әби һәрвакыттагыча кырыс кына төзәтә:

—Алла теләсә дип!

Күр, әби дә ул чакта нинди яшь, төз булган икән. Мин анын ул чагын инде хәтерләмим дә.

Әти урыныннан кузгала, анын кулында мәктәпкә йөртә торган ачык зәңгәр төстәге өр-яңа сумка. Шуны миңа сузып:

—Туган көнең белән котлыйбыз, кызым,—ди.—Зур үстең, быел бишенчегә барасың инде. Шатлыгыбыз булып үс.

Букча буш түгел, анын эчендә «Татар халык әкиятләре» дигән бик матур тышлы калын китап ята.

—Тормышың әкият кебек матур, күнелле булсын, кызым. Әкиятләрнең ахыры гел бәхетле бетә,—дип елмая әнием.

Табыныбыз түгәрәк, барыбыз да исән-сау. Өй эченә язгы кояш нурлары кереп тулган. Безнең арада әлегә Илнарыбыз юк. Ул әлегә безне күктән генә күзәтә. Ләкин анын киләсен беләбез. Шуңа күрә әни гел елмаеп йөри дә инде.

Мин кино караган кебек үткәннәремне ап-ачык күреп ятам, күрәм генә түгел, төшемдә дә уйлыйм, бәялим.

Шулчак күренеш алышына. Башта таулар, аннары офыкларга тоташкан мәк даласы пәйда була. Кып-кызыл чәчәкләр арасында Янгураз белән бер-беребезгә сыенып басып торабыз. Мин Янгуразга гажәпләнеп карыйм:

—Син ничек кайттың соң, Янгураз? Син бит үлгән идең. Жир астыннан чыгып буламыни?

Янгураз дәшми, күзләремә карап елмая гына.

Ә мин анын каршымда басып торуына шатланып та, гажәпләнеп тә сорыйм:

—Мин сине гел төшемдә күрәм. Төшләремдә син гел кайта идең. Бусы төш түгел, бу юлы син чынлап та кайттың, әйе бит, Янгураз? Тик ничек кайттың соң син? Башка китмисеңме, югалмыйсыңмы, Янгураз?

Янгураз елмаеп кулларын суза:

—Бөтенләйгә кайттым, Нәркис. Мин сине башка беркайчан да ташламам, асылым.

Янгураз сөйләшә! Ул, китмим, диде! Бу юлы ул чынлап та кайткан! Бусы инде чын, бусы төш түгел!

—Гайнуллина!

Нигә әле Янгураз минә фамилиям белән эндәшә? Кайдан белә ул минем Гайнуллина икәнемне? Ә нигә исемем белән генә эндәшми, исемемне онытканмы әллә? Оныткандыр да шул. Без бит кайчаннан бирле күрешмәгән...

—Наргизә апа!

Мин күземне ачмакчы булам, тик керфекләремне күтәрә алмыйм, алар шундый авыр. Ник соң күзләремне ачалмыйм, сукырайдыммы әллә?

—Наргизә апа... Наргизә апа!

Ниһаять йокы әсирлегеннән айнып, уянып китәм. Күзләрем дә бик ансат ачыла икән. Каршымда ак халатлы Алия басып тора, миңа уч кадәрле генә түгәрәк көзге суза:

—Наргизә апа, ясаныгыз-төзәтенегез. Менә сезгә көзге. Хәзер телевидениедән киләчәкләр, сезне төшерәләр.

—Нигә?—дип аптырыйм мин. Үзем һаман төшемнән айнып бетә алмыйм.

Алия серле генә елмая:

—Аннары белерсез! Матурланыгыз.

Мин әлегә аякка басарга куркам. Караватта утырган килеш кенә өс-башымны рәтлим, чәчемне төзәтәм. Шуннан ары тагы нишли алам, иннек-кершәннәрем янымда юк.

Палатага үзе хәтле видеокамера күтәргән кендек буе егет белән, Барби курчагыдай нечкә билле, озын аяклы, алтын чәчле бер кыз килеп керә. Икесе дә өсләренә ак халат бөркәнгәннәр.

—Озак булмагыз, аның хәле юк,—ди Алия.—Мин хәзер баланы алып киләм.

Сары чәчле кыз микрофонын авызына куеп, тиз-тиз сөйли башлый:

—Кадерле тамашачыларыбыз! Бүген Яңа ел төнендә безнең районда яңа гасыр, яңа меңьеллык кешесе дөньяга килде. Без аның бәхетле әнисе белән сөйләшәбез.

Мин каушап елмаям. Гомердә дә телевизорга төшкәнем юк.

—Менә монда микрофонга сөйләгез.

—Ни сөйлим соң?

—Кем сез, кайда яшисез, кем булып эшлисез—шуларны сөйләгез. Курыкмагыз, каушамагыз, камера күзенә туры карагыз. Ялгышсагыз, монтаж вакытында төзәтербез.

Мин курыкмыйм, әмма дулкынланам. Күңелдәге уйлар һич кенә дә бер сафка тезелеп баса алмый, шуларны берәм-берәм чүпләп, өтек-өтек җөмләләр оештырган булам:

—Мин... Наргизә Мидхәт кызы булам... Укытучы булып эшлим. Тарих, география укытам...

Үзем сөйлим, үзем уйлыйм: «И-и кыяфәтемдер инде... Таптылар бит вакытын...»

—Башка балаларыгыз бармы?

—Юк... Бу—көтеп алган беренче сабыебыз.

Сары чәчле кыз, мине тыңлап та бетерми, борсаланып тирә-якка карый:

—Бала кая? Ник һаман алып килмиләр? Аны да төшерергә кирәк!

Палатага бәләк кадәр төргәк күтәреп Алия йөгереп керә, сабыемны өстәлгә сала. Камералы егет аның янына атыла. Тик мин кычкырып өлгерәм:

—Төшермәгез! Төшермәгез аны! Йә күз тияр. Үземә бирегез. Минем кулда килеш кенә төшерерсез.

—Әйе шул,—ди Алия.—Аның нәрсәсен төшерәсең? Бала бала инде. Алар барысы да бертөсле.

Улымны тәүге тапкыр кулыма алам. Сабыкаем берни белми йоклый. Ләкин миңа үз балама озак сокланып утырырга ирек бирмиләр, аны яхшылап күрергә дә өлгермим, яна сораулар ява:

—Наргизә ханым, ә сез кемне көткән идегез? Балагызның Яңа ел төнендә туасын белдегезме?

—Якынча гына чамалаган идек...

—Ә район башлыгының бүләге турында белгән идегезме? Моңа ничек карыйсыз?

—Әйе, газеттан укыган идек. Яңа гасырда беренче булып туган бала исеменә биш мең акча салыначак.

—Сез моңа шатмы?

Нинди мәгънәсез сорау! Бу кызыйның бала табып караганы юктыр шул әле... Туасы сабые өчен ут йотып, ике көн, ике төн тулгак белән җәфаланган хәлсез хатында акча кайгысы була димени?!

—Мин улымның исән-сау тууына шат. Бүләк турында уйларга өлгермәдем.

—Ә сез улыгызга исем сайладыгызмы инде?

—Аның исеме Янгураз булачак.

Кызый аптырап кашларын җыера:

—Андый исем буламыни? Ни дигән сүз соң ул?

—Янгураз—яңа бәхет дигән сүз.

—Кызык исем икән... Бер дә ишеткән юк иде. Наргизә ханым, Яңа елда нинди теләкләр теләр идегез?

Мин бик арыдым, көчсезлегемнән шабыр тиргә баттым. Шуңа күрә озын-озак уйлап тормый гына гап-гади сүзләрне әйтәм. Гасырлардан-гасырларга, телдән-телгә күчеп, җир шарының һәр кешесе «Амин!» дип мөхер сугарлык гап-гади сүзләрне әйтәм:

—Дөньялар имин булсын!

Ниһаять, барысы да чыгып китә, палатада күнел тансыклаган тынычлык урнаша. Ләкин озакка түгел, биек үкчәләре белән цак-цок басып, атыла-бәрелә, теге кызый кабат атылып керә:

—Сорарга онытканмын, сез кайдан әле? Ирегез бармы? Кем ул, кайда эшли? Ачуланмагыз инде, үзем өчен түгел, тапшыруга кирәк.

—Шатлык авылыннан мин... Ирем дә бар, бәби карашырга әбием дә...

Сары чәчле курчак минем җавапларны тиз генә блокнотына сырлап куя да, ишеккә таба чигенә-чигенә, кул болгый: «Пока!» Әйтерсең, якын кешесе белән хушлашып, самолетка утырып китүе.

Без улым белән икәүдән-икәү генә калабыз. Мондагы ыгы-зыгыда бер эше булмыйча, рәхәтләнеп йоклап яткан сабыемны мендәргә салам да, үзем дә аңа сыенып ятам. Бәгыремнән өзелеп төшкән, галәмнән җан иңгән бу серле зат, җиргә үз бәхетен эзләп килгән нәни кеше белән сулышларыбыз бергә кушыла. Улымның алсу алмадай битенә текәлеп, йөрәгемнән чыккан кайнар наз белән, үткәнемнең, бүгенгемнең, киләчәгемнең бөтен мәхәббәтен берьюлы аңа түгәрдәй булып, тәүге тапкыр сабыема эндәшәм:

—Саумы, улым! Саумы, яңа бәхетем!



Рашат
Низами

# ВАКЫТ ЭРГӘСЕНДӘ

***

**Җир әйләнә—минем катнашым юк,**
**Кояш чыга көн дә кызарып.**
**Серле сорау: Күкнең катламнары**
**Белә микән җирдә без барын?**

**Сулар ага—минем катнашым юк,**
**Челтер-челтер ага бузарып.**
**Белеп, аңлап сөртә микән Җилләр**
**Таулардагы вакыт тузанын?**

**Үлән үсә—минем катнашым юк,**
**Куып уйный үзенең шәүләсен.**
**Белә микән Адәм баласының**
**Чалгы тотып беркөн киләсен.**

**Үз-үзенә шулай җай таба да,**
**Бакый дөнья йөзә кай таба?**
**Минем катнашымнан башка гына**
**Бу Табигать**
**Никадәрле эшләр майтара!**

**Ходай-кодрәт алтын җепләр белән**
**Чорнап тоткан Вакыт агышын.**
**Дөнья гаҗәп! Мин җәяүләп киләм,**
**Хакыйкатьне эзләп барышым...**

***

**Илләр белән илләр көрешсә дә,**
**Без яшибез барыбер чикләнеп,—**
**Язлар гына тоткарлыксыз уза**
**Баганалы дәүләт чикләрен...**

Рашат НИЗАМИ (1950)—*шагыйрь, прозаик, публицист; «Кызыл җәй», «Тормыш трамвае», «Ут һәм җыр» (роман-хроника) һ. б. китаплар авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгының һәм Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

Тынчу, кысан төрмә эчләрендә
Җан бирергә мөмкин узаман,—
Чәнечкеле тимер чыбыкларны
Кошлар гына очып узала...

Җирдә тагын бер могҗиза яши:
Үтеп туфрак,
еллар аркылы,—
Безнең көнгә хәтле килеп җиткән
Китап сүзе,
хәким акылы...

## Һаваларда—кошлар...

Җил тузгыта карга ояларын,
Яфракларны җәйге җил кисә.
Күктә бары... соры бер тап кала—
Ала карга канат җилпесә.

Матурлыкны тояр, аңлар өчен
Яратылгансың бит син, кеше!—
Күктә ап-ак чәчкә булып балкый
Аккошларның канат җилпеше.

Балачакның хыял-очышларын
Кайта күңел, кайта сагынып.
Офыкларны сөреп, иңләп килә
Ялгыз бөркет, канат кагынып.

Давыл хәбәрчесе—болытларның
Йөрәгенә яшен, ут сала;
Колач-колач канатлары белән
Диңгезләрдә давыл куптара!..

## Йокысыз төн

Төшләр күрә-күрә йокымсырый
Тәрәз төбендәге гөлләрем.
Мине генә йокы ташлап качкан,
Йоклый алмый ятам төннәрен.

Атылыплар китә сыңар йолдыз—
Кемдер шырпы сызды галәмдә.
Йолдыз булып хәтта йолдызлар да
Уздырмыйдыр гомерен әрәмгә.

Нинди гамь бу мине эзәрлекли
Меңәр чакрым ерак ноктадан?
Күләгәләр оеп-катып калган—
Гүя җирдә вакыт туктаган!

Галәмдәге кара бушлык сыман
Күңелемдә өнсез бер халәт.
Битарафлык чоңгылына мине
Ташлап китте мәллә мәхәббәт?

Төнге боҗра кысып-авырттырып
Урап ала мине бер мәлдә.
Күктәге ай, алтын балдак булып,
Йоклап ята ялгыз мендәрдә...

## «Болгар» номерлары җимерелгәч...

*Мин—татарның бер угланы,*
*Гаҗәпмени, еласам:*
*«Болгар» нигезенә ятып*
*Бүре кебек уласам...*

Кешеләр йоклап ятканда
Хәтер генә йокламый,—
Барлый тарих катламнарын
Төнката, бертуктамый...

Шәһре Казан уртасында
Гөнаһлы эш башланды:
Бульдозерның пычаклары
Кисеп кера ташларны!

Экскаватор чүмече
Таш-туфракны актара.
Беләме—кылган гамәле
Дегет сыман кап-кара...

Тузан булып күккә аша
Тукай яшәгән бүлмә...
Дулкыннар, нидер сизенеп,
Елаша Кабан-күлдә.

Кемнәр батырчылык иткән
Рәнҗетергә Тукайны?!.
Безнең җир һәм күкләребез
Булды мәңге Тукайлы!

...Искә төшә илбасарның
Болгарны җимергәне...
Тураклый кыпчак токымын
Шовинист тегермәне.

Тере булсаң, туфрагыңа
Әйләнеп кайт, Ак бүре!
Төркиләрнең байрагында
Син—бердәнбер хак бүре.

Кояш калка...
Күңелләрне
Әллә ниткән моң баса.
Гаҗәпмени: Казанымның
Туфрагына ятып-ятып
Ак бүредәй уласам?..

## Кырыс чынбарлык

Бер көнлек күбәләк, җилфердәп,
Ни кылмак бу фани дөньяда?
Вакытның басымы астында
Кыялар, ком-ташлар уала.

Тын гына, моң гына агыла—
Булмыйдыр туктатып вакытны.
Сулышың, дәрманың, яшәвең...
Болар бит һәммәсе—вакытлы.

Бел, кеше: кем сиңа эндәшә
Курада сызгырган җил булып;
Таң белән офыклар артыннан
Ни хәбәр китерә ак болыт?..

Күкләрнең пәрдәсе чишелеп,
Яуса да кар-яңгыр ишелеп,
Эткәләп яисә төрткәләп
Рәнҗетмәс табигать кешене.

Тормышта, ә менә тормышта
Кайчакны зур уен башлана:
Адәмнәр башына еш кына
Котырган усаллык ташлана.

Берәүнең бәхетле күзләре
Кемнеңдер нәфесен кабарта.
Гел шулай: жаһилләр кулында—
Йә пычак... йә балта...

Убылып-чайкалып сораулар
Өстеңә ишелеп килгәндә,
Күзгә-күз карашып, дөньяга
Ни әйтә алырсың син, бәндә?

## Ирек турында

**Кысып ала безне мәҗбүрият,**
**Йолкып-йолкып тота куллардан:**
**Юл сызылган, син тайпылма, кеше,**
**Баганалы шушы юллардан.**

**Юк, буйсынмый күңел зынҗырларга,**
**Ирек эзләп читкә ташлана:**
**Йә күгеңдә йолдыз табасың син,**
**Йә буласың туфрак, ашлама.**

**Куыш кирәк. Очар канат кирәк...**
**Урап алган меңәр ихтыяҗ.**
**Ачлык мәйданына баса кеше,**
**Азатлыкның тәмен бер тойгач.**

**Гомерләрне, әрәм-исраф итеп,**
**Ләззәт шаукымына берикме?**
**... Сакта тора күпме мәшәкатьләр,**
**Кеше—үлгәч кенә иректә...**

## Күңелемдә кояш бар әле

*Күңелнең иге-чиге юк,*
*Бар ләкин офыклары.*
*Гомер юлын чуарлаган*
*Пунктир сызыклары...*

**Шатлыкларның, шампан шәрабыдай,**
**Булды ташып чыккан чаклары...**
**Чатнап-чәчрәп яшен яшьнәгәндә**
**Фәрештәләр, ахры, саклады.**

**Уңга таба китәр чакларымда**
**Сулга таба никтер кителгән.**
**Нахак сүзләр... Шуны ишетүдән**
**Күңел бәллүрләре кителгән.**

**Гөрләп тора тормыш ак-карадан,**
**Без генәме җирдә яралы?**
**Болытларны ертып-ерып чыгам—**
**Күңелемдә кояш бар әле...**

**Бер-беренә шатлык белән кайгы**
**Килеп тора шулай алмашка.**
**Бу тормышта**
**Кирәк ничек тә бит**
**Култык таягына калмаска!**

**Безнең яра—яра ишеме соң,**
**Ватанымның җаны яралы.**
**Татарстаныма,**
**шиксез, Ирек килер—**
**Күңелемдә Кояш бар әле!**

*2006—2010.*



Әнәс
Хәсәнов

# ӘҖӘТ

ХИКӘЯ

Беркөнне әни миңа:

—Бар әле, улым, шушы ярты гына пот арышны тиз-тиз генә тегермәннән тарттырып кайт әле,—дип төбенә ашлык салган капчык тоттырды.—Насыйбулла абзый, зинһар, шушыны гына тарттырып бир әле, диген.

—Ул мине тыңлар микән соң?—дим.

—Тыңлар, тыңлар. Әйбәт кеше ул. Ерак кына булса да, үзе безгә туган тиешле кеше дә бит әле.

Капчыкны эләктәреп мин кыр капкасыннан ерак түгел калкуырак җирдә утырган тегермәнгә җилдердем. Беләм бит, арыш тартылса, әни ипи салачак, камыр башыннан гына бәрәңге пәрәмәче дә әмәлләми калмас. Насыйбулла абзый мине көләч елмаеп каршылады. Мин аның калкып торган яңак сөякләренә, кызыл борычка ком кушып сипкән кебек кызгылт төк баскан йөзенә, очкыннар уйнап торган күзләренә игътибар иттем. Танырмы, юкмы. Таныды.

—Син Габделбәр малаемы әле, улым? Үскәнсең, үскәнсең. Яраткан кызың бармы соң?—диде ул. Аның шаян, җор сүзле, мәзәкчән кеше икәнен олылардан ишетеп белсәм дә, мин аптырый калдым.

—Һи, Насыйбулла абзый, син бигрәк инде. Мин бит әле өченчедә генә укыйм,—дидем.

—Буең җегетләрнеке. Исемең ничек әле?

—Карип мин. Карип.

—Хе-хе-хе. Исемеңне беләсең икән. Хуш. Маладис. Ә менә син, Карип, әйт әле, минем бакчага кыяр урларга төшкәнең бармы?

Бу абзыйның менә шулай тиктомалдан күзгә туп-туры карап сорау бирә торган гадәте барын беләм. Хәйләкәр ул, җавабыңның ялганмы-юкмы икәнен шундук сизеп ала. Ялганладыңмы—кызарасың. Кызардыңмы—

Әнәс ХӘСӘНОВ (1935)—*прозаик, шагыйрь, тәрҗемәче; «Җырым—ал җилкән», «Минем сандугачларым», «Кояшлы яңгыр», һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

тотылдың. Мин кызармыйм, бакчаларына төшкәнем юк. Исән чагында әби дә әйтә иде, хәзер әни дә, кеше әйберенә кул сузасы булма, ди. Зур гөнаһ ул, ди. Минем сират күперен чыкканда егылып төшеп тәмугта янасым килми, Алла сакласын.

—Юк, Насыйбулла абзый, төшкәнем юк,—дим, аның миңа төбәлгән сирәк соры керфекле күлемсерәп торган күзләренә карап.

—Күрәм, күрәм, төшмәгәнсең. Кыяр яратасыңмы соң?

—Булса яратам инде... Аны кем яратмый? Яшь кыярның хуш исләре борынны ярып кергәндә авыздан сулар килә...

—Вәт, вәт...

Насыйбулла абзыйның кушаматы «вәт-вәт». Кайсы Насыйбулла дигәндә, теге тегермәнче «вәт-вәт Насыйбулла» инде, диләр.

Заманында йомышы төшеп, күрше авылдан бер хатын Насыйбулла абзыйны сорап килгән, имеш. Хатыны Мәүлия апа, шаяртыпмы, көнләшепме:

—Син кайсы Насыйбулланы эзлисең соң? Теге тел бистәсе, озын, ябык, чандыр, үзе ямьсез, үзе кәкре аяклы, зур башлы кешене эзлисенме?— дигән.

Теге хатын әйткән, имеш:

—Вәт, вәт. Шуны, шуны.

Шуннан бирле аңа «вәт-вәт Насыйбулла» кушаматы ябышып калган. Шаян, мәзәкчән кеше буларак, ул үзе дә бу сүзләрне кушып җибәреп, авыз кырыйларын уйнаклатып, көлдерергә ярата:

—Вәт-вәт, дөресен әйттен.

—Вәт-вәт, өстенә бастың.

Әй, сүзем кыяр турында иде бит әле.

—Кыярны аны кем яратмый инде.

Тегермәнче абзый иске кәчтүменең бүлтәеп торган кесәсеннән зур гына кыяр алып, җиңенә сөртте дә миңа сузды.

—Мә, яратсаң. Мәүлия әбиең буш арада кимерерсең дип биреп җибәргәли. Кайгырта карчык, кайгырта минем тамакны. Тик минем теш-шәрифләремнең рәте юк. Аша, мә, аша. Син дә шундый үзеңне кайгырта торган кызга өйлән, яме.

Минем кыстата торган гадәтем юк. Ашыйсым килгәндә бигрәк тә. Ә минем гел ашыйсым килеп тора. Әни, үскәнгә шулай ул, ди.

—Син, кем, Карип улым, ул кыярны шыкырт-шыкырт иттереп, мин дә ишетелерлек итеп аша, яме.

Мин шартлатып тешләп кыярны ике-өч кенә каптым. Миңа елмаеп карап торган Насыйбулла абзыйның төк баскан бугаз төене кыймылдап-кыймылдап алды. Ашап бетергәч, мин:

—Рәхмәт, Насыйбулла абзый. Кыярың бик тәмле, сусыл икән,— дидем.

—Вәт-вәт,—диде ул.—Көненә икешәр кат үзең су сипсән, тагын да тәмлерәк була әле ул.—Ә менә япь-яшь килеш йокыга куерып, эшенне онытырга ярамый. Ник килгәнеңне ник әйтмисең? Ә?

—Әни әйткәние, ипи салырга менә шушыны...—дип, мин оялып сүземне башлаган идем, ул үзе дәвам итте:

—Вә-әт. Тарттырып бирсен әле, дигән ие, шулаймы? Әй, Карип улым, бу җурнагыз тегермән ташларына сыланып кына бетәчәк ие. Әз бит бу. Шөкер, ташларны себереп куймаганыем. Тарттырырмын анысы, Алла боерса. Тик җил туктады бит әле, гөнаһ шомлыгына каршы. Күрәсең ич,

тегермән канатлары әйләнми. Күтәргә кала.

—Озакмы инде ул, Насыйбулла абзый?

—Анысын бер Ходай гына белә инде.—Шулай дип, тегермәнче абзый, өстендәге кәчтүмен салып, селеккәләргә кереште. Тирә-якка он тузаны таралды.

Шул мәлне, нәрсәдер исенә төшкәндәй, Насыйбулла абзый капыл гына торып басты, бер мина, бер тегермәненә карап тора башлады. Аннары бөтен гәүдәсе белән артка таба киерелде дә кинәт алга бөгелеп, тирә-юньне яңгыратты:

—А-а-ап-чхи!

Ана тегермәне җавап бирде:

...пчхи!

Тегермән өстендәге тук күгәрченнәр, чыпчыклар пырылдашып һавага күтәрелде.

—Исәнлеккә-саулыкка!

Насыйбулла абзый тагын артка киерелде, тагын көтүче Ризван абзыйның озын, очы ат койрыгыннан йолкып үргән кыллы чыбыркысы шартлаган тавыш яңгыратты:

—А-а-ап-чхи! Исәнлеккә-саулыкка!

Мин саный башладым—ике, өч, дүрт, биш... Насыйбулла абзый төчкерә дә төчкерә, аның саен үзенә-үзе теләк тели—исәнлеккә-саулыкка. Шуның өстенә төчкергән саен кысылып кына әллә керә, әллә чыга торган һава тавышы ишетелеп китә:

—А-а-ап-чхи! Пси-и-ий...

—А-а-ап-чхи! Пси-и-ий... Исәнлеккә-саулыкка...

Шулай шактый кабатлангач кына мин Насыйбулла абзыйның төчкергәч тын алуы шундый тавышлы икәнен анладым. Ризван абзый чыбыркысы әле тагын кат-кат яңгырады. Күгәрченнәр инде шактый еракта әйләнеп-әйләнеп очып йөриләр иде. Төчкерү ничек кинәт башланса, шулай ук кинәт бетеп тә китте. Насыйбулла абзый кесәләрен актарып, сап-сары кулъяулыгын эзләп тапты, күз яшьләрен сөртте, тәмләп, ыңгырашкан авазлар чыгарып, озаклап борынын сеңгергәч, берни булмагандай миңа борылды:

— Әлләрги диләр миндә. Әлләрги. Он тузаны шулай итә. Унар-унбишәр төчкертә. Син әнә серкә очырган арыш исен, юл кырыйларындагы чәчәк исләрен сизәсеңме?

—Сизәм. Алардан бал исләре дә аңкып тора.

—Ә мин яз көннәре берни сизмим. Мать якасы. Ә менә син, Карип, әйт әле, сүгенәсеңме?

Мин тагын аптырап калдым. Тиктомалдан сорый бит.

—Юк-у-ук. Сүгенмим. Син бигрәк инде.

—Алдашмыйсынмы?

—Имансыз китим! Сүгенмим!

—Әстәгъфирулла диген, үскәнем. Имансыз киткән кеше—ул тәмуг кисәве. Теге дөньяда сүгенгән кешегә утлы таба ялаталар ди. Менә бит. Алла сакласын. Болар дөрес булса, имансыз да китсән, анда инде син—пропал.

—Әни дә әйткәне бар ие...

—Туты шул. Ярый әле, дөресен сөйлисең, алдашмыйсың.

Шулай дип Насыйбулла абзый каешланып беткән эшләпәсен баш түбәсенә чигәреп куйды. Аның кырмыска таеп егылырлык шома, ялтырап

торган пеләшенә кояш нурлары кунды.

—Сүгенсәң, менә минем шикелле пеләш каласың...

Әллә дөресен әйтә, әллә тагын шаярта. Минем бер генә дә пеләш каласым килми.

—Ә син сүгенә иденмени?

Насыйбулла абзый бераз тын торгач:

—Баш бар синдә. Ба-ар,—дип нәтиҗә ясады.—Агач пәке түгел син. Сүгенгәнгә түгел, минем чәчләр фронтта генераллар гына кия торган каракүл бүрек киеп, фарсит иткәнгә күрә коелып беттеләр. Менә маңгайдагы җөйне күрәсеңме? Ул да шуның эзе.

Белмим, әллә тагын шаяра, әллә дөресен әйтә.

—Йә, киңәш ит әле, хәзер нишлибез инде?

—Белмим шул,—дим,—нишлик соң?

—Җил чыкканны икәүләп көтәбезме, диюем. Әллә Сәгыйдә әбиләренә барып киләсеңме? Шулай итик без. Кайчан чыга әле ул җил. Ә син, менә ипи салырга әни көтеп утыра дисең... Йөгереп кенә барып кил син Сәгыйдә карчыкка. Үзегездән якында ялгыз яшәүче Сәгыйдә карчыкны беләсеңдер ич инде.

—Беләм инде, беләм.

—Менә яхшы. Йөгереп кенә барып кил әле. Менә шушы капчыкны бир үзенә. Әйт, җил туктаган, тегермәнгә җил кирәк, диген. Насыйбулла абзый җибәрде, диген.

Минем ышаныргамы, юкмы дип икеләнеп торганны күргәч:

—Бармасаң, мин кайтып китәм, алайса. Үзең тарттырып бир әле дип торасың. Мин бит җилсез тегермәнне эшләтә алмыйм.

—Бу капчык белән ул нишләсен икән?

—Үзе белә ул, үзе белә. Аның белмәгәне юк.

Әйе шул, Сәгыйдә әби бөтен авылда дан тота. Аның урман-кырда әллә нинди чәчәкләр, үләннәр, тамырлар җыеп, авыру кешеләрне дәвалаганын кем генә белми. Барысы да кышын-җәен аңа йөри. Ә ул юмарт, бирә.

Мин киттем, Насыйбулла абзый күзендә шаян чаткылар уйнатып озатып калды. Мин йөгерә-йөгерә барып җиткәндә Сәгыйдә әби чип-чиста себерелгән ишек алдында чеби-чеби дип тавык-чебиләрен ашатып йөри иде. Насыйбулла абзый йомышын әйткәч, ул миңа карап:

—Әй, бала, бала,—дип, башын чайкап авыр сулап куйды. Авыз эченнән генә тагын нәрсәдер әйтте. Аннан соң бераз уйланып торды да:

—Кая әле, шушында салырга куштымы?—дип кулымнан капчыкны алып өйалдына кереп китте. Мин кызыксынып аңа иярдем. «Әллә әфсен-төфсен укып, җил чыгара беләме икән?» Сәгыйдә әби лардан соскыч белән кырып-себереп капчыкка нидер салды да миңа тоттырды.

—Нишләп соң ул сине үз карчыгына гына җибәрмәгән... Миңа җибәргән. Мә, улым, илтеп бир шуны үзенә. Менә моны ул синең карчыгың Мәүлия әбидән алып торган булган, диген. Шул әҗәтне кайтарам. Шулай дип әйтте, диярсең.

—Сәгыйдә әби, моның белән ничек җил чыгарып булсын инде?—Мин берни аңламый карчыкка текәлдем.

—Ул да үзе белә. Бар, илтеп бир,—дип күзлек пыялаларын сөрткәләп артымнан карап калды. Бер аулак тыкрыкка җиткәч, мин капчыкны ачып карадым. Анда бернинди серле әйбер юк, бер чеметем борчак кына бар иде. Һи!

Мин кире кайтканда Насыйбулла абзый минем шикелле эш белән килгән ике-өч яшьтәше белән сөйләшеп утыра иде.

—Булмадымыни? Капчыгың буп-буш,—дип ул кеткелдәп көлә башлады.—Нәстә диде, әйт әле, нәстә диде?

—Ник мина җибәргән сине, үз карчыгына гына җибәрмәгән,—диде.—Ә капчык төбенә бер соскыч борчак салды.—Мәүлиясеннән әҗәткә алып торган ием, илтеп бир шуны, диде. Нәрсәгә ул, дигән ием, үзе белә, ул да үзе белә, диде.

Насыйбулла абзый ышанмады бугай, капчыкны төбеннән тотып селкеде. Аннан чирәм өстенә аз-маз борчак коелды. Абзыйның йөзенә караңгылык йөгерде. Ул «ык» итте дә ютәлли башлады. Шомарып беткән ватык тегермән ташлары өстенә менеп кунаклаган картлар, эчләрен тотып, чирәм өстенә аудылар. Аларның туктый алмый шарык-шарык көлеп ятуына кәефе киттеме, Насыйбулла абзый:

—Сез дә инде... Картаеп акылга туймаган нәстәләр... Җырдылар авызларын... —диде дә үзе дә кушылып, стена сәгате герләрен күтәреп куйган тавышлар чыгарып көлә башлады. Көлеп аргач:

—Мин сезнең журнаны иртәгә тарттырырмын, Карип улым. Син инде, мотри, моны әниләреңә сөйли күрмә, яме,—диде.

Сөйләргә ник ярамаганны мин соңыннан, бу хәлне Илһам дустым белән уртаклашканнан соң гына аңладым. Искә төшкән саен хәзер дә аның белән көлешәбез әле. Теге картлар мине очратканда:

—Ничек соң, егет, җил капчыгың тишелмәдеме әле?—дип озак еллар көлеп аптыраттылар. Оят булса да әйтим инде. Мин дә Насыйбулла абзый каршында әҗәтле булып калмадым.

Теге хәлләрдән соң бер-ике ел узгач, буйга да шактый тартылгач, Илһам дустым:

—Әйдә, кызык ясыйк әле,—дип, көтмәгәндә мина бер кинәш бирде. Насыйбулла абзыйның яшь чагында Сәгыйдә апайны яратып, өйләнергә йөргәнен, тик эше пешмәгәнен без олылардан ишетеп белдек. Аулак урыннарда кызны туры китереп туксан тугыз тапкыр тупсасын какшатып бетергән, имеш. Әмма һаман да ярмасы бүртмәгән. Җор, тиктормас теле аркасында аның җилбәзәк дигән даны таралган булган шул.

—Синең бөтен эшең телең белән тегермән тарттыру,—дигән, имеш, аңа Сәгыйдә апай.—Кулыннан эш килсә, әнә тегермәнче бул, калхуз тегермәненә тегермәнче кирәк ди.

Ничек килеп чыккандыр, әйтә алмыйм, ә менә фронтка киткәнче дә, аннан күкрәгенә орден-медаль тутырып кайткач та Насыйбулла абзый тегермәнче булып эшләде. Хәер, мин бераз читкәрәк киттем бит әле. Сүзем бит Насыйбулла абзыйга әҗәт кайтару хакында иде...

Көннәрдән бер көнне ул авыл картлары белән кибет янындагы ыштан төпләре шомартып бетергән агач бүкәннәр өстендә сугышта күргәннәрен сөйләшеп утырганда мин аның янына килдем дә:

—Насыйбулла абзый, читкәрәк китик әле, сиңа әйтәсе сүзем бар,—дидем. Шайтан котырса, оят кача икән шул.

—Сүзең булса, әйт. Яшь киленмени,—диде ул.—Вәт бит, ә?

—Кеше алдында әйтмәскә кушканнар ие. Бик тә үтенгәннәр ие.

—Кем кушты, кем?

—Әйтә алмыйм, ачуланма. Читкәрәк китик.

—Менә күрдегезме, җәмәгать. Насыйбулла абзагыз чутта әле. Бәлкем берәр нечкә билнең мина күзе төшкәндер.—Насыйбулла абзый янындагыларга

күз кысып алды да минем янга килде.

—Насыйбулла абзый, Сәгыйдә әби авырып киткән бит.

—Сун?

—Зинһар, үзенә генә барып әйт,—ди.—Сүз чыгып, Мәүлиясе колагына чалынып кала күрмәсен, ди. Яшьли үк бик көнче ие. Насыйбулланың тенкәсенә тигәнен ишетеп беләием, ди. Хәлем бик авыр, ди.

—Һе-е...

—Якты дөньяда бәхилләшик. Иртәгә әллә калам, әллә юк. Кеше аягы басыла төшкәч кенә кереп чыкмасмы икән, ди.

—Шулай ук мыни? Ялгыздан-ялгыз калды шул, мескен...

—Ие. Иртәгә миңа улларына телеграмма сугарга да кушты...

—Юләр сатмыйсыңмы, малай актыгы? Юк елгага юк тегермән корып йөрмисенме?—дим.

—Имансыз китим!

—Әстәгъфирулла! Китәрсең шул һаман болай каргангач. Әлгаязы билләһи. Тәүбә диген, тиле бәрән орлыгы ашадыңмы әллә? Каргануынны һаман онытмыйсың икән.

—Тәүбә, тәүбә.. Тик, зинһар, сак йөрсен, ди. Картайган көндә рисвай булмыйк, ди.

—Вәт-вәт... Исенә төшә башлаган алайса... Иске авыздан яна сүз.

—Нәрсә?

—Әй, анысы сиңа кирәкми лә.

—Ярар, Насыйбулла абзый, мин киттем. Нәрсә дим сон?

—Авырып торгач, керми булмас дип әйтте, диген.

Шулай итеп, абзыйның ризалыгын алып, мин китеп бардым. Ә кичен караңгы капкач кына Илһам белән без Сәгыйдә әбинең коймасы янында кеше буе булып үскән кычыткан арасына кереп постык та «кызык» көтеп утыра башладык. Килерме, юкмы? Утырабыз, утырабыз, юк та юк. Ышанмады, күрәсең. Инде китәргә җыенганда гына Сәгыйдә әбинең ишек алдындагы казлары каңгылдый башлады. Сак кына капка келәсенә кагылган тавыш та ишетелеп китте. «Килде!» Капка ачылмады, бикле иде. Казлар тынды дигәндә генә каралтының бакча ягыннан ашлык тулы капчык гөпелдәп ауган тавыш килде. Кемдер ыңгырашып әби-бабайларны да искә төшереп алды бугай. Казлар инде бик каты каңгылдашырга керешге. Ул арада шыгырдап ачылган өйалды ишегеннән тышка тонык кына ут яктысы сирпелде. Аннан Сәгыйдә әбинең шомлы тавышы яңгырады:

—Нәрсәгә борчыласыз инде? Ни булды сезгә, малкайлар? Ә? Берәр җәнлек кердеме әллә? Әстәгъфирулла! Кем бу? Карак бар! Карак! Ярдәм итегез!

—Сәгыйдә... Сәгыйдә, дим. Шаулама әле, зинһар.—Бу Насыйбулла абзый тавышы иде.—Мин әле бу, мин... Менә үзең әйткәч кереп чыгыйм дигәнием. Капкаң бикле. Аякны каймыктырдым, ахрысы.. Булыш әле, булыш... Торыйм әле...

—Насыйбулла? Син нишләп йөрисең, ә? Төн уртасында? Ә?

—Сине бик сырхаулап ята диделәр ләбаса. Уфф! Бу аяк әллә сынды микән? Басарга да авырта...

—Әй, Насыйбулла, Насыйбулла... Картаеп акылга туярга вакыт бит инде... Кара әле кыяфәтеңне, күлмәгеңне... Умырылып төшкән ләбаса. Йа, Хода.

—Койман аша төшкәндә нәстәгәдер эләгеп аерылды ла ул. Кадалгыры...

Ичмасам, бу казларын разбуй сала... Хәлен ничек соң, ә?

—Миңа нәрсә булсын. Ялгыз башым, тыныч колагым. Әлегә Ходайга шөкер.

—Авырып ятасың, диделәр бит. Кереп кенә чыкмас микән, бәхилләшеп калыйк, дип әйтте диделәр.

—Нәрсә, нәрсә? Моны нинди кара ялганчы уйлап тапкан тагын?—Сәгыйдә әбинең тавышында артык дәрәҗәдә аптырау, гаҗәпләнү төсмерләре яңгырады.—Уемда да булганы юк. Йа, Алла...

—Хакмы? Хәер, үзем дә күреп торам инде. Алай икән, алайса... Менә бит гөнаһ шомлыгы, ә? Габделбәр малае Карип килеп әйтте. Кара чутыр, чегән кисәге! Үзем дә инде, тегермәндә сакал агарткан нәстә.

—Их, карт юләр... Шуңа ышандыңмы? Сине шул шайтан ялаган малай җилгә атландырган инде алайса, тегермәнче. Шуклыкта сине дә уздырган бу, ә?

—Ну инде! Очратыйм гына, чәчкәнен урам мин аның. Чәүкә мие эчкән нәстә... Үземне әйтәм әле...

—Һи, урган ди шул берәү. Шым бул инде син, шым бул... Авызыңнан җил алсын, илтеп дәрьяга салсын, исән булса, атасына гына әйтер идең дә бит. Ярамый балалар белән булышып йөрергә. Бөтен авыл халкы шау килер. Үзең дә көлкегә калырсың, мине дә рисвай итәрсең. Ил авызына иләк ябып булмый. Зинһар, шым бул. Картаймыш көндә гыйшык-мыйшыкларын яңартып йөриләр икән дип, даныбызны чыгарырлар. Ишетелсә, балаларыбыз алдында да оятлы булырбыз.

—Рәсүл тырнагы булдың инде син дә. Гомер буена.—Насыйбулла абзый үпкәләргә дә өлгерде бугай.

—Әй, сакаллы сабый. Һаман яшьлек юләрлекләрен оныта алмыйсың, ә... Хи-хи-хи...

—Ах-ти, шайтан таягы, ә! Теге малайны әйтәм. Менә бит хәзерге яшьләр! Ә? Киттем алайса. Авырмыйсың икән, бит әйбәт. Хуш, гаеп итмә инде. Ах-ти, шайтан таягы... Хи-хи-хи...

Насыйбулла абзый белән Сәгыйдә әбигә кушылып Илһам да «пырх» итте:

—Шайтан таягы дип сине әйтәләр, хы-хы...

Илһамның авызын томаларга дип сузылуым булды, кулымны ачы итеп кычыткан өтеп алды. Кычкырып җибәрүдән чак тыелып калдым. Ул арада капка келәсе әкрен генә ачылды да тирә-ягына карана-карана безнең яннан шыпан-шыпан гына Насыйбулла абзый узып китте.

Бу хәлләр ул чакта мәзәк тоелса да, мин озак вакытлар олы кешеләрне рәнҗеттем бит дип борчылып йөрдем. Тора-бара, нишләп болай күңелемдә борчу саклап йөрим соң, Насыйбулла абзыйны күрим дә гафу үтеним дигән уйга килдем. Элемтә училищесына кереп кайткан елны тартмалы инглиз чәе, тәмле конфетлар алып, Насыйбулла абзый янына киттем. Капкаларыннан кергәндә ул аяклары тирәсендә чуалган зур гына сары мәче белән сөйләшә-сөйләшә помидор бәйләр өчен казыклар әзерләп йөри иде. Аның бөгелә төшкән какча гәүдәсен, ябык җилкәләрен күргәч, башымнан картлач шактый мәлҗерәгән икән дигән уй йөгереп үтте. Еллар эзсез узмый шул.

—Исәнме, Насыйбулла абзый, сау-сәламәт кенә торасыңмы?—дип каршына киттем.

—Кем буласың? Күзем шәйләп бетерми. Якынрак кил,—диде ул.

—Мин әле бу, Насыйбулла абзый, Карип мин, дим, Габделбәр улы.

Карт һич көтмәгәндә житез генә гәүдәсен турайтты да, аксый төшеп мина каршы атлады. Башыма секунды белән уй килде: теге хәлләрне искә алып янакка салып жибәрә күрмәсен тагын. Карт килеп туктады, жетелеген шактый югалта төшкән күзләре белән йөземә текәлде. Мин дә анын бөтереп куйган мыегыннан, чип-чиста итеп кырылган янакларыннан, кыска гына калдырылган ап-ак сакалыннан күз алмый торам. Юк, һичнинди усаллыкнын эзе дә юк иде бу ачык йөздә. Юкка гына шикләнгәнмен икән. Ул әле кичә аерылышкандай гади генә:

—Ир кеше булгансын... Үзгәргәнсен. Тәс-буен, килбәтен, бигрәк тә мыегын гел бабаенныкы икән,—дип күрешергә кул сузды. Мин жинел сулап куйдым. Насыйбулла абзый зәңгәр тамырлары бүлтәеп торган куллары белән минем кулны нык кына кысып жибәрми торды да хихылдап көлә башлады. Аннары ачык тәрәзәгә борылып:

—Сәгыйдә, Сәгыйдәкәй дим, чык әле бирегә... Сина әйтәм, чык әле, менә безгә кем килгән!—дип кычкырды. Гажәпләнүемнән мин авызымны ябарга да оныттым—ишек ачылып, аннан ап-ак күлмәген жилфердәтеп, чигүле яулыгын пөхтә итеп арттан бәйләгән Сәгыйдә әби килеп чыкты. Анын кин кашлары астыннан кызыксынулы күзләре мина төбәлде. Таныды:

—Теге Габделбәр малае Карип шушы лабаса,—дип, кул бирде. Мин, ниһаять, сүз әйтерлек хәлгә килдем.

—Менә училищега кереп кайттым. Хәлегезне белим дип кердем.

—Хуш, хуш. Кендек канын тамган жир гомерен буе тартып тора ул, бәбкәм.

—Сез инде теге чактагы шуклык өчен, зинһар, гафу итә күрегез. Ямьсез килеп чыккан иде бит. Гаеп миндә.

—Вәт-вәт.—Картлар бер-берсенә күз атып алдылар да, көлә башладылар.

—Ярар инде, узган эшкә салават, ди халык... Инә белән тагын кое казыйсын бар икән әле алайса, бохара мәчесе. Гыйлем бик кирәк нәстә ул. Ә теге чакта икебезнен дә сина кәеф бик киткән ие. Әйе. Аннары инде...

Минем әле һаман гажәпләнүем йөземдә чагылганга, күрәсен, Насыйбулла абзый күнел тартмаларын бушатырга ниятләде.

—Менә, күрәсенме дөнья хәлләрен. Без хәзер берничә ел бергә инде. Син, Сәгыйдәкәй, әйдә, чәй куеп жибәр. Хуш исле үләннәренне салып. Бар әле, бар, —дип карчыкны өйгә кертеп жибәрде. Аннары:

—Мәүлия әбиен вафат булды бит. Авыр туфрагы жинел булсын. Мин инде шуннан сон түздем-түздем дә Сәгыйдәнен капкасын барып кактым. Әйе... Көндез! Уйлама—көндез! Бер кактым, ике кактым, өч кактым... Ялгызлык ул, энем, үләт ялаган нәстә, бер тешләсә, өзми калмый. Әнә, Сәгыйдә дә килене белән улы янына сыймады. Тормыш ул кырык катлы дип юкка гына әйтмиләр шул. Мине кызларым Казанга алып китәргә теләгәннәр ие дә, туган туфрагымны ташлап китәсем килмәде. Аннары, вчу-теки, мин кәжә катыгы түгел ич... Төтен санап ятмыйм, хәрәкәтләнәм... Сәгыйдәкәй дә ялгызлыктан гарык ие. Тәкъдиребездә шулай язылган, күрәсен. Менә бит ул ничек килеп чыкты.

—Мин, Насыйбулла абзый, сезнен өчен бик шат. Әйбәт булган. Яшьли кавыша алмаганны менә хәзер кавышкансыз икән. Тегермән сагындырмыймы сон?

—Әй, энем... Сагындырмаган кая... Хәзер анын инде кирәге калмады, дөнья икенче. Тегермән ул, улым, изге нәстә. Чөнки дә ризыкка бәйле. Нигъмәт тулы ашъяулык шикелле. Ипекәй төргән тастымал шикелле.

Тегермән ташы астыннан агып торган жып-жылы он, ул, энем, адәмгә Ходай сые ... .

Ул арада ап-ак алъяпкыч япкан Сәгыйдә әби ачык тәрәзәгә килде:

— Йә, керәсезме инде... Чәем өлгерде.

Картның йөзе яктырып китте.

Тәмле чәй исләре аңкып торган бүлмәгә кергәч, өстәл өстендә майлы тура, бал, өрек, тәбия, ап-ак күмәч күреп мин шатланып куйдым, әйбәт яшиләр. Минем карашны сизеп алган Насыйбулла абзый:

—Менә, Ходайга шөкер, табыныбыз һәрчак мул,—дип аңлатырга кирәк тапты.—Балаларыбыздан күчтәнәч агып кына тора. Мин бит әле участник войны! Пенсиям әйбәт. Сәгыйдәкәйнең дә иш янына куш. Яшибез шулай шөкерана кылып, чуак көннәребездә. Никах укыттык...

—Аллергия җәфаламыймы соң?

—Бетте ул минем, бетте. Менә Сәгыйдәкәй үләннәр белән дәвалап тәки савыктырды, рәхмәт төшкере.

Насыйбулла абзый рәхмәтле карашы белән карап алгач, миңа:

—Сиңа сөйлим әле. Яшь киленне алып кайтуым үзе бер кызык булды әле, —дип елмаеп сөйләргә тотынды.

—Син инде, атасы, бик туарылып китмә. Нинди кызык таптың инде шуннан,—дип Сәгыйдә әби аның сүзен бүлдерде. Карт аңа:

—Дөресен әйткәндә, чәчәгебез коелса да безне кавыштыручы Карип булды лабаса,—диде.—Теге төндә егыла-мәтәлә килеп кергән төннән соң минем түбәгә дә кояш чыкты, син мине күргән саен елмая башладың лабаса.

...Шул. Бардым мин киленне алырга. Сөйләшкәнчә, ул әйбер-төрбирен төйнәп куйган. Күз салуга шикләнә калдым—зур, авырдыр бу. Сер бирмим әле. Күтәреп чыгып бер-ике адым атлавым булды, теге чакта каймыккан аяк отказ бирә генә бит. Киленгә сиздермәскә тырышып, кесәгә тыгылам да аякны борып-борып чеметеп алам, тыгылам да чеметеп алам. Юк, атламый гына, иблис. Рәхмәт, Сәгыйдә әбиең, юк ла, апаң, минем хәлне аңлады. Төенемне күтәрде, икенче кулы белән мине култыклап өемә алып кайтты. Шуннан бирле чөкердәшеп яшибез менә... Күчтәнәчләрең өчен рәхмәт. Хәер-дога сиңа. Аяк-кулың сызлаусыз булсын. Туган ягыңны онытып бетермә, яме.

Мин сәламәтлек, игелекле озын гомер теләп бәхетле картлар өеннән чыгып киткәндә алар, елмаешып, кул болгап калдылар.

—Вәт-вәт. Ходай һәркайсыбызга гомер бирсә, сәламәтлек тә бирсен.

—Рәхмәт.

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Татарстан язучыларының VIII съезды президиумы. Җентекләп карaганда байтак таныш йөзләрне күрергә мөмкин. Казан, 1974 ел.*



*Драматург Юныс Әминов (1921-82). 1980 елда төшкән фоторәсем.*

*Әдәбият-сәнгать вәкилләреннән бер төркем. Сулдан уңга— Диләрә Зөбәерова, Наил Хәйретдинов, Фәйзи Йосыпов, Мөдәррис Әгъләмов, Әхмәт Рәшитов, Малик Хәмитов. Октябрь (хәзерге Нурлат) районы. 1979 ел.*





*«Җыен» фондының җырчы Илһам Шакиров хөрмәтенә оештырылган утырыш-мәҗлестә катнашучылардан бер төркем. Сулдан уңга: Рабит Батулла, Илһам Шакиров, Равил Фәйзуллин улы Газиз белән, Марсель Галиев, Нәзифә Кәримова. Аккош күле. 2008 ел.*



*Шагыйрә Фирая Зыятдинова (1945-2006).*



*Танылган җырчы Шамил Әхмәтҗанов кызлары Гөлнар һәм Чулпан белән. 2005 ел.*

# ШАРТЛЫ ДӨНЬЯДА...

Хәзерге татар драматургиясе турында галимнәрнең фикерләре шактый күп төрле. Мактаучылар да, кискен тәнкыйть утына тотучылар да житәрлек. Чыннан да, милли драматургиябезнең бүгенге хәле уйланырлык. Әдәбиятыбызның «Алтын фонд»ын тәшкил итәрдәй пьесаларыбыз да юк түгел. Шул ук вакытта үзләренең сыйфаты, тематик һәм проблематик әһәмиятсезлеге, персонажларының тел ярлылыгы, ышандыру көченең житенкерәмәве белән йомшаграк сәхнә әсәрләре дә бар. Драматургиягә тартылучылар да, башка әдәби жанрлар белән чагыштырганда, күп түгел. Күрәсең, драма әсәрләренә хас чиклелек аларны да сагайта. Ләкин драматургиядә канат ныгыткан, танылган әдипләребез, төрле-төрле алым-чараларга мөрәҗәгать итеп, чит ил әдәби үрнәкләренә салынган кыйммәтләргә дә игътибарлы булып, күпмедер жанр чикләрен дә җимерә төшеп, укучы-тамашачы күнелендә озак еллар сакланырдай сәнгать әсәрләре тудыралар.

Мона ирешү, әлбәттә, җинел түгел. Алга таба классика булып китәрдәй пьесалар язылырмы? Бүгенге драматургия балаганнар, кәмитләр, шаккатризмнар кысаларында гына каламы? Әлеге һәм башка сораулар танылган драматург Мансур Гыйләҗев иҗаты тирәсендә дә куе болыт булып бөтерелә. Анын әсәрләре турында тәнкыйтьчеләрнең төрлесе төрле фикердә. Безнең максат исә, бу сорауларга ачыклык кертүдән бигрәк, М.Гыйләҗев иҗаты мисалында драматургиябезнең асылын тәшкил иткән шартлылык алымнары турында сөйләшү.

Шартлылыкның асыл сыйфаты, анын драматургиядәге урыны турында әдәбият галиме Фәрит Хатипов түбәндәге фикерне әйтә: «Шартлылык әдәби әсәрләрдә еш кулланыла. Шулай да ул пьесаларда, башка әдәби төрләргә караганда, күбрәк файдаланыла. Ә инде моның төп максаты,—кара-каршы сөйләшү формасының беркадәр кысанлыгы кайчак үзен сиздереп куйганда, фикер, тойгыларны, кирәкле информация белдерү мөмкинлеген бераз чикли төшкәндә, әлеге житешсезлекләрне яшерү, аларны бизәп җибәрү». *(Хатипов Ф. М. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма.— Тулыландырылган икенче басма.—Казан: Раннур, 2002.)*

Әлбәттә, шартлы дөньяны тудыруның үз алымнары һәм ысуллары да байтак. Аларны ачыклау һәм өйрәнү максатыннан, М.Гыйләҗевнең «Баскетболчы» комедиясенә тукталыйк. Комедия 1999 елда языла, ләкин, 2002 елда гына сәхнәләштерелгәнлектән, ара нибары өч кенә ел булса да, бу зур әһәмияткә ия. Гасырлар чиге—шактый сикәлтәле чор. Сәясәт үзгәргән, төрле кыйммәтләр буталган бу вакытта күпләр үзенә урын таба алмый, җәмгыять өчен үзенең кирәкле кеше икәнлеген дәлилләргә тырыша. Моның шулай булуын М.Гыйләҗев тә оста тоемлый. «Баскетболчы»ның шулай аталуы ук әсәрнең XXI гасыр укучы-тамашачысына адресланганлыгын күрсәтә кебек.

Пьеса шартлы алымнарның берсе—миф-хикәя белән башланып китә. Хыялый Сократ (төп персонаж) ниндидер бер журналдан мәкалә табып укый. Тик мәкаләнең миф-хикәя, автор уйдырмасы гына булуын без нибары комедия ахырында гына беләбез. Ә ул миф буе 165 сантиметрлы берәүнең баскетболчы буларак дөньякүләм

танылу вакыйгасына багышланган. Әлбәттә, гел яңалыкка омтылып яшәгән, авылның үзенчәлекле кешесе булган Сократ өчен әлеге миф-хикәядә тасвирланган сенсацион вакыйга зур бер максатка әйләнә. Әсәрнең сюжеты да шуңа нигезләнә.

*«**Тәлгать.** Беләсеңме, әти, теге журналны мин укып чыктым.*

***Сократ.** Нинди журналны?*

***Тәлгать.** Мексика баскетболчысы турындагы мәкаләне.*

***Сократ.** Шуннан ни?*

***Тәлгать.** Мәкалә түгел, хикәя икән ул. Язучы фантазиясе уйлап чыгарган хикәя. Буе йөз алтмыш сантиметр гына булган Мексика баскетболчысы дөньяда булмаган. Авторның хыялында туган хикәя генә ул.*

***Сократ.** Шулай икәнен үзем дә яхшы беләм».*

Әлеге мәгълүматның ялган булып чыгуын, уйдырма икәнлеген Сократ үзе дә белә, ләкин, кеше ялганына үз ялганын да кушып, үзенчәлекле хакыйкать уйлап чыгара, шуңа үзе дә ышана.

М.Гыйләҗев абсурдлык элементларыннан оешкан комедия иҗат итә һәм татар «абсурдлык театры»на нигез салучыларның берсе булып тора. «Безнең өчен сәеррәк яңгыраган бу исем билгеләгән әдәби агым, Көнбатышта XX гасырның 50-60нчы елларында кин җәелеп, рус драматургиясенә һәм театрына 80нче еллар ахырында үтеп керә. Ул, моңа кадәр өстенлек иткән реалистик традицияләр урынына килеп, традицион булмаган, заманча, яңа (модернистик) алымнарга, форма-чараларга нигезләнә. Анарда гадәттән тыш арттыру, трагифарска хас сурәтләр, фантастик һәм метафорик күренешләр өстенлек итә. Моңа омтылу, билгеле, һич тә үзмаксат түгел. Тормыш-чынбарлыкның ямьсез, кешелекне рухи һәм физик изә торган, кешелек сыйфатларын юкка чыгара торган күренешләрен автор һәм режиссер шартлы ситуацияләр ярдәмендә ача» дип яза Ә.Закирҗанов. *(Закирҗанов Әлфәт. Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре.—Казан: Татар.кит.нәшр., 2004.)*

М.Гыйләҗевнең «Баскетболчы» комедиясе—моның ачык мисалы. Шартлы мотивлардан авылның сазлык һәм су белән уратып алынган утрау рәвешендә бирелүенә басым ясау кирәктер. Автор шартлылыкның бер алымы булган аллегорияне бик оста файдалана һәм моның астына тирән фәлсәфи чынбарлыкны яшерә. Чынлыкта исә әлеге «утрау» Россия уртасындагы Татарстанны хәтерләтә. Ягъни Татарстан, батмаклыктагы авыл кебек, Рәсәй «сазлыгы»на чумган.

Шартлылык алымнарын төгәл билгеләү өчен, комедияне мизансценаларга бүлеп карау уңышлы. «Баскетболчы» егерме биш мизансценадан гыйбарәт. Алар арасындагы бәйләнеш гаять тыгыз. Күчешне тоемлавы вакыты-вакыты белән бик авыр. Пьесаны оештыруда әһәмиятле шартлылык алымнары булган кайбер мизансценаларга тукталыйк.

Беренче мизансцена—Сократның ишегалды уртасындагы такта ишек өстендә йоклап ятуыннан башланып китә. Әлеге күренешне тудырганда, автор шартлылыкның бер алымы—метафорага мөрәҗәгать итә. Шушы метафора Сократ тормышының билгесезлегенә ишарә ясый. Ягъни Сократ—тормышта үз урынын тапмаган, урталыкта калган шәхес. Ишек ачык та түгел, ябык та түгел, ә нәкъ менә күгәненнән алынган һәм ишегалды уртасында ята. Бу күренеш Сократның начар хуҗа булуына да ишарә. Йорт-җирен яраткан ир-атның ишегалдында һәрвакыт тәртип, эш-гамәлләре дә кысага сыя. Ә Сократның холык-фигыле аңлашылып бетми. Ул, уянгач, ишеккә нindидер билгеләр төшерә, буен үлчәп, сызык сыза.

*«**Сократ.** Нинди хикмәт инде бу? Кичтән генә буем бер метр да илле сигез сантиметр иде, ә хәзер бер метр да алтмыш биш сантиметрга җиткән. Моны ничек аңлатасың? Адәм баласы йоклаганда буйга үсә микәнни?(Уйлана). Дөп-дөрес—төнлә үсә, ә көндез кыскара. Бигрәк тә авыр әйберләр ташып маташсаң... Иртән санап чыгарсаң, минем буем бер метр да алтмыш биш сантиметр, һәм, нәтиҗәдә, минем язмыш үзгәрә дә куя! Хатын! Хатын! Кил әле монда!..»*

М.Гыйләҗевнең «Баскетболчы» комедиясе күңел монологларына бай түгел. Шулай да әлеге алым берничә мизансценада күзәтелә, алар шактый кыска. Әсәрдәге күңел монологлары афоризм һәм сентенцияләргә шактый бай. Драма әсәренә хас булганча, монологларны, һәм, гомумән, персонажлар сөйләмен импровизатор шагыйрьләр,

халык алдында ялкынлы чыгышлар ясаучы сүз осталарына тиңләргә була. Шул рәвешле комедиядә эпиклык белән лириклыкның күпмедер үрелеше күзәтелә. Ягъни эпиклык вакыйгалар бирелешендә, ә лириклык сөйләм экспрессиясендә чагыла.

Шартлы поэтик детальгә тагын бер үзенчәлек, автор табышы килеп кушыла. Ул—йокы. М.Гыйләҗевнең пьесаларында йоклау, гырылдау тавышлары, уяну зур урын алып тора. Мәсәлән, аның «Рәхәт яшибез!» комедиясенең проблематикасын ачуда гырылдау тавышларының әһәмияте зур булса, «Бичура» драмасында, халык йоклаган вакытта, кара җаннарның килүе, бөтен тирә-юньне туздырып китүе мөһим элемент булып тора. «Баскетболчы» комедиясе исә Сократның йокыдан уянуы белән башланып китә, хатыны Люция дә йокы ярата, тыныч тормышны сөя. Алга таба әлеге алым М.Гыйләҗевнең башка пьесаларында да күзәтелә. «Бала баласы балдан татлы»да Алмаз-Алик үз йокысын бүлүчеләр белән көрәшә, «Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре» комедияләрендә салмыш егетләр йоклап торуларына үзләренең кайда килеп эләгүләрен аңламыйча йөдиләр һ.б.

Шартлылыкның күзгә ташланган һәм әсәрдә мөһим функция башкарганнарының тагын кайберләренә тукталсак, Ләззәтнең хатыны Мәдинәне игътибардан читтә калдыру мөмкин түгел. Ул үзен биоробот-андроид дип атый һәм галәм белән тыгыз элемтәдә булуын әйтә. Күрәсең, әсәрнең соңгы мизансценасында аның су баскан авылга кайтып керүе дә шуның белән бәйледер. М.Гыйләҗевнең мондый аллегорик персонажларга мөрәҗәгать итүе Европа әдәбиятыннан килә һәм автор үзе дә моны искәртә.

Ләкин безнең татар әдәбиятына да аллегорик персонажлар ят түгел. Г.Коләхмәтовның Кызыл һәм Кара фикерен («Ике фикер»), Т.Миңнуллинның Әҗәл, Газраил һәм фәрештәләрен («Әлдермештән Әлмәндәр»), М.Гыйләҗевнең Бичура һәм кара җаннарын («Бичура») һ.б. мисалга китерергә мөмкин. Бу персонажларны Европа халыклары әдәбиятларыннан кергән дип әйтү һич дөрес булмас. Аларга миллилек хас һәм алар бөтенләе белән безнеке булып тора.

Шартлы алымнарга гомумирәк якын килсәк, «Баскетболчы» комедиясендә сурәтләнгән геройларның эш-гамәлләре дә акылга сыймый, ягъни шартлы алымнардан исәпләнә. Персонажлар, бер яктан, мәгънәсез, хәтта көлке генә уята торган комиклар, икенче яктан, яңа социаль шартларга җайлаша алмыйча аптыраган, кыйблаларын югалткан шәхесләр итеп бирелә.

Абсурд пьесаларында төрле интерпретациягә, ягъни үзенчә фикерләүгә, әсәрне үзенчә кабул итүгә киң урын калдырыла. М.Гыйләҗев моннан уңышлы файдалана. Бу без санап узган шартлылык алымнарында да ачык чагыла. Символик образлар, күренешләр аша автор җитди сәяси мәсьәләләр күтәрә. Бу—Татарстанның бүгенгесе һәм киләчәге. Россия арбасына утырып, аның җырын гыны җырлап йөрсәк, әлеге сазлыкта батып калмабызмы? Әсәр укучы-тамашачыны әнә шул турыда да уйланырга этәрә.

«Баскетболчы» комедиясенең мәсьәлә-проблемалары, сәхнәләштерелүе турында автор болай ди: «Әсәр комедия булса да, биредә фикерләр күп, милли, иҗтимагый проблемалар киң яктыртылган. Пьесаны сәхнәләштергәндә, режиссер М.Сәлимҗанов үз фикерләрен дә кертте. Аның кайберләре минеке белән чагышып та бетмәде. Ләкин әсәр бик уңышлы куелган дип уйлыйм» (шәхси әңгәмәдән).

«М.Гыйләҗевнең «Баскетболчы» әсәре—милләт язмышын яктырткан иң уңышлы комедияләрнең берсе. Милләтнең чишмә башы булган татар авылының әкренләп бетүе сәбәпләрен драматург түбәндәгеләрдә күрә: дәүләт тарафыннан авыл хуҗалыгына тиешле ярдәм булмау, эчкечелек, кешеләрнең, авылдан шәһәргә китеп, кире әйләнеп кайтырга теләмәве, яшьләрнең гасырлардан-гасырларга, буыннан-буынга күчеп килгән гореф-гадәтләрне санга сукмавы, катнаш гаиләләр арту, ир кешеләрнең, җиң сызганып, җир эшкәртү, йорт торгызу һәм башка эшләр урынына, холыксызланып, файдасыз эшләр белән мавыгуы... Кызыклы һәм мавыктыргыч сюжетка корылган пьесада милли, иҗтимагый-мәдәни, фәлсәфи проблематика төрләрен аерып чыгарырга була»,- дип язды А.Саттарова да *(Саттарова Алсу. Яңа дулкында Татар драматургиясе (1980-2000 еллар): Сайланма пьесалар.—Казан: «Хәтер» нәшрияты (Тарих), 2003.).*

Комедиянең төп персонажы—Сократ, дидек. Ул үзенчәлекле, каршылыклы герой булып күзаллана. Сократ кайчандыр укытучы булып эшләгән, хисап, физика,

биология, химия, астрономия, рәсем... укыткан. Ул—шагыйрь, космонавт, геолог, астроном, экстрасенс, гипнозчы, артист. Аның һөнәрләрен санап кына бетерерлек түгел! Мәктәп ябылгач, Сократның эзләнүчән, тынгысыз җаны эшсез калуны кабул итә алмый. Аның яшәү рәвеше, асылы—хәрәкәт, нәрсәгәдер омтылу.

М.Гыйләҗев җәмгыятебезне ничек бар, шулай сурәтли. Сократ күршесе Диогенның эчүгә сабышуы, үзенә таяныч ноктасы таба алмавы, хатыны романтик Хәнифәнең гомере буе иренең эчүеннән куркып яшәве, эчмәсен өчен, Сократның барлык фантазияләренә кушылып юләрләнүен хуплавы—барысы да чынбарлыгыбыз. Автор Хәнифә образы аша гомерләрен эчүче иргә буйсынып яшәүгә сарыф иткән хатыннарның җыелма образын тудыра, аның фаҗигасен ачарга омтылыш ясый. Тик, жанр мөмкинлекләре күпмедер чикләү сәбәпле, Хәнифә фаҗигале шәхес буларак бар тулылыгында ачылып бетми. Шигъри җанлы, мөлаем, хыялый булып кала. Сократның хатыны булса, ул күпкә бәхетлерәк булыр иде. Әнә бит: аны ишеп яуган яңгыр да Люцияне куркыткан кебек куркытмый. Ул яңгырга соклана, аннан матурлык таба. Хәнифә—оптимистик карашлы. Шуның белән дә ул башка персонажлардан аерылып тора. «...драматургиягә һәм сәхнәгә яктылык һәм күтәренке рух җитми, оптимизм хас түгел. Моның өчен иҗатчыларны гына гаепләү дә дөрес үк булмас, чөнки заманы шундый—оптимизм рухыннан мәхрүм. Ә алар иң башта чынбарлыкны дөрес чагылдыруны максат итәләр» *(Әхмәдуллин Азат. Үрнәк герой сагындыра. Казан утлары, 2004.—№ 7.).*

Драматург, шартлы алымнарны, ситуацияләрне урыны-урыны белән арттыргаласа да, чынбарлыктан читкә китми. Мәсәлән, реаль чынбарлыкны аеруча да үтемле чагылдыру максатыннан, тагын бер шартлы алымнан оста файдалана. Ул поэтик деталь—зонт. Аның астында Диоген, Сократ та, Хәнифә, Платон да, Венера да, башкалар да яңгырдан саклана. Әлеге деталь пьесаның сәнгатьчә эшләнешен тагын да баета, автор салган мәгънәне укучы-тамашачыга тиз һәм ансат җиткерә.

Җәмгыятебездәге көчле сәяси «туфаннардан» бер бәләкәй генә зонт саклап кала алырмы? Үзебезгә шундый кечкенә таяну ноктасы табуыбыз киләчәк язмышыбызны ничек хәл итәр? Автор әнә шул сорауларга да җавап эзли, төрледән-төрле персонажларның эш-гамәлләре, уй-хыяллары аша үзенең борчылуларын чагылдыра.

Комедиядә Әмир образы кызыклы. Ул үзенең укытучысы булган Сократ белән берлектә һава шары ясый башлый. Ләкин, эш барып чыкмау сәбәпле, Сократ икенче идеяне «тормышка ашырырга» алына, ә Әмир эшен ахырына җиткерә.

Әйе, Сократ—гади кеше. Аның да кимчелекләре күп, күп кенә әйберләргә аның да көче җитми. Бу очракта мисалга аның кечкенә буен китерергә мөмкин. *«Менә бик бәләкәй чакларда ук кәрлә дип йөртәләр иде, ул кушаматны ияртеп мәктәпкә дә килдем. Гөнаһ шомлыгы, укучылар да шулай атап йөртте... Тәбәнәк булуыма хурланып, усалланып үстем...»*—дип ачыргалана ул үзенең кимчелеге турында. Күп кенә эшләренең барып чыкмавына шул буй гаепле кебек.

Комедиянең исеменә игътибар итик. «Әсәрнең исеме уңышлы түгел кебек. Моны пьесаның авторы да, куючы режиссер да сиземли, күрәсең, чөнки газитләрдәге белдерү-рекламаларда бу турыда язылды. Баскетболчы булу Сократның төп сыйфаты яисә гамәле түгел бит. Әлегрәк ул вертолет төзүче конструктор булган, алга таба җырчы булачагын беләбез. Бик үк яңгырашлы булмаса да, «Хыялый» дип атарга мөмкин»,—дип язган иде бу турыда әдәбият галиме Ә.Закирҗанов (шул ук китапта).

Ни генә булмасын, «Баскетболчы»—бүгенге татар сәнгатендә шартлылык алымнарына бай «абсурдлык театры»ның матур бер үрнәге.

М.Гыйләҗев драмаларының теле сынландыруларга да бай. Мисалга *чир асрау, баскетболын ашатыр, бәла арты бәла килә* кебек мисаллар китерергә мөмкин. Җансыз предметларны җанлы итеп күрсәтеп бирүгә корылган, метафораның бер төре булган сынландыру—шулай ук шартлылыкның бер алымы.

Драматург образлы сурәтләү чараларын да белеп, урынлы файдалана. Эпитетларга игътибар итик: *томана халык, буш такмазалар, йогышсыз сорау, авыр юл* һ.б. Бирелә эпитетлар предмет-күренешләрнең сыйфатын белдереп киләләр һәм репликаларны тагын да аһәңлерәк итәләр.

Пьесада чагыштырулар да уңышлы кулланыла. Алар тасвирлау предметын,

объектын жанлы, конкрет, сурәтле итеп күз алдына китереп бастыра. Мисалга *ач талпан кебек кадалу, корымлы казан* кебек кара, иреннәре башмактай, чабатадай авыз кебек чагыштыруларны китерергә мөмкин.

«Баскетболчы» комедиясенең теле гадилек, халыкчанлык белән дә аерылып тора. Персонажлар сөйләме мәкаль-әйтемнәргә, диалектизмнарга, фразеологизмнарга, гади сөйләм сүзләренә шактый бай. Мәкаль-әйтемнәр персонажларның тапкырлык, гадилек кебек сыйфатларын ачалар. Мисалларга игътибар итик. Сократның теленә, мәсәлән, *«Шуннан шул, алган да шуган»*, *«Акчаның бакчада үсмәгәнен беләсеңдер»*, *«Төтенең туры йөри икән»*, *«Ерак сәяхәтләр берәр адымнан башлана»*, *«Итсән хәрәкәт, булыр бәрәкәт»* кебек халык авыз иҗаты үрнәкләре хас. Платон *«Акчалының эше күп, бакчалының ашы күп»*, *«Адашкан кешедән юл сорамыйлар»*, Люция *«Юл атны сыный, авыр юл ирне сыный»*, Хәнифә *«Барып та чыгар, бәреп тә егар»*, *«Юл белмәгән юлдашын адаштырыр»*, Ләззәт *«Адәм йөрми җир танымас»* кебек әйтемнәр куллана.

Персонажлар фразеологизмнарга да еш мөрәҗәгать итә. *«Суйган да каплаган»*, *«колак тону»*, *«акчаны суга салу»*, *«күзне ачыбрак карау»*, *«күлеп эч кату»*, *«баш вату»*, *«өстенә басу»*, *«дөнья тану»*, *«якага яка килү»*, *«бүре йотардай булу»*, *«күз күеге»*, *«җиргә ябышып яту»*, *«җирне кысыр калдыру»*, *«күз салу»*, *«кырык мирдән калган»*, *«мыегыңа чорна»*, *«табан ялтырату»* һ.б. әсәрнең телен тагын да халыкчан итә, образлылык төсмерен көчәйтә.

Комедиядә халыкчан тел үзенчәлекләрен диалектизмнар да көчле сиздерә. Гәрчә вакыйгалар Питрәч районының бер авылында барса да, персонажлар Минзәлә, Туймазы сөйләше, Көнбатыш диалекты сүзләрен дә кыстырып сөйләшәләр. Мәсәлән, *тилемсәр, кәтәнә, аякны каймыктыру, атлыгып тормай, таякларына таяклап чаба, иләсләндермә (башны), кыйты (гына булса да фатир бирерләр, бәлки), зәнки, сурәбәт, җүләр, котыйчык (кебек кенә проблема), курач (ямьсез), кым-кырыч (күнегүләр башланса, халык күп җыела, кым-кырыч. Артларыннан чүп-чар күп кала), котылмак юк, ятрәк* һ.б. Шулай ук авторның *елау* белән *җылау* арасындагы аермасын аңлау кыен. Бер очракта ул персонажны «елата», ә икенче вакытта «җылата».

Әмма шуны да әйтергә кирәк: пьесада стилистик төгәлсезлекләр, «шадра» җөмләләр дә очрый. Мәсәлән:

*«**Люция.** ...Әйдә әле, авылдашларыбыз кебек итеп, гадәти тормыш белән яшик!*

***Сократ.** Мин алай итеп яшәргә булдыра алмыйм һәм теләмим дә».*

Люция сөйләмендә итеп сүзе артык булса, Сократның инфинитив формасын тавтологик куллануы колакны яра, итеп сүзенең куллануы да урынсыз. Бәлки, «Мин алай яши алмыйм» булса, ә Люция сөйләме «кешечә гомер итик» дип бирелсә («тормыш белән» түгел), уңышлыractыр.

Шулай ук Әмир сөйләмендә дә төгәлсезлекләр бар.

*«**Сократ.** Яле, яле, кайда ул шарың?*

***Әмир.** Әнә генә агачлар артында?..»*

Күрсәтү алмашлыгына кисәкчә кушу, гомумән, бу очракта кирәкмәс иде.

Әйтергә кирәк, әсәр үзенең гаять бай тел-сурәтләү чаралары белән дә, кызыклы персонажлары, уйланылган һәм төгәл сюжет-композициясе белән дә татар милли сәхнәсендә дәрәҗәле урын алып тора. «Баскетболчы»ны иҗат иткәндә, М.Гыйләҗев шартлы алымнардан уңышлы файдалана, драматург шартлылыкның гротеск, гипербола, метафора, сынландыру, символ, поэтик деталь, аллегория, литота кебек алымнарына еш мөрәҗәгать итә.

Әсәрдә шартлы алымнар вакыйгаларның киеренкелеген саклау, хәрәкәт һәм фикер тыгызлыгына ирешү мөмкинлеге бирә. Мизансценалар арасындагы күчеш-сикерешләрне, мәгънәви бәйләнешләрне оештыруда да шартлылык алымнары әһәмиятле.

Шартлылыкның матур үрнәкләре драматургиябезне тагын да баета.

**Рамил ХАННАНОВ,**

*филология фәннәре кандидаты*

## РӘХМӘТ СИҢА, ДУСТЫМ!

2006 елның октябрь башлары иде. Өйдә телефон шалтырады.

—Алло?

Жавапка бик ерактан пышылдап кына кемдер нәрсәдер әйтте.

—Кем бу? Кем?

—Бу мин, Мөдәррис, Казаннан.

Дуслар шаярталар, дип уйлыйм.

—Нәрсә булды, Мөдәррис, кычкырыбрак сөйлә, начар ишетелә.

—Кычкыра алмыйм, Халисә, тавыш юк.

—Суык тидеме әллә, ангинамыни?—дим, үзем шул «зәхмәт»тән еш жәфаланганга.

—Авырыйм, ангина түгел, хәтәррәге...

Авыр тынлык урнашты. Бу инде шаяртуга охшамаган иде.

—Ни булды?—дим.

—Тыңла, шигырь укыйм, соңгы язган ике шигырь.

Мөдәррис телефон аша пышылдап кына шигырь укый. Начар ишетелә. Берсен, икенчесен... Хатын-кыз фамилиясе... Кудашева дигән фамилияне аңлыйм. Шигырь тыңлаудан бигрәк Мөдәрриснең хәле баш миен өтә. Мең төрле уй, чыннан да, бу шаяртуга һич кенә дә тартмый.

—Шәпме?—ди.

—Шәп,—дигән булам, ишетеп бетермәсәм дә.

—Халисә, күрешеп сөйләшәсе килә, кил әле Казанга, минем хал шәптән түгел...

—Мөдәррис, дәваханәгә бар, дәвалан, медицина көчле хәзер.

—Соң инде, дәваланып булмас...

—Операция ясат, ничаклы иртәрәк эшләтсәң, шулчаклы яхшырак булачак.

—Операция эшләтмим, аннары, анысына соң бугай инде...

Барысы да аңлашыла иде. Мондый каты авыру белән авырып һәлак булган кешеләрне белә идем, тик күңел барыбер ышанырга теләми.

—Ерунда, чир килә дә китә, дәваланырга кирәк,—дип юатам, тавышка ышанычлырак төсмер өстәп.

—Ярар,—ди Мөдәррис,—үзенне күрәсе, шигырьләр укып утырасы, сөйләшәсе иде. Нажар ага белән Атнабай үлгәннән соң рәхәтләнеп сөйләшеп, шигырь укып утырасы килгән кеше Уфада син генә калдың.

Монысы инде аның арттырыбрак жибәрүе булдымы, әллә яшьтән дуслар булып аралашып яшәгәнгә якын күреп әйтүе булдымы, тавышы Мөдәрриснең үзәкләргә үтәрлек моңсу иде.

—Нәжибә кайда,—дим.

—Ул әле өйдә юк, эш белән йөри, ана да мәшәкать инде... Юбилейга кил, юк, юбилейга чаклы кил, күрәсе, сөйләшәсе килә...

Икенче көнне Нәжибәгә шалтыратам. Ул барысын да аңлатып бирде.

—Коткарып булмыймыни, табиблар ни ди соң?

—Соң инде, диләр, кил, аның сине күрәсе килә,—ди Нәжибә.

Кызганычка каршы, икенче атнада ук, мин дә операциягә эләгәм. Нигә, ни өчен, нәкъ ана мондый язмыш?! Ир уртасы, заман чагы, ижатының чәчәк аткан, шигъриятенең канатланган, фикерләренең тирәнәйгән, зиһененең үткенләнгән генә чагы.

Больницадан тагын Казанга шалтыратам. Нәжибә белән сөйләшәбез.

—Әле бераз гына дәрт керде, юбилей тантанасына әзерләнү көнелен күтәреп җибәрде, кәефе ярыйсы гына, тик тамагына ашый алмый, кисель шикелле сыек ризыкта гына инде,—ди.

—Юбилейга бара алмыйм, ләкин больницадан чыгу белән, һичшиксез, барам,—дим Нәҗибәгә.

Юбилей кичәсе үтү белән тагын шалтыратам: «Хәле ничек?» «Шәптән түгел, стена ягына карап ята, йоклый шикелле, сөйләшә алмый»,—ди Нәҗибә.

Мин шифаханәдән чыгуга, Мөдәррис бакый дөньяга күчкән иде инде. Күнелдә олы үкенеч калды: олы шагыйрь, якын дустымның соңгы үтенечен үти алмадым, үзе исән чакта. Соңгы тапкыр сөйләшеп утыру насыйп булмады, бәлки әйтәсе килгән сүзләре, җиткерәсе килгән фикерләре, тыңлыйсы яки сөйлисе килгән шигырьләре калгандыр.

Үлем һәрчак үкенечле була. Безнең дуслык студент елларында, 70нче елларда ук башланган иде. Ул елларда Башкортстан дәүләт университетының мин старостасы булган «Акчарлаклар», татар һәм башкорт бүлегенең «Шонкар» әдәби-иҗат түгәрәкләре белән, Казан дәүләт университетының «Әллүки» әдәби-иҗат түгәрәкләре арасындагы иҗади дуслыкның чәчәк аткан чагы иде. Тукай, Мәҗит Гафури кичәләре, үзара Уфа-Казан яшь шагыйрьләренең алмаш иҗади очрашулары елына берничә тапкыр үтә. Ике республика арасында һава һәм тимер юлларының даимилеге, билет хакының арзан булуы аралашуларны җиңеләйтә, ә бәлки очрашасы килүнең, бер-беребезнең иҗаты белән кызыксынуның көчлелеге, бер-беребезгә хөрмәтнең зурлыгы да хәлиткеч роль уйнагандыр.

Бу очрашулар ике республика яшь язучыларының иҗатына бинаһая әһәмиятле этәргеч, көч һәм илһам бирә, баета иде. Шушы «мәктәп»не тәмамлаган, хәзер инде олпат әдипләр булып танылганнар арасында олырак буыннардан Рәдиф Гаташ, Рим Идиятуллин, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, яшьләрдән Римзил Вәлиев, Марсель Галиев, Госман Садә, Шәмсия Җиһангирова, Башкортстан әдипләре арасында Факиһә Тугызбаева, Рамил Янбәк, Зөһрә Котлыгилдина һәм, һичшиксез, татар әдәбиятының горурлыклары, хәзер инде мәрхүмнәр Мөдәррис белән Зөлфәт һәм Фәннүр Сафин да бар иде.

Күп еллар дәвамында Казанга килгән вакытта мине Мөдәррис каршы ала иде. Пристаньдамы, вокзалдамы, редакцияләрдәме, килә-килешкә беренче булып Мөдәррис очрый. Хәтта хәбәр бирми килгән очракта да лифт каршында иң беренче аның белән очрашабыз, әйтерсең ул гел көтеп торган кебек.

Казанга еш килеп булмагач, бер килгәндә бар булган йомышларны үтәп китәсе килә. Казан урамнарын яхшы белмәгәч, редакцияләргә, радио, нәшриятләргә йөртү дә Мөдәррис җилкәсенә төшә иде.

«Вакыт кысаларыннан иң азат кеше безнең Мөдәррис»,—дип, Рәдиф абый Гаташ мине Мөдәррискә «тагып» җибәрә.

Ә Мөдәррис мине Казанның иң очсыз транспорты булган трамвайга утыртып шалтыр-шолтыр шәһәр буйлап алып китә. Мөдәррис билетны миңа гына ала да, үзе куен кесәсеннән кызыл тышлы кенәгәсен «ялт» иттереп кондукторның күзенә теки дә тиз генә кесәсенә кире тыга. Икенче, өченче трамвайга утыргач та шул ук хәл.

«Мөдәррис, нинди шулхәтле «крутой» удостоверение күрсәтәсең соң син, бер кондуктор да сиңа бәйләнергә җөрьәт итми?»—дим.

«Язучылар таныклыгы ул, дустым, кайвакыт файдасы тиеп куя аның, аңламаган кешегә»,—ди үзе, рәхәтләнеп көләбез. Кайвакыт җәяү генә дә алып китә.

«Әйдә, мин сине турыдан алып чыгам, иске Казанны күрерсең»,—дип, кеше аягы сирәк баскан караңгы, тар тыкрыклар, бакчалар аша радио редакцияләренә, автовокзалга, йә Берлеккә алып чыга. Аның Казанны яхшы белүенә шакката идем. Ул һәр урамның, һәр йортның, һәр тыкрыкның дип әйтерлек тарихын, анда яшәгән билгеле кешеләрен, булган вакыйгаларын яхшы белә, оста итеп сөйли, мин аның белгәненә тагылып, терек-терек атлап, кызыклы риваятьләрен тыңлап барам.

—Шигырь укы,—дим.

Ул туктап торып Казан урамында шигырь укый. Үзенекен, борынгы болгар-татар шагыйрьләрен, Дәрдемәндне, Акмулланы, Тукайны, башка төрки телле шагыйрьләрне.

—Кемнеке?—дип сорый миннән, бер өзек китерә дә.

Мин буташтырам, юк, бу шагыйрьне укымаганнан түгел, хәтернең сыйфатыннан. Тагын укый, тагын, тагын... Мөдәрриснең хәтере чыннан да феноменаль иде. Ул күп вакыйгаларны, күп әдәби әсәрләрне, авторларның тормыш юлларын, кызыклы халләрне бик оста итеп җиткерә, аның фикер сөреше, сөйләү куәсе ышандыру көченә ия иде.

Гади генә киенгән, чандыр гәүдәле, буй да чама белән генә, ләкин Мөдәррис шигырь укый башласа, аннан да баһадиррак, аннан да матуррак, аннан да батыррак, аннан да акыллырак кеше булуы мөмкин түгел кебек күренә иде.

Аңа «ялтыраш»лык хас түгел, ул кешегә дә, заманга да яраклашырга, яхшырак күренергә тырышмады, киресенчә «йортлыксызрак», дөнья мәшәкатьләреннән ераграк торган шикеллерәк фикер калдыра, гәрчә тирән рухи дөньясы, күңел хисләре һәр шигырендә ярылып ята.

Нәрсә иде бу, аның яшәү рәвешеме, әллә бу заманга протесты идеме? Хәтердә 1994 елның 29 октябре. Безне берничә кешене Язучылар берлегенә кабул итеп алу алдыннан сөйләшүгә чакырдылар.

Бу сәфәргә Уфадан үзебезнең машинада гаилә дусларыбыз белән 4 кеше кузгалдык. Табигать ай буе коры торды-торды да иртән үк карлы яңгыр ява башлады. Түбән Камага төнлә күз ачкысыз бозлы яңгыр ярып килеп кердек, туганнарда кундык, икенче көнне сәгать икедә Берлектә булырга тиеш идек. Иртәниртүк тагын юлга—Казанга кузгалдык. Юл—көзге кебек ялтырап торган бозлавык, үргә күтәрелгән җирләрдә «бөкеләр»—колонна-колонна машиналар тезелгән, юлның ике ягында чакрым саен машиналар аунап ята. Чак-чак күрсәтелгән вакытка барып өлгердек. Безне Берлек капка төбеннән үк Мөдәррис белән Зөлфәт каршы алдылар.



*Бертөркем язучылар «Казан утлары» редакциясендә. Алгы рәттә, сулдан уңга: Ф. Латыйфи, Н. Сафина, Р. Фәйзуллин; икенче рәттә: М. Әгъләм, Х. Мөдәррисова, Р. Гаташ. 2003 ел.*

Зөлфәт: «Без сезнең инде исән-имин килеп җитүегезгә өметне өзгән идек, Аллага шөкер, сау-сәламәтсез»,—дип шатланып каршы алдылар. Эш беткәннән соң, күп дуслар үзләренә кунакка чакырса да, без Мөдәррис белән Нәҗибәләргә киттек. Зур булмаган пөхтә фатир. Нәҗибә ханым кухня тирәсендә бөтерелә. Мөдәррис мине кош оясы шикелле генә җыйнак эш кабинетына чакырды. Китаплар, китаплар, китаплар... Өстәл өсте язмалар белән тулы, юлдашларым телевизор карый, ә Мөдәррис миңа яңа шигырьләрен укый. Мин үземнең яңа шигырьләрне укыйм, кич шигырь кичәсенә әверелде.

Юлдашлар тыныч түгел, сизеп торам, борчылалар, чөнки ул елларда машина урлау, йә булмаса, тәгәрмәч салдыру Россиядә чәчкә аткан күңелсез күренеш иде.

Ә Мөдәррис бик ышанычлы итеп: «Шагыйрьнең ишек төбеннән кунакларның машинасын алып китсәләр, Мөдәррис «пегасын» урлаткан шикелле булыр бу, борчылмагыз, ди. Соңыннан белдек: ул төн буе керфек тә какмыйча, тәрәзә каршысына куелган машинаны саклап чыккан.

2002 елның яз айлары. Рәдиф абый Гаташ миңа телефон аша: «Мөдәррис белән Наис Гамбәр Мөдәрриснең «Гасыр капкасы» кардәшлек китап киштәсе сериясендә чыккан китабына гонорар алу өчен Уфага юлланалар, син аларны каршы алып урнашырга ярдәм ит инде, шагыйрь халкының хәлен беләсең, кунакханәләрдә бик кыйммәт, берәр торак юнәтеп булмас микән, азрак егетләргә «күз-колак» булу да артык булмас, чит

шәһәр, «азатлык хисе» башларына бәрмәсен...»—дигәнрәк үтенеч белдерде.

Мин районнан Дилә Булгаковага шалтыратам. «Ике шәп шагыйрь килә, Дилә апа, каршы ал инде, сыендыр, дим, үзем дә тизрәк килеп җитәргә тырышырмын».

Мин килеп җиткәндә изге күңелле Дилә апа җитәкчелегендә Мөдәррис белән Наис бер төркем студентлар арасында шау-гөр килеп очрашу кичәсеннән университеттан чыгып киләләр иде. Аннары Башкортстан «Китап» нәшриятына очрашуга юнәлдек. Түгәрәк өстәл артында нәшрият җитәкчеләре, мөхәррирләр, язучылар, шагыйрьләр: Сафуан Әлибаев, Факиһә Тугызбаева, Сабир Шәрипов һәм башкалар. Ике республика әдипләре, кызыклы әңгәмә, дуслык табыны, җылы мөнәсәбәтләр. Мөдәрриснең дә, Наисның да күңелләре күтәренке, кәефләре шәп, янып, ашкынып шигырь укыйлар.

Гонорарны алгач, мин: «Мөдәррис, нишләтәсең бу акчаны», дип шаяртам. Ул: «Яңа фатир бар бит, буп-буш тора, эчендә берни дә юк, күңелсез. Азрак кешеләрчә мебель-фәлән рәтләргә иде, кыз да, оныклар да килеп йөрер иде»,—ди. Мебель алганмы, юкмы, белмим, ләкин кызын, оныкларын бик яратканы, аларга карата күңел җылысының никадәр зур икәне ярылып ята иде. Ә икенче җәйдә, Казанга баруыбызда җавап йөзеннәндер инде, Мөдәррис белән Наис Дилә апа белән безне кунакка чакырдылар. Табынны Наисларда әзерләгәннәр. Наисның хәләл җефете Гөлфира ханым белән егетләр бөтерелеп йөреп безне кунак итә, шигырь уку китә. Рәдиф Гаташ: «Сезнең белән һәр очрашу шигырь кичәсенә әверелә, тик сирәгрәк киләсез»,—ди. Сүз әдәбият, шигърият, аның үткәне, киләчәге турында.

Зөлфәтнең сәламәтлеге барыбызны да борчый. Фирая ханымның бетмәс-төкәнмәс күңел җылылыгы, чын мәгънәсендә шагыйрь хатыны булуына сокланабыз. Мөдәррис: «Зөлфәт көчле, шагыйрь алай гына бирешергә тиеш түгел, ул әле яшәргә тиеш, аның гомере минекеннән дә озынрак булачак, менә күрерсез»,—ди ул ышанычлы итеп.

И гомерләр, Наис та, Мөдәррис тә, Зөлфәт тә юк инде. Мөдәррис дөнья мәшәкатьләренә битараф күренсә дә, тирә-яктагы гаделсезлеккә эче пошып, әрни, зарланып та куйгалый иде.

Тел төбеннән сизелгәнчә, аның гаделсезлекне авыр кичергәне Аккош күлендәге «сәләмә» генә йортын—тыныч оясын югалтуы, саклап кала алмавы иде. Очрашкан саен ул ерак алтмышынчы елларда Уфада Черниковка бистәсендә һөнәрчелек училищесында бераз укып, яшәп алуы хакында искә алырга ярата иде.

Мөдәрриснең күңеле бик сак һәм сизгер иде. Ул кешеләр арасындагы иң нечкә тойгыларны да күңеле аша үткәрә, кайсы чакта әңгәмә вакытында төркемнән сиздерми генә югала, китеп бара, үзенең артык булуыннан курыккан шикеллерәк хис калдыра иде. Мөдәррис горур, кайсы чакта бунтарь холыклы да иде. Кешенең кем булуына, дәрәҗәсенә, титулына карамыйча, үзенең хак икәнен белсә, гадел фикерен, үз карашын җиренә җиткереп әйтә белә иде.

Шагыйрь буларак Мөдәррис бары тик талантларны, шәхес буларак гадел, ихлас кешеләрне генә яратты. Соңгы очрашу 2005 елның сентябрь башында булды.

Мөдәррис Дилә апа белән мине Уфага китә торган поездга озата төште. Урамда инде караңгы булса да, «кайт», «соңга каласың», дигәнгә дә карамыйча сумкаларны күтәрешеп купега чаклы кертеп урнаштырды, тизрәк очрашуны теләп хушлашты, поезд кузгалгач та кул изәп перронда озатып калды.

Мөдәррис Әгъләмов ике гасыр арасында—социализм, коммунизмны яулау, үзгәртеп кору һәм демократия дигән битлек астында хөкем сөргән авторитаризмны хаос, хаосны авторитаризм алыштырган чорда яшәп чынбарлык хисен югалтмаган, заманның ерткыч йөзенә туры карап, аңа яраклашмыйча, үз сүзен кыю әйткән, үзе булып кала алган шәхес һәм шагыйрь булып яшәде.

*Ә ул сирәкләр язмышы.*
*Рәхмәт сиңа, дустым!*

**Халисә МӨДӘРРИСОВА,**
*шагыйрә. Башкортстан.*

# БОРЫЛЫШ ЧОРЫНДА

Г. ТОЛЫМБАЙНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Гомәр Толымбай 20-30 еллар татар әдәбияты мәйданында күренекле урын тоткан талантлы һәм үзенчәлекле әдипләребезнең берсе. Ул—үз заманының гаять катлаулы, каршылыклы социаль чоңгылында кайнап, ярларына «утырып» җитмәгән милли мәдәният ташкынында бата-чума үз рухи кыйбласын һәм үз иҗат юлын эзләгән чор баласы.

Егерменче-утызынчы еллар татар әдәбияты үсешендә тирән эз калдырып үткән бу әдибебез үзе иҗат иткән унбиш ел вакыт эчендә, ягъни 1922 елдан 1937 елга кадәр, утыз бер китабын бастырып чыгарган. Шул чорның көн кадагына суккан тәнкыйди-публицистик мәкаләләре, очерклары, фәнни хезмәтләре, яңа социаль җәмгыятьнең яңа әсәрләре буларак тәкъдим ителгән этюд һәм хикәя-повестьлары белән замандашлары күңеленә көчле тәэсир ясаган. Әдәбият галиме Г. Нигъмәти 1927 елда «Безнең юл» журналында (6—7 саннар) аны «татар революция әдәбияты күгендә» булган биш йолдызның (К. Нәҗми, Һ. Такташ, Х. Туфан, Г. Толымбай, Г. Кутуй) берсе итеп күрсәтә.

Әмма, белүебезчә, бу үзенчәлекле тарихи чор әдәби ачышлар белән генә түгел, һәртөрле социаль тетрәнү, эзләнү, табу-югалту, хаталану, фаҗигаләр белән дә тулы. Диктатура һәм тиранияннең сикәлтәле юлы, мираж булып балкып торган мавыктыргыч социаль кыйбласы, табигый ки, иң талантлы әдипләребезнең дә иҗат куәтен шактый зәгыйфьләндергән, әсәрләренең шигъри яңгырашын еш кына шул заман кысалары белән чикләп куйган. Тик, ни хикмәт, чын мәгънәсендә талантлы язылган әсәрләр, төрле дәверләрнең кырыс сынауларын да исән-сау үтеп чыгып, үзенең яңа буын укучысына да исән-сау барып ирешә ала икән... Бүген Гомәр Толымбайның егерменче-утызынчы елларда яңалиф шрифтендә «алашып» калган һәм бернинди заман җилләре дә искертә алмаган классик хикәяләре белән очрашу безгә әнә шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Аларның кайберләре заманча эчтәлекләре белән сокландырса, икенче берләре безгә бу шау-шулы алмашыну елларының табигый-натураль сулышын китереп җиткергәннәре өчен кыйммәт. Ахыр чиктә, ул хикәяләрнең һәрберсе татар әдәби мирасының үзенчәлекле фондын тәшкил итә. Социаль-сәяси «тоткын» булып, җитмеш ел буена яңалифтә «консервланып» торганнан соң, ниһаять, алар мәдәни кулланышыбызга, рухи тормышыбызга—лаеклы үз урыннарына—кабат әйләнеп кайта алды.

Гомәр Толымбай (Габделхак Җәләлетдин улы Шаһиәхмәтов) хәзерге Татарстан республикасының Буа районы Адав-Толымбай авылында дөньяга килә. Уналты яшенә кадәр туган авылы һәм Буа мәдрәсәләрендә белем ала. Үз истәлекләреннән күренгәнчә *(«Безнең юл», 1927, № 6-7)*, каләмен унөч яшьтән—«мәхәббәт хатлары», мәктәптә—инша, сугыш башлангач «солдат хатлары» язып шомарта. Аның Г.Тукай һәм Г.Ибраһимов әсәрләрен аеруча яратып укуы да шул елларга барып тоташа. Әмма моннан соң Г. Толымбай тормышында кискен борылыш күзгә ташлана: ул бабалары кебек муллалык юлыннан да китми, дөньяви гыйлемнәрне алга куйган Европа университетларына кереп тә белем алмый. Замананың болганган чагы... Аның да киләчәк язмышы, башка бик күп каләмдәшләре һәм кордашларыныкы кебек үк—ягъни нәкъ Такташ, Туфан, Нәҗми, Кутуйларныкы кебек үк—бөтенләй

өченче бер эздән, тормышның төбеннән башланып китә. 1916 елда (16 яшьлек үсмер егет) укуын ташлап Петроградка барып чыга... 1917 елгы Февраль революциясен дә шунда йөк ташучы-извозчик булып каршылый. Шул елның җәендә туган авылына кайта, Октябрь көннәрендә крестьяннарның алпавытларга каршы җир даулау көрәшләрендә катнаша. 1918 елда күрше Бикмураз авылы мәктәбендә укыта. Сембер (Ульяновск) шәһәрендә («Колчакның Сембергә һөҗүм итеп килгән» көннәрендә) большевистик «Таң» газетасында беренче шигырьләрен язып бастыра. 1919 елда шул вакыттагы тормыштан алып ике пәрдәле пьесасын яза, ул Буада куела. 1919 елда РКП(б) членлыгына кандидат итеп алына. Гражданнар сугышы чорында Г. Толымбай үз теләге белән Кызыл Армиягә китә. Көнбатыш фронтта ак полякларга каршы сугыша, яралана. Армиядән кайткач, бөтен көч-сәләтен, гомерен яна татар совет әдәбиятын булдыруга, татар матбугатын үстерүгә багышлый.

Габделхак—«Алла колы» дигән сүз. Мондый революцион 20 нче еллар башында әдәбиятка килгән коммунист егетнең «Алла колы» буласы килмәгән, күрәсең, аның әсәрләре туган авылына бәйле төстә «Гомәр Толымбай» яисә «Гумир Толымбайский» псевдонимы белән басыла башлый. Сугышчан рухлы мәкалә-очерклары, тормышның табигый асылын нигезгә алып иҗат ителгән әдәби әсәрләре аны тиз арада яшь әдәби көчләрнең берсе буларак таныта. Бу чорда—НЭП хәрәкәте нәтиҗәсендә илдә яңа бер колач алып җанланып киткән капитализм белән социализм тартышында—яшь әдип аяусыз көрәшкә ташлана.

1922—1923 елларда В. Маяковский җитәкчелегендә төзелгән «Левый фронт искусства»га ияреп, ул «Октябрь» һәм «Сулф» (сул фронт) әдәби оешмаларын төзүдә катнаша. Ләкин әлеге оешмалар озын гомерле булып чыкмый. Киләчәктә анык бер үз юлын табу өчен Г. Толымбай ныклап торып белемен күтәрергә тотына.

1923—1927 елларда ул Татар Коммунистлар университетында укый. Аны тәмамлагач, «Гажур» нәшриятында редактор урынбасары, «Крестьян» газетасында редактор булып эшли. 1929—1931 елларда татар педагогия институтында гыйльми эш алып бара. 1931—1934 елларда Мәскәүдә әдәбият институтында укый. Диссертация яклап, «кызыл профессор» дигән гыйльми дәрәҗә ала. Казан педагогия институтында укыта. Татарстан дәүләт нәшриятының матур әдәбият секторында мөдир булып эшли. 1937 елның 10 апрелендә нәшрият партоешмасы җыелышында Г. Толымбай Г.Ибраһимов, Ф.Сәйфи-Казанлы һ.б. белән бер милли-контрреволюцион төркемдә торып көрәш алып баруы, «Кызыл Татарстан»да «милли-буржуаз язучы» Ф.Әмирханны «унай тип» дип бәяләгән—«ачыктан-ачык зарарлы булган» кайгы уртаклашу мәкаләсен бастыруы, Ж.Вәлидинең «милли» аңлатмалы сүзлеген чыгаруда катнашуы, «фашист» Г.Исхакыйны популярлаштыруы, Яңалифне кертүгә каршы көрәш оештыруы, партиядән куылган Г.Галине, С.Атнагуловны яклап чыгуы, «милләтче» Г.Рәхимне эшкә урнаштырырга ярдәм итүе, әсәрләрендә кулак идеологиясен алга сөрүе һәм авылда сыйнфый көрәшне юкка чыгарып күрсәтергә маташуы өчен ВКП(б) членлыгыннан азат ителә. Шомлы 1937 елның 8 июнендә Г. Толымбай кулга алына.

***

Язмышның әче көлүедер, күрәсең: ул үзе инанган, җаны-тәне белән бирелгән һәм бөтен барлыгы белән хезмәт иткән совет җәмгыятендә үзе үк шул җәмгыятькә каршы көрәшүче, Киров, Горький кебек шәхесләрне үлемгә дучар иткән контрреволюцион оешма төзешүдә, Совет властен бетереп, пантюркистик буржуаз дәүләт оештыруда гаепләнә. Әйтергә кирәк, әлеге гаепләү аңа инде шул елның март айларында ук үзенә кадәр кулга алынганнар тарафыннан тел яздыру буларак әзерләнә башлаган. Шуңа күрә сораулар да, архивта саклаңган сорау алу беркетмәләреннән күренгәнчә, шактый гына «предметлы» итеп алып барырга тырышыла.

Үзенә «ябыштырылган» бу гаепләүләрне Г. Толымбай ярты ел буена кире кагып килә. Биредә һәрбер сорау алуның төрле җәзалау алымнары белән алып барылуын да истән чыгармаска кирәк. Г. Толымбай турындагы шундый кайбер мәгълүматларны без Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре»ндә очратабыз. Ул Октябрь бәйрәме алдыннан Пләтән төрмәсендәге тоткыннарның стенаны шакып: «Галимҗан Ибраһимов каты авырый. Толымбайский дүртенче тәүлек стойкада.

Тинчурин...»—дип хәбәр итүләре турында яза.

Тагын күпмедер вакыттан соң аларга: «Галимҗан Ибраһимов каты авырый. Төрмә больницасына салдылар. Толымбайский допроста акылыннан язган. Кыям Абрамов допростан чыкканда баскычтан ташланган...»—дигән яна хәбәр килеп ирешә.

Беркетмәләрдән күренгәнчә, Г. Толымбай 1938 елның гыйнварендa «сындырыла». Һәм үз өстенә өелгән бөтен акылга сыйган һәм акылга сыймаган гаепләрне инде танырга мәҗбүр ителә. 20 гыйнварда ясалган 15 битлек «признание»сендә Г. Толымбай 15 ел буена ВКП(б) ның ҮК линиясе белән көрәшүе, пантюркистик буржуаз Туран дәүләте төзү эше алып баруы, СССР белән капиталистик илләр арасында хәрби каршылык туу белән хөкүмәтне кулга алу бурычын куеп яшәве, бу эшкә бик күп язучылар белән берлектә киң халык массаларын тарту эшен җәелдерүе кебек гаепләрен «таный».

«Ничек булган бу хәл?—дип яза бу уңайдан Рафаэль Мостафин 1998 елның 29 маенда «Шәһри Казан» газетасында басылып чыккан «Олы әдипме, «кызыл кыңгыраумы?» мәкаләсендә.—Башына тимер кыршау кидереп, винтлар белән кысып җәзалаганнармы? Арт ягына кызган тимер тыкканнармы? Женси әгъзаларын үкчә белән басып сытканнармы? Хәзер инде моны беркем дә төгәл генә әйтә алмас.

«Толымбайский допроста акылдан язган»,—дигән хәбәр барысын да аңлата шикелле...»

1938 елның 8 маенда суд була. Суд нибары ун минут бара. Беркетмәдә күрсәткәнчә, Г. Толымбай «үз гаебен тулысынча таный». Үз-үзен аклап берни дә әйтми. Аны иң югары җәзага—үлемгә хөкем итәләр. Карар икенче көнне үк—1938 елның 9 маенда тормышка ашырыла—әдипне Черек күл подвалына төшереп атып үтерәләр. Кабере кайда булуы билгеле түгел, әмма ул Казанның Архангельский зиратына күмелгән дип фараз ителә.

«Халык дошманы»ның гаиләсен дә онытмыйлар, әлбәттә. Хатыны—балалар врачы профессор Акчурина Мәрьямне—сигез елга төрмәгә ябалар, соныннан ул үзе кебек үк сәяси тоткын булган бер полковникка кияүгә чыга, Киров шәһәрендә яши. Улы Хәнҗәр балалар йортына озатыла. Шул чордагы тетрәнүләр нәтиҗәсендә башы нык сызлый башлап, авыр операция кичерә. Белем алып, элемтә эшләре инженеры булып эшли. Ул Мәскәүдә яшәде, бик аз сүзле кеше иде, берничә тапкыр Казанга да кайтып китте.

Унтугыз елдан соң, ягъни 1957 елның 8 октябрендә Шаһиәхмәтов Габделхак «дело»сына бөтенләй икенче төрле юллар килеп өстәлә: «Элеккеге НКВД хезмәткәрләре тарафыннан ясалган ялган материаллар буенча нигезсез хөкемгә тартылган»,—диелә анда. Улы Хәнҗәргә исә: «әтиегез, үлгәннән соң, тулысынча реабилитацияләнде»,—дигән хат җибәрелә.

Репрессия елларында совет иленең миллионлаган иң аңлы һәм вөҗданлы шәхесе юк ителгән. Бездә дә милли интеллигенциянең зарар күргәннәре хәтсез. «Социалистик Татарстан» газетасының 1990 елгы 23 март санында күренгәнчә, шәхес культы елларында Татарстанда гына да, ягъни чит өлкәләрдә яшәүче әдипләребезне санамаганда да, илледән язучы кулга алына, күбесе төрмәләргә ябыла, сөргенгә сөрелә. Егерме беренең исә гомере өзелә.

***

Заманының каршылыклы, һәлакәтле язмышы, табигый ки, әдипнең фәнни һәм әдәби иҗат эшчәнлегенә дә үзенең тирән эзен салмый калмаган.

Г.Толымбай үзенең фәнни эшчәнлеген нигездә ике төп юнәлештә: фольклористика һәм әдәбият белеме өлкәсендә киң җәелдереп җибәрә.

Кайбер чыганаклар күрсәткәнчә, «фольклор» терминын татарда башлап куллана башлаучы кеше дә ул була. *(Ф.Г. Галимуллин. Социология һәм эстетика. Казан, «Мәгариф», 1998, .. бит)*

1928 елда «Мәгариф» журналында Г. Толымбайның балалар иҗатын өйрәнүгә—аның төрләрен, жанрларын ачыклауга, материал җыю һәм башка методологик проблемаларны чишүгә караган «Балалар фольклоры мәсьәләсе» дигән мәкаләсе басылып чыга.

Г. Толымбай татар фольклорының үзенчәлекле жанрлары саналган җыр һәм бәетләрне өйрәнүгә дә җитди күнел куйган. Бик күп бәетләрне җыеп, системага салып, 1935 елда аларны укучыларга аерым китап рәвешендә тәкъдим иткән.

1936 елда, ягъни кулга алынуыннан бер ел элек (әдәби әсәрләр язу иреге тәмам кысылгач), Г.Толымбай әкият җыю эшенә керешә. Шушы елда экспедициягә чыгып 51 әкият язып ала. Шуларның утыздан артыгы бүгенге көндә дә, үлмәс мирасыбыз булып, китапларда кат-кат басыла килә.

Г. Толымбай фольклорның язма әдәбиятка ясаган йогынтысын өйрәнүне фәнни нигездә башлап җибәрүче галимнәрнең берсе булды. Бу проблемага багышлап ул 1930 елда «Тукай һәм халык әдәбияты» дигән аерым китабын да бастырып чыгарды. Яна тип совет югары уку йортларында әдәбият укытуның комплекслы программаларын төзеде.

Г. Толымбайның әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме өлкәсендә башкарган эшләре дә игътибарга лаек. Аның газета-журналларда яна—татар совет әдәбиятының географик һәм тарихи чикләрен, алда торган бурычларын ачыклауга, аерым әдипләрнең иҗат үзенчәлеген яктыртуга багышланган дистәләрчә кыю мәкаләләре дөнья күргән.

1926 елда галимнең яна заман рухы белән сугарылган «Матур әдәбият фронты», 1931 елда «Татар буржуа теле—безнең тел түгел», 1936 елда «Фатих Әмирхан» исемле хезмәтләре китап рәвешендә басылып чыга. Әлеге хезмәтләр яна совет әдәбиятының эзләнү-үсеш этаплары буларак кабул ителәләр.

***

Г.Толымбайның әдәби иҗаты күпкырлы: әйтеп үтүебезчә, ул пьесалар, шигырьләр дә язган, аның балалар поэзиясенең классик үрнәгенә әверелгән «Буран» шигырен дә без яхшы хәтерлибез. Чәчмә әсәрләреннән әдәбият тарихы программаларында укытылып килгән «Түбән елгада» (1932), «Куян солдат» (1933) кебек повестьлары да бар. Автор шулай ук үзен үткен юмор-сатира остасы итеп тә таныта: аның «Фамилия ясаучылар» (1926) , «Саматов» (1926)), «Әтәчләр сугышы» (1928) кебек хикәяләре әнә шундыйлар. Хәер, Г.Толымбай үз хикәяләрендәге бу көлү бәясен, ахыр чиктә, үзенең гомере белән түләгән!

Без биредә авторның язучылык талантын аеруча тулы ачкан һәм аның иҗатындагы ике төп юнәлешкә кинрәк тукталып үтәргә уйлыйбыз.

Беренче төр хикәяләрдә (аларны, шартлы төстә, «авыл хикәяләре» дип атау урынлы булыр иде) җир кешесенең гадәти көндәлек көнкүреше, уй-кичерешләре, хыял-өметләре, табигатькә һәм ата-бабалардан күчә килгән йола, гореф-гадәтләргә мөнәсәбәте, кыскасы, авыл кешесенең табигый холкы-тормышы үзәккә куеп сурәтләнә.

Шундыйлардан «Язгы ташкыннарда» (1926), «Мужик фәлсәфәсе» (1927), «Егет» (1928) хикәяләре триптих рәвешендә, ягъни авыл кешесенең өч гомер этабын чагылдырган, әмма уртак яшәү стиле һәм охшаш шигъри җепләрдән тукылган тормыш эпизодлары буларак күз алдына килеп баса. Автор яшәүдә һәрбер гомер этабының да кеше өчен гаять кадерле булуын, әмма гомер баскычларының үзенчәлекле үзгәрешләр ала баруын гади һәм тәэсирле тормыш детальләре аша сурәтләп бирүгә ирешә.

Г. Толымбайның композицион яктан катлаулырак һәм гаять кызыклы булган «Читән буе» (1928) хикәясен дә әнә шундый «авыл турындагы әсәрләре»нә кертеп карарга мөмкин.

Көзге җылы кичләрдә, караңгы төшә башлагач, тәмәкеләрен кабыза-кабыза, авыл агайлары берәм-берәм Идият абзыйлар тыкрыгына, читән буендагы чирәмлеккә җыела башлыйлар. Авызларын авызга куеп, ашыкмый гына, үз җае белән генә дәвам иткән иректә темага гәпләшү башланып китә. Һәркайсының үз табигате, үз холкы, үз кичерешләре. Һәркайсының хәтерендә яшәп узган тормыш вакыйгалары. Һәркайсының үз характеры, бер-берсенә урнашкан ныклы үз мөнәсәбәтләре. Шулай итеп, күз алдында зур бер полотноның үзенчәлекле каһарманнары пәйда була.

Бүгенге кичләре дә шулай, гадәттәгечә, үз сүзләре белән мавыгып, бәлки, үтәр

иде, аларның сүзен бүлеп, урамның теге ягыннан чатанлый-чатанлый Минҗамал әби үтеп китә. Сүз, көтмәгәндә, ана кучеп, мәҗлесне дә, әсәрне дә урталай бүлеп дигәндәй, шушы гап-гади бер татар хатынының, җанны тетрәндергеч фаҗигале язмышы күз алдыннан уза.

Толымбайның талантлы каләм көче тарафыннан корылган «читән буе» мини театр мәйданчыгына, шулай итеп, тагын да дистәгә якын үзенчәлекле характер, алар белән бергә элеккеге татар дөньясының яна бер тормыш чынлыгы килеп керә.

Әмма автор чынбарлыкны хәрәкәттә күрә, әсәрдә бүгенгедән үткәннәргә генә түгел, киләчәк көннәр ягына да ачык күз ташлана: «Читән буе» мәҗлесе халкы монсу уйга батып соң гына тарала, авыл инде күптән тирән йокыда, тик еракта артель булып авылдан күчеп киткән Габдрахманнар уты гына җемелди... Зур үзгәрешләр аша үткәннән киләчәккә күчеп барган авыл образы, әнә шулай символлашып, бөтен натураль табигыйлеге белән күз алдыбызга китереп бастырыла.

«Җәйге җил» (1929) хикәясендә җил һәм тормыш тегермәнендә купкан бәхәс, үткен диалог, тарткалашу, сүз көрәшенең җәелә, тирәнәя барган төенләнешләре авылның кечкенә бер мажаралы-детектив повестена, драматик көрәш белән сугарылган тарихи елъязмасына әверелә. Авыл тормышының көлкеле дә, фаҗигале дә чынбарлыгы тегермән ташына уралып, җил һәм тегермән канатлары тавышына кушылып, он белән аралашып ага да ага.

Авторның бу әсәрендә дә авылча гади, җанлы теленә, үзенчәлекле типик характерлар табуы һәм аларның психологиясен ачу алымнарына, сюжет кору һәм әсәрне композицион яктан оригиналь итеп төзи белү осталыгына сокланмый мөмкин түгел.

***

Г.Толымбай иҗатында төп үзәк агымны тәшкил иткән тагын бер иҗат юнәлешен күздән кичерик. Бу—авторның турыдан-туры революцион-сыйнфый көрәш мотивларын алга куеп язган әсәрләре.

Алда карап үткән «авыл хикәяләре»ндә, игътибар итсәгез, җәмгыятьтәге социаль-сыйнфый бүленеш шул чорның атмосферасын сиздереп кую белән, ягъни чынбарлык таләп иткән микъдарда, әсәргә фон буларак алу белән чикләнә. Игътибар үзәгенә исә авыл тормышының милли-тарихи үз традицияләре, авыл кешесенең табигый эчке дөньясы куела.

Икенче төр юнәлештә алар, әйтерсең лә, урыннарын алмашалар. Революцион-социаль әверелешләр әсәрне төп әйдәп баручы көчкә әйләнә. Сыйнфый көрәш мотивлары, әлбәттә инде, бер авыл тормышы белән генә чикләнми. Ул актив рәвештә яшәешнең башка сфераларына да үтеп керә. Шунысын да искәртеп үтик, сыйнфый көрәш Г. Толымбай әсәрләрендә сугышу мәгънәсендәге ачык көрәш рәвешендә тасвирланмый, бу—төрле социаль катламнарның көнкүреше һәм күңел дөньясы кысаларында барган ярым яшерен, ярым пәрдәләнгән, әмма эчтән бертуктамый очкынланып торган эчке ялкын. Ул еш кына әсәр геройларының психологик үсеш-үзгәрешендә, яшәү принципларының кискенләшү-ныгуында, иҗтимагый яшәү активлыкларының арта баруында чагылыш таба.

Авторның «Нигә кыр үрдәге булмаганнар» (1927) хикәясендә сыйнфый көрәш сызыгы гадәти бер авыл гаиләсен—Биктимер карт белән Гыйльмиҗамал абыстай һәм уллары Сәйфетдинне—икегә аерып, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтен тамырдан өзеп, йөрәкләрен кыл урталай бүлеп, аркылы үтеп чыга.

Кабак яфраклары әлсерәгәч, алабутага барып сөялә. Маэмайлар да, хәлсезләнгәч, келәт астына кереп ята. Ә Биктимер абзый белән Гыйльмиҗамал абыстайга кая барып сөялергә дә юк, кая барып посарга да мөмкин түгел. Аларны «кайгы кайчысы да телгәли, оят камчысы да чыбыркылый».

Якында гына мылтык тавышы яңгырады. Бер мәхәббәтсез аучы икән. Ул бер кыр үрдәген пыр туздырып куалап йөри, имеш. Үрдәге, канаты сынык булса да, ай-яй чая. Теге аучы якынайгач кына чумып китә дә, өскә күтәрелмәс өчен, камыш төбен тешләп алып, тик су астында утыра. Надан аучы икән—үрдәкнең шул хәйләсен белми, тик чаба-чаба эзли.

Сынык канатлы кыр үрдәге Биктимер абзыйда көнләшү утын гөрләтеп кабызды. Биктимер абзыйлар да хәзер канатсыз. Аларның да хәзер канатлары сынык. Әгәр бит кыр үрдәге булсалар, Биктимер абзый да, Гыйльмиҗамал абыстай да кешеләр алдында көек булып йөрмәсләр иде. Сынык канатлы үрдәк кебек чумарлар иде дә, камыш төбен тешләп, утырып кына калырлар иде... Нинди зур бәхетсезлек килде башка».

Авторның үз әсәрен «Нигә кыр үрдәге булмаганнар?!» дип атавы һәм шул юллар белән тәмамлавы да, безгә калса, тирән фәлсәфи мәгънәгә ия.

Г. Толымбай кебек ук хаксызга корбан ителгән—милләтебезнең каймагы, асыл заты булган—миллионнарча корбаннарга да кайчак шул ук сүзләрне әйтәсе килә: ул шомлы 37 елларда... нигә инде алар кыр үрдәге булмаганнар?! Хәер, язмышыннан алай гына качып котылып булса икән?!

«Кара такта янында» (1930) хикәясе—язучының шулай ук иң гүзәл әсәрләреннән берсе. Ул революциядән соңгы дистә еллар дәвамында барган сыйнфый көрәшнең каршылыклы табигатен, шул заман кешеләренең аңындагы эчке үзгәрешләрне гаҗәеп нечкә психологик төгәллек, эстетик камиллек, философик дөреслек, ифрат чиста намуслылык белән тасвирлап биргән әсәр. Революцион үзгәрешләрнең көчен дә, аның фаҗигале нәтиҗәсен дә автор бирердә үзенчәлекле һәм кодрәтле каләм иясе буларак ачып салуга ирешә. Шунысы игътибарга лаек: сыйнфый көрәш сызыгының әсәрдә без интеллигенция вәкиле—укытучы Ярхәм—йөрәген, аның эчке дөньясын төгәл ике өлешкә бүлеп узуын күрәбез.

Ярхәм гади бер авыл укытучысы. Укытудан бушаган араларда аны авыл советы һәм колхоз оештыру эшләренә дә тартып, төрле налог җыю, машина авансларын түләмәгән кулакларның әйберләрен язып чыгарга да ияртеп чыгалар. Бу эшләрне ул күңеле кушканга түгел, ә бәлки, үз ихтыярына каршы барып эшләргә мәҗбүр. Хәзрәт йортына кереп аның әйберләрен язып алган чакта, Ярхәм әлеге эчке бунтны бигрәк тә ачык тоя: ни дисәң дә, үзе дә мөгаллим-укытучы кеше; балалар йөрәгенә белем индерүче, игелек, яктылык таратучы; җитмәсә, күңеленә «шәт безнең авылда да—безнең әтиләргә дә шулай барып кергәннәрдер»... дигән уй килеп төшә. Остабикәнең дә әле чәйгә чакырып, әле нишләргә белми аптырап йөрүен күргәч тә, ул иң элек үзенең әнисен күзаллый.

Шулай итеп, Ярхәм бөтен хис-кичерешләре, уй-фикерләре белән каршылык эчендә кала. Хәер, ул үз эченә генә бикләнеп яшәми. Тирә-як авыллардагы укытучыларның барысы да диярлек мулла малайлары. Ара-тирә ул аларны, үзенең шәрекътәшләрен, күрә тора: әмма аларда да билгеле бер үзгәреш—яшьлек хыялларының сынуын, үз-үзләренә йомылуларын һәм бер-берсенә булган мөнәсәбәтләрендә нинди салкынлык—сизә.

Шушындый эчке бәргәләнүләр эчендә яшәп яткан авыл укытучысы Ярхәм көннәрдән бер көнне гаҗәеп хикмәтле һәм тарихка кереп калырлык гыйбрәтле сәяхәт ясый.

Мәктәптә укулар вакытлыча туктатылгач, колхоз оештыру эшенә алай бик атлыгып тормаганлыктан, дусларын да сагынганга, фатир хуҗасының чибәр кызын бераз күлмәк алып кайтып сөендерәсе килгәнгә дә һәм тагын да вак-төяк сәбәпләр табып, ул Казанга барырга була. Аны фатир хуҗасы Фазлый абзый юл уңаенда районга кадәр ат белән озатып куя һәм Ярхәм шунда, очраклы төстә колхоз председателе Хәйбуллага очрап, Казанга китәсе урында, аңа утырып кирәдән авылга кайта.

Иң гаҗәбе шунда, кемнең арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың, дигәндәй, барганда Фазлый абзыйның советларга каршы китергән дәлилләрен күңеленнән хуплап барган Ярхәм, кайтканда инде әкренләп кире якка—колхоз председателе позициясенә—күчеп бетә яза. Аның һәр ике очракта да ихлас булып, юлдашлары мисал итеп китергән тормыш детальләренә нигезләнеп фикер йөртүе—икейөзлегеннән яисә җитди бер үз фикере юклыктан түгел, ә бәлки тормышның төбенә төшеп уйлаганда, шактый катлаулы булуыннан килеп чыга. Бүгенге көндә без аның нинди каршылыклы тойгылар кичереп барганын һәм кире кайтканын бик ачык аңлыйбыз. Монда авторның тормыш дөреслегенә һәм вөҗданына ни

кадәр тугрылыклы калуына, шуны ни дәрәҗәдә нечкә итеп, төгәл детальләр белән җанландыра алуына сокланырга гына кала.

Язучының деталь һәм символлар белән гаҗәеп оста эш итүе, табигый ки, әсәрнең ышандыру һәм тәэсир көчен бермә-бер арттыра.

Ярхәм районга барганда, Фазлый абзый чанасына артка карап утырса, кайтканда, председатель чанасына да ул артка карап утырып кайта. Барганда да кагылмада чанадан тәгәрәп төшсә, кайтканда да, чана салулап, аны тәгәрәтеп төшереп калдыра.

Авылга кайткач та, Ярхәм шактый каршылыклы авыр хәлдә кала. Торган фатирында аларны кулак дип өйләреннән куалар, хуҗа хатыны да, аның кызы чибәр Зәйтүнә дә Ярхәмнән ярдәм көтәләр. Ә аның үз хәле хәл. Шулай да аптырап чыгып китә ул, тик кич җиткәч, торган фатирына әйләнеп кайтырга инде аның көче дә җитми, намусы да кушмый—кайтыр юлы киселә. Ул мәктәпкә кереп кунарга мәҗбүр була.

Шунда автор безнең карамакка тагын бер өр-яңа символ тәкъдим итә. Бу—кара такта.

Әнә Ярхәм кара такта янына килә. Анда кәкре-бөкре язылган хәреф кисәкләре генә күренә. Шунда кулына акбур алып, Ярхәм бозылган сүзләрне янартырга керешә. Тик файдасыз—иске хәрефләрне янартып кына мәгънә чыкмагач, ул элек язылганнарны ашыгып кына бетереп ташлый да, тагын кулына акбур ала. Әмма Ярхәм—киләчәк яшь буынның укытучысы—әлегә нәрсә язарга да белмичә аптырап кала.

Юк, ул икейөзле түгел, ул әлегә ныклы бер фикергә килмәгән. Әлеге буталган заманда Ярхәм үзенең ныклы бер урынын тапмаган күчсез, бәхетсез милли интеллигенция вәкиле генә. Аның өчен ике як та бердәй хаклы кебек. Ә заман ашыктыра, бу икенең тизрәк берсен сайлап алырга мәҗбүр итә...

Хикәядә нечкә юмор да, үткен сатира да, җанны әрнетерлек шиксыз фаҗига дә бергә үрелеп бирелә. Шулай итеп, сыйнфый көрәш сызыгы алдагы хикәядә бер гаиләне, андагы ата-ана һәм баланы икегә бүлсә, монда ул укытучы Ярхәмнең кешелекле, зыялы һәм кыюсыз күңел дөньясын ике өлешкә бүлеп үтә. Автор революциянең җәмгыятьне һәм милләтне икегә бүлү фаҗигасен дә үз укучысына әнә шулай гыйбрәтле сәнгать чаралары ярдәмендә искәртеп үтә.

Сыйнфый көрәшне үзенчәлекле төстә чагылдыруы белән «Яз көне» (1929) хикәясе автор иҗатында аерым бер урын тота. Зур урындагы җаваплы кешенең эчке дөньясына үтеп кереп, эш стиле белән якыннан таныштыру, үзләрен җәмгыятьнең өстен катламы дип санаган җитәкчеләрнең асыл табигатен ачып салу, алар хезмәт күрсәткән бу идарә системасына да билгеле бер дәрәҗәдә тел-теш тидерүгә батырчылык итү—һичшиксез, авторның бу елларда күрсәткән шактый зур кыюлыгы иде.

Ул гына да түгел, үз заманының нинди заман булуы турында автор шактый гына ачык итеп үз фикерен дә әйтеп калдыра. Без аны сорау алу беркетмәләрендә сакланган, шымчылар язып биргән күрсәтмәләрдән укыйбыз. Әле кулга алынганчы ук, Зәки Гыйймранов белән 1935 елда Татарстан китап нәшриятында сөйләшкәндә, Г.Толымбай алдагы иҗат планнары хакында сорагач: «Хәзер социалистик реализм, дөреслекне язу турында сөйлибез... ә безнең тормышта булганны син язып кара—берәр «уклон»га эләгүеңне көт тә тор. Шунда ук өстеңә теләгән эт үләксәләрен асачаклар. Бөтен кешегә дә ярап бетә алмассың—һәркем үзенчә фикер йөртә»,—дип җавап бирә.

«Толымбайский,—дип алга таба дәвам итә шымчы,—чынлыкта язучыга эшләү мөмкин түгеллеген, һәрбер теманың тормыштан алынганлыгын, ә совет тормышының реаль образларда бер дә әйбәт күренмәве турында сөйләде. Аның фикеренчә, уңай образларны тудырырга маташу—ул чын тормыштан ерак булган фантазия...»

Күрәбез, әдипнең сыйнфый карашы бик үк беркатлы булмаган, тормышка һәм иҗат шартларына ул шактый аек күз белән караган.

**Равил РАХМАНИ**

# АФЗАЛ ШАМОВ—ГОМӘР БӘШИРОВ: ФРОНТҺӘМ ТЫЛ ХАТЛАРЫ

***

30 октябрь, 1945 ел, Кытай.

Гомәр!

Синең хатыңны алдым. Рәхмәт. Хинган таулары зурлыгындагы рәхмәт!

24 сентябрьдә язылган беренче хатың үзе белән бераз борчу да алып килде. Хатыңның тонына һәм андагы сүзләргә караганда, мин сине үземнең хатым белән үпкәләткән булсам кирәк. Нәрсә белән үпкәләтүемне һич тә хәтергә төшерә алмыйча, берничә көн борчылып, пошынып йөрдем. Җавап язар өчен кулыма каләм дә ала алмадым. Бары икенче хатың гына тынычлык бирде. Җылы һәм дусларча язылган хат булып чыкты ансы.

Дөрестән дә, 2нче сентябрьдә җибәргән хатымны миңа коры гына һәм бик ашыгыч кына язарга туры килде. Ул көнне мин командировкага чыгып китәргә хәзерләнә идем. Хатымны шул командировкага чыгып китәр алдыннан гына сызгалап ташлаган идем. Күрәсең, ул тупас һәм күңелне кырырлык булып чыккан булса кирәк. Син мине андый тупаслыгым өчен гафу ит, дус кеше! Исән булып, кайтсам, кайчан да булса бер утырып, хәят шәрабе белән (әйе, хәят шәрабе белән!) урынсыз үпкәләрнең табын бик ныклап юарбыз. Ибрай Газый әйтмешли: долой кызыл аракылар, яшәсен рус әчесе! (Нәрсә әйтсәң дә, фронтовиклар шул!)

Әгәр сез безнең монда Казандагы иптәшләргә нинди зур хөрмәт саклаганны белсәгез иде, андый үпкәләрнең исен дә чыгармас идегез. Киткәнгә шактый булды шул, озакламый өч ел тула. Егетләр безне оныта башлаганнардыр. Сугыш, фронт мәшәкатьләре белән күмелеп, кулга тотарлык рәтле нәрсә дә иҗат иткән юк. Анда халыклар, күрәсең, безгә инде әдәби балласт, төшеп калмаган эч пошыргыч йөк дип карый башлаганнар булса кирәк. Нишлисең, алар да хаклы. Без еракта. Күренмибез һәм нишләп ятуыбыз да мәгълүм түгел.

Син тагын моны, зинһар, үз хисабыңа алма. Бу һич тә сиңа карата әйтелгән түгел. Син фронт, сугыш авырлыгын үзең татыган кеше. Аллага шөкер, ертык ботинка киеп, винтовка күтәреп 20 яшьлек малай чагында Украина даласын таптап үткән һәм 42нче елда Старая Русса сазлыкларында аяк чолгауларын гына түгел, тезләренне һәм түшләреңне дә чылаткан кеше. Бу тормышның прозасы да һәм поэзиясе дә сиңа таныш. Син аңлый аласың аны.

Син журналлар һәм китаплар җибәртермен дигән идең. Котәбез. «Совет әдәбияты»ның 3,4,5,6,7 номерларын күргән юк. 8нче номер килде. Килде генә түгел, кинәт бер «олау» килеп төште. Әллә инде журналлар исергәннәр, әллә инде аларны безгә җибәрүче кеше исерек булган,—анысын белмим. Ләкин Әпсәләмгә, Эль-Габидка[1] һәм башкаларга дигән журналлар безгә килеп төште. Тик шунысы кызганыч, барсы да 8 номер. Җитмәсә тагын безнең адрес та дөрес язылмаган. Безнең адрес 74232-П. Ә журналга «П» хәрефе куелмаган. Журналлар шул 74232 адрес буенча барганнар. Анда, бәхеткә каршы, мине белгән кеше бар икән, ул аларны миңа җибәргән. Кайчандыр миңа дигән журналлар Г.Бакиров[2] һәм башкалар адресы

[1] Эль-Габид – Гиз-эль-Габид (1918-55), шагыйрь.
[2] Г.Бакиров – Госман Бакиров (1896-1982), язучы.

*Ахыры. Башы 5 санда.*

белән икенче фронтларда алынганлыгын вакытында мина язганнар иде. Мондый «шаяруны» бетереп булмыймы анда? Бәлки, бу эшне Ф.Хөсни үз кулына алыр. Ул аккуратный һәм намуслы егет.

Әгәр син 3,4,5,6 һәм 7 номерларын да җибәрә алсаң, бик яхшы булыр иде. Билгеле, синең хикәяне башлап укып чыгар идек. Мин «Дустым кабере янында» дигән бер хикәя кебек нәрсә калдырган идем, басылдымы ул, юкмы? Бу әле син редактор чагында иде. Шуңа күрә синнән сорыйм.

«Ник кайтмыйсың?» дип сорыйсың син. Чынлапмы бу, әллә шаярып кынамы? Әгәр ССПдан нинди дә булса чакыру булса, аз гына вакытка булса да, кайтып китәр идем. Кайтасының ничек килүе турында язып тормыйм инде. Балаларны һәм семьямны сагыну һәркемгә дә таныш, аның ачы шәрабын татымаган кеше юктыр. Моннан җибәрергә уйламыйлар. Доброволь булып килдең, мәҗбүри кал диләр. Менә әкәмәт, доброволь итеп кайтармыйлар бит. Анда Ерикәй кызулатса ярар иде. Каләмебез тупаслана, барлы-юклы әдәби көче кими, хәтта сүнеп бара. Вак хәбәрләр, мәкаләләр, зәвыксыз очерклар язган буласың. Ә алар тычкан кебек әдәби хәзинәне кимерәләр. Тутыкканлыгымны бөтен җаным-тәнем белән сизәм.

Шушы көннәрдә генә «Агач башмаклы кыз» исемле бер хикәя язып бетердем. Кыска гына. Шушы көннәрдә җибәрәм.

Безгә берәр нәрсә яз әле. Мәсәлән, бүгенге Казан, яисә бер мәктәп турында, булмаса, юл өстендәге берәр артельга, йә фабрикага кереп, яшьләр һәм кызлар турында. Гомумән, теләсә нинди темага 200-250 юллык нәрсә. Ул кадәр читен эш түгел бит инде. Ачуымны китерсәң, синең исемнән монда үзем язам. Дүрт айга нәкъ 4 номер «К.Т.»[3] газетасы алдык. (Чынлап 4 номер гына!) Шул номерлардагы мисалларны алам да язам.

Иптәшләргә сәлам диген. Кашшафны күрсәң, минем исемнән кулын кыс һәм терелүен телә.

Хатларың өчен рәхмәт. Ачулы булса да, хат ичмасам. Тагын бер кат рәхмәт.

Утыртыйнскийдан (ай, дөрес тә әйткәнсең, каян уйлап таптың!) Гыймадидан, Ахмеровтан[4] да сәлам.

Кулыңны кысып, исәнлек һәм иҗат уңышы теләп, Афзал.

P.S. Хатың кыска дигән идең. Мә ындыр табагы буе хат. Мантоның аның шундый тел бистәсенә әверелә торган гадәте бар. Милли бәрәңге кәлҗемәсе түгел ул!

***

Афзал!

Синең хатыңны юлга чыгар алдыннан толыпны кигәч кенә алганлыктан, синең сәламнәреңне тапшыра алмыйча, журнал җибәрү турындагы үтенечеңне башкара алмый киттем. Исән булсам, аларны инде кайткач үтәрмен.

Монда, Буденный районының Шәйморза авылына килеп төшкәч, хатыңны тагын бер укып чыктым. Бу ни хикмәт, бу ни гаҗәп? Шулай ук синең кәефеңне кырырлык хат булып чыктымы икәнни? Үземә калса, мин аны синең кыска хатыңа пародиясыман шаяртып кына язган идем. Белмәссең тагын: сөйләшә белмәгән телдән т. белгән к. яхшы диләр бит. Кайчагында минем шаяртуым чыннан да шулай кызык нәтиҗәле булып чыга. Мин көлдермәкче булам, ә ул, мин көлдерәсе кеше, минем гаҗәпләнүемә каршы, көләсе урында җенләнә башлый. Хәзер менә шундый «шаян» хат язуыма бик үкенәм дә, нишләмәк кирәк, эш узган.

Ышан, Афзал, анда һичбер үпкә-фәлән дигән әйбер юк һәм аның булуы да мөмкин түгел. Каян килсен ул, нәрсәдән, ана нинди нигез бар? Без инде, биргәненә шөкер, бала-чага, малай-шалай түгел ләбаса.

Минем хатны ялгыш аңлапмы, яисә башка сәбәп булганмы, син тылдагы иптәшләр турында күңелсез уйларга бирелгәнсең кебек сизелә. Бик ялгышасың син, Афзал! Мондагы иптәшләр сезнең нинди шартларда эшләвегезне беләләр ләбаса. Әгәр хәзер зур нәрсәләр язарга вакытыгыз юк икән, ул бит киләчәктә дә

[3] «К.Т». – «Кызыл Татарстан», хәзерге исеме «Ватаным Татарстан».

[4] Ахмеров – Котдус Ахмеров, журналист, «Алга, дошман өстенә» һәм «Суворовча кысырыклау» фронт газеталарының хәрби хәбәрчесе.

булмас дигән сүз түгел. Аннары бит әле мондагы бәндәләр—без дә үз өебездә, тыныч урында, үз иптәшләребез, үз гаиләбез янында һәм үз иркебездә була торып та әлләни ишкәнебез юк. Андый зур әсәрләр бит ул әле иң элек мондагылардан сорала торгандыр.

Бәлки, син гаиләңнең тәэминаты белән канәгать түгелсең? Ул як чыннан да йомшаграк шул. Союз башка оешмалар белән чагыштырганда аз эшләмәде, ләкин шулай да ул канәгатьләнерлек түгел әле.

Сиңа Ерикәй хат язмадымы? Ул сезнең турыда башкалада үтенеч кузгаткан иде. Нәтиҗәсен әлегә ишеткән юк. Өмет шунда инде. Аннан соң, сезнең газетагыз чыкмый башлаган имеш дип ишеткән идем, дөрес булмады, ахрысы. Шулай булса бу якка бәлки тизрәк борылыр идегез. Кешеләр ялга кайталар, син дә кайта алмыйсыңмы?

Казанда миннән шул искечә калганнар иде. Хәер, Маннур[5] кайтты. Әх.Исхак [6] ялга кайтты. М.Садрый[7] кайтып китте.

Без Ярми[8] белән ватан сугышы фольклоры җыярга чыккан идек. Мин килгәндә чирләп менә бу авылда тоткында ятам, Ярми парлап күрше авылга кунакка китте.

Малайлар урамда шар уйныйлар, кече якта, казанда Мәгъсүмә әптинең быкыр-быкыр «алма»сы кайный, минем янда «Казан апа, ашасым кели!» дип сары чәчле бер мишәр баласы кайнаша.

Менә саквояждан алып шәмне дә яндырып җибәрдек. Өстәл өстенә буын бөркеп бер табак чикмәнле бавырсак килеп утырды. Хәзер без Мәгъсүмә әпти белән каршы утырып бәрәңге бөгәргә тотынабыз.

Казанга тагын бер 15 көнсез кайтып булмас шикелле. Китапны җибәрдек дигәннәр иде бит, алдадылар микәнни? Кайткач белешермен инде.

А. Әхмәт, Гыймадиев һәм Әхмеров иптәшләргә күп сәлам. Вакытың булганда хат язсаң мин бик шат булыр идем. Сәлам белән, Гомәр.

23/XI-45.

Шушы йөргән чакта берәр нәрсә очрар, шуны язармын дип торам (сезгә).

***

2 январь, 1946 ел.

Гомәр!

45 ел артта калды. Аның көннәре, сафка тезелгән солдатлардай нык басып, кайгы һәм шатлык аралашкан гомер юлы буенча узып киттеләр. Без вакыты белән кайгы касәсендәге шәрабын да, шатлык касәсендәге шәрабын да тамчысын да калдырмыйча эчтек. Инде безнең алдыбызда тыныч көннәр җәелеп ята. Сугыш көннәрендәге кайгыларны, өзлексез борчуларны татымыйбыз инде, ләкин күнелләребездәге сагыну хисләре электәгечә яши. Хәтта электәгедән дә көчлерәк дисәм, дөрес булыр. Элек тә безнең алда зур һәм билгеле максат бар иде. Без, авыр еллар аша үтеп, ул максатка барып җиттек. Җиңүгә ирештек. Бу омтылыш безнең сагыну хисләре—безне томалап тора иде, хәзер инде алар бәреп, ташып чыктылар.

Билгеле, без үзебезнең семьяны гына түгел, Казанны да, матбугат йортын да, әдәби эшне дә һәм каләмдәш иптәшләребезне дә сагынабыз. Үзебезнең эшкә кайтырга бик вакыт инде. Бу турыда андагы иптәшләр дә теләктәшлек белән тулган хатлар җибәрәләр. Бик рәхмәт аларга!

Күрәсең, язучыларны кайтару мәсьәләсе Москвада уңайлы рәвештә хәл ителгән булса кирәк. Моннан инде рус язучылары кайтып беттеләр. Зур язучылар түгел, өлкә күләмендәге язучылар гына. Ә безнең беребезгә дә чакыру килгәне юк. Нәрсә, әллә безнекеләрне кайтармаска ясаганнармы? Ни өчен кайтармаска ясадылар икән? Менә шушы нәрсә мине бик гаҗәпләндерә. Казаннан бу турыда берәүдән дә хәбәр ала алмыйм. Син шушы турыда ачыграк язып җибәрә алмыйсыңмы?

Дөрес, мин бу турыда Ерикәйгә дә яздым. Бәлки, ул да җавап бирер. Ләкин

[5] Маннур – Шәйхи Маннур (1905-80), язучы.
[6] Әх.Исхак – Әхмәт Исхак (1905-91), шагыйрь, тәрҗемәче.
[7] М.Садрый – Мөхәммәт Садри (1913-99), шагыйрь.
[8] Ярми – Хәмит Ярми (1904-81), фольклорчы галим.

ул бераз соңгарак калып җавап бирергә ярата. Әгәр унай хәбәр булса, телеграмма белән хәбәр итсәң дә ярар иде.

Журналның бары №8 генә алдык. Шуна кадәр һәм шуннан соңгы номерларны да күргәнебез юк. Әллә инде исереп, дөнья гизеп йөриләр.

Матбугат дөньясында нәрсәләр бар? Үзеннең әсәреңне бетердеңме? Без монда газета битенә сыярлык нәрсәләр белән генә шөгыльләнәбез. «К.Татарстан»дагы Гариф абзый булып калмасак кына ярый инде дип куркам.

Кара әле, үзенә генә әйтим әле: безнең турыда кайгыртучылар бармы анда, юкмы? Әллә болай да кайтырлар дип көтәләрме? Болай гына булмый. Бертөрле дә өмет юк. Болай гына китәргә генә мөмкин иде, ә кайтырга—юк. Мин Ватаныбыз өчен иң авыр көннәрдә үзем теләп киткән идем, хәзер инде каләмемне әдәбият өчен йөртәсем килә.

Минем сүзләрдән син, бәлки, көләрсең дә. Шулай да дусларча аңлый белерсең.

Сәлам белән А.Шамов.

Адресым: Хабаровск, ул.Карла Маркса, 16.

***

Афзал!

Сиңа хатыңны алган көнне үк җавап яза алмадым, бераз көттерергә туры килде. Чөнки син язган мәсьәлә турында Ерикәйнең үзе белән янадан бер мәртәбә сөйләшмәкче идем, аннан иң соңгы чаралар һәм мөмкинлекләр турында сорашмакчы, мәсьәләне (әгәр соңгы вакытта сизелерлек эшләр башкарылмаган булса), кабыргасы белән куймакчы идем. Кызганычка каршы, аның белән очрашып булмады. Без бит аны депутатлыкка кандидат итеп билгеләдек. Хәзер ул үзе сайланасы округта сайлаучылары белән очрашып йөри, һич күзгә күренгәне юк.

Мин синең хәлеңне аңлыйм, Афзал, бик аңлыйм. Сез инде күптән монда булырга тиеш идегез. Без генә, иптәшләрегез һәм гаиләгез генә түгел, сезне әдәбият та бик сагына. Чөнки ни генә булмасын, без монда һаман да бик аз бит әле. Аннары, үзең беләсең, ул азның да барысы да төпкә җигелердәй кешеләр түгел, бәлки перәжкәдә[9] генә баручылар. Аннары, болай да бик житкән иде инде югыйсә. Син монда йөз тапкыр файдалырак булыр идең... Ләкин болар бит әле син сораган нәрсәнең ачкычы түгел, болар безнең теләк кенә.

Мин сиңа язмаган идемме икән? Республиканың җитәкче оешмалары аша Мәскәүнең тиешле урынына мөрәҗәгать белән керделәр, кайтырга тиешле иптәшләрнең исемлеге шунда бирелде. Анда син дә бар. Ул язу буенча, минемчә, бер кеше дә кайтмады әле. Һич ашыкмыйлар кебек. Минем белүемчә, була дип тә, булмый дип тә хәбәр дә килми. Менә шундый хәл. Әпсәләм кайтты бит. Ул авырып йөрде, комиссия торып тазалыгы чикле дигәнсыман бугай язу да алды. М. аны да җибәрми, югары белемле кеше булгач, шулай инде ул ди үзе.

Ерикәй һәм башка кайбер кешеләрне мин шушы арада күрәм. Әгәр дә инде ул гомуми мөмкинлектән берни дә чыкмый икән (бәлки, ул шул гомуми булганга күрә дә эш чыкмыйдыр?), ул вакытта синең турыда аерым мөрәҗәгать белән керергә кирәк. Чөнки син китүең һәм башка якларың белән дә бүтәнрәк кеше. Ерикәй сессиягә баргач шул мәсьәләне кайгыртуын үтенеп бирәр нәрсә эшләп булмасмы.

Тагын ниләр языйм? Хәзер сайлау белән мәшгульбез. Яңа, зур әсәрләр юк әле. Язылганнары кайсы җитлекмәгән, кайсы гарип туган була. Мин һаман бетерә алмыйм әле. Вакыт җитми һәм тагын шундый кайбер дөньяви нәрсәләр.

Ул сиңа бармаган жур. нишләтергә инде? Синең теге хатыңны алгач, редакциягә махсус барып, Иделле белән икәү Әнәснең нинди адрес белән һәм кайчан, ничәне җибәргәнен үзебез тикшердек. Журнал дөрес адрес белән һәм барысы да җибәрелгән. Ул нинди гаҗәп эш? Бәлки, юлда адашып йөриләр?

Татиздаттан да теге китапның җибәрелүен тикшердем. Зөбәйдә аны да декабрь аенда ук җибәрде. Аңысы барып җиттеме?

[9] Перәжкәдә – пряшкә аты – төп атка янга,ярдәмгә җигелгән ат.

Хәзергә шуның белән тәмамлап торыйк. Ерикәй һ. башка иптәшләр белән кинәшкәч, тагын язармын. Әле теге хикәяңне укытканнар иде, ул турыда да язасы бар.

Ярый, сәламәт булып тор.

Абдулга һәм башка иптәшләргә күп сәлам.

Тиз көндә күрешүне көтеп, Гомәр Р.

30/I-46

***

Афзал!

Моннан берникадәр вакыт элек язган хатымны шәт алгансың. Монысы инде шуның дәвамы сыман бер нәрсә булыр.

Әлеге дә баягы—теге мәсьәлә.

Ул турыда кичә генәк Әх.Ерикәй белән тагын сөйләштем. Ул миңа сине куандырырлык яңа нәрсә әйтмәде диярлек. Тик әлеге сиңа әйткән исемлекнең язмышы турында ул кайбер нәрсә белә икән. Башта аның буенча җибәрергә булганнар. Әнә С. Баттал форсатны ганимәт белеп дип әйтимме, яисә шулай «мач» килгәнме—шул уңай белән кайтып өлгерде. Ләкин ул караш бик тиз үзгәргән, шул арада ук рөхсәт капчыгының авызын бик нык итеп бәйләп куйганнар. Син инде, бик табигый, нигә алай икән диярсең. Үзең беләсең, барысын язып бетерү дә мөмкин түгел.

Бәла шунда, башка халыкларның язучылары бит газетада язучы булып эшләгәннәр иде. Ә сез алай түгел, сез штаттагы сотрудниклар. Әгәр дә сезнең ул яза торган нәмәстәкәегез чыкмый башласа, мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителгән булыр иде. Шундый нәрсә ишетелмиме соң?

Безнең башлык Ерикәй хәзер депутат бит инде. Ул киләсе ай башында Мәскәүгә бара. Аңа хәерле юл телик.

Шулай да син, әгәр кирәк-мазар була калса дип әйтеп, үзеңне җибәрү мәсьәләсен хәл итә торган башлыгыңның адресын, звание-фәләннәрен язып җибәр әле. Чөнки Мәскәү дә бит, әгәр шулайга китсә, аның фикере белән исәпләшә торгандыр.

Шулай итеп, Афзал туган, мин сиңа бу юлы бер дә куанычлы нәрсә яза алмадым. Әгәр андый берәр хәбәр булса, хат язып утырырга түземлегем җитмәс, тыр-тыр телеграфка гына йөгергән булыр идем. Инде икенче хатларның берсендә, бик озакламыйча шундыйны язарга насыйп булсын инде.

Монысы шуның белән бетте шикелле.

С.Ә.ннан синең хикәяңне укырга биргәннәр иде. (Үч иткәндәй, бу хатка гел күңелсез нәрсәләр турында гына язарга туры килә. Монысы өчен үзем дә бик уңайсызланам. Ләкин нишләмәк кирәк?...) Туп-туры гына әйткәндә, ул хикәяң миңа ошап җитмәде. (Хәер, миңа ошау-ошамау ул әле зур әйбер түгел.) Нигә алай? Соры песинең нагрузкасы бик зур. Аңа шул кадәр авыр йөк йөкләнгән, ул аларны күтәрә алмыйча һичшиксез үзе шул йөк астында калыр иде. Соры песи монда песилегеннән чыгып сугышчылар арасындагы нечкә мөнәсәбәтләрне, аларның рухани хәлләрен үзгәртә алырлык бик дәү бер фигура булып китә. Шуннан ихтыярсыз хикәяңнең ышандыру көче кими, канәгатьсезлек туа. Белмим, бәлки миңа гына шулай тоеладыр. Ул хәзер редакциядә. Иделле нишләтә торгандыр.

Тагын ни язарга? Казанда үзгәрешләр юк кебек. Бу арада матбугат дөньясында да телгә алырлык зур вакыйгалар булмады. Без һаман шулай акрын гына яши бирәбез, сез кайтканны көтәбез.

Ярый, шуның белән тәмамлыйк инде. Хикәяң турында ялгыш сөйләнсәм, ягъни ялгыш фикер йөртсәм, язарсың әле.

Абдул Әхмәткә һәм бүтән иптәшләргә сәлам.

Гомәр Аккомасты. 16/II-46.

***

3 апрель, 1946 ел.

Гомәр, Акком асты егете!

Менә шулай була ул: кеше сиңа яхшылык эшли, бу эшкә ул үзенең иң яхшы

хисләрен, изге ниятләрен сала, ә син, аның тагын изгерәк эш эшләвен көтеп, ана рәхмәтенне әйтмичә тукталып торасың. Минем белән дә шундый ук хәл булды. Син миңа Хабаровск адресы белән берничә хатынны җибәрден, мин икенче хатынны көттем. Икенче хатынны алгач, Ерикәй Москвадан кайткач биреләчәк телеграмманы көттем. Телеграмма бирерлек күңелле хәбәр булмады, ахры. Чөнки телеграммалар ташучы почтальонның әле һаман да безнең ишекне килеп шакылдатканы юк. Ә без шундый шатлыклы шакылдатуны һәр көнне, хәтта һәр сәгать көтәбез. Кайчакларында шундый көтү хисләре белән йокыга китәбез һәм шул хисләр белән урыныбыздан да торабыз.

Әгәр дә бу хисләрне миңа, мин Казанда яшәгән вакытта, минем шикелле бер карт солдат язган булса, мин солдат йөрәгендә мондый акылсыз, хәтта җүләр дип әйтерлек йөгәнсез хисләрнең яшәвенә гаҗәпләнер идем. Аннары ана, дилбегә озынлыгы итеп, тозлап-борычлап, шул ук вакыт вәгазь-нәсихәтне һич тә кызганмыйча хат язар идем. Оялтыр идем мин ул егетне. Менә югарыдагы юлларны язганда мин синең дә шундый сүзләрне күңелең белән язарга ашкыначагыңны сизгәндәй булдым. Язма син аны, дус кеше, кирәкми! Кирәкми! Андый сүзләреңне очрагач, кайткач, аббылхаят касәләрен күтәргән вакытта әйтерсең. Андый минутларда әйтүе дә һәм тыңлавы да җиңел булачак. (Минем якын дусларымнан берсе—ак аракыны сугышка кадәр татып та карамаган бер әдәпле егет—күптән түгел генә бер хатын: «Долой кызыл шәраблар, яшәсен Мәскәү ачысы!» дип бетергән иде. Миңа да ул фикеремне шундый сүзләр белән очларга туры килер, ахры. Сугыш безне ачы кайгыны гына түгел, ачы хәмерне дә эчәргә өйрәтте.)

Тукта, язган хатларың һәм минем турыдагы барлык кайгыртуларың өчен рәхмәт әйтеп үтим. Тиз җавап бирмәвем белән бер әдәпсезлек күрсәттем, инде рәхмәт әйтмичә торып, бу әдәпсезлегемне тагын да дәвам итмим дим.

Без һаман да әле Амур суын эчәбез, тимер дагалы итекләребез белән көнчыгыштагы кала урамнарын таптыйбыз. Сугыш беткәннән соң да инде икенче пар итекне туздырабыз, ул көннән соң инде шул кадәр күп вакыт узды, хәтта А.Әхмәткә инде яңа тешләр дә чыга башлады.

Без синнән монда очерклар көтеп ятабыз, ә син анда хәтта мыегыңны да бөтереп карамыйсың. Шушы көннәрдә сиңа 80 сум акча барып җитәр, ул сиңа кайтарылып алынмый торган «аванс». Берәр очерк көтәбез.

Син хатыңда: «Сезне кем җибәрә ала?» дип сораган идең. Безне бары Москва гына, Шикин гына җибәрә ала. Аннары син анда капчык авызын каты итеп бәйләү турында да язган идең. Нәкъ шуны инкяр иткән кебек, синең хатны алган көннәрдә бер казах егете, бер бүрәт егете китте дә барды. Барсы да безнең шикелле штаттагы халыклар. Рус иптәшләр шундый ук штаттагы халыклар иде.

Тастымалның[10] (Ибрай шулай атый) тукталуы турында сүз юк әле.

Ерикәй Москвадан нинди хәбәрләр алып кайткан? Казанда нәрсәләр бар? Тукай көннәре ничек үтте? Барсын да яз әле.

Мине искә төшергәннәр булса, сәлам диген аларга.

Сәлам белән А.Шамов

P.S.

А.Әхмәтнең теше турында яздым, хәтта аның дагалы итеген дә искә алдым, ә аннан сәлам язарга оныткан мын. Безнең заман Хуҗа Насретдинының да сәламен кабул күреп ал инде син!

«С.Ә.»ның №7дә Әдип Маликовның[11] поэмасы бар. Нинди егет ул? Нигәдер ул Х.Т.ны бик хәтерләтә. Ул түгелме икән дигән фикер дә килә кай минутларда. Чынлап та.

А.

[10] Тастымал – Язучылар фронтта үзләре чыгара торган газеталарын үзара гына шулай атаганнар.

[11] Әдип Маликов (1921), язучы.

Рөстәм
Зарипов

# КОЯШКА КАРШЫҺӨҖҮМ...

## Тәхет китабында ниләр бар?

Мин фәкыйрьне Төзүче инженерлар институтында укый башлап, проектның ни икәнен төшенгәч, «Алтын Урда дәүләтенең һәлакәте артында да кемнеңдер проекты ятмыймы, Казан, Әстерхан, Кырым ханлыкларының юк ителүе шул проектның ахыргы пунктлары түгелме» кебек сораулар бимазалый башлаган иде. Габдрахман Авторханов «Хакимият технологиясе» дигән хезмәтендә төрки халыкларга Сталин чорында ничек итеп латин, аннары кириллицаны тагылуын тасвирлый. Ә бүген, Путин чорында латин әлифбасына кайтуны тыю һәм мәктәпләрдән «милли компонент»ны алып ташлау, ягъни туган телдә укуны тыю, Россия хакимиятендә кем утырса да һәм иҗтимагый корылыш ничек аталса да татарны юк итү сәясәте үзгәрмәве хакында сөйли. Әйе, миңа калса, борынгы заманнарда иҗат ителгән һәм расланган проект бар, ә бәлки ул фараздагы «тәхет китабы»ның төп өлешедер, һәм Россия хакимиятенә килүчеләр аннан бер карыш та тайпыла алмыйдыр? Татарстанның 3 миллиард тонна нефте табигатен пычратып суырып алыну татар халкына ни бирде? Җыелган налогларның 70-80 % ы үзәккә озатылу тәҗрибәсе тарихта кайсы колонизаторның төшенә кергән? Ил язмышы хәл ителгән сугышларда пушка ите сыйфатында файдалану бер хәл, Чиләбе өлкәсендәге милләттәшләребезне атом афәтенә юлыктырып һәлакәткә дучар итү һәм исән калган зыян күрүчеләргә тишек тиеннәргә ирешү өчен дә судта көрәшүләр кирәк булуны ни дип юрарга? Туган телдә белем алудан, туган тарихыбызны өйрәнүдән тыю, чын белем бирергә дип килгән төрек кардәшләребезне йортыбыздан кууга куанасымы? Һәм шундый шартларда, әллә кайчан, Алтын Урда чорында илдәге һәркемгә тигез салынган 10 % ясакны «иго» дип улаулар, дәреслекләр аша халкыбызны кеше ашаучы, тәмуг кисәве итеп тасвирлауларны без ничек кабул итәргә тиеш? Һәм шундый җәмгыятьтә безне киләчәктә нәрсә көтә? Хуш, туган телебезне тыю турында фашистик канунны ачыктан-ачык кабул иттеләр. Моннан чыгып, безгә карата нинди яшерен карарлар кабул ителгәнен фаразларга гына кала... Димәк, алдагыны чамалар өчен, безгә турыдан-туры кагылышлы проект белән танышу, шуны эченә алган «Тәхет Китабы»н уку, архимөһим. Ә Тәхет Китабын уку өчен ачкыч бармы соң? Ул бар һәм аяк астында гына ята дип уйлыйм. Адольф Гитлерның «Минем көрәшем» атлы хезмәтендә һәм кайбер рус патриотлары язган бүгенге ( иң гайрәтлесе мөгаен Юрий Дмитриевич Петуховның, 2004 елны Мәскәүнең «Мегагалактика» нәшрияты бастырып чыгарган « Геноцид. Общество Истребления» дигән китабындадыр) яһүдләр дөньякүләм җинаятьләрдә гаепләнә. Петухов әфәнде Палестина җирләренең әүвәлдән урысныкы булуын дәгъвали. Аның раславынча, борын-борын заманда урысларны шуннан сөйләшә дә белмәгән яһүдләр куган, имеш. Ягъни татар «игәүләвенә» кадәр рус халкына әле яһүдләр холокост оештырган булып чыга. Яһүдләрне «талантлы булмауда», «башкалар хезмәтен үзләштерү аша» гына уңышка ирешүчәнлектә дә фашлый әлеге ике

*Ахыры. Башы 6 санда.*

автор. Ә борынгы халыкны «чиста суга чыгаруда» иң саллы нигез итеп 1911 елны С. Нилус тарафыннан Изге Троицк Сергиев Лавры типографиясендә басылган «Сион акыл ияләре беркетмәләре» (Протоколы Сионских Мудрецов) санала. Гавәм арасында киң таратылган әлеге басмада мондый юлларга да тарабыз: «Китапның тышлыгындагы фотоны яхшылабрак күздән кичерергә чакырабыз. Тоташ яһүдләрдән, террористлар өереннән торган хакимиятчеләрнең (Ленин хөкүмәте) кыяфәтләре аларның кемлеген ачып сала. Шушы явыз шайканың 1917 елны 150 миллионлы рус халкы өстеннән деспотчыл хакимият урнаштыра алуының сере, яһүдчелекнең һәрвакыт үз сион программасы булуында. Һәм шул кеше күрәлмәүчел программа, тимер ихтыяр белән, бернәрсә каршында да тукталып тормастан, катгыян үтәлә һәм үтәлеп килә...»

Бүген Фәләстыйнда дәвам иткән канкоешлар фонында, «Майн кампф» һәм әлеге беркетмәләр, янә рус патриотларының бүгенге фаш итүле иҗатлары белән танышкач, яһүдләрнең кешелеккә каршы дошман булуларына ышанырга да күп калмый. Әмма шушы урында безгә «Ә син, татар, үзең кем соң син?» дигән сорауга да җавап табу фарыз. Урыс чыганаклары, тарихи романнар, фильмнар, дәреслекләрдә, хәтта балалар өчен чыгарылган китапларда без—явызлык эквиваленты, сабый балаларны ашаучы каннибаллар, чәчәк аткан Русьне 300 ел буе «иго» чиктергән, талаган, изгән, каһәрләгән затлар буларак танытылабыз... Көндәлек матбугат, кайсы фирканыкы булуына карамастан, уртак сыйфатка ия. Адым саен «коммунистические орды», «фашистские орды», «демократические орды», «бюрократические орды» кебек төшенчәләр аша татарофобиягә, татарны күралмауга юлыгылабыз. «Халыклар дуслыгы» турында сафсата тудыручы һәм куертылучы бу илдә бер безне генә «зурламыйлар» анысы, чеченнар—бандит, прибалтлар—фашист, урта азиялеләр—чуркалар, японнар—япошкалар, американлылар—пиндослар, кытайлар—китаезалар һәм башка шуның ише билгеләмәләр табигый, шулай тиеш сыман кабул ителә. Хуш, яһүдләргә ташланган гаепләүне йоттык ди. Әмма ләкин, татарларны пантюркизмда һәм бер үк вакытта панисламизмда гаепләгәндәге капма-каршылык сыман, биредә дә мантыйкый мәгънәсезлеккә тап булабыз түгелме? Әгәр, «башкалар хезмәтен үзләштерүдә маһирлар» дигән гаепләү белән килешсәк, бу «беркетмәләр» ниндидер даһи оригиналга нигезләнеп тудырылган булып чыга. Ә даһи оригиналны кем тудырган? Кайсы бөек халык? Ә ул оригинал без әчтәлеген белергә теләгән «Тәхет Китабы» түгелме? Шунысы да сер түгел, яһүдләр инде ничә еллар нәни генә биләмәдә тыныч тормышлы тотрыклы дәүләт кора алмый иза чигә, ничә мең ел казганып оештырган дәүләтләре язмышы, туктаусыз дәвам иткән сугыш шартларында, кыл өстендә. Бөтен дөньяга баш булганга кадәр яһүдләргә әнә шул бик нәни биләмәдә үз-үзләрен дәүләт тотарга сәләтле халык буларын исбатларга кирәк әле. Беренче чиратта—үз-үзләренә. Ә менә руслар дәүләт тота белә. Аларның империяләре кабыгын алмаштыра-алмаштыра яши бирә... Ә бәлкем бу империянең саклануы—«Тәхет Китабы»на тугрылыгы нәтиҗәседер?

Детективлардан, разведка эшчәнлеге турындагы ишле әсәрләрдән укып беләбез, разведчикның уңганы үз эшчәнлеге нәтиҗәләрен башкаларга сылап, аларны бәлагә тарытып котылу җаен кайгырта. Ул легенда ярдәмендә дошман арасына үтеп керә һәм шулай ук катлаулы чаралар үткәреп, аннан «чыга». Әйтик Үктәбр түнтәрелеше вакытында патша хөкүмәтенең дөнья яулау юнәлешен алга сөрүче әһелләре, әлеге җинаятьчел китапларын, план-проектларын революция белән җитәкчелек итүчеләр токымына, яһүдләргә ябарга тырышса гаҗәпмени? Башка халыкларның дөньяны яулау нияте табигый саналып, яһүдләрнең шундый омтылышларын гайре табигый явыз ният итеп шәрехләү, аларны дөнья әшәкеләре итеп танытырга омтылу тенденциясе яши. Гаепләүчеләр— шул ук максатлар белән янучы конкурентлар булса кирәк. Ә «беркетмәләр» яһүдләрне деспотия тарафдарлары итеп фашлый. Димәк, фальшивканы ашыгыбрак әтмәлләгәннәр дип уйларга нигез бар, чөнки яһүдләр теләсә кайсы иҗтимагый корылышта да югалып калмый торган кавем, ә самодержавие алар өчен иң сөйкемсез, дәресрәге, иң мокыт чишелеш. Гитлер яһүдләрне теләсә нинди дискриминацияле кануннар чыгарып кысрыклаган очракта да немецлардан өстен чыгачакларына инанганга, үзенең раса теориясен чәлпәрәмә китермәүне күздә тотып «холокост»ка керешә. «Холокост»—яһүдкә каршы оештырыламы, татарга яки чеченгамы—без бөек дип кабарынучыларның кимлек кәсафәте җимеше. Ә менә русларның дөньякүләм уңышлары иң котырган деспотия чорлары белән

бәйле. Империя Явыз Иван һәм аның канлы опричинасы шартларында ярала. Үз халкын чебен урынына кырган Петр I заманында ныгый, канат яра, киңәя. Бөек рус әдәбияты, илнең күпчелек халкы крестьяннар крепостной кол булып яшәгән заманда, миллионнарча күңелләрне аулый. Сукадан космик корабкача сикереш, Сталин оештырган колхоз, ГУЛАГ коллыгы һәм ачлык муры шартларында ясала. Шуңа күрә, әйдәгез, самодержавиене данлавы белән шикле «беркетмәләр» ярдәмендә Тәхет Китабының кайбер сәхифәләрен укырга тырышып карыйк... Беркетмәләрдәге ак җеп белән тегелгән өстәмәләрне танып кыркысак, кибәген очыртсак, төп текстка якынаербыз, шөт. Текстта «гой» дигән билгеләмә бар, һәм ул—яһүд түгел халыкларның уртак атамасы. Шул атаманы «татар» дип алмаштыру «беркетмәләрдәге» мәгънәгә хилафлык китермәстер...

Бер мәкаләдә «тәхет китабын» тулаем торгыза алырмын дип өметләнмим. Бәлки галимлек сәләте булган, һөнәри әзерлекле милләттәшләрем бу эшне ахырынача башкарып чыгара алыр? Алай да, хәл кадәренчә тырышып карыйк әле, ә «гой» дигән гомуми билгеләмәне «татар» дип тарайту максатка ярашлы булыр :

| Сион Акыл Иләре Беркетмәләре. С. Нилусның 1911 елны Изге Троицк Сергиев Лавры типографиясендә басылган дип тәкъдим ителгән, интернеттан алынган текст. Сайланма маддәләр тәрҗемәсез бирелә | Шәхси фаразларыма турылаган искәрмә һәм шәрехләр |
|---|---|
| Народы гоев одурманены спиртными напитками, а молодеж их одурела от классицизма и раннего разврата, на которое ее подбивала наша агентура—....наши женщины в местах гоевских увеселений. | Биредә сүз рус патшасы хозурына хезмәткә киткән хан нәселе вәкилләре, морза балалары хакында бара дип аңлыйм. |
| ...Аристократия, пользовавшаяся, по праву, трудом рабочих, была заинтересована в том, чтобы рабочие были сыты, здоровы и крепки. Мы же, заинтересованы в обратном—в вырождении гоев(татар). | Татар аристократиясенең милләте нинди булуга карамастан тигез, 10 % ясак түләүче эшче көчләргә мөнәсәбәте турында . |
| Наша власть—в хроническом недоедании и слабости рабочего, потому что, он не найдет ни сил, ни энергии для противодействия ей. | |
| Голод создает права капитала на рабочего вернее, чем аристократии давала это право законная Царская власть | Ясалма оештырылган ачлыкның буйсындыру тәэсире, татар ханнары биргән ярлыкка караганда куәтлерәк булуы күздә тотыла. |

«Беркетмәләр»дә маддәләр шактый, әмма диңгез суының түмен аңлар өчен аны тулаем эчеп бетерү мәҗбүри булмаган кебек, китерелгәннәре дә иң кирәген аңлар өчен җитеп ашкан дип торыйк. Мин биредә күрәләтә яһүдкә төртеп күрсәтә торган, «ак җепләр белән тегелгән» маддәләргә игътибарымны юнәлтмәдем. Ә китерелгән кадәреләре әлеге «беркетмәләрнең» иҗатчысы яһүд булуына шик калдыра. Иҗатчы яһүд булган очракта да заказчысы кемдер бит? Инде килеп, С. Нилус хаклы булган очракта, әлеге беркетмәләр, «Тәхет Китабы» җирлегендә, аны үтилләштереп тудырылган икенчел продукт булуы, шәхсән минем өчен, ап-ачык... Кичерегез, мин шулай уйлыйм.

## Кояшка һөҗүм...

Аерым җинаятьчел элементларның, төркемнәрнең шәхескә яки дәүләткә карата кылган җинаятьчел гамәлләреннән, аларның төр, ысулларыннан күбебез хәбәрдар, болар җинаятьләр кодексында тәфсилләнгән һәм бу өлкәдә телевидение, матбугат һәм детектив жанрга караган әсәрләр гавәмне даими «агарту» белән мәшгуль... Шулай ук дәүләт тарафыннан төрле тарихи дәверләрдә ил эчендә

аерым этносларга, үзгә дини конфессиядәгеләргә, социаль катламнарга карата үткәрелгән җинаятьчел гамәлләр хакында да мәгълүмат юк түгел.

Россия президенты В. Путин, тарих дәреслекләре хакында сүз барган телетапшыруда, АКШны күздә тотып:

—Такмасыннар безгә гаепле лек хисе. Тарихта әллә ниләр булган. Һәрхәлдә, без тыныч халык өстенә атом бомбасы ташламадык, бөлекәй генә илне Бөек Ватан сугышындагыдан 7 тапкыр артык күләмдә бомбага тотмадык, агулы химикатларга коендырмадык,—дип белдерде. Шул ук 25 июнь (2007) кичендә Соловьевның «К барьеру» тапшыруында әлеге хакта сүз дәвам итте һәм анда, «әгәр бертуктаусыз АКШ гражданнарына Япониягә атом бомбасы куллануын, Вьетнамга карата кылган золымын, ә Кытайга даими рәвештә «Тяньанмынь» мәйданындагы вакыйгаларны исләренә төшереп торсаң, бу бөек халыклар бөек халык булудан туктаячак, үсешләре тоткарланачак, шуңа күрә СССР кылган кайбер гамәлләргә дә (ГУЛАГ, Әфганстанга басып керү һ. б. ш.) дәреслекләрдә «илнең киләчәген күздә тотып» бәя бирергә кирәк дигәнрәк фикер үткәрелде.

Әлеге тапшыруда шул ачыкланды: димәк, бертуктаусыз «татарское иго» дип туглаулар артында татар халкын үсештән туктату һәм юк итү нияте ята булып чыга...

...Көнчыгыш көрәшләрендә көндәшне гәүдәсенең мөгълүм нокталарына сугып сынын катыру, тынсыз калдыру алымнары кулланыла. Безнең халык өчен университетка тиң Татарстан радиосын «үзгәртеп кору», дөньяның теләсә кайсы илендә генә димим, хәтта чит планетада татарны лаеклы танытырга сәләтле «Җыр һәм бию ансамбле» җитәкчесе Лима Кустабаеваны эшеннән алып ату да шундый сугуларга тиң.

Тукай, Сәйдәш, Хәсән Туфан, Фәрит Яруллин, Кәрим Тинчурин, Солтан Габәши, Латыйф Хәмиди, Хәйдәр Бигичев, Таһир Якупов язмышлары... Латинга кайтуга киртә салу, уенчык суверенлыкны кире тартып алу, яңа Шартнамәне расламау, татар-төрек лицейларын кысрыклау, Башкортстанда төзелүче татар гимназиясен җимерү, мөстәкыйль татар институтларын педогогик университет карынына көшәләп кертү, калада ачылган татар мәктәпләрен кабаттан төкәндерү, оптимальләштерү сылтавы белән авылдагы татар мәктәпләрен «кыскарту», татар мохитен саклау вазифасын җилкәсеннән төшерми җан асраучы авылларны бетемсезлеккә юнәлтү һәм киң таралышлы татарча газета-журналларыбыз офыкларын тарайтып, тиражларын котайту... Ягъни татарның калдык-постык яшәү стимулларын да, ниндидер илкүләм максатчан көч, эрегә-вакка бүлмичә генә бөртекләп һәм чиратка салып, төкәндереп ята ...

Мәскәүдә, Михаил Леонтьев («Однако» тапшыруы аша мәгълүм) кебек журналистлар канат ныгыткан «Кургинян Үзәге» дигән аталышлы иҗтимагый оешма эшли. Рус патриотларыныкы дип тәкъдим ителүче матбугатта («Завтра» газетасының 2007 ел 24 санында) әлеге үзәк «оештыру коралы» темасын яктыртуны дәвам итә. ...Рональд Рейганның СССРны «явызлык империясе» дип атавы да, «оештыру кораллары» арсеналыннан икән.. Мәкаләдә, «корбан»ның энә белән кадап филне аударырдай ноктасын табып булуы хакында тәкрарлана. Һәм «корбан»ны, ул триумфка ирештем дип хаталанган шатлыклы мәлендә, елмаеп-балкып, бернинди кызганусыз, бер кадауда җан тәслим итү отышлы, имеш ки... һәм СССР белән шулай килеп чыккан да?!

«Үзәк» эзләнүләре мантыйгыннан чыгып бәяләгәндә, чукчалар турында анекдотлар—чукча халкының рухын сындырып, «энә белән кадап үтерү» ысулындагы оештыру коралы булып аңлашыла. Прибалтларны «нематукайтис»лар, Урта Азия халыкларын—«чурка», татарларны—«чаплашка» дип «зурлаулар» да шул җөмләдән. Заманында мөселман-татар мәчетләренең гөмбәзләренә хас айны төре хәнҗәр аша үткәреп, чиркәү гөмбәзенә беркетү, мөселман кабер ташларын чиркәү нигезенә салып калдыруларның хикмәте дә шушы төр коралның элгәрләренә барып чыга...

Яшел Үзән каласында «Сююмбике Зилант» (Сөембикә—Җылан) атлы спорт командасы булдыру ( ул команда хакында күптән ишетелгәне юк, таралган булса кирәк?), киң мәйданда һәйкәлен бастырасы урында «Сөембикә»не җир астында метро төзелешендә эшләтү, (әле бит «аска төшерү» дигәннең Русиядә үзгә мәгънәсе дә бар) аңа ярдәмгә «Алтынчәч»не кушу, сыра бәйрәме ясап, ярминкә мәйданында, Кол Шәриф мәчете каршында Кремль дивары буйлап кыз балаларны, трусикларда килеш кенә тезү һәм башка шундый чаралар, моңа татар

телендәге күрсәткеч язмалардагы хаталар да, татар бөекләренең исемнәрен иң кадерсез урамнарга бирүләр дә керә, әлбәттә. Безгә карата аяусыз һәм даими рәвештә оештыру коралы кулланылуын (татар бахырга инде шундые гына җитми иде!) аңларга булыша Кургинян үзәге эзләнүләре... Димәк, тиздән, Казанны саклаучылар урынына шул кыю кызларны гәүдәләндерүче һәйкәл ансамбле сафка басарга да озак калмагандыр...

Әлеге «Үзәк» хезмәтләрендә, дошман тарафыннан коррупциягә баткан җитәкчеләрне үз иленә каршы эшләтү ысуллары да тәгаенләнә. Ә моның нәрсәсе гаҗәп соң? Караклыкка баткан милли номенклатураны үз халкына каршы эшләтү безнең өчен яңалыкмы?

«Үзәк» эзләнүләре белән танышу—Гариф Гобәй исеме белән элегрәк дөньяга чыккан «Коръән серләре»нең дә «оештыру сәләте» белән «йөкле» хезмәт булганлыгын аңларга ярдәм итте. Хәзер дә, милли әдәби табыннарга җенси мөнәсәбәтләрне тасвирлауны һәрдаим үзәккә куюлар... шулай ук оештыру коралы куллануга тарта. һәм башкалар, һәм башка шуның ишеләр... Алайга китсә, авылга читтән колхоз рәисе, районга читтән китереп куелган башлык та—оештыру коралы. Чөнки болар, килү белән, күренеклерәк, сүзен батырып әйтердәй шәхесләрне эзәрлекләү һәм көчләре җиткән очракта куу, озату хәстәренә керешеп, үзләренә тапшырылган биләмәне фәһемсезләндерү бурычын үтиләр.

...Латин хәрефләрен куллануны тыю, Башкортстанда, Уфа каласында төзелүче татар гимназиясен җимерүише карарларны кабул иткәндә телгә алынган үзәк сыман иҗтимагый оешмалар коткысы роль уйнавы да мөмкин. Путинның, русны тырмаштырсаң, татар килеп чыга, дигән сүзе дә «патриотлар»ның җен ачуын чыгарды. «Тырмаштыруга» ризасызлык белдереп язылган мәкалә дә күзгә чалынды телгә алынган газетаның шул ук санында. Гайсә пәйгамбәрнең «Не судите, да не судимы будете» дигән өйрәтмәсен үзгәртеп, «башкаларны тырмаштырмасагыз, үзегезне дә тырмамаслар» дигән кисәтү дә яңгырады хәтта. Кыскасы «патриотлар» туган халкының негрлардан башлануына да каршы түгел, ( бүгенге фән, беренче кеше кара тәнле африкалы булган дип раслый башлаган), Дарвинның, маймыл белән кардәшлек турындагы тәгълиматы да ярсытмый иде шикелле «ватанпәрвәрләрне», ә менә татар белән кардәшлек хакында ишетәселәре дә килми... Достоевский, Тургенев, Суворов, Кутузов, Булгаков, Гумилев һәм башка күп кенә даһиларның нәсел очы татарга чыгуын белмәмешкә салышуны хуп күрәләр.

Золым чишмә башын 1552 елдагы тар-мардан санарга күнеккәнбез.

Ә бит урыска татардан да якын кеше булырга тиеш түгел кебек. Алардан тәүге «индеецлар» өәләргә ниятләгән тәре йөртүче Тевтон орденын, 1252 елда Александр Невский, башында тәҗрибәле найон Нюврюй торган атлы татар корпусы ярдәмендә җиңүгә ирешә. Янә тәре йөртүчеләр тарафыннан басып алынган православие үзәге—руслар табынган Византия, 1261 нче елны Нугай морза яугирләре, ягъни татарлар тарафыннан азат ителеп, ауган православ дәүләтчек кабат торгызыла. (Төрекләр бу илне 1452дә яулап алалар, әмма ул җиңүдә татар яугирләре дәхеле юк.). Мин инде соңгы зур сугышлардагы татар батырлыкларын санап тормыйм.. Бүген, урыс дусты яки туганы юк татарны гомумән табып булмыйдыр да .

Соңгы елларда «Салтан патшалар», татарга каршы өзлексез яла ягучы, ыскытучы «Бабариха»ларга әллә ни ышанмый да башладылар шикелле. Ельцин һәм Путинның Сабан туе уеннарында катнашып, түбәтәй киеп йөрүләре татар күңеленә хуш килде һәм монда үзара мөнәсәбәтләр ачыклануда алга китеш булып алды диярге дә ярыйдыр. Югары урыннарга татарлар утыртылуы шулай ук начар фал түгел. Әле кайчан гына Татарстандагы эчке эшләр эргәсендә, кая ди сиңа министр посты, түбәнәгрәк урындыкларны да татар фамилияләләр әллә ни «иярли» алмый иде. Бүген хәтта Русия МВД министры—татар. Әле президент В. Путин, төрле ил журналистлары белән уздырган бер очрашуда «русны бераз арчысаң, татар килеп чыга» дигән әйтемне дә искә алды. Хәлбуки, Пушкинның Салтан патша турындагы әкиятен дә тагын бер кат укып чыгып, кайбер нәтиҗәләр ясау зыян итмәс...

Россия дәүләтчелеге сагында дим микән, әллә «Бабариха»лар вазифасында диярсәме, дәүләти структуралардан тыш һәртөрле иҗтимагый оешмалар эшләп торуы сер түгел. Шуларның алдарак телгә алынганы, әйткәнемчә «Эксперементаль Иҗади Үзәк «(Кургинян Үзәге) дип атала һәм аның эзләнүләре Россия патриотик

мәгълүмат чараларында дөнья да күрә. Сергей һәм Ирина Кургинян, Мария Маниконян һәм башка аналитиклар язган әтрафлы мәкаләләр сискәнергә мәҗбүр итә.

«Үзәк» үткәргән фикергә ышансак, элек СССРга, ә хәзер Русиягә каршы АКШ һәм Көнбатыш тарафыннан «оештыру коралы» (оргоружие) кулланып «оештыру сугышы» (оргвойна) алып барыла. АКШны яклап бәхәскә керү ниятем юк, һәм мондый адвокатка андый илнең мохтаҗлыгы да шуның кадәр генәдер, әмма Ирина Кургиняның Россиядәге мазлум халыкларга, шул исәптән татарга карата да русларны шомландырырлык фикерләр уздыруы күңелдә рәхмәт хисләре уятмый.

Регионнарны эреләндерү сәясәте кысаларында ( бәлки сылтавы белән дию урынлырактыр?) Адыгеяне Краснодар краена кушуга адыг халкының каршы чыгуы, аңа барча чиркәс бердәмлеге теләктәшлек күрсәтеп, Адыг, Кабарда, Чиркәс һәм Шәпсуг халыкларының уртак илен тарихи чикләрдә торгызуны таләп иткән үз планнарын тәкъдим итүләре авторга ошамый. Дөньякүләм халыкара оешмаларның бу мәсьәләдә үз мөнәсәбәтләрен белдерүләре, ә фикерләрен нигезләү максатында, «Басып алынган халыклар турында Декларация» дигән «кортканы» яңадан яктыга тартып чыгаруларына да (Ирина ханым халыкара документка карата шундый метафора куллана) автор риза-бәхил түгел.

Кургинян ханымны Финляндиядә, 1947 елны тартып алынган биләмәләрне кире кайтару хакында әңгәмәләр корыла башлавы, һәм 1990 елдан бирле әлеге илнең фин-угор халыклары удмурт, мари, мордва белән багланышларда булуы да хафага сала. Күрәсең, әлеге хадимә, телгә алынган, телләре, мәдәниятләре яшәү белән үлем арасында тыпырчынган халыкларга кабынган бердәндер өмет нурын да күпсенә...

Хәтта халыкара шәһәрләр һәм җирле үзидарә хакимиятләр бердәмлеге «ХАБИТАТ» дигән оешманың Евроазия үзәге Казанда берегеп, аңа башта Камил Исхаков, ә соңра Ильсур Метшинның җитәкче булып билгеләнүенә дә ханым борчылуын әйтә, аныңча, Мәскәү—Казан арасындагы киеренкелекне мондый оешмалар җайга салуны күз уңында тотмаячак икән...

Аның укларыннан руслар да коры калмый. Әйтик публицист Вадим Штепаның, Мәскәүне рус шәһәрләрен берләштерүче буларак катгый рәвештә кире кагуын һәм аның урынына яңа үзәкләр, Бөек Новгород, Себерне тәкъдим итүен Кургинян ханым нечкә диверсия дип бәһали...

Сергей Кургинян исә мәкаләсендә җәмгыять һәм дәүләтнең үтә катлаулы система булуын ассызыклап, аларны оештыру коралы ярдәмендә җимерү ысулларын (какшату, тирбәтеп тигезлегеннән яздыру, яньчү, элементларен бозу һ. б.) тәсфилләп тәгаенли, катлаулы билгеләмәләргә, аныклауларга бай язмасы фәннилеккә дәгъва итә.

Мин фәкыйрь, үземнең кара акылым белән, теләсә нинди системаны туздыру, туктату, зарарлау яки тулаем сафтан чыгару гамәлләрен, үз эш тәҗрибәләренә таянып—табиб, сантехник яки шофер да гадирәк телдә һәм үтемлерәк мисаллар ярдәмендә аңлата алыр иде дип чамалыйм. Ә инде көтүче бу эшкә алынса, бер алама сыерның бөтен көтүне пычратырга сәләте турындагы татар халык мәкаленә таянасын көт тә тор...

Озын сүзнең кыскасы, әгәр иҗади үзәк тараткан фикерләрне кабул итсәк, СССРны үз гражданнарын көндәлек икмәк һәм сөт белән тәэмин итүне җайга салырлык сәләте дә калмаган, акыллары сусәргән «алама сыерлар» түгел, ә мәгълүмати-психологик сугыш алып барган тышкы дошманнар һәм ил эчендәге бишенче колонна харап иткән булып чыга...Соңгысына, Ирина ханым Кургинян телгә алган халыклар, шул исәптән без фәкыйрьләр дә кермибез микән әле?..

Хәлбуки, СССР чорында бер төрле (коммунизм тәэсүгә өндәп), хәзер икенчеләй (теле-әрҗәдән криминал, эротика, мәзәкчеләр күрсәтеп, мөселман яугирләрен үзенчәлекле тасвирлап һәм шәп киенү, шәп ашау, шәп ял итү, байлык туплауга кызыктырып) «оештыру кораллары» дәүләтебез тарафыннан үз халкына карата тын да алмаслык дәрәҗәдә кулланылды һәм кулланыла шикелле... Хәтта, милләтнең йөз аклыгына дәгъва итүче татар әдәби журналларда да җенси мөнәсәбәтләрне тасвирлау үзәккә куела башлады. Өметле бер авторның «Казан утлары» журналында 2006 елның 9 санында чыккан «Күкләр никахы» хикәясе генә ни тора! Әсәр герое , хатыны бар, улы күптән түгел туган яшь имамның бер кызга күзе төшә. Теге кыз Коръән укырга өйрәнергә бүтән талибәләр белән бергә

әлеге остазда укый башлый. (Туташларны абыстайлар укыта торган иде?) һәм бу икәү, мәчеттә, җомга көнне, җомга намазының сөннәте укылган чорда, дин сабагы өйрәнү бүлмәсендә, аулакта калып( балигъ ир-атка хәләле булмаган хатын кыз белән аулакта калуны ислам дине катгыян тыя), Изге китап укыган җирдән бүленеп, зина кылалар?!... Автор да, хикәянең янә бер герое—мәчет карты да моны мәхәббәткә чыгара.. Хикәянең исемен кат-кат укыдым, «Күкләр никахы», әгәр хәреф хатасы китмәгән булса...

Бәлкем, АКШ оештыру коралы уңышының сере—үзебезнекеләрнең артыграк тырышып, халкыбыз аңын тәмам тондырып бетерүләре аркасындадыр? Яки безгә карата кулланылган примитив һәм тупас чараларны чит-ятларга, яулап алынмаган шартларда, көчләүсез тагып булмавын үз «җитештерүчеләребез» таныйсылары килмидер һәм АКШны гаепләү ихтыяҗы шуннан туадыр? Янә килеп әлеге үзәк кабартып тасвирлаган, үзебездә җитештерелгән, тәҗелләрдән тәҗел аракы атлы оештыру коралының илебез халкы өчен мең тапкыр куркынычрак һәм нәтиҗәлерәк булуын танудан да, ихтимал, качасыбыз килә торгандыр?

Система дигәч, мәктәптә, астрономия дәресендә хәтергә уелып калган «Кояш системасы» дигән төшенчә искә төшә. Ул системаның үзәге-төше—Кояш үзе. Димәк, әлеге системаны юк итүнең иң туры юлы—Кояшка һөҗүм. 11нче гасырда яшәгән бөек Шәрекъ философы әл-Газали фикеренчә, иң югары күрү сәләтенә күз түгел, чөнки ул предметларны тыштан гына иңли, асылына үтми, ә акыл ия. Ә Кеше акылы өчен Кояш, әл-Газали фикеренчә, Коръән.

Чорлар дәвамында лашманчылыкта имгәтеп нәселен корыту, төрмәләрдә черетү, ачлык золымына һәм атом афәтләренә дучар итүләр, бетмәс-төкәнмәс сугышларда пушка ите сыйфатында файдаланулар белән берряттән (рәхмәт, Кургинян үзегенә, әл-Газали фәһемләгән күзебезне дә ачкан өчен), безгә карата бертуктаусыз оештыру коралы кулланылып, оештыру сугышы да алып барылган лабаса... Тарих дәреслекләре дә шул «оештыру сугышы» арсеналындагы үтемле коралларның тәэсирләренә булып чыга. (Әгәр Россиядә дөрес тарих укыту әлегә мөмкин түгел икән, хакыйкый татар тарихы дәреслеген язып, татар яшәгән демократик илләрдә укыта башларга кирәшәседер, бәлки?)

...Халкыбызны юк итү өчен иң әвәле әнә шул алда телгә алган Кояшны сүндерү мәсьәләсе куелган. Аны Иван Грозный башлаган, ә большевиклар Лука Канашевичлардан да уздырып дәвам иткән. Шул максатта милләтебезне гарәп хәрефләреннән аерганнар, мулла-мөәзиннәрне юк иткәннәр, мәчет манаралары аударылган...

Аннары мәктәпләребез тар-мар ителгән. Татарныкы дигән бүгенге аз санлы мәктәпләр дә татарныкы ук түгел бит. Әгәр православие тарихы да укытыла башласа, хаклы рәвештә аларны керәшен мәктәпләре дип атау акылга муафыйк булачак.

Мәдрәсәләрне дөньяви фән укытылмаудан этенеп, гаепләү модага кергән заман булган. Тукай чорында бу тәнкыйть аларның сыйфатын тагын да яхшыртуны күздә тотса, большевиклар , шул тәнкыйтьләргә таянып, милли мәгарифебезне төкәндерүне алга сөргән. Ә мәдрәсәләр милләткә хезмәт иткән, татарга Садри Максуди, Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакый, Дәрдмәнд, Йосыф Акчура, Салих Сәйдәшев, Габдулла Тукай кебек гигантларны биргән.

Мәдрәсәләрдә нинди энҗе-мәрҗәнгә тиң гыйлемнәр укытылуына мисал итеп әл-Газалидан русчадан, үз тәрҗемәмдә, математик биремнәргә хаслап төзелгән сөйләннәрдән берсен китерәм һәм «солтан» сүзен чорыбызга турылап, җитәкче дип аңлап кабул итү мәслихәтлеген искәртәм:

« ...Бел һәм аңла, солтан, гаделлек урнашу акылның тулылыгыннан. Ә тулы акылга ия булу—димәк, әйберләрне ничек бар шулай күрү, асылына төшенү һәм тышкы кыяфәтенә алданып ялгышмау. Әйтик, әгәр син җирдәге тормышың хакына кешеләрне рәнҗетәсең икән, яшәвең максаты нәрсә икәнен аңларга тиешсең. Әгәр максатың тәмле ашау булса, бел, бу хайвани теләк, чөнки ашау-эчүдәге чамасызлык аларга хас. Әгәр максатың ефәк киемнәргә төренү икән, димәк син ир-ат кыяфәтендәге хатын-кыз, чөнки һәртөрле бизәнүләргә омтылу һәм җиңел акыллылык—аларга хас. Ә инде максатың бар ачуыңны дошманнарыңа түгү булса, син кеше кыяфәтендәге ерткычсың. Әгәренки кешеләрне үзеңә хезмәт иттерергә ирешмәкче икәнсең, димәк син акыллы булып кыланучы ахмак, чөнки акылың булган очракта белер идең: сиңа хезмәт итүчеләр чынлыкта үз теләкләре һәм корсакларының колы, һәм хакыйкатьтә аларның хезмәте һәм бил бөгүләре һич

тә сиңа түгел, ә үз-үзләренә. Шуңа да алар, синнән бүтән зат кулына хакимият көчүе хакында хәбәр ишетүгә үк, сиңа арка белән борылачак: алар динар һәм дирһәм китерүче теләсә нәрсәгә хезмәт итүчеләр, һәм мондый хезмәт—адәм көлкесе...»

Мәктәпләребездә шушындый гыйлемнәр укытылса, сыйфатыбыз үзгәрәк булып, авылны ,укытучыларны һәм милләтне бүгенгедәй авыр хәлгә калдырмаска зиһенебез-фәһемебез җитәр иде.

Дингә кайту акрын бара, диләр. Балта эшенә балта остасы, музыкага музыка белгече, спортка спорт остасы өйрәтә һәм шәкертләр уңышка ирешә. Дингә дә тирән белемле, иҗтиһатлы һәм абруйлы дин белгечләре өндәсә, аңлатса, әл Газали әйткән Кояшыбызны, шәт иншалла, табарбыз.

Әл Газали зиһене ирешкән хикмәтләрдән берсен булса да бәянләп китүне урынлы саныйм. Кяфер каберенә еланнар керә дигән риваятькә ышанып, кабер ачып, анда еланнар күрми аптыраучылардан ул көлә. Аныңча—гадәти, тышкы еланнарны куалап чыгару дөрес булыр иде. Тик еланнар дәһринең күңелендә мыжлый һәм алардан бер дөньяда да берничек тә котылу әмәле юк... Тәмугта да бер нинди дә ут янмый, анда килүче һәркем үз утын үз күңелендә үзе алып килә... Шулай аңлата Аурупа Альгазал дип таныган бөек дин белгече, атаклы суфи әл Газали...

Күренә ки, хәлебез мөшкел, әмма өметсез түгел... Чөнки, нинди генә кораллар куллансалар да, әл Газали тәгаенләгән Кояш ничек бар, шул хәлендә, хәрефе дә үзгәрмәгән... Аның яктысы һәм җылысына кабат тиенү өчен СССРда үткәрелгән сукырайту сәясәте нәтиҗәләреннән арынып, тернәкләнү, акылга килү өчен бүген, киртәләр калкытылып торуга карамастан, мөмкинлекләр дә юк түгел...

## Чемберленга бездән җавап

Инде килеп, янә дә яһүдләрне фаш итүче тагын бер документ—«Катехезис еврея в СССР» дигән кулланманың бәгъзе маддәләрен «гой» яки урыс урынына юри генә «татар», нацменга, ә яһүдне—руска, антисемитизмны милләтчелеккә алмаштырып, укып карыйк, нәрсә килеп чыгар икән? Рус телендә бирик.

*....Татары ( нацмены) не способны глубоко мыслить, анализировать и делать глубокие выводы. Они воспринимают все явления слишком поверхностно, слишком конкретно, они не видят факты в их последовательности, в их связях, они не способны думать, обобщать и абстрагироваться.*

*...Когда двое татар дерутся, выигрывает не татарин ....*

*...Татары (нацмены) глупы и грубы.Свою глупость и грубость они именуют честностью., порядочностью и принципами.*

*Из-за пустых принципов, они кончали жизнь самоубийством. Пусть они продолжают делать это!*

*Постоянно помните о пределах, которые ставят себе татары, их мышление—закорузло в этих пределах. Они не способны выйти из них.*

*Обвиняйте в национализме тех, кто пытается разоблачить вас.*

*Клейте им ярлык националистов и вы увидите, с каким удовольствием остальные подхватят эту версию.*

*Вообще то все татары—националисты, но, вы как только приклеите ярлык одному—он становится беззащитным, ибо все остальные кидают его нам в жертву и уничтожают своими руками.*

*Не разрушайте открыто памятников татарской старины, но и не восстанавливайте их. Пройдут годы, и они сами разрушаться. Делайте вид, что не замечаете этого, будучи заняты решением больших народнохозяйственных задач.*

*Народ без истории, как ребенок без родителей и из него можно вылепить все, что необходимо, вложить в него свое миропонимание, свой образ мыслей.*

*Таким способом могут быть обезличены целые народы; с начала они лишатся истории и традиций, а затем, мы формируем их по своему образу и подобию.*

*Вынуждайте их жениться на русских женщинах и только после этого, открывайте им «зеленую улицу»*

*Не бойтесь, их дети, все равно будут нашими, чей бы бычок не скакал, теленочек будет наш.*

*Ради своих детей, они потеряют свои «национальные» (заменено слово «гражданские») права, чувства и ум, во всяком случаи, не смогуть быть националистами.*

*Сожительство с русской женщиной—это один из способов вовлечения талантливых татар в сферу нашего влияния, наших интересов.*

*Берите себе в жены красивых и здоровых татарских женщин, пусть они принесут вам здоровое потомство, пусть улучшат нашу породу.*

*Итак, каждому перспективному татарину—русскую подружку или друга.*

*Главное обвинить. Пусть они оправдываются. Тот, кто оправдывается—уже наполовину виноват.*

*Мы должны действовать решительно и быстро, ставя их всегда перед свершимшимся фактом.*

*Пусть они,после этого, ведут долгие, бесплодные дискуссии, против наших методов у них нет оружия.*

*Пусть их сопротивление будет нам необходимым стимулом, но не тормозом.*

Әгәр бу «катехезис» безгә карата «иҗат»тан плагиат булмаган очракта да, безгә карата тулы куәтенә эшләве акылы камил бер генә милләттәшебездә дә шик уятмыйдыр... Һәм монысының да тамырлары фаразымдагы «Тәхет китабы»на ялгана шикелле. Катехезисның Израильдә дөнья күрүеннән берни дә үзгәрми, әлеге документны шундый эшләнештә матбугатта чыгару, Рәчәйнең бәгъзе көчләренә, рус түгел халыкларга карата эшләнгән яшерен документларыннан хәбардар булуларын үзенчәлекле белгертүләре, ирештерү дип тә гоманлап була...

Хуш, кайбер сорауларга өлешчә җавап табылды дип исәплик. Ә нәрсә эшләргә соң ?

Хак Тәгалә «саклангāнны саклармын» дигән... Ә безнең йомшак ягыбыз—«оборона» дигән төшенчәнең асылын аңышып бетермәвебездә кебек. Телебездә ул сүзнең төгәл тиңдәше юклыгы да тикмәгә түгелдер. Россия хәрби уку йортларында, тактика дәресләрендә оборона тотуны саклану әмәле генә түгел, ә көч туплап, әзерләнеп, дошманны тар-мар китерү чарасы дип укыталар. Үткән сугыштагы оборона—кеше һәм бигрәк тә техника узардай тигезлекләрне рәт-рәт мина кырлары, дот, дзотлар урнаштыру, окоплар казып җиргә иңүне күздә тотса, элек—борынгы чорларда руслар урманда үскән агачларны мәгълүм биеклектә кисеп аударып, «засека»лар (бездә окоп кына түгел, бу сүз дә юк) ясаган һәм мондый үтеп чыккысыз аударылышларның тирәнлеге калын массивларда кайчак алтмыш чакрымнаргача сузылган. Бары сазлыкларга кереп батар өчен юллар уңайланган.. Моннан тыш капкыннар, алдавыч чокырлар, поскыннар, «алтын бишек»ләр ясалган һәм баскынлык нияте яисә җавап явы белән килүчеләрне вак-вак отрядлар, даими талкып егәрләрен киметкән, көтелмәгән һөҗүм өстенлегеннән мәхрүм иткән. Яулану янаган Казанга коткару, ярдәм эстәп кая да булса юнәлергә ниятләгән илдәшләребез төркемнәре юлына шундыйлар аркылы төшкән. Казанга ярдәмгә атлыгучы кырым татар кардәшләребезне шундый обороначылар башта туктаткан, аннары чигенергә мәҗбүр иткән. Безне азат итү нияте белән кузгалган төрекләрне дә ихтимал, шундый токтарлыклар «суындыргандыр»... Әлеге дә баягы, тактика дәресләре: һөҗүм өчен гаскәр күп кирәк, ә оборона өчен аз, өч тапкыр кимрәк булса да җитә, дип өйрәтә алар.

Казанны алу максатында мәскәүләр иң әвәле ныгытмалар, саклану корылмалары торгыза. Иң хәллесе—татар авылы урнашкан Зөя ярында калка һәм тора бара Свияжск каласы булып аза. Казан аугач, баскынчылар Казан Кремленең җимерелгән диварларын мәңге алынмаслык итеп кабаттан ныгыту белән генә чикләнмичә, Тәтештә, Лаешта, бүтән юнәлешләрдә уннан артык кирмән торгызалар... «Смута» дип тарихка кергән, 16 гасыр башында, ягъни поляк баскыннары Россиягә ия булган заманда, Мәскәү Казан ягын «онытып» торырга мәҗбүр була. Әмма оборона корылмалары нык, безнекеләргә бер югалтканны кабат кайтарулар насыйп булмый. Әле аннан алда Кырым ханы Мәскәүне алып яндыра һәм талый. Әмма ул җиңү дә казанлыларга ирек китерми.

Рухи һөҗүмнәргә каршы да оборонаны кайгырту зарур... «Татар игосы» дип тамгаланган дәвердә руслар үзләренең рухи оборонасын ныгыталар, ягъни православие чиркәүләрен, монастырьларын күпме кирәк шулай үрчетәләр..

Аларга каршы бернинди тукынулар булмый. Шул рухи учакларда рус халкының рухи куәте артканнан-арта барып, Җир шарының алтыдан берен үзенеке итәрлек кодрәт туплана.

Явыз Иван Казанны алгач, Алтын Урда биләмәләрендә яшәп килгән диннәргә карата хөерхаһлы мөнәсәбәт тамырдан үзгәрә. Татарларны физик юк итүләр, бетмәс-төкәнмәс сугышларда пушка ите урынына файдаланулар, лашманчылыкта имгәтүләр өстенә, рухи җимерү, мәчет-мәдрәсәләрне, китапханәләрне туздыру, китапларны яндыру, һәм көчләп чукындыру сәясәте үткәрелә. Бабаларыбыз баш күтәргәләгән, рухи оборонаны ныгытуны шулай ук алга сөргән, ата-баба йоласын ташламаган, мөмкинлек туу белән мәчетләр төзегән, үз мәгарифен тергезгән. Совет чорында исә дәһриләндерү, милли милексез калдыру һәм әлифбаны төкәндерү аша милләткә каршы һөҗүм яңа көч-куәт ала. Брежнев заманында милли төбәкләргә интернациональ калалар калкытып, бөтенсоюз дәрәҗәсендә төрмә-колонияләр торгызып һәм әтрәк-әләмнәр ташкынына хут ачып, аларны җирләштереп милли рухны черетеп таркату кайгыртыла. Ә бүген шул шаукымлы афәт, мәктәпләрдән милли компонентны алып ташлау, православие турында дәресләр тагу һәм тарих китапларына безгә карата яңа ялалар ягуда чагылыш таба...Без чигенәбез дә чигенәбез... Ә оборона турында әз булса да кайгыртабызмы соң? Сабантуйларны «бөтен кеше белгән телдә», миллилектән ерак өстәмәләр белән бизәп бетерүебез дә һич безнең файдага түгел ләбаса...

Безне, «җирдә коны калмасын» дип кайгыртучы аяусыз көчнең тамырлары, әтрәк-әләм түрәләребез мисалында толерант булып маймылланмый гына кулны йөрәккә куеп әйткәндә, православиегә барып ялгана. Димәк оборона тоту өчен чара бер генә ул—Исламга кайту. Ансыз гына дәүләтчелеккә ирешсәк тә безнең тамырны хөмер, төрле бозыклыклар корытачак. Исламга кайтсак, дәүләтчелекне кайтара алмаган тәкъдирдә дә без исән калачакбыз. Динне торгызу өчен бәгъзеләргә кайбер батыр адымнар ясау кирәк. Бу адым күкрәк белән амбразура каплау ише генә түгел, ә Данконың йөрәген күкрәгеннән умырып алып факел итеп кешеләрне яктылыкка алып чыгуына тиң гамәл. Без—Алтын Урда халкы дәвамчылары, хәрби тәртипләргә буйсыну, субординация саклау—каныбызда. Әйтик, район башлыгы мәчеткә йөри башласа, шундый үрнәк күрсәтсә, шул төбәктә аңа ияручеләр, рияданмы, ихластанмы, күбәер иде.

Ислам динен кабул иткәндә халык башчыларына ияргән. Димәк, аңа кайту әмәле билгеле.. Әмма район башлыгы субординацияне боза алмый. Фальстарт булып аңлаячак аны күпчелек. Уңыш мулдан булсын өчен башта бу адымны иң мөхтәрәм зат—заманында без үзебез бертавыштан сайлаган кеше, президент ясарга тиеш. Кайсыдыр газетада кемдер, коткарса безне Шәймиев коткарачак дип язган, ә ничек коткарачагын ачыкламаган иде. Миңа калса экспрезидент һәм хәзерге президентыбыз җомгага йөри башласа, халкыбыз кыргыйлыктан чыгып, мәдәниятлелеккә зур алгарыш кичерәчәк... Бәгъзеләр, бу юлларны укып, әлләкемнәргә дә нишләргә кирәклеген хәл итә башлаган бу Зарипов, дип көлемсерәр. Әмма бу күрсәтмә түгел, ә шушы юнәлештә җөмһүрияттә барган житди эшләрнең логик чишелешен күзаллау гына. Җитәкчеләр тарафыннан бу юнәлештә эшләнгән эшләрне һәркем күрә һәм таныйдыр дип уйлыйм.. Ленинның «Бетерсә безне бюрократия бетерәчәк» дигәнен чак кына үзгәртсәк, «Бетерсә безне әтрәк-әләмлек бетерәчәк» дигән кисәтү тукыла... Исламга кайтсак, бөек ислам мәдәниятенә кабат ирешәчәкбез һәм әтрәк-әләмлек чигенәчәк... Чигенсен, коны калмасын...

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Кичке Таң

Татарстан авылларының атамалары гадәттә күптәнге чорларга барып тоташа. Ләкин вакытлар үтеп аларның әйтелеше һәм язылышы шактый үзгәрә. Әгерже районында Баржы суы буена урнашкан Кичке Таң авылы шушындый атамалар исәбенә керә. Авыл район үзәге Әгерже шәһәреннән 70 чакрым ераклыкта утырган.

Русча ул төрле чыганакта төрлечә: Кичкетан, Кичке Тан язылышында бирелгән. Ләкин таң бервакытта да кич белән атмый. Атаманы халык матуррак янгырашка яраклаштырган һәм Кичке Таң барлыкка килгән. Бу очракта яна атама борынгылыкны, тарихилыкны каплап тора.

Кичке Таң авылы табигатьнең матур урынына утырган. Янынnan Баржы суы агып үтә. Аңа Ялгыз (Жангыз) елгасы килеп кушыла. Авыл һәм Баржы суы тирә-юнендә күлләр, чишмә-чыганаклар, буалар һәм башка географик берәмлекләр сибелгән.

Халкыбызның үсешен уйдан үткәргәч һәм фонетик үзгәрешләрне күзаллаганнан соң, атаманың ни аңлатуы турында фикер кузгатырга мөмкин. Үзебезнең җирлектәге һәм илебездәге авыл атамаларының күбесе «Олы» һәм «Кече» аергычлары белән ясалган, мәсәлән, Олы Нырсы, Кече Нырсы, Олы Елга, Кече Елга һ. б. Кичке Таң атамасы да кайчандыр шушы нигездә ясалган. Ләкин фонетик үзгәрешләр кичерүе нәтиҗәсендә «Кече» («Кечек») сүзе «Кичке»гә үзгәреп киткән. Ләкин Олы Тан исемле авыл юк. «Олы»сы булмыйча (яисә бетеп) «Кече» аергычы белән авыл аталган очраклар башка җирлекләрдә дә күзәтелә. Андый мисаллар Түбән Новгород өлкәсендәге авыллар арасында да очрый. Монда Кече Пожар исемле авыл бар, ә Олы Пожар авылы юк. Кичке Таң атамасының беренче, аергыч өлеше «Кече» («Кечек») булса, икенче кисәге кыпчакларның бер кабиләсе этнонимы «Котан»га барып тоташа. Димәк, авыл атамасы «Кече Котан»нан «Кичке Тан» булып үзгәргән дип әйтергә мөмкин. Шуны да ассызыклап үтәргә кирәк, бу төбәктә, һәм гомумән, җөмһүриятебездә, Урта Идел, Урал буйларында һ. б. урыннарда кыпчакларга нисбәттән барлыкка килгән атамалар бу гына түгел, тагын да бар. Татарларда «Котан» этнонимы кеше исеме буларак та ныгып калган. Димәк, татар халкының этник составында кыпчакларның котан кабиләләре дә урын алган. Фәнни әдәбиятта «Котан» исеменең мәгънәсе «бәхет» дип аңлатыла.

Татар халкы үзенең үсеш юлында күп төрле кабиләләр берләшүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Халкыбызның оешуы барышында аның составына һун, бәҗәнәк, угыз, кыпчак, нугай һ. б. кабилә-кавемнәр үтеп кергән. Аларның эзе исем-атамаларда

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

мәңгегә ныгып калган. Күргәнебезчә, авыл атамалары—үзе зур бер тарих. Аларны кирәккә-кирәкмәскә алмаштыруны туктату, ә тарихи ядкарь булган атамаларны кире кайтару зарури.

## Килдебәк

Килдебәк авылы Саба районында, район үзәге Байлар Сабасы авылыннан 8 чакрымда, Шәмәрдән тимер юл станциясеннән—30, якындагы пристань Балык Бистәсеннән 68 чакрымда урнашкан.

1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә күрсәтелгәнчә, Казниш суы ярына утырган авылның (Килдебәк) 116 хуҗалыгында 358 ир-ат һәм 401 хатын-кыз яшәгән. Мәчет эшләгән.

Олылар сөйләве буенча, моннан 400 еллар элек Килдебәк һәм Бирдебәк исемле туганнар шушы төбәккә килеп ике нигез корып урнашып калалар һәм авыл бүгенге көнгә кадәр туганнарның берсе исемен йөртә. Бу туганнар килгәнче Казниш-Казкаш елгасының югары һәм түбән агымнарында мари, ар халыклары яшәгән. Алар, нигездә, аучылык белән шөгыльләнгән. Авылның ике урынында зират бар. Аның берсен Изгеләр зираты дип атыйлар. Ул җирләрдә юл эшләре алып барганда кеше сөякләре, бизәнү әйберләре, көмеш беләзек, алка, калфак һ. б. табылган. Ләкин алар берсе дә бүгенге көнгә кадәр сакланмаганнар. Кеше сөякләре зурлыклары белән аерылып торганнар. Авылның түбән ягында мари зираты бар. Язгы ташу вакытында ярны су ашау нәтиҗәсендә бу урыннан кеше сөякләре чыккан.

Элек барлык җирләр, урманнар алпавыт һәм патшаныкы булып исәпләнгән. Тау як урман патша урманы була. Ә Туры як урман Лебедев фамилияле рус алпавытыныкы исәпләнгән. Соңыннан Лебедев урманны һәм утарын Кукмарадан итек фабрикасы хуҗасы Комаровка сатып китә.

Патша һәм алпавыт урманыннан бер чыбык алырга да рөхсәт ителми. Патша урманының идарәсе хәзерге Лесхоз бистәсендә була.

Элек җир 18 елга бер тапкыр ирләргә генә бирелә торган була. Җир өләшкәндә җирәбә салганнар. Бер иргә бер имана җир тия, ул 70 сутый була. 18 ел буена ир бала туса да, аңа җир бирелми. Гаиләдә ирләре булмаса, алар җирсез кала һәм алпавыт Комаровка ялланып эшләргә мәҗбүр булалар.

1917 елда алпавыт Комаровның җирләре тартып алына, крәстиәннәр аны үзара бүлешәләр, ә утарын яндыралар.

1941 елда авылдан сугышка 165 кеше китә, авылда карт-коры, хатын-кыз һәм бала-чага гына кала. Атларны, тракторларны һәм арбаларны да сугышка алып китәләр. Күп җирләр сөрелми кала, чәчелгән җирләрнең дә уңышы бик түбән була. Хезмәт көненә 200—300 грамм икмәк бирәләр. Күп кенә балалар, картлар ачыгалар, икмәк күрмиләр. Кибетләрдә сатып алырга тоз, шырпы кебек нәрсәләр дә булмый.

Авылны икегә аерып торучы зур гына чокыр, коры елга бар. Аның башлангыч өлеше Шәкүр елгасы, ә азагы Җәләли тавы дип атала. Моннан 30 еллар элек бирелдәге агачлар куе урманны хәтерләткән. Ләкин аларның күбесен давыл аударып бетергән. Анда агачлар хәзер дә күп. Бигрәк тә Пәри тамагы дип аталган елга буенда юан-юан нарат һәм чыршы агачлары үсә. Исеменнән үк күренгәнчә, бу елга шомлы булып тора. Ул Казкаш суына килеп тоташа.

## Карлы

Карлы авылы Буа районында, район үзәге Буа шәһәреннән 3, Тәтеш пристаненнән 45 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл тарихи белешмәләрдә Байбулат (Мещеряки) исеме белән бирелгән. Карлы суы ярына утырган бу авылның 66 хуҗалыгында 275 ир-ат һәм 282 хатын-кыз яшәгән, лашманчылар булганнар. Авылда мәчет эшләгән.

Олылар сөйләве буенча, Карлы авылы XVII йөзнең икенче яртысында нигезләнә. Авылның беренче кешеләре—патшага хезмәт итеп кайткан Байбулат Борисов һәм

аның якыннары—барысы 40 кеше була. Соңыннан алар янына атлы гаскәрдә хезмәт итеп кайтучылар килеп төпләнә. Авыл үсә һәм зурая.

1930 елда авылда колхоз оеша. Ана «Кызыл йолдыз» исеме бирелә. 1898 елда авылда ике мәчет төзелә. Аларны беренче һәм икенче мәхәллә мәчетләре дип йөрткәннәр. 1936 елда аларның манаралары киселә. Шуннан соң мәчетнең берсе авыл советы һәм китапханә бинасы, икенчесе мәдәният йорты итеп файдаланыла.

Хәзерге вакытта авыл үз асылына кайта. Манарасы киселгән мәчеткә манара куелган, ае да беркетелгән. Авылның ике егете—Гайнәтуллин Фәнис һәм Әхмәтҗанов Фәһим авыл балаларына җәйге ял вакытында дин сабагы укыталар.

Авылда изге дип саналган һәм исемнәре хәзер дә халык телендә йөрүче истәлекле урыннар бар. Изге кизләү кечкенә генә калкулык битеннән тибеп чыккан саф сулы чишмә. Аны беренче тапкыр кем ачканы билгеле түгел. Читтән туган ягын сагынып кайткан һәр кеше анда барып баш ия, аның көмештәй саф суын авыз итә. Шунысы гаҗәп, җәй көне чишмә суы бик салкын, ә кышын аннан җылы пар бөркелеп тора. Изге кизләүне чистартып, карап һәм төзекләндереп торалар.

Кершән күле болын уртасында булган. Хәзер аның суы кипкән. Аның тарихы болай. Авыл кызлары болынга киләләр. Йөреп аргач, бу су янына бит-кулларын юарга киләләр. Су буенда утырган бер кызның кулындагы кершәне суга төшеп китә. Кыз кершәнне алам дип суга ташлана һәм батып үлә. Дус кызлары елашып кайтып китәләр. Ә кыз баткан җирне Кершән күле яисә Кызлар күле дип атап йөртә башлыйлар.

Авыл басуы тау-атауларга бай: Килә тау, Туры тау, Мәскәү тавы, Кызлар атавы, Мойка атавы, Күчән атавы, Озын атау һ. б.

Авылдан 500 метр ераклыкта урнашкан Купоннар зираты бар. Олылар сөйләвенә караганда, ул Столыпинның аграр реформасы башлану вакытына барып тоташа. Бу чорда Карлы авылы кешеләренә дә җир бүлеп бирәләр. Җирләре ерак булган кешеләр шул урында йорт-җир төзеп яши башлыйлар. Кырда эшләп йөрүче кешеләр яныннан үтеп барган юлаучы аларның кем икәнлекләре белән кызыксына. Эшләүчеләр: «Без купонлылар»,—дип, бирелгән купоннарын күрсәтәләр. Шуннан соң бу авыл кешеләрен «купонлылар» дип, ә авылны «Купон» дип атый башлыйлар. Күпмедер вакыттан соң Купон авылы халкы янадан Карлыга кайтып урнаша. Хәзер Купон авылы җирләрендә ашлык үсә, ә зираты тимер рәшәткә белән уратып алынган.

Карлы суының уңъяк яры буйлап тирән чокыр казылган булган. Анда Глухая һәм Проезжая дип аталган ике манара торган. Бу ныгытмаларның калдыклары берничә гасырлар буе сакланып килгән. Аның өелеп торган туфрагын, сузылып яткан агачларын әле алтмышынчы елларда да күрергә мөмкин булган.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# К

**КОЛМӨХӘММӘД** ибне Солтанбәк әл-Болгари (1775, Орунбург губ., Эстәрлетамак өязе, Түбән Карамалы а.—1845, Оренбург губ., Эстәрлетамак өязе, Кормантау а.), шагыйрь. Татар һәм фарсы телендә яза. Казан губ. Казан өязе Иске Ашыт а. мәдрәсәсендә укый. Казан губ. Мамадыш өязе Югары Ошма (1803-30), Ак чишмә (1810), Ольяз (1815) авылларында имам булып тора. 1830 да Оренбург губ. күчә, Кормантау а. мәдрәсәсендә укыта. «Нәсыйхәте шәһре Казан» (фарсы телендә), «Мөһимматес сыйбъян» («Сабыйларның бурычлары», 1810), «Тәгърифел вилдан» («Балалар турында», 1815) исемле нәсихәт б-н сугарылган шигырь һәм поэмалар авторы. Әсәрләрендә әхлаки-фәлсәфи проблемалар, тәрбия, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр мәсьәләләрен күтәрә. Лирик шигырьләр циклын яза (бүгенгә табылмаган). К.нең иҗатын М.И.Әхмәтҗанов, Г.Н.Зәйниева өйрәнә.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том; Әхмәтҗанов М.И. Татар кульязма китабы. К., 2000; Зәйниева Г.Н. Шагыйрь Кол Мөхәммәд тормышына караган яна мәгълүматлар (XVIII йөз ахыры—XIX йөз башы) // Тел, әдәбият һәм халык иҗаты мәсьәләләре. К., 2002. 2 чыг.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**КОМЕДИЯ** (грек. komodia—шат халык төркеме һәм oide—җыр), хәрәкәт, конфликт, характерлар юмористик һәм сатирик формада күрсәтелгән, ахыры мәҗбүри рәвештә бәхетле итеп тәмамланырга тиеш булган драма жанры. К. шыксызлыктан көлеп, чынбарлыкны комик категориядән чыгып чагылдыра. К.нең персонажы, көлкеле ситуациягә эләгеп, үзен фаш итә. Бер төрле К.ләрдә тискәре геройга каршы уңай герой тора, икенчеләрендә автор идеяләре функциясен көлке үти.

К. жанры татар әдәбиятында халык уеннарына, йолаларга, бәйрәмнәргә, фольклор әсәрләренә барып тоташа. Ш.у. аның үсешенә «театрлаштырган уеннар» сюжетлары («Мәҗмугыль—хикайәт», «Мен дә бер төн»), диалогларга корылган дастаннар («Бүз егет», «Таһир белән Зөһрә»), төрекмән, әрмән, әзәрбайҗан әдәбияты әсәрләре дә сизелерлек йогынты ясаган. Мөстәкыйль жанр буларак, К. татар әдәбиятында 19 йөз ахыры—20 йөз башында формалаша; бу процесска рус һәм көнбатыш—Европа әдәбияты һәм театры нык тәэсир итә. Төрек һәм рус телләреннән тәрҗемә ителгән К.ләрдә («Хөсет бабай», «Комедия Чистайда») артта калганлык көлү объекты була, белемгә омтылу, әхлаклылык хуплана, барлык кешеләрнең тигезлеге идеясе тәкрарлана. Г.Камал («Беренче театр», «Бүләк өчен», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре»), Г.Исхакый («Җәмгыять», «Кыямәт»), И.Багданов («Помада мәсьәләсе»), С.Рәмиев («Низамлы мәдрәсә»), Ш.Камал («Хаҗи әфәнде өйләнә»), К.Тинчурин («Көйсез кияү») һ.б. иҗатында К. аеруча киң гәүдәләнеш таба. Г.Камал, Г.Исхакый К.ләрендә халыкның көлке традициясе торгызыла, замананың милли сатирик типлары тудырыла («Банкрот»та Сираҗетдин, «Беренче театр»да Хәмзә бай, «Җәмгыять»тә Муса мирза, «Кыямәт»тә Шаһияздан бай), әхлак, социаль, милли мәсьәләләр, тормышның югары һәм түбән яклары бер-берсе б-н тыгыз бәйләнештә тора. 1920-30 нчы еллар К.сен 3 төргә бүләләр: беренчеләрендә ирония ярдәмендә үткән заманнар һәм вакыйгалардан, буржуазия вәкилләреннән (Н.Исәнбәтнең «Хиҗрәт»е, К.Әмиринең «Печән базары»), икенчеләрендә—яңа тормышта үз урыннарын таба алмыйча, үткән заманның кире кайтуы турында хыялланучы, гомерен «җәмгыять өчен» мәгънәсез кайнашуда уздыра торганлардан (К.Тинчуринның «Американ»ы), өченчеләрендә—җәмгыять тормышының бюрократизмы, эш урынын шәхси мәнфәгатьләр өчен файдалану өше күләгәле якларыннан (К.Тинчуринның «Хикмәтле доклад»ы, Н.Исәнбәтнең «Портфел»е) көләләр. Ләкин тулаем алганда бу К.ләргә замананың актуаль мәсьәләләреннән читләшү, вульгар со-

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынан басылып килә.*

циологизм принципларын гәүдәләндерү хас. Г.Исхакыйның «Жан Баевич» пьесасында фарс элементлары да бар. 1930 нчы еллар репрессияләре жанр үсешенә тискәре тәэсир ясый. Бөек Ватан сугышы елларында фольклор сюжетына таянып язылган пьеса (Н.Исәнбәтнең «Жирән Чичән белән Карачәч сылу»ы) аеруча иҗтимагый-мәдәни яңгыраш алды. Сугыштан соңгы елларда К. әхлакый эзләнүләр юлында үсте, ләкин совет әдәбият белемендә тамыр җәйгән «конфликтсызлык теориясе» ул елларда язылган пьесаларда үз йогынтысын сиздерде һәм К. үсешен тоткарлады. Язучыларның хөкем сөргән идеология таләпләренә буйсынуы К.не мораль уку б-н мавыгуга, конфликтларның җиңел чишелүенә китерде. Ш.у. вакытта—карьеризмга, эгоизмга, бюрократиягә, артта калганлыкка каршы чыгучы яңа фронтовик геройның тууы жанрны бераз җанландырды, көнкүреш водевильләр язылуга сәбәп булды (Ш.Хөсәеновнең «Профессор кияве», Р.Ишморатның «Директор хатыны», Н.Исәнбәтнең «Зифа»сы, Г.Насрыйның «Яшел эшләпә»се). 1960 нчы еллар «Хрущёв җепшеге» К.дә халыкчанлык традициясен торгызды. Замана героена игътибар арта, пьесалардагы конфликт реаль характер ала. Жанрны сизелерлек итеп баеткан яңа төр водевиль (Х.Вахитның «Күк капусы ачылса»), көнкүреш К. (Ю.Әминевнең «Әй әшнәләр, әшнәләр»), трагикомедия (Ш.Хөсәеновнең «Зөбәйдә—адәм баласы») язылa. Көнкүреш К.се һәм драма синтезы үрнәге булып Т.Миңнуллинның «Нигез ташлары» һәм Ю.Әминевнең «Сатучылар» пьесалары тора. Көн кадагына куелган әхлакый проблемаларны күтәрү, замандашның рухи дөньясын аңларга тырышу комедия характерларына билгеле бер драматизм өстиләр һәм тамашачыга психологик тәэсирне көчәйтә иде. 1970 нче еллар эзләнүләре жанрлар синтезына, психологик аспектның тирәнәюенә, чынбарлыкны фәлсәфә тирәнлегендә аңлауга китерделәр. А.Гыйләҗевнең «Энгер-меңгер», Ю.Әминевнең «Кан кардәшләр», Ф.Садриевнең «Кондырлы кодачасы» пьесаларында көлү объекты булып көнкүрештәге ыгы-зыгылар, әхлаксызлык, гаделсезлек, артта калганлыклар тора. «Житди» (И.Юзеевнең «Сандугачлар килгән безгә»), «монсу» (Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр») К.ләр тудылар; музыкаль К. (Х.Вахитнең «Кияүләр»), водевиль (Т.Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү») үсеш ала. Идеологик басым арткан саен «ябык» темалар пәйда була, җәмгыятьнең социаль һәм сәяси мәсьәләләре әдәбияттан читтә кала тора. 1990 нчы еллар җәмгыятьтә барган үзгәрешләр нәтиҗәсендә К. активлаша төшә. Җәмгыятьтә туган сәяси һәм идеологик каршылыклар, хөкем сөргән әхлаксызлык, кеше рухы сынуы, карашлар тараюы, түрәләр алдында баш июләр К. объектына әверелә (З.Хәкимнең «Кишер басуы», «Мин төш күрдем»; Т.Миңнуллинның «Бәҗәй—хайван түгел, кәҗә—туган түгел»; М.Гыйләҗевнең «Баскетболист»; Ф.Яруллинның «Бер курешү—үзе бер гомер»; Д.Салиховның «Булса кодаң генерал» пьесалары). Чынбарлыкны сатирик рәвештә тасвирлауның яңа формалары, ысуллары һәм чаралары К.дә тематик һәм жанр ягыннан да чагылыш таба (лирик К.—Т.Миңнуллинның «Йөрәк маем»; сатирик К.—Д.Салиховның «Пуля»; музыкаль К.—Г.Каюмовның «Һинд кызы»; иҗтимагый К.—И.Юзеевнең «Безнең эти мировой», З.Хәкимнең «Чапты атым Казанга»; көнкүреш К.—Ф.Яруллин «Бер курешү—үзе бер гомер»; водевиль—Р.Батулланың «Сөйгән ярым ятка кала»).

Әд.: Ханзафаров Н.Г. Татарская комедия (истоки и развитие). К., 1996.

*Ә.М.Закиржанов.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Ринат Таҗетдинов



Актер, җәмәгать эшлеклесе Таҗетдинов Ринат Арифҗан улы 1938 елның 3 гыйнварында Чүпрәле районы Кече Чынлы авылында туа.

Мәскәүнең Щепкин исемендәге Югары театр училищесын тәмамлаганнан соң, 1961 елдан бирле–Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә. Драматик образның эчке дөньясы, рухи кичерешләрен, психологик халәтен ачу юнәлешендә зур уңышларга ирешкән актер.

Төп рольләре: Минлегали, Надир мәхдүм («Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», К. Тинчурин); Бәһави («Һиҗрәт». Н. Исәнбәт); Антоний («Антоний һәм Клеопатра», У. Шекспир); «Тартюф» («Суган суфие», Мольер); Ильяс («Гүзәлем әсәл», Ч. Айтматов); Мирвәли («Өч аршын җир», А. Гыйләҗев); Муса («Моңлы бер җыр», Т. Миңнуллин); Карандашев («Бирнәсез кыз», А. Островский) һәм башкалар.

Ул–ТАССР һәм РСФСРның халык артисты (1973, 1982). Татарстанның Тукай исемендәге (1967) һәм СССРның Дәүләт (1985) премияләре лауреаты. 1988 елдан–Татарстанның Театр эшлеклеләре берлеге рәисе.

## Хәйдәр Бигичев

*(1949—1998)*



Татар халкының атаклы җырчысы Бигичев Хәйдәр Габбас улы 1949 елның 16 июнендә Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь районы Чүмбәли авылында дөньяга килә.

1977 елдан–М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты (драматик тенор). 1979 елны Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаганнан соң театр сәхнәсендә аның иҗади эшчәнлеге, кабатланмас тавышының мөмкинлекләре өр-яңача биеклектә ачылып китә.

Төп партияләре: Җәлил («Җәлил», Н. Җиһанов); Хозе («Кармен». Ж. Бизе); Герман («Пики дамасы», П. Чайковский); Отелло («Отелло», Дж. Верди). Ул–ТАССРның халык (1986), РСФСРның атказанган артисты (1986), Татарстанның Г. Тукай исемендәге *Дәүләт бүләге лауреаты* (1984).

1998 елны Казанда вафат булды.

**Альфрет АБДРӘШИТОВ**

*Камил Кәримовка 60 яшь*

# АЛТЫДАГЫ АЛТМЫШТА...

*«Елганы кинәт туктатсаң—
ярларны җимерә...
Чабыш атын кинәт туктатсаң—
йөрәге ярыла. Һәм Фазыл да
бүген, йөк төялгән арбасыннан
тугарылып болынга куылган ат
кебегрәк...»*

К. Кәримов.
*(«Ком сәгате» романыннан.)*

**—Әгәр дә бик өлкән яшьтәге кешегә: «Камил Кәримовка 60 яшь тулган дисәләр, «ул шулай яшьмени әле»,—дияргә, ә яшьрәк кеше, киресенчә, «ул шулай картмыни инде?»,—дияргә мөмкин. Синең өчен 60 яшь нәрсә ул?**

—Үзем бик ашыгып яшәсәм дә, сонрак өлгердем. Кем өчендер, бәлки, картлыктыр, минем өчен исә—ир уртасы чагым. Зур-зур эшләрдән үземне чак-чак тыеп торам.

**—Хәзер халык китапны аз укый дибез. Син нигә язасың: укучы өченме яки язасың килгәннәнме?**

—Язасы килгәннән. Киләчәктә ябырылып укырлар дигән ялган хыял белән яшәмим, язмыйча булдыра алмыйм, гәрчә әдәбият тамагымны туйдырмаса да.

**—Беренче язманы 14 яшьтә яздым дисең. Әдәбиятка урау юллар аша килгәнсең...**

—Үземә нинди һөнәр кирәклеген тиз генә белә алмадым, эзләндем. Бәлки, озаграк эзләнгәнмендер...

**—Әгәр дә Синең турында фильм төшерсәләр: «Юк, бу елларны кертмибез»,—дип әйтерлек елларың бармы?**

—Балачагымны һәм соңгы 20 елымны кертер идем. Яшьлек елларын төшереп калдырыр идем, гел нужа, югалтулар... Ул елларда мин сагынырлык берни дә юк.

**—Син Язучылар союзында, «Чаян» һәм «Казан утлары» журналларында эшләгән язучы. Әдәбиятның бүгенге хәле һәм киләчәге турында нәрсә әйтә аласың?**

—Татар әдәбияты соңгы татар яшәгәнче яшәячәк.

**—Кайсы һөнәрең күңеленә иң якыны: сәхнәдәгесеме, әллә язучылыкмы?**

—Сәхнәдә мин үзем язган әсәрләрне сыныйм, анысы да минем өчен иҗат. Ул минем моңарчы тамагымны туйдырды, гаиләмне алып бардым.

**—Үзеңнең кайсы сыйфатларыңны балаларыңда күрергә теләр идең?**

—Оптимизмны. Хәзерге чор өчен бик тансык өмет ул. Физик эштән курыкмасыннар иде. Мин бу дөньяда һәр нәрсәне дә гел үзем эшлим дип яшәдем. Алай ук та кирәк түгел икән. Күбрәк табигать белән аралашып яшәсеннәр иде, мониторлардан аерылып.

**—«Уен» романының прототибы үзен таныган диләр. Үпкә белдермәдеме?**

—Беренчедән, бернинди прототибы юк, ул—җыелма образ. Мин бер генә артист турында яза алмыйм, аларның барысын да яратам. Кемдер үзен таный икән, мин моңа сөенәм генә. Димәк, образ белән укучыны ышандыра алганмын.

**—Озак еллар матбугатта эшләү дәверендә әсәрләрен кире борып, кул бирешмәслек дәрәҗәдә дошманлашкан кешеләрең бармы?**

—Алар бик күп. Үпкәлисе килгән кеше сәбәбен таба ул, гаепне әсәреннән түгел, башка кешедән эзли. Үпкәчел кешеләрнең шунысы да бар, үзләренең кеше кульязмасы белән эшләгәннәре юк аларның.



**—Сент Экзюпери әйтә: «Мине язганнарымнан эзләгез»,—ди. Сине әсәрләреңдә күреп буламы?**

—Кызганычка каршы мин язганда биографиямнән котыла алмыйм. Әле миңа биографиямне язасы да язасы. Һәр әсәремдә «Мин» бар.

**—Әсәрләрең вакыт сынавын уза алыр дип уйлыйсыңмы?**

—Шуңа омтылам да. Бүгенге көнне генә язар өчен журналист булу да җитә. Ә минем хыялым—зур язучы булу.

**—Син—татар язучысы. Тел, милләт, әдәбиятның киләчәге сагында торырга тиешле кеше. Үзеңнән кирәк дәрәҗәдә өлеш кертәм дип уйлыйсыңмы?**

—Кызганычка каршы диалектизмнардан котыла алмыйм. Әгәр дә инде мин авыл, саф татар телендә язам икән, димәк, өлеш кертәм дигән сүз. Шуңадыр, мине тәрҗемә итеп тә булмый.

**—Син дөньяны үртисеңме, дөнья синеме?**

—Без нинди дер пародияләр илендә яшибез. Үзебез җитәкче урында эшләмәгәч, гади халыкка читтән күбесе күренә. Мин халык белән бергә көләм. Халыкның көләсе килә, тешен кысып, курка-курка булса да көлә.

**—Туган авылың Шәле киңәя-киңәя олы юлга арты, абзарлары белән чыкты. Син аны дөньяга йөзе белән борырга теләмисеңме?**

—Миңа калса олы юлны Шәле артына салдылар. Аның үз йөзе уртада калсын инде, күрәсе килгән кеше эченә керсен.

**—Бу дөньяда нәрсәдән курkasың?**

—Кешеләрнең, җәмгыятьнең, сәясәтнең каты бәгырьлегеннән, ертлачлыгыннан куркам. Киләчәк буын өчен дә куркам. Җәмгыятьне баетабыз дип «кирәксез» кешеләрне күбәйттек. Бер миллионерга бер бомж туры килә бездә хәзер.

**—Чибәр хатын-кыз күрсәң синең күзләрең бии, сүзләрең бии, мыегыңның һәр бөртеге аерым-аерым бии башлый. Бу синең сокланулы табигый халәтеңме яисә кешеләр каршында артистлануыңмы?**

—Бу—минем табигый халәт. Әгәр кодрәтемнән килсә, җир йөзендәге бөтен хатын-кызны бәхетле итәр идем. Язучы булып китүем дә күзем төшеп йөргән кызны үземә каратасы килүдән башланды.

**—Элегрәк чит ил яки Мәскәү иҗат әһелләре турында тапшырулар караганда аларның тормыш-көнкүрешләрен, затлы йортларда яшәүләрен күреп гаҗәпләнә**

**идек. Хәзер исә үзебездә дә шулай яшәүчеләр юк түгел. Иҗатташ дусларының кайберләренең бай тормышын күргәч, күңелеңдә ризасызлык тумыймы?**

—Мина калса, байлык күбрәк хәрәм белән керә. Минем тормышым ул кадәр үк начар түгел. Әни гел: «Хәләл маллар насыйп итсен»,—дип тели иде. Әнинең теләге кабул булды, әниләр догасы зур әйбер ул.

**—Рус телен мәҗбүри өйрәнергә куйган кебек тагын берәр чит телне өйрәнергә кушсалар, кайсы телне сайлар идең?**

—Кытай теленә мөкиббән түгелмен, гәрчә халкы күп булса да. Немец теле бик сөйкемле түгел. Инглиз телендер.

**—Ни өчен?**

—Ул хәзер аралашу теленә әйләнеп бара. Хәтта үзебезнең түрәләр дә өйрәнә башлады. Ә алар киләчәкне бераз алдан күрә белә.

**—Бер китабың: «Үзеңне бел...» дип атала. Син үзеңне беләсеңме? Исемең җисемеңә туры киләме?**

—Гомереңең ярты юлына житкәч кешенең фәлсәфәсе үзгәрә. Мин үземне-үзем көзгедән танымый башладым. Үземә ни кирәген беләм, ләкин шуны ничек тормышка ашырасын белмим, тел белән аңлатып бетерә алмыйм. Язганда әкренләп үземне ачам. Моңарчы үземне бик гади кеше дип йөри идем, бик үк гади түгел икәнмен. Иң мөһиме—мин явыз кеше түгел.

**—Бер-ике ел элек Тукай премиясенә кандидатураңны куйдың. Синең өчен акчасымы, данымы кирәгрәк?**

—Бездә хәзер бит исеме булган кеше генә санда, хөрмәттә. Әлбәттә, исеме. Тик гомере буе бюджет системасында эшләгән кеше өчен акчасы да бик мөһим.

**—Әдәби җәмәгатьчелек синең иҗатка игътибарлы булдымы? Кайбер язучылар: «Мине күрмәделәр»,—дип үпкә белдерәләр...**

—Ул әдәби җәмәгатьчелекнең чын йөзен кем белгән бит әле. Күзгә-күз сөйләшкәндә мактыйлар, яшерен тавышка куйганда—киресенчә. Бездә гадәттә графоманнарны гына иркәлиләр. Мин бик иркәләнеп үсмәдем.

**—Иҗат кешеләренең күбесенә «вакытында картая белмәү» сыйфаты хас. Вакыт агышын үзеңдә сизәсеңме?**

—Минем вакыт үлчәме башкачарак. Әйткәнемчә, соң өлгердем, әкрен үсәм. Эшләнмәгән эшләр бик күп, шуңа күрә картлыктан бик куркам.

**—60 яшьтән соң Камил Кәримов нинди булачак?**

—Әле яңа гына «Игезәкләр йолдызлыгы» исемле роман тәмамладым. Бу—минем, мин яши торган йолдызлык. Шушы романны тәмамлау белән икенче әсәр сюжеты туды. Язучы буларак, димәк, әле яшәячәкмен. Мәйданнарга чыгып бил алышмасам да, иҗат, гаилә, мәхәббәт, саулык өчен көрәшә алырмын, Алла боерса!..

**—Безгә дә синең уңышларыңны күреп сөенергә язсын!**

*Әңгәмәдәш*—**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА.**

## Заһид Мәхмүдигә 50 яшь



Язучы, журналист Заһид Мәхмүди (Заһид Борис улы Мәхмүдов) 1960 елның 4 июлендә Татарстанның Кукмара районы Кукмара бистәсендә эшче гаиләсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт мәдәният институтында белем ала. Студент елларында көндәлек матбугатта актив язышa, «Чаян» журналында, «Идел» альманахында, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») һәм «Татарстан яшьләре» газеталарында дистәләгән юмористик һәм фантастик хикәяләрен бастыра.

1984 елда Совет армиясендә хезмәт итеп кайткач, ул Кукмара район газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли, иҗади эзләнүләрен дәвам иттерә, каләмен драматургиядә дә сынап карый: «Көнче күбәләк» исемле комедиясен яза. Әсәр 1989 елда «Безнең сәхнә» дигән күмәк җыентыкта дөнья күрә.

1988 елда Заһид Мәхмүди Казанга күчеп килә, 1991 елга кадәр Республика китап сөючеләр җәмгыятендә инструктор, Татарстан радиосында балалар тапшырулары мөхәррире, «Шәһри Казан» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1991 елда аның балалар өчен «Профессор Мияугөл» дигән фантастик хикәяләр җыентыгы басылып чыга.

1993-1998 елларда Заһид Мәхмүди «Татарстан» журналы, «Татар иле», «Мәдәни җомга» газеталары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, аннары, чыбыклы «Казан» радиосында мөстәкыйль татар бүлеге оештырып, бүлекнең җитәкчесе һәм дикторы булып эшли.

Бу елларда язучы әдәби иҗат эшчәнлеген дә гаять активлаштыра. «Тәмуг чәчәге», «Җен тыкрыгы», «Соңгы очрашу», «Имтихан», «Эзләмә» кебек хыялый-фәлсәфи әсәрләрен яза. 1999 елда әдипнең мажаралы кыйссалары һәм хикәяләре тупланган «Ак болыт» исемле күләмле китабы басыла. Китап Татарстанның матбугат, телерадиотапшырулар һәм гаммәви элемтә чаралары министрлыгы, Республика Милли китапханәсе оештырган «Ел китабы—1999» бәйгесендә II дәрәҗә дипломга лаек була. Язучының 2003 елда нәшер ителгән повестьлары, шигырьләре тупланган «Әче балан» исемле китабы да укучылар һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан җылы кабул ителә. Аның әсәрләре, әдәби тәнкыйтьнең гомум фикеренчә, үзенә генә хас иҗат ысулы һәм эзлекле милли рухта язылуы белән аерылып тора. Сатира-һәҗү, мажара, көлке, фәлсәфә, лирика—болар һәммәсе дә Заһид Мәхмүди әсәрләрендә бергә үрелеп, язучының беркемне дә кабатламаган үзенчәлекле стилен хасил итә.

2001 елдан ул «Татарстан» радиосында иҗтимагый-сәяси тапшырулар мөхәррире булып эшли, проза өлкәсендә дә иҗади тәҗрибәләрен уңышлы дәвам иттерә: 2005 елда «Казан утлары» журналында (№ 3,4) аның күләмле әсәре—«Һәркемнең үз юлы» дигән романы, ә 2006 елда «Идел» журналында (№ 8) «Ахырзаман» шаукымы» исемле бәяне дөнья күрә.

Соңгы елларда Заһид Мәхмүди «Шәһри Казан» газетасында эшләде, бүгенге көндә исә үзенең шәхси матбагасын ачып, «Күрәзә», «Себерке», «Гөнаһлы дөнья», «Серемне сиңа чишәм» дигән гәзитләр чыгара.

## Җәвад Тәрҗемановның тууына 90 ел

Җәвад Әфтахетдин улы Тәрҗеманов 1920 елның 8 июлендә Казан шәһәрендә дини гаиләдә дөньяга килә. 1938 елда Яңа бистәдәге татар урта мәктәбендә белем ала, аннан соң Казан дәүләт химия-технология институтының механика факультетын тәмамлый. Институтта уку белән беррәттән, Ватан сугышы елларында хәрби заводта станоклар көйләүче мастер һөнәрен дә башкара. Институтны тәмамлаганнан соң металлар технологиясе кафедрасында аспирантурага калдырыла. 1950 елда техник фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була, шушы ук кафедрада чирек гасырдан артык доцент булып эшли. Бер үк вакытта институтта чыгып килүче «Гыйльми язмалар» («Ученые записки») басмасының җаваплы сәркатибе һәм мөхәррире вазыйфаларын да башкара. Фән һәм техника өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ж. Тәрҗеманов 1981 елда «Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек була.

Әдәбият өлкәсендә исә Ж. Тәрҗеманов балалар язучысы буларак танылу ала. Беренче шигырьләре мәктәптә укыганда ук язылып 1935 елда «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында басылып чыга. 1938 елда «Галстук» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

Ул шулай ук балалар өчен язылган чәчмә әсәрләре—кыска хикәяләре, әкиятләре белән дә балаларның яраткан язучысына әйләнә. «Ябалак һәм Тавык» (1940), «Шуктуган» (1962), «Шаян белән Наян» (1965), «Көмешкойрык» (1967)—бүгенге заман балаларының да яраткан әкиятләре. Алар күп телләргә тәрҗемә ителеп аерым китап булып дөнья күргәннәр. Кайбер шигырьләре исә композиторлар тарафыннан көйгә дә салынып, балалар җыр сәнгатендә матур бер урын алып торалар.

Фән һәм техника өлкәсен яхшы белүе «Лобачевскийның яшьлеге» («Юность Лобачевского») исемле документаль романы тууга җирлек булып тора. Язучының тынгысыз хезмәте нәтиҗәсендә әлеге роман фактик материаллар белән тулыландырылып «Көмеш дага» (1971) романы дөньяга килә.

Ж. Тәрҗеманов публицистика, балалар драматургиясе, мемуар жанрында да актив эш алып бара. Шул уңайдан Татарстан китап нәшриятында 1980 елда «Ачкыч һәм баскыч» исемле китабы басылып чыга.

Ул—1947 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

1995 елның 9 мартында Казанда вафат була.

## Киләсе санда укыгыз

Журналыбызның 8 санында проза әсәрләреннән **Альберт Хәсәнов**нең «Данәгөл» романының ахыры, **Адлер Тимергалин**ның «Карурман аша» исемле хикәясе, **Туфан Миңнуллин**ның «Мулла» драмасы урын алган. Шигърият сөючеләрне **Роберт Миңнуллин, Нур Әхмәдиев, Айрат Суфиянов, Иделбика**нең яңа шигырьләре көтә.

8 санда **Батулла**ның «Азатлыкка таба» исемле публицистик язмасы, **Фирдәвес Хуҗин**ның «Күкләр шаһит» дигән истәлекләре дә укучыларга кызыклы булыр дип уйлыйбыз. Киләсе санда шулай ук «Авылларыбыз тарихы», «Татар энциклопедиясе битләреннән» сәхифәләре дәвам итәчәк, әдәбият елъязмасы булган «Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан», «Казан утлары» архивыннан» рубрикалары дөнья күрәчәк. «Ак җилкән» сәхифәсендә яшүсмерләрне мажаралы повесть-хикәяләр, шигырьләр, башка язмалар көтә.

*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!



Мин туганнан соң Җир Кояш тирәли 17 тапкыр әйләнеп өлгерде инде. Ә туусын мин Аксубай районының Иске Кыязлы авылында туганмын. Әле дә шунда яшәп,ягъни укып, өйдә эшләр эшләштереп,төрле хыялый уйлар уйлап ятмыш. Калганын шигырьләремнән белерсез.

**Алнур КАМАЛОВА**

***

Илһам—мизгел.
Тыныч түгел, бәргәләнә күңел.
Халәтемдә—җиһан үзе,
Кочмый калу мөмкин түгел.

Ашкынуым юкка түгел.
Ләззәт белән тулган касәм,
Әйдә, түгел,
        түгел,
            түгел...
Тусын шигырь йә җыр,
Ташымасын күңел,
Түгел,
    түгел!

Илһам—йөгәнсез ат.
Узар канатында.
Өлгерергә кирәк.
...Йөгәнләргә?!
Юк! Вакыт бик тар...

И җангынам, мең-мең рәхмәт,
Сүндерергә теләп,
Шул мәлеңә мандың—
Ә мин дөрләп яндым!

## Үҗәтлек

Алманы бит агачыннан ерак
        тәгәрәми диләр.
Тәгәрәдем менә.
Кавемем дә ишетмәгән җырның
Туган чагы миндә.

Сулар үргә таба беркайчан да
        ага алмый диләр.
Агам әле менә.
Ярларыннан ургып, җан-дәрьямның
Ташкан мәле миндә.

Бер киселгән икмәк телеме кире
ябышмыйдыр диләр.
Ялгаштырам менә.
Ялгыш кылган хаталарны бүген
Адаштырам җилдә.

Кайгы-сагышлардан йөзләр
саргаядыр диләр.
Саргаядыр, беләм...
Ә мин, татлы газапларга батып,
Алсуланам гелән!

## Татар кызы

Мин гади бер татар кызы үзем,
Кигәнем юк милли калфагым.
Такыялар үреп кыр гөленнән,
Хыялларны кочкан бер чагым.

Мин моңлы бер татар кызы үзем,
Чулпы чыңын тоймыйм толымда.
Эчтән генә көйләп «Әллүки»не,
Бәбкә саклыйм хәтфә болында.

Мин купшы бер татар кызы үзем,
Беләгемдә йөртмим беләзек.
Күңелем тулы ямьне, гүзәллекне
Бизәк итеп җиргә тезәрлек.

Мин шаян бер татар кызы үзем,
Читекләрем тормый шыгырдап.
Бию такмакларын ишетүгә
Табаннарым китә тыпырдап.

Мин серле бер татар кызы үзем,
Йөзгә тартмыйм яулык читемне.
Карашымны читкә ташлап кына,
Оялудан тыям битемне.

Мин хыялый татар кызы үзем,
Яңрар җырларның бер нотасы.
Болытларны этеп җир балкыткан
Уртак кояшның бер яктысы.

Мин кыю бер татар кызы үзем,
Милли моңым йөрәк түрендә.
Татарлыгым ята тамырымда,
Затлылыгым—әнкәм телендә!

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ СӘХӘБИ

### Мин шундый идем...

Белмим, сез минем кечкенә чагымны ничек күз алдына китерәсездер, әйтә алмыйм. Хәзерге кыяфәтемә, шөгыльемә, эшләгән урыныма карап, һичьюгында, карале бу Рафаэль Сәхәбиев шундый шук, шаян, тәртипсез булган икән дип уйларлык түгел. Чөнки, йөземдә зыялы караш, гәүдәм ыспай, һөнәрем—опера җырчысы, консерватория укытучысы! Мин үземне әллә нинди зур шәхес дип чутламыйм, ә шулай да... Һәрхәлдә, татар җыр сәнгатен сөючеләр мине таныйлар, беләләр, хөрмәт итәләр. Олы рәхмәт аларга! Ә менә яшьләргә, кайчандыр операда сәхнә тоткан җырчылар булганын белеп торсалар комачауламас иде. Бу—СССРның халык артисты Азат Аббасов, легендар Фәхри Насретдиновлар, сонрак буын—Хәйдәр Бигичевның (мин ир-зат җырчыларын гына санап үтәм), әле дә исән-саулары—Мөнир Якуповларны, Руслан Дәминовларны һәм без фәкыйрегезне... Мин үземнең бала чагымдагы кайбер ялгыш адымнарымны да һич яшерми язып бирергә булдым. Андый ялгышлыклар һәммәбездә булгалый, ләкин бу киләчәктә начар кеше булачаксың дигән сүз түгел әле. Бүтән кабатламаска өйрәнәсең икән, алар сине бары тик тәрбияләүчеләр генә...

### Тамак кипкәч

Миңа дүрт яшьләр булгандыр. Жыенга (Сабан туе алдыннан бер ай чамасы бәйрәм вакыты) әче бал куялар иде. Ул вакытларда әле хөкүмәт үз аракысы белән халыкны хәзерге кебек сыйламый, кибеттә дә шешәле шәраблар бу кадәр масаеп утырмыйлар иде. Һәркем кунаклар чакыра, ә кунакны чәй белән генә каршы алып, озатып булмый—«мәй» кирәк. Менә шул «мәй» мич башында чүмереп, матур гына җырлап утыра. Аны нәкъ Сабан туйларына өлгереп житәрдәй итеп куялар. Агач кисмәк , башында борыны. Әти көн саен тәмен татып карый, көчен, куәтен чамалый. «Их, тагын әзерәк торса!—дип иреннәрен чапылдатып куя. Тәмледер инде, чокыр төпләрен ялап ала бит. Икенче көнне тагын килә, бераз агызып ала: «Булгандыр инде, өлгергәндер, дия. Әллә сабан туй көненә өлгермәс дип курка, әллә бәрәңге утыртканда ял итәргә җай табып, чамалап керә. Әйе, бәрәңге утыртабыз. Әйтәм бит, мин әле бик кечкенә. Нәрсә беләм соң мин? Тәрәзәләр ачык, мин утыртучыларны күзәтәм. Тамагым кибеп китте. Тоттым да әти кружкасына теге кисмәктән шул «су»ны агызып эчеп куйдым. Рәхмәт! Шундый тәмле компот булып чыкты ул!

Калганын әнкәй сөйли: бер заман нишләп тавышы чыкмый соң бу баланың дип кереп карасам, син изрәп йоклап утырасың, ди. Сөялеп кенә.

Менә, җәмәгать, хәзер минем хәмер дегустациясендә осталыгымның кайчан башланганын белдегез инде.

### Чалбар үтүкләү

Без гаиләдә биш малай, бер кыз үстек. Шулай үскәнгә кызлар эшен дә үзем башкара идем. Беренче сыйныфка барган елны миңа вельвет чалбар алдылар, пиджаге дә шул материалдан иде. Чалбарын үземә үтүкләргә туры килде. Инде мин аны бөтен кануннарына туры китереп башкардым. Аннары сызгыра-җырлый ындыр артлап, тыкрыктан мәктәпкә юнәлдем. Чалбар шәп бит, күраләр микән? Кинәт күзем чалбарга төште: күрәм, аркылыга үтүкләгәнмен бит, сыры як-якка туры килгән. Ярый әле берәү дә күрмәде. Өйгә йөгердем. Тиз генә үтүкләп бирделәр.

## Һөнәр сайлыйм

Һәркем башыннан үтә торган нәрсәдер инде ул һөнәр сайлау. Кечкенә чагында әллә кемнәр булып бетәсе килә. Машина күрсәң—шофер буласы килә, трактор күрсәң—тракторчы, комбайнчы буласы килү дә үтте минем баштан. Мәктәптә укыганда минем клоун буласым килде. Шәп һөнәр бит—бөтенесен көлдерәсең. Аннан соң кинәт баянчы буласы килә башлады. Йөрәк сыза, их бер уйнап җибәрсәң, бөтен кызлар синеке булыр иде дим. Әйбәт музыкант булыр өчен нота белергә кирәк икән шул—авыр эш, миннән булмас. Бу хыялымнан өметемне өздем, ПТУга китеп бардым.

Әле бәләкәйрәк чагымда тракторларга, комбайннарга май ташучы булып урнашасым килеп киткән иде. Нигә дисезме? Безнең урамнан дегет арбасына утырып, калын тавышлы, авызына тәмәке капкан маржа апа үткәли иде. Их, мин әйтәм, шуның кебек тәмәке тартып барсан иде!.. Шул хәтле җайлы эш—атка: «На, малкай!—дип кенә әйтәсе бит. Арба артына тагылган дегет чиләкләренә хәтле күнелгә якын тоела башлады, минсинайтим!



Менә инде артист булынды. Җинел эш эзли-эзли килеп каптым. Моннан да авыр эш юктыр дөнья йөзләрендә!..

## Солдат булып алдым

Әле солдат буласы килүемне язмаганмын икән. Мәктәптә укыганда мин хәйран юан идем. Гәләфи киеп, солдат каешы буып йөрдем. Бишмәткә погоннар тагып саташтым. Бер вакыт, дәрес алдыннан каешны катырак тарттыруда ярышабыз. Мин җинәргә тиеш! Шул хәтле дә кысканмын бүксәне—каешны инде ычкындырып булмый! Тын кысылды. Агара башладым. Инде укытучы да керде. Берсенен дә гамендә дәрес юк—минем белән маташалар. Мине партага сузып салдылар, әчкә басып каешны ычкындырмак булалар. Инде «бетәм» дигәндә генә, ничек булгандыр ул, каеш ычкынып китте тәки. Ну көлделәр дә инде соңыннан, һәм журналга «2»ле дә чәпәлде әле.

## Әтине танымадым

Иң кечкенә вакытымның бер вакыйгасын хәтерлим. Минем әти бик оста артист иде. Алар бөтен укытучылар коллективы белән концертлар да, спектакльләр дә куялар, Яңа ел кичәләре дә уздыралар—бер сүз белән әйткәндә, әллә ниләр кыланалар иде. Хәтеремдә Яңа ел бәйрәме—чыршы кырыенда тезелешеп утырабыз. Кыш бабай килә дә берәребезнең исемен әйтеп, йә шигырь сөйлә әле ди, йә бие ди, җырла ди. Шул вакыт бу минем янга килде дә: «Әйдәле, Рафаэль, һөнәренне күрсәт әле!»—димәсенме? Мин куркып елап җибәрдем. Кыш бабай шунда, сакалын аска тартып, йөзен күрсәтте. Шаклар каттым—әти икән бит бу. Шуннан соң тынычландым инде.

Бәлки, шушы мизгел миңа артистлык тылсымын таныткандыр.

## Саңгырау

Беркөн әти белән әни кинога киттеләр. Без энекәш белән икәү өйдә калдык. Кино беткәч, болар кайтканнар, шакыйлар, шакыйлар, мин ишетмим икән. Бүселеп йоклаганмын.

«Рафаэль, Рафаэль!»—дип кычкыргач, исәрләнеп верандага чыкканмын, ләкин, нишләптер тагын кереп ятканмын.

—Рафаэль, ач улым!

Мин:

—Кем бар анда?—Тагын борылып киткәнмен. Инде ярты сәгать рәттән кычкырганнар. Әти балта алып өй почмагын төя башлаган:

—Рафаэль, Рафаэль!

Интегеп беткәннәр. Энекәш тә уянмаган бит, ичмасам.

—Нишлисең син, улым!—ди икән әти.—Үлдең мәллә?

Шуннан соң алар беркайчан да кинога бармадылар. Ә бит югыйсә булачак җырчының колагы яхшы ишетергә тиеш.

## Арка таба, кул урлый

Яшьләргә бер «этлек» өйрәтеп алыйм әле. Хәер, хәзер андый заман түгел инде. Кыяр урларга өйрәтмәкче идем. Аны кул белән капшап табып булмый, фонарь кабызып йөрергә дә ярамый, күрергә мөмкиннәр.

Без менә болай эшли идек. Кыяр түтәленә аркаң белән ятасың шунда, кай төшеңне нәрсәдер каезлый.—Кыяр дигәнең шул була инде. Рәхәтләнеп җыясың.



## Ат билендә

Юктан килеп чыкмагандыр инде ул бәләкәй чакта ук волокушага печән, салам төяп ат белән эскерткә тарттырулар. Атта йөрисе килү дә малай-шалайның бер хыялы иде инде ул. Жилдереп кенә ат өстендә төшке ашка кайту үзе бер могҗиза. Күрше Раиф бигрәк оста иде ат дигәндә. Йөгереп килә дә сикереп сыртына менә дә куна. Ә мин капка төбендәге утыргычка басып кына менә ала идем. Минем атның исеме «Липат». Шул хәтле куркак ат. Бер заман чаптырып барам, басудагы чөгендер чүмәләсеннән куркып шып туктады бу. Мин тимер сука кырыена мәтәлеп килеп төштем. Сукага эләккән булсам, Рафаэль Сәхәбиев дигән артистны белмәгән булыр идегез. Ходай Тәгалә саклаган.

## Дустым Толик

Безнең Шәңгәнче авылы уртасында бик тирән һәм киң буа бар иде. Андагы балык! Шунда бервакыт миннән олырак абыем Рафис белән бер тас балык тоттык. Кармакка. Бик соң кайтканга күрә, кичен чистартып маташмадык, өстенә кәгазь каплап, чоланда калдырдык. Иртән торсам—ике балык калган. Мәчеләр ташып бетергән. Әллә шуна күрә, мәче халкына хөрмәтем зур түгел. Этләр белән бик дус үзе. Безнең Сарбай белән Толик атлы этләребез бар иде. Аларга мин кышын чана тарттыра идем, җәен бергә каз көтәбез, балыкка барабыз. Толикны атып үтерделәр. Кем атканын беләм, хәзергә хәтле шул абыйга хөрмәтем юк. Аңлыйм да югыйсә, авылда чир таралган чак. Этләр тарата диделәр. Нишлим соң, Толикны җәллим. Ул бит ишек алдыннан да чыкмый иде, гел минем белән йөри иде.

Без аны дусларым белән авыл башындагы тау итәгенә күмдек. Кабере өстенә: «Монда ерткычларча үтерелгән Толик ята»—дип язып та куйган идек. Күп еллар үтте, әле һаман шул тау кырыеннан үткәндә Толикны искә алам.

## Яшәсен кунак кызлары

Мин, нигәдер, үзебезнең авыл кызларын яратмадым. Хәер, яратмадым дип әйтү дөрес тә түгелдер. Күз төшеп, акылдан шашып, аның өчен үләрдәй булып йөргәнем булмады. Кечерәк вакытта, яз җиткәч, яшел чирәм чыккан җирләрдә кызлар белән төрле уеннар уйнаштырадыр идек. Ул күбрәк малайлар уены була торган иде. Кайсыдыр кызны яклаштырыбрак маташсаң—елатканчы үртиләр, янәмәсе, мин аны яратам булып чыга. Ташаяк белән дә уйнадык, курчаклар белән дә. Үсә төшкәч, бераз борын астына мыек чалымнары сызылгач, бергәләп йөзек салышлы да уйнадык. Ничек әле?

*Зәй, Зәй, Зәйнәбем,*
*Атны кая бәйләдең?*
*Алмагачка бәйләдем.*
*Алма төште шап итеп,*
*Зәйнәп чыкты ялт итеп!*

Менә искә төште. Учларына йөзек салганны күтәреп утыручы кызлар, малайлар күз алдына килде. Берәүләре көенеп утыра, берәүләре сөенеп. Чөнки көенгәненә җә биергә, җә җырларга җәза бирелә, ә аның кулыннан бернәрсә дә килми, таланты юк. Сөенүчесе, кем йөзек салуына карап, куанып утыра. Их, мина салса иде ди. Бу фал аны яраталар дигән сүз дә бит әле. Малайлар йөзекне минем кем учына саласымны белеп торалар. Ул кызны сикереп чыкканчы ук тотып алалар. Исемен әйтмим. Инде байтак еллар үтсә дә, җә оялыр.

Ә менә кунакка кайткан кызлар өчен үлә идек. Ул ял көннәре җиткәнен көтеп кенә торабыз—шәһәрдән безнең авылныкыларга ияреп кызлар кайта. Сабан туйлары җиткәнне көтүне әйткән дә юк. Бер заман Мәскәүдән берәү кайтты. Ул аның гәүдәсе, йөрешләре, чибәрлеге. Шуның кулын гына тотып карасам да дөньяда миннән дә бәхетле кеше булмас кебек иде. Кулын тоттырды үзе—тән буйлап чымырдап кайнар ток йөгерде. Шунда көн тагын да ныграк эсселәнеп китте. Русчалы-татарчалы итеп бераз сөйләштек тә әле. Тик нәрсә турында сөйләшкәнне хәтерләмим. Мин үземне—«Рафаэль!» дидем, ул үзен—«Гөлсинә!»—диде. Без бүтән күрешмәдек. Ә ул сабантуй минем күнелдә иң шәп, иң матур бәйрәм булып истә калды. Мәхәббәт ул булса була, булмаса юк. Ул китте, бетте, дөньяда яшәүнең мәгънәсе җуелды.

Әй, кызлар бетмәгән лә! Күрше Разим белән шәһәрдән кайткан кызларны озатырга керештек. Бер кичкә өчәр кыз «озаткан» чаклар булды. Разим икене дисә, мин өч кыз дим, ул: «өч!»—дисә, мин «дүрт!»—дим. Нәрсә, телнең сөяге юк бит, сынмый. Минем баянда уйнарга өйрәнүем дә шул кызлар мина карамас микән дигән хыял белән бит инде. Кара мунчаларга кереп көне-төне шыгырдатуымның нәтиҗәсе хәйран булды. Кичке уеннарда, клубтагы «вечер»ларда мин идем инде баянда сыздырып уйнаучы. Тик файдасына караганда зыяны күбрәк шул. Ник дисән, кич буе уйнап утырасың, бер заман, инде таралышырга вакыт җитәрәк, кызлар капылт кына торалар да клубтан чыгып шылалар. Каласын шунда баяныңны кочаклап берьялгызың. Чыгуына егетләр кызларны өләләп бетергән булалар. Соңыннан мин дә җаен таптым тагын: уйнап утырам-утырам да, шалт итеп баянны эскәмиягә куям, ишек төбенә барам да басам. Кызлар күтәрелеп ишеккә килүгә үземә ошаганын эләктереп тә алам.

**Рафаэль СӘХӘБИЕВ**

---

## ИСЕМЕҢНЕ ДОГА КЕБЕК КАБАТЛАП ТУЕП БУЛМЫЙ

### КӨНДӘЛЕКТӘН БЕРНИЧӘ БИТ

*Кич җиттеме*
*Күңел елый,*
*Җаным елый*
*Сине сагнып.*

*Көн тудымы,*
*Күзем эзли,*
*Йөрәк эзли*
*Бары синең назлы карашны.*

**Беләм, без беркайчан да бергә булмабыз, ләкин йөрәгем моңа ышанмый. Бергә булырга өметләнә ул. Юк шул...**

**Бергә үткән көннәрнең, кичләрнең истәлеге күңелемне авырттыра. Алар мәңге онытылмас. Нигә шулай килеп чыкты соң бу?.. Елыйсым килә, бөтен дөньяны күз яшенә батырасым килә, ләкин күз яшем чыкмый.**

Көзге яфраклар кебек көннәр коела,көннәр янына атналар кушыла,шулай әкрен генә гомер үтә. Ә безнең юллар мәңгелеккә аерылган, аларны бергә тоташтырып булмый. Вакыт елга кебек—туктап тормый, үз агымы белән ага да ага.

Сине бөркет кебек күз алдына китерә идем,кояш кебек җылы,ай кебек якты идең. Җылылыгыңны, яктылыгыңны бүтәнгә бүләк иттең, синең канатың астында бүтән яши,бүтән синең күзләреңә карап туя алмый.

Язмышмы, әллә инде ялгышмы, яшь чак бигрәк җүләр чак шул. Тиз генә үйлыйсың да,аннары гомер буе үкенергә туры килә. Гомер буе үкенергә...

Безнең мәхәббәтне син аердың... Син аерылдың. Аңламадың шул мәхәббәт учагын сүндергәнеңне. Ләкин минем йөрәгемдә ул учак әле сүнмәгән, әкрен генә яна.

Әйтер сүзләр күп, әмма барсын да язып бетереп булмый. Күздән әкрен генә ике пар яшь бөртеге тәгәри, хәтта алар да мине аңлый алмый,чөнки алар икәү...

**9 сентябрь. 02.42.**

*Күңелдә өмет була—*
*Өметне өзеп була.*
*Сине күргән төшләрне дә*
*Сөйләми түзеп була.*
*Учка йомарлап йөрәкне,*
*Дәшмичә үтеп була.*
*Тик шашкан йөрәккә генә*
*Сөюне тыеп булмый.*
*Исемеңне дога кебек*
*Кабатлап туеп булмый.*

Бәгырь кисәгем,сөеклем! Менә синнән башка тагын бер көнем үтә. Минем җаныма син җитмисең. Беләм,барсына да мин үзем гаепле. Нишлисең,яратам бит үзеңне,үлеп,шашып сөям... Ләкин ни генә булмасын,кичерә белергә кирәк. Тик син моның өчен артык горур шул. Әмма аңла, мин синнән башка бүтән яши алмыйм: кара күзләреңнән, сөйкемле елмаюыңнан башка, ишетәсеңме, яши алмыйм. Алар миңа бик кирәк, сулар һава кебек, эчәр су кебек кирәк. Белмим, ничек син шулай яши аласыңдыр?! Ә бәлки, син инде минем бу дөньяда барлыгымны да оныткансыңдыр? Ә мин—юк... Йөрәгемне биләп алган мәхәббәтем сүрелмәде минем,ул һаман да күңелемдә яши. Хисләрем учактагы күмернең соңгы чаткысы төсле пыскып яналар.

Син хәзер еракта... Чакрымнар һәм күңел ераклыгы безнең арада. Мин сине шундый сагындым... Хыяллар һәм уйлар... Бары алар ярдәмендә генә яшим мин дөньяда. Сине бөтенләйгә күңелемнән чыгарып ташларга көчем җитми. Ә хәтер... Ул һаман да хатирәләрне кузгата,күңел түрендә пыскып торган учакның күмерләренә ут өсти. Инде төзәлә барган җәрәхәтләр ниндидер яңа ачышлар белән сызлап әрни! Ә күңел һаман сине көтә...

Бәлки, хәзер башка берәү синең матур карашларың, җылы кочагың эчендә яшидер. Минем сиңа үпкәм юк,синең бәхетле булырга хакың бар. Ә мин ничек булса да түзәрмен, килешермен. Синнән башка күпме вакыт үтеп китте бит инде...

Төн... Моңсулык... Сагыш... Күңелем тагын сине уйлап сыкрый. Менә бүген дә сиңа хат язам,алар берәр кайчан сиңа барып җитәрме,син аларны укырсыңмы? Әлегә билгесез... Син миннән еракта... Бик еракта. Минем барлык җиһанга сине яратуымны әйтәсем килә,әмма синең тормышыңда минем өчен урын юк. Беләсеңме,үз-үземә сине уйламаска сүз бирсәм дә,хисләремне җиңәргә көчем җитми. Ә бит мин үземне синең янәшәңдә иң көчле кешеләрнең берсе итеп тоя идем. Мин синең янәшәңдә бәхетле идем. Юк,мин сиңа үпкәләмим,мин бит сине яраттым,әле дә яратам,күз нурым,шуңа күрә дә бәхетле мин.

Бүген миңа күңел тынычлыгы биргән,сине онытырга булышкан бөек шәһәргә, Казанга килдем. Автобустагы урыным тәрәзә янында иде. Көне бигрәк шомлы, урамда бозлы яңгыр ява. Бәләкәй генә боз бөртеге тәрәзәгә килеп бәрелә дә, әйтерсең, авыртудан түзә алмыйча тәрәзә буйлап күз яше ага. Табигать һәм тереклек бергә елый... Беләм, син андый матурлыкны күрә белмисең. Күрсәң дә аңламыйсың һәм сакламыйсың.

**Без синең белән бик еракта,безнең араларны таулар,елгалар,бик күп шәһәр-авыллар аера,ләкин мәхәббәт ул чакрымнарны тоймый,кош булып каядыр ашкына. Беләсеңме,әгәр Аллаһы Тәгалә мине кошка әверелдерсә,мин синең янының очып барыр идем,сөюемне сиңа аңлатыр өчен матур-матур җырлар җырлар идем. Ләкин мин кеше шул... Беләсеңме,кадерлем,менә монда мин синнән аерылам. Чөнки мин яраттым,минем күңелем,йөрәгем сөю утында дөрләп-дөрләп янды һәм мәңгегә югалмас,төзәлмәс мәхәббәт эзе калдырды...**

**4 март. 01.20**

**Гөлнар АБЗАЛОВА**
*Гуманитар-педагогик*
*университет студенты.*

---

## ОРБИТАЛАР ҖИМЕРЕЛЕП БЕТМӘГӘНМЕНИ?

Узган гасырның илленче елларында, космонавтика гамәли эшләрдә тәрәккый итә башлагач, КПСС яисә ВЛКСМ өлкә комитетлары да, «Знание» җәмгыяте дә халык арасында астрономия һәм космонавтикага багышланган лекцияләр уку, бу хакта төрле брошюралар һәм китаплар нәшер итүгә бик игътибарлы иде. Газеталар һәм журналларда популяр мәкаләләр, радио һәм яңа тернәкләнеп килгән телевидение тапшырулары да багышлана иде моңа. Бу чараларның барысында да, туган телендә чыгыш ясый алган бердәнбер астроном буларак, мин фәкыйрегезгә бик актив катнашырга туры килде. Лекцияләр укырга дип күрше төбәкләргә дә йөрдем. Шундый лекцияләрдә чыгыш тәмамлангач, сорау ява башлый. Кызыклы һәм мәзәк сораулар хәтергә нык сеңеп кала икән. Бер тапкыр алдагы рәттә утырган бабай болай  дип сораган иде:

—Менә, балакаем, син, ясалма иярченнәрне тиешле орбиталарга җибәрделәр, дисең. Моны берничек тә аңлый алмыйм инде. Тунгуска метеориты орбиталарның барысын да җимереп бетермәгәнмени?

Бер апаның соравы мондый булды:

—Син, энем, җир хәрәкәт итә дип сөйлисең дә соң, ә мин менә бу авылга килен булып төшкәннән бирле утыз ел буена бер чокыр янында яшим дә яшим бит әле.

Болай дип сораучы да булды:

—Ни өчен елгаларның барысы да төньяктан көньякка акмый? Үзең глобуска кара әле, төньяк котып югарыда, ә көньяк котып түбәндә ич!

**Ким ШАКИРОВ**

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@telebit.ru.*

Замандашым Миргазиян Юнысның «Батып барган карабны кем, ничек коткара алыр? (2009. № 8) язмасын укыгач йокым качты. Ул язма татар халкының киләчәк язмышы, бөтенләй юкка чыгу мөмкинлеге турында. Ниһаять, фикерләрем житлекте, сезгә хат язып жибәрергә булдым.

Татарны урыслаштыру инде дүрт йөз дә илле жиде ел дәвам итә. Бу процесс совет чорында бигрәк тә куәтләнде. Төгәлрәге, узган гасырның утызынчы елларыннан. Ә инде Суслов заманында бигрәк котырды, һәм бүген дә шулай дәвам итә.

Менә аның этаплары һәм сәбәпләре.

Безнең чеп-чи татар Актаныш районында дүрт урыс һәм бер мари авылы бар иде. Ни гажәп, алар барысы да тап-таза итеп татарча сөйләшәләр иде. Алар безне урыслаштырмады, киресенчә, үзләре татарлаштылар. Әмма мин үскәндә безнең авылда (анда гына да түгелдер, шундый бер фикер йөри иде: «татар теле Әжәкергә чаклы гына». Чөнки Әжәкер Агыйделнең иң соңгы түбән пристане). Безнең район халкы читкә китү-кайту гамәлен бары тик су юлы белән генә бәйли иде. Башкасы (тимер юл, автобус, һава юлы) юк та иде. Шул Уфа, Ижау, Казан юнәлешендә бердәнбер юл (чара) иде. Парахутка кереп утырдың—татар теле бетте. Урыс телен белү дәрәжә иде. Безнең күрше урыс Михайловка авылына 1938 елны дүрт гаилә кереп утырды. Янәсе балалары урысчага өйрәнсен. Анда дүрт сыйныфлы башлангыч мәктәп бар иде. Ә татар мәктәпләрендә икенче сыйныфтан башлап урыс теле дәресе керә иде. Мин үзем шәхсән шул дәресләр аркасында рус телен өйрәндем. Шулай итеп татар мәктәбендә укып та урыс телен үзләштереп була иде. Бу хәл миңа югары уку йортына (академиягә) керергә комачауламады. Хәзерге ата-аналарга киңәшем шул: курыкмасыннар татарча укып бала югары уку йортына керәлми дип.

Ә инде житмешенче елларда бер тапкыр ялга кайткач күрдем гажәп хәл: чеп-чи татар авыллары арасындагы юлга такта куйганнар: «Добро пожаловать», «Счастливого пути». Колхоз идарәсе һәм авыл советы йортына такта беркеткәннәр: «Дом советов». Ул гына аз—авыл урта мәктәбендә урыс сыйныфы ачканнар. Укытучысы татарча бер авыз сүз белмәүче маржа кызы, Иваново өлкәсеннән. Менә сиңа мә!

Колхозга күрше Михайловка авылын да кушканнар. Колхоз бухгалтериясендә бар исәп-хисап урыс телендә, район үзәгендә урта мәктәп урысча. Авыл советы рәисе урыс, бер бригадир урыс. Дөрес, алар татарча бик иркен сөйләшәләр.

Колхозда зур дуңгыз фермасы бар. Хужалыкларда да дуңгыз үстерәләр икән (хөкүмәткә сатарга)—гадәткә кергән. Бер елны әткәй дә үстереп сатарга чучка баласы алган. Әнкәй мәрхүмә элек шул дуңгыз баласын ашатканда жиңги кия торган бияләйне кими иде жирәнеп дип сөйләгән иде әткәй. Дуңгыз алгач, шул эшне үзе башкарган. Психология!

Ә инде катнаш никахларга килгәндә, монда өйдә татарча тәрбия булмаса, бу хәл котылгысыз.

Телне, милләтне саклыйк дисәк, мәктәпләрдә 4нче сыйныфка кадәр тик татар телендә генә укытырга кирәк.

**Саняф ГАРДАНОВ**
*Гродно шәһәре, Беларусь*



*Бертөркем әдипләр, галимнәр, журналистлар «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә. Сулдан уңга—Нәби Дәүли, Әмин Раков, Илдар Юзеев, Риза Ишморат, Мөхәммәт Садри, Ил Саттаров, Хатыйп Госман, Нил Юзиев, Гомәр Бәширов, Флүн Мусин, Зәйнәп Хәйруллина, Рафаэль Мостафин, Хәсән Хәйри, Сибгат Хәким, Шамил Маннапов, Зиннур Мансуров, Юрий Белостоцкий, Шәмси Хамматов. 1980 ел.*



*Шагыйрь, галим, җәмәгать эшлеклесе Рәшит Ягъфәровның (1946-2009) иҗат кичәсеннән күренеш. Янәшәдә—якташы, җырчы Сәнифә Рангулова. Язучыларның Тукай клубы. Казан. 2001 ел.*



*Татарстанның һәм Россиянең халык артисткасы Вера Минкина (1918). 90 яшь тулган көннәрдә төшерелгән фоторәсем. 2008 ел.*



١٣٢٥ سنه ١٠ ذوالحجه سهشنبه ١٩٠٨ سنه ١ غنوار №13

اخطار:

غزيتەنك بهاسی

Казань, Номера „БОЛГАРЪ“
Редакція газ. „ЭЛЬИСЛАХЪ“
Телефонъ № 74

ЕЖЕНЕДѢЛЬНАЯ ГАЗЕТА
„ЭЛЬ-ИСЛАХЪ“

*Тукай яшәгән «Болгар» номерларында (2008 елның көзендә җимереп вәйран иттеләр) нәшер ителгән «Әл-ислах» газетасының титул бите.*



*1979-93 елларда «Казан утлары» журналы редакциясендә эшләгән язучы Кояш Тимбикова (1937-2004). 1985 ел.*



*Ринат Мөхәммәдиев һәм Рахмай Хисмәтуллин (1934-2004). 1994 ел.*

## Илүсә Нәбиуллина



Илүсә Салих кызы Нәбиуллина 1958 елда Мөслим районы Баек авылында туган. Туган авылында урта белем ала. Мәктәптә яхшы билгеләргә генә укый. Зур оештыру сәләтенә ия, үз артыннан ияртә белә торган, тиз аралашучан һәм максатчан кызны мәктәптә укыганда дружина советы рәисе, аннан комсомол секретаре итеп куялар.

Авылларына шагыйрә Асия Минһажева килеп, татар теле укыта башлагач, иҗади түгәрәк тә оештырып җибәргәч, яңалыкны эләктереп алырга гына торган Илүсә дә кулына каләм ала. Бишенче сыйныфта укыганда аның шигырьләре, мәкаләләре район газетасында күренә башлый. Сонрак Илүсә мәктәп, авыл хәлләре турындагы мәкаләләрен республика газеталарына да җибәрә.

Илүсә Нәбиуллина Алабуга дәүләт педагогия институтының филология факультетын тәмамлый һәм милли мәктәпләр өчен рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты укытучысы дигән белгечлек ала.

Югары уку йортын тәмамлаганнан соң юллама белән Әлмәт шәһәренә эшкә җибәрелә. Башта балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Балалары үсә төшкәч, «Әлмәт таңнары» газетасына эшкә килә. Шул ук вакытта җирле радиода, сонрак «Татар радиосы»нда да эшли. Газетада, радиода эшләү Илүсәнең каләмен тагын да чыныктыра, кешеләр белән күбрәк аралашырга, гыйбрәтле язмышлар белән танышырга мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта Илүсә Нәбиуллина гимназиянең талантлы балалары белән эшли, «Офык» дип аталган балалар өчен газета чыгара.

Илүсә Нәбиуллина 1990 елдан Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы.

Әлмәткә килеп, район һәм шәһәр газетасына эшкә урнашкач, Илүсә Нәбиуллина янә иҗат белән шөгыльләнә башлый. Үз көчен төрле жанрларда сынап карый. Аның хәятнамәләре, юмористик хикәяләре, лирик парчалары, актуаль темаларны яктырткан мәкаләләре «Татарстан яшьләре», «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» газеталарында еш күренә. 2004 елда «Миләш тәме» дигән повесте «Казан утлары» журналында басыла.

Аннан соң бер-бер артлы зурлар өчен «Миләш тәме», «Җанкаем» дигән китаплары, балалар өчен «Кояш бүләк итәм»дип аталган китабы дөнья күрә.

2010 елның 22 апрелендә Клара Булатова, Камил Кәримов, Ләйсән Кәшфи тәкъдимнәре нигезендә Кабул итү комиссиясе һәм Идарә Илүсә Нәбиуллинаны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алу турында карар чыгарды.

## Россиянең истәлекле даталары исемлегенә яңа истәлекле датаны— Россиянең хәзерге территориясендә Ислам дине рәсми кабул ителгән көнне кертү турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы Рәисе С.М. Мироновка, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе Б.В. Грызловка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы

# МӨРӘҖӘГАТЕ

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы 2010 елның 21 маенда «Россиянең хәрби дан көннәре һәм истәлекле даталары турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул итте. Анда яңа истәлекле дата—Русьны Чукындыру Көне гамәлгә куела. Бу көн Россиядә ел саен 28 июльдә билгеләп үтеләчәк.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, кабул ителгән бу Законны хуплап, Россиянең тарихи яктан күп динле һәм күпмилләтле дәүләт буларак төзелүенә игътибар итә. Россиядә күп динлелек ерак гасырлардан килә. Бу тарихи тәҗрибә уникаль һәм гыйбрәтле, чөнки ул төрле диннәр арасында бүгенге Россиянең уңай чынбарлыгына әверелгән тотрыклы дуслык булдыруга ярдәм итә.

Россия җәмгыятендә диннәрне тергезү илдәге рухи яңарышның бер өлешенә әверелгән хәзерге шартларда тарихи нигезләнгән бу модель тулы канлы конфессиональ сәясәт булдыру өчен зур әһәмияткә ия. Монда Россиядәге традицион дини конфессия вәкилләренең дәүләт тарафыннан үзләренә карата бертигез мөнәсәбәт тоюлары мөһим.

Россиядә Ислам, күпгасырлы тарихка ия булып, илебездәге халыкларның рухи тормышында әһәмиятле роль уйнады. Ул, күбесенчә Идел буенда, Кавказда һәм Көнбатыш Себердә таралып, тамыр җәюнең һәм үсүнең төрле этапларын үтте.

Заманында хәзерге Россиянең Идел һәм Урал буйларындагы зур җирләрне биләгән Идел буе Болгар дәүләте Исламны дәүләт дине буларак рәсми рәвештә 922 елның 21 маенда (иске стиль белән 16 маенда) кабул иткән. Күренекле гарәп географы һәм сәяхәтчесе Әхмәт ибн Фадлан Багдад илчелеге белән бергә Идел буе Болгарында булганнан соң X гасырның шушы истәлекле вакыйгасын тасвирлап калдырган, әлеге вакыйга Идел буе Болгар дәүләтен дипломатик тануда төп рольне уйный һәм аның социаль-икътисадый һәм мәдәни үсешенә көчле этәргеч бирә. Алга таба Россиянең бөтен төбәкләрендә Ислам гомумкешелек кыйммәтләренең нигезен тәшкил итә. Шуны ассызыклап үтәргә кирәк, Россия мөселманнары гомумроссия мәдәнияте үсешенә үзләренең лаеклы өлешен кертәләр һәм иң авыр чорларда да дини каршылыкның түгел, ә диннәр арасындагы хезмәттәшлекнең һәм үзара рухи баюның уртак илдәге төрле халыкларның бергә яшәве өчен бердәнбер ихтимал шарт икәнлеген яхшы аңлыйлар.

Бүген күпмилләтле илебезнең 20 миллионлы мөселман җәмгыяте гомуми Ватаныбыз хакына актив хезмәт итә һәм Россия үсешенең төп юлын билгели торган гамәлләрне уңай кабул итә.

2005 елда Россия Федерациясе Ислам Конференциясе Оешмасында күзәтүче ил буларак үзенең даими урынын алды, мөселман илләре белән даими актив аралашып яши. Россиянең истәлекле даталары исемлегенә яңа истәлекле датаны—21 май (иске стиль белән 16 май) көнен—Россиянең хәзерге территориясендә Ислам дине рәсми кабул ителгән көнне кертү, Русьны Чукындыру Көне кебек үк, һичшиксез, илдә киләчәктә дә күп динлелек үсешенә һәм Россия Федерациясенең халыкара абруен ныгытуга ярдәм итәр иде.

*9 июнь 2010 ел*

## ТАССР ТӨЗЕЛҮГӘ—90 ЕЛ

***

Май ахырында Татарстан бәйрәм чараларыннан гөрләп торды. Моннан 90 ел элек, ягъни 1920 елның 27 маенда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү турында декрет кабул ителә. Шунлыктан башкалабыз Казанда да, республикабызның калган шәһәр һәм районнарында да Татарстан беренче адымнарын ясаган көннәрне, 90 ел эчендәге тарихи вакыйгаларны искә алдылар.

Әлеге юбилей чараларының йомгаклау өлеше 27 майда Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында үтте. Бәйрәм тантанасының мөхтәрәм кунаклары арасында ТР Президенты Рөстәм Миннеханов, ТРның беренче Президенты, ТРның Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, РФ Дәүләт Думасы Рәисенең беренче урынбасары Олег Морозов, ТРның беренче Премьер-министры Мөхәммәт Сабиров, 1982-89 елларда КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булган Гомәр Усманов, Казан мэры Илсур Метшин һәм башкалар бар иде. Тантанада шулай ук ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Федерация Советының Татарстаннан сайланган әгъзалары, РФ Дәүләт Думасы депутатлары, җәмәгать эшлеклеләре дә катнашты.

ТР Президенты Рөстәм Миннеханов үз чыгышында 1920 елда ТАССР төзелүне татар дәүләтчелеге тарихындагы яңа сәхифә буларак билгеләп үтте.

—Татар теленең статусын үзгәртү, яңа милли кадрлар тәрбияләү максатыннан мөһим чаралар күрелгән. Республика барлыкка килү хуҗалык төзелешендә дә радикаль үзгәрешләргә китергән,—диде Президент.

Утырышта төп докладны ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ясады.

—Үзара аңлашып эшләү нәтиҗәсендә без, дәүләтнең бөтенлеген бозмыйча, милләтара татулыкны саклап, Татарстанны һәрьяклап үстерүгә ирештек. Яңа йөзьеллыкта республика нинди булыр, заманча Россия шартларында, глобаль системада ул нинди урын алыр? Боларның барысы да безнең—татарстанлыларның ихтыяр көченә һәм уңышка омтылышына бәйле,—диде ул. Фәрит Мөхәммәтшин белдергәнчә, ТР Дәүләт Советы Президиумы якын арада Татарстан Гимнының сүзләрен язуга бәйге игълан итәргә җыена.

90 ел тарих өчен зур вакыт аралыгы булмаса да, татар халкына ул бик күп яңалыклар, күңелле вакыйгалар һәм шул ук вакытта шактый зур сынаулар, авырлыклар да алып килде. Татарстан үз тарихын киләчәктә тагын да матуррак юллар белән язар, аңа тагын да әһәмиятле һәм сөенечле вакыйгалар өстәлер дип ышанасы килә.

***

Россия Федерациясе Президенты Дмитрий Медведев Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннехановны һәм республикада яшәүчеләрне ТАССРның 90 еллыгы белән котлады.

«Сезне Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 90 еллык юбилее белән чын күңелдән котлыйм.

Татарстан уникаль мәдәни-тарихи мираска ия. Ул илгә танылган галимнәр, шагыйрьләр һәм музыка белгечләре, хәрби башлыклар һәм спортчылар әзерләгән. Республика милләтара һәм конфессияара дуслык буенча үрнәк төбәк булып тора. Гасырлар дәвамында бирелә йөздән артык халык һәм барлык дөньяви дин вәкилләре тату һәм бер-берсен хөрмәт итеп яши.

Бүген Татарстан сәнәгать житештерүе күләме буенча илдә алдынгы урыннарда, социаль-икътисади өлкәне һәм дәүләт идарәсен модернизацияләү буенча лидерлар рәтендә.

Татарстан Республикасына һәм аның халкына уңышлар, иминлек телим»,—дигән юллар бар анда.

***

Казан шәһәр Ратушасында ТАССРның төзелүенә 90 ел тулу уңаеннан тантаналы шәһәр җыены үткәрелде. Әлеге чарада РФ Дәүләт Думасы, ТР Дәүләт Советы, Казан шәһәр Думасы депутатлары, Казанның

мактаулы гражданнары, элекке елларда партия, комсомол, Казан шәһәре һәм районнарның совет органнары җитәкчеләре, Казан шәһәре башкарма комитеты һәм структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм башкалар катнашты.

Тантанада Казан мэры Илсур Метшин чыгыш ясады. Ул Казан шәһәренең һәм районнарының партия һәм совет органнары җитәкчеләренә шәһәр бүләкләрен, «ТАССР төзелүгә 90 ел» истәлекле медален тапшырды.

***

ТР Фәннәр академиясендә исә «Татарстан Республикасы: тарих һәм бүгенге көн» дигән фәнни-гамәли конференция узды. Монда Россия Фәннәр академиясе исеменнән академик, Океанология институты директоры Роберт Нигъмәтуллин чыгыш ясады. ТР ФА Президенты Әхмәт Мазһаров АКШта яшәүче академик Роальд Сәгъдиевнең котлавын укыды, армия генералы Мәхмүт Гәрәев тәбрикләү сүзен әйтте.

Пленар утырыштан соң эш дүрт секциядә дәвам итте. Монда үткән тарихыбыз искә төшерелде, бүгенге уңышларыбыз билгеләп үтелде, киләчәккә планнар ачыкланды.

## ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ УҢАЕННАН

Татарстанда Бөек Җиңүнең 65 еллыгы зурлап билгеләп үтелде. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында Бөек Җиңүнең 65 еллыгына багышланган тантаналы кичә булды. Анда Президент Рөстәм Миңнеханов, ТРның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Премьер-министр Илдар Халиков, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Казан мэры Илсур Метшин һ. б. катнашты.

Кичәгә республиканың төрле төбәкләреннән 600дән артык сугыш ветераны, БДБ илләреннән кунаклар чакырылган иде. Тантанада катнашучыларны бәйрәм белән Президент Р. Н. Миңнеханов тәбрик итте, республика җитәкчесе Бөек Җиңүгә Татарстан халкының зур өлеш кертүен билгеләп үтте.

Тантаналы концертта Татарстан, Украина, Беларусь, Мәскәү артистлары башкаруында сугыш турында җырлар яңгырады.

## ЖУРНАЛИСТЛАР БӘЙРӘМ ИТТЕ

19 майда Татарстан Республикасы Матбугат көне зурлап билгеләп үтелде. Шул уңайдан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан гаммәви мәгълүмат чаралары баш мөхәррирләре, радиотелевидение компанияләре җитәкчеләре, журналистлар белән очрашты. Очрашуда җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлекне ныгыту юллары да тикшерелде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы каршындагы Ватанны саклап һәлак булган журналистлар һәм полиграфистлар истәлегенә торгызылган һәйкәл алдына чәчәкләр куелды. Тантанада Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, республика матбугат һәм гаммәви коммуникация чаралары агентлыгы җитәкчесе Марат Моратов, федераль һәм республика гаммәви коммуникация чаралары җитәкчеләре катнашты.

«Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында «Татмедиа» агентлыгы, Журналистлар берлеге белән берлектә, Татарстан Республикасы Матбугат көненә багышлап, тантаналы кичә үткәрде. Анда XIII «Бәллүр каләм—2010» журналистлар конкурсында җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды.

## МӘСКӘҮ ТАТАРЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Татарстан Премьер-министры Илдар Халиков Россия башкаласында Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсенең татар җәмәгатьчелеге вәкилләре белән очрашу үткәрде. Әлеге очрашу Мәскәү татарларының мәдәни үзәге булып торган Әсәдуллаев йортында уздырылды. Премьер-министр башта Татар милли үзәген карады, аннары татар җәмәгатьчелеге вәкилләре алдында чыгыш ясап, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсенең татар җәмәгатьчелеге активистларына ТР Президентының Рәхмәт хатларын тапшырды.

Очрашуда шулай ук ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев һ.б. рәсми кешеләр катнашты.

## БАШЛАНА БАШЛАДЫ

Болгар билгәмәсендә «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск шәһәр-утравы» проектын тормышка ашыру буенча эшләр башланды.

«Тергезү» республика фонды (аның Попечительләр советына нигез салучы һәм рәисе—Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев) Болгар һәм Свияжскида эшләр оештыруны дәвам иттерә. Шушы көннәрдә Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы биләмәсендә реставрация-тергезү эшләре башланды.

Хәзерге вакытта Татарстанның киләчәктәге туристлык үзәкләреннән берсенең иң зур объектларын төзүне башлап җибәрү хәстәре күрелә. Аерым алганда, тыюлык территориясендә юл салына, Идел буе болгарларының Ислам динен кабул итү хөрмәтенә истәлек билгесе кую

өчен урын әзерләнә. Шул ук вакытта археологик казу эшләре алып барыла. Тәүге табылдыклар да бар. Болар—балчыктан ясалган савыт-саба ватыклары, ук очлары, төрле дәверләргә караган тимер акчалар, ау һәм балык тоту әйберләре, эш кораллары. Археологик казу эшләрен Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты археологик тикшеренүләр үзәгенең фәнни хезмәткәрләре алып бара. Озакламый Болгарга тәзүчеләр киләчәк. Алар елга вокзал-музеен төзүгә керешәчәк.

## МӘСКӘҮ ҮЗӘГЕНДӘ—ТУКАЙ ҺӘЙКӘЛЕ

Мәскәү үзәгендәге Новокузнецкий урамында Татар мәдәни үзәге янәшәсендә бөек шагыйребез Габдулла Тукайга һәйкәл урнаштырылачак. Бу җәһәттән тиешле боерыкка Мәскәү мэры Юрий Лужков кул куйган.

## БАЛАЛАР ФЕСТИВАЛЕ

Июнь башында Казанда халыкара балалар фольклоры фестивале булып узды. Анда Венгрия, Греция, Литва, Малайзия, Мексика, Польша, Россия, Сербия, Төркия, Финляндиядән 11-16 яшьләрдәге 200ләп сәләтле бала катнашты.

Фестивальдә танылган иҗат коллективлары да чыгыш ясады. Алар арасында Польшаның 60 еллык тарихлы «Люблин» җыр һәм бию ансамбле, Төркия телерадиокомпаниясе һәм күптән түгел генә үзенең 30 яшьлеген билгеләп үткән безнең «Бәхетле балачак» ансамбле дә бар.

## РЕКТОРЛАР СОВЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

Татарстан вузлары ректорлар Советының яна җитәкчесе итеп Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры Илшат Гафуров сайланды, чөнки ул хәзер республиканың төп югары уку йортын җитәкли. Ә «Татарстанның элеккеге баш ректоры» һәм КДУ ректоры Мәгъзүм Сәлахов бу көннәрдә КИФУ президенты итеп сайланды.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда соңгы айда башкарылган эшкә хисап, шул исәптән әдәби ел йомгаклары кысаларында яшь язучылар иҗатына багышланган фәнни-гамәли конференциягә нәтиҗә ясалды. 14-15 июльдә Лаешта Бөтенроссия Державин фестивален үткәрү турында сөйләшү булды. Прозаик, публицист Нонна Орешина Г. Державин бүләгенә тәкъдим ителде. Аннары утырышта катнашучылар Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллинга 75 яшь тулу уңаеннан үткәреләчәк чаралар турында Татарстан Язучылар берлеге тәкъдимнәре турында фикер алышты. Утырышта галимә, прозаик Халисә Ширмән, шагыйрәләр Ләйсән Юнысова, Миннеруй Гайфуллина Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.

## БӨТЕНРОССИЯ САБАН ТУЕ

Быел татар халкының милли бәйрәме Самара өлкәсенең Похвистнево районы Гали авылында I Бөтенроссия татар авыллары Сабан туе белән башланып китте. 28 майда үткән бу бәйрәмдә РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Александр Жуков, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Григорий Рапота, ТР Президенты Рөстәм Миннеханов, Самара өлкәсе губернаторы Владимир Артяков, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе, мөфти Тәлгат хәзрәт Таҗетдин һәм башка рәсми кешеләр катнашты. Борынгы һәм зур бу татар авылына Россиянең 14 төбәгеннән—Татарстан, Чувашстан, Удмуртия, Киров, Ульян, Оренбург, Марий Эл, Төмән һ. б. өлкәләрдән, шулай ук Кытайдан делегацияләр килгән иде.

«Бирелә хуҗалык ныклы, халык тырыш, ә Гали үзе бөтен Россия төбәкләренә дә үрнәк булырлык»,—диде Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов кунакларны сәламләгәндә. Ул өлкә губернаторына ил күләмендәге шундый чара оештырган өчен рәхмәт сүзләре җиткерде һәм Татарстан исеменнән Гали авылы җирле үзидарәсенә «Фиат Дукато» автомобиле бүләк итте. Самара өлкәсе Похвистнево районы хакимияте башлыгы Александр Ларионовка һәм «Туган як» оешмасы рәисе, шәхси эшмәкәр Расих Латыйповка Казан белән ике арада мәдәни һәм икътисади элемтәләрне ныгытуда керткән өлешләре өчен «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләре, Гали авылының зур китапханәсенә бүләк итеп татар китаплары тапшырды.

Бөтенроссия татар авыллары Сабан туеның икенчесе Чувашстанның Шыгырдан авылында узачак.

## ФРАНЦИЯ КУНАКЛАРЫ

Россия-Франция елы кысаларында күренекле француз язучылары 28 майдан 14 июньгә кадәр Транссебер магистрале буйлап «Блез Сандрар» әдәби поездында Мәскәүдән алып Владивостокка кадәр сәяхәт итте. Әлеге сәфәр Россия-Франция елының үзәк вакыйгасы булып тора.

Доминик Фернандэз, Паскаль Брюкнер, Жан Эшноз кебек күренекле француз язучылары бу сәфәрләре белән француз шагыйре Блез Сандрарның хыялын тормышка ашыра. Блез Сандрар 1913 елда «Транссебер экспрессы һәм кечкенә Жанна Французская турында проза» дигән әсәр язган булган.

Әлеге сәяхәтнең максаты—француз

язучыларын хәзерге Россия белән таныштыру. Язучылар Казанда ике көн кунак булды. Алар Зөя утравы һәм Казан шәһәренең тарихи урыннары белән танышты. Татарстан Милли китапханәсенең француз залында китап сөючеләр белән очрашу да узды.

### ТЕАТР ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ КИҢӘШӘ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында төрки халыкларның «Нәүрүз» Халыкара театраль-агарту форумы ачылды. Анда катнашу өчен төрле төбәкләрдән 200гә якын театр эшлеклеләре, режиссерлар, драматурглар, тәнкыйтьчеләр килде. Аның ачылышында Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева бер төркем театр эшлеклеләренә Президент Указы нигезендә бирелгән бүләкләрне, мактаулы исемнәр тапшырды. Г. Камал исемендәге театрдан Наилә Ибраһимовага «Татарстанның халык артисты», Айрат Арсланов белән Олег Фазылҗановка «Татарстанның атказанган артисты» исемнәре бирелде. Татар дәүләт «Әкият» курчак театрыннан Валентина һәм Александр Губский «Россиянең атказанган рәссамы», Туймазы Татар дәүләт драма театры режиссеры Байрас Ибраһимов «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән исемгә лаек булдылар.

Катнашучылар һәр көнне пленар утырышларда үз фикерләре белән уртаклаштылар. Мәскәүнең Россия театр сәнгате академиясе профессоры Анна Степанова исә 11 июньгә кадәр журналистлар белән тәнкыйть турында семинар үткәрде. Бер үк вакытта «Яшь йөрәкләр», «Курчак туе», «Гөлҗамал», «Өч сенел» спектакльләре буенча фикер алыштылар.

### АСТАНАДА АУРАЗИЯ ҖЫЕНЫ

Май ахырында Казакъстанның башкаласы Астана шәһәрендә Төрки цивилизациясе проблемаларына багышланган халыкара конгресс булып узды. Анда АКШ, Казакъстан, Төркия, Россия,Украина, Кыргызстан, Кытай һәм кайбер башка илләрнең күренекле гыйлем ияләре белән бергә, Казан галимнәре академик Мирфатыйх Зәкиев һәм профессор Хатыйп Миңнегулов та докладлар сөйләделәр, фәнни җыен эшендә актив катнаштылар. Конгресс кысалары эчендә «Төрки дөньясы Академиясе»н рәсми ачу тантанасы да булды. Анда Казакъстан президенты Нурсолтан Назарбаев һәм Төркия президенты Абдулла Гөл котлау сүзләре белән чыктылар. Аларга җавап итеп галимнәр һәм гомумән, тантанада катнашучылар исеменнән академик Мирфатыйх Зәкиев чыгыш ясады. Астананың әкияттәй гүзәл «Пирамида»сында («Иминлек һәм килешү» сараенда) барган бу чаралар күп кенә илләрнең матбугатында һәм радио-телевидениясендә киң чагылыш тапты.

### ТИНЧУРИН ТЕАТРЫ ЯҢАРДЫ

2006 елның февралендәге янгыннан һәм 4 елга сузылган капиталь ремонттан соң К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасы кабат ачылды. Театр танып булмаслык үзгәргән, күркәмләнгән. Тамаша залында VIP-ложа да пәйда булган. Сәхнә һәркайдан бик яхшы күренә. Яна заманча ут һәм тавыш кую җиһазлары, кондиционерлар урнаштырылган. Фойене театр актерлары һәм режиссерларының портретлары һәм Чехиядән кайтартылган зиннәтле люстралар бизи.

Яңартылган театрны ачу тантанасында ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты. «Бүген тинчуринлылар өчен генә түгел, театр яраткан һәркем өчен дә зур бәйрәм,—диде журналистлар белән әңгәмә вакытында Ф. Мөхәммәтшин.—Бу бинада республикабызның иң тәҗрибәле театр коллективларыннан берсе эшли.» Парламент башлыгы тинчуринлыларның элгәрләрдән килгән игелекле традицияләрне саклап калуын канәгатьләнү хисе белән билгеләп үтте һәм киләчәктә дә аларның тамашачыны үзенчәлекле репертуарлары белән сөендерәчәгенә ышаныч белдерде.

Капиталь сипләү эшләре 230 миллион сумга төшкән. Ф. Мөхәммәтшин республика хөкүмәтенә, Мәдәният министрлыгына, төзелеш компанияләренә рәхмәт әйтте, театр коллективын өй туе белән ихлас тәбрикләде, «ТРның халык артисты», «ТРның атказанган артисты» дигән мактаулы исемнәргә лаек булган актерларны бүләкләде, театрга яна микроавтобус бүләк итте.

Кичәдә котлаулар күп булды. Камал театры Кәрим Тинчуринның шәхси әйберләрен һәм кульязмаларын тапшырды. Тинчуринлыларның иң яхшы спектакльләреннән өзекләр кичәне тагын да ямьләндерде.

### «ОРФЕЙ» «КҮЧТӘНӘЧ»НЕ САЙЛАДЫ

«Татарстан—Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең балалар өчен чыгып килүче «Күчтәнәч» тапшыруы «ТЭФИ Регион-2009» Бөтенроссия телевизион конкурсында «Балалар өчен тапшырулар» номинациясендә җиңү яулады. Җиңүчеләрне Калининград өлкәсе Светлогорск шәһәрендә бүләкләделәр. Быел төбәкара ТЭФИ телевизион фестиваленә 450 эш тәкъдим ителгән. Конкурсның финал өлешендә «Күчтәнәч» тапшыруының көндәшләре «Шустрое утро» (Краснодар) һәм «Зебра» (Төмән) тапшырулары иде. Ләкин тылсымлы Яңа ел мәҗараларыннан торган «Күчтәнәч» Бөтенроссия телевизион

Академиясе жюри әгъзаларын әсир итте һәм ин-ин яхшылардан дип танылды. Төп бүләк—Эрнст Неизвестный тарафыннан бронзадан эшләнгән алты килограммлы «Орфей» статуэткасы.

### ХАТИРӘЛӘР ЯҢАРДЫ

1944 елда Мәскәүдәге Луначарский исемендәге театр сәнгате институтының татар студиясе ачыла. Анда укырга Казаннан бер төркем егетләр һәм кызлар китә. Шуларның 25е уку йортын тәмамлап кайта. Аны тәмамлауларына 60 ел тулу уңаеннан Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында зур кичә узды. Коллектив иң элек әлеге төркемнән бүгенге көндә исән-сау яшәүче Татарстанның халык артисты Асия Галиеваны, Татарстанның атказанган артисты Рауза Әхмәрованы, телевидениедә режиссер булып эшләгән Гөлсем Йосыпованы тәбрикләде. Алар исә үз хезмәттәшләренә, тамашачыларына рәхмәтләрен ирештерде. Режиссерлар Празат Исәнбәт, Рәфкат Бикчәнтәев, Гали Хөсәенов, актерлар Дэллюс Ильясов, Гәүһәр Камалова, Шәхсәнәм Әсфәндиярова турында да хатирәләр яңарды. Ринат Тажетдинов, Равил Шәрәфиев, Хәлим Җәләлев, Рузия Мотыйгуллина, Луара Шакиржанова, Наилә Гәрәева, Илдар Хәйруллин, Луиза Солтанова кебек күренекле артистлар алар турында үз истәлекләре белән уртаклашты.

### СӨЕМБИКӘ ВАРИСЛАРЫ

Татарстанның халык артисты Гөлзадә Сафиуллина инициативасы белән үтә торган «Сөембикә варислары» халыкара төрки-татар иҗат фестивале быел янә яшь талантларны Кырымга дәшә. Мәдәният, шулай ук Яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министрлыклары, Бөтендөнья форумы, Кырым-татар халкының милли мәҗлесе, Ялта шәһәре мэриясе, «Акчура» мәдәни үзәге ярдәме белән фестиваль 2010 елның 9-21 июлендә үтә. Анда 30 яшькә кадәрге яшь талантлар вокал, бию, инструменталь жанр, нәфис сүз, рәсем номинацияләре буенча сәләтләрен күрсәтәчәк. Фестиваль программасында—экскурсияләр, иҗади очрашулар, семинарлар, мастер-класслар, Сабан туе, «Татар кызы», «Татар егете» конкурслары, «Мин татарча сөйләшәм» акциясе, спорт-сәламәтләндерү чаралары.

Катнашырга теләүчеләр Казанның Галактионов урамы, 3 «б» йортта урнашкан «Гөлзадә» иҗат студиясенә яки «Идел» яшьләр үзәгенә мөрәҗәгать итә алалар.

Телефоннар: 89631200021 яки 264-42-66.

### ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Гаммәви мәгълүмат чараларында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Саба муниципаль районының җәмәгать тормышында актив катнашканы өчен хезмәт ветераны (Саба муниципаль районы) **Нәҗмиев Тәлгат Самат улы** «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

***

Хәзерге татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен язучы **Вәлиева Резеда Тәвгалүн кызы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

***

Әдәбият өлкәсендә күпьеллык хезмәте, татар әдәбиятын һәм сәнгатен пропагандалауда зур өлеш керткәне өчен **Мирхәйдәров Рауль Мирсәет улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* «Җәйге хозурлык».

*Дүртенче биттә:* шагыйрә **Иделбикә**.

# Яңа китаплар




Татарстан Язучылар берлеге. Бер тамырдан, уртак язмыштан без... *Әдипләр сүзе.* Одного корня мы, одной судьбы... Төзүчеләре—**Гәрәй Рәхим, Рәфикъ Юныс,** рәссамы—**Диләрә Нәүрүзова.** Казан, 2010. Тиражы—30 000 данә.

Быел октябрьдә үтәчәк халык исәбен алу уңаеннан Татарстан Язучылар берлеге татар һәм рус телләрендә әнә шундый җыйнак, мәгънәле һәм бай бизәлешле китап чыгарды. Аннан татарның үткәне, бүгенгесенә кагылышлы бай мәгълүмат алып була. Безне уртак киләчәгебезгә зыян салырга мөмкин хаталардан да кисәтә ул. Китапта дөньякүләм мәшһүр акыл ияләренең, шулай ук классик әдипләребезнең һәм бүгенге яшьрәк буын шагыйрьләренең татар халкы язмышына кагылышлы фикер-уйлары туплап бирелгән.




**Җамал Вәлиди.** Әдәби һәм тарихи-документаль җыентык. Төзүчеләре—Диләрә Абдуллина, Җәүдәт Миннуллин. Казан, «Җыен» нәшр., 2010.—624 б. Тиражы—1000 данә.

Җыентык күренекле татар галиме, телче, әдәбиятчы, тарихчы, педагог, публицист Җамал Вәлидинең (Җәмаледдин Җәләледдин улы Вәлидев (1887-1932) фәнни иҗатын киң катлау укучыларга таныту максатыннан төзелгән.

Китапта Җ. Вәлидинең монарчы хәзерге графикада дөнья күрмәгән һәм аз билгеле булган хезмәтләре, аңа багышланган мәкаләләр, библиографик күрсәткеч һәм фоторәсемнәр туплап бирелгән.

Китап милли мәдәниятебез тарихы белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.



Иделбикә

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZANUTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)